

# Казан утлары

9.1985



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

9

1985

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

Н. ДӘҮЛИ. Язмышка юл. Повесть . . . . . . . 3
Н. АРСЛАНОВ. Яшенле төндә. Шигырьләр . . 51
В. НУРУЛЛИН. Ике урам арасы. Повесть . . . 57
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Туган халкым. Шигырьләр . 97
Р. МИҢНУЛЛИН. Яхшылык. Шигырьләр . . . . 103

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

А. ХӘСӘНОВ. Фатиха. Хикәя . . . . . . . . . . 108

КПССның XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Җ. РӘХИМОВ. Ерактагы биләмәләр . . . . . . 115

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ХАҖИӘХМӘТОВ. Уральскида Тукай урыннары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Ш. ТУРДЫЕВ. Тукай һәм үзбәк әдәбияты . . . 121

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

С. ТӨХБӘТУЛЛИН. Без — Ленин якташлары . 125

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. ИЗМАЙЛОВ. Көрәш дәвам итә . . . . . . . . 128

Т. ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 90 ел

Җ. ВӘЗИЕВА. Хезмәт кешесе иде . . . . . . . . 134
К. ГЫЙЗЗӘТОВ. Әти турында. . . . . . . . . . . 138
Р. ГЫЙЗЗӘТОВ. Ял вакытында . . . . . . . . . 143

ЮБИЛЕЙЛАР

...Яктылыкка, нурга илтә (Т. Миңнуллинга — 50 яшь) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Ф. МУСИН. Олы юлдан (Г. Ахуновка — 60 яшь) . 154
Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Такыялар балкышы. (М. Маликовага — 50 яшь) . . . . . . . . . . . . . . . . 162

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

**БИБЛИОГРАФИЯ**

**Ф. УРМАНЧЕЕВ. Зур мирасның җитди өлеше** . 167
**Ф. ВӘЛИЕВ, С. ИСХАКОВА. Себер татарлары турында** . . . . . . . . . . . . . . . 170

**СӘНГАТЬ**

**Н. ӘЛМИЕВА. Җырлап ачыла күңел** . . . . . . 172

**КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА**

**Н. ИСМӘГЫЙЛЕВ. Гасырларны кичкән сюжет** . 179

**ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС**

**Р. АБДУЛЛИН, Р. ХАРИС. Кама Аланы. Җыр** . 184

**Укучыларыбыз яза** . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
**Кызыклы хәлләр** . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . . . . 190
**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Продолжение автобиографической повести Н. ДАУЛИ «Дорога к судьбе». Повесть В. НУРУЛЛИНА «Друзья-товарищи». Рассказ молодого писателя А. ХАСАНОВА.

Стихи Н. АРСЛАНОВА, Р. ФАИЗУЛЛИНА, Р. МИННУЛЛИНА.

К 100-летию Тукая: рисунок Т. ХАЗИАХМЕТОВА из серии «Тукаевские места в Уральске», статья Ш. ТУРДЫЕВА «Тукай и узбекская литература».

Навстречу XXVII съезду партии: З. РАХИМОВ. «Дальние владения».

В рубрике «Татарстан — родной мой край». Статья первого секретаря Дрожжановского РК КПСС С. ТУХБАТУЛЛИНА.

Путевые заметки Р. ИЗМАЙЛОВА «Борьба продолжается» (Из Вьетнамского блокнота).

К 90-летию Т. ГИЗЗАТА: воспоминания З. ВАЗИЕВОЙ, К. ГИЗЗАТОВА, Р. ГИЗАТОВА.

В номере отмечаются юбилеи Г. Ахунова, Т. Миннуллина, М. Маликовой.

В разделе «Библиография» рецензии Ф. УРМАНЧЕЕВА, Ф. ВАЛЕЕВА, С. ИСХАКОВОЙ.

К истории культуры: Статья Н. ИСМАГИЛОВА.

«АЭС — литературный пост». Песня, посвященная строителям АЭС (авторы Р. АБДУЛЛИН, Р. ХАРИС).

Из почты редакции, «занимательные истории», дневник культуры. На наших обложках: творчество художника Х. Якупова.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53—07—09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

Техник редактор Р. Сөләйманова. Корректорлар Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.

Производствога бирелде 28.06.1985 ел. Басарга кул куелды 21.08.1985 ел. ПФ 02143. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64049. Заказ К-291. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1985 ел.

**Нәби Дәүли**

# ЯЗМЫШКА ЮЛ

ПОВЕСТЬ

## Таң атканда

Бу куркынычлы шау-шулары белән көннең узганын да сизми калдык. Төн җитте. Болытлы, караңгы иде бу төн. Юк, болытлы гына түгел, караңгы гына да түгел, кайгылы, хәсрәтле иде бу төн.

Безгә нишләргә хәзер? Без, бу дөньяның дүрт җан иясе, кечкенә генә өйдә үзебез дә кечкенә генә булып калдык кебек. Кайгырабыз, куркабыз. Өйдә тынлык. Урындыклар да, савыт-сабалар да берберсе артына яшеренеп торалар. Ә самавыр кая качарга белми шикелле.

Без дә тәрәзә буенда тынып кына утырабыз. Ә хуторда шау-шу. Кемнәрдер кычкырына, көлешә. Ара-тирә атлар кешни. Кайчак мылтык аткан тавышлар ишетелә.

Без әле бер якка, әле икенче тарафка күз йөртәбез. Әнә, кайбер йортлар каршында инде учак яга башладылар. Тирәләрендә башкисәрләр кайнаша. Ары-бире киләләр. Нәрсәдер алалар, салалар. Бераз тынып торалар да: «Ур-ра, ур-ра!»— дип кычкырышалар. Җырлыйлар, бииләр. Бирелән караганда, ул учаклар тирәсендә койрыклы җен-пәриләр үрлекырлы сикерешә-сикерешә, кулларына ялкынлы кисәү тотып уйныйлар шикелле күренә.

Безнең тәрәзәдән Бөкре әфәнде йорты төнлә белән бөтенләй күренми иде. Әмма ул тарафта да ут балкышы чагыла. Анда инде бандитларның атаманнары, үз дуслары белән кәефләнә булыр. Рәхәтләнеп сыйланалар бугай...

— Кырыштыралар,— ди эби,— кырыштыралар. Янгын чыгара күрмәгәйләре тагын, нәләтләр.

— Шул янгында үзләре дә янып бетсеннәр иде, исерек башлары белән,— ди Мөршидә апа.— Аларга шул кирәк.

Олылар үзара шулай сөйләшә тора. Мин Мөршидә апаның култык астына сыенып, мәче баласы кебек каранам. Үзем уйланам: «Кемнәр соң бу бандитлар? Каян килеп чыкканнар? Бабай аларны басмачлар, ди. Караклар, кеше үтерүчеләр, ди. Алайса, ни өчен аларны тотып алмыйлар да, ни өчен төрмәгә ябып куймыйлар?» Юк, мин төшенмим әле.

Тик соңга таба гына, инде үсеп җитәрәк бу сорауларыма җавап таптым.

---

Ахыры. Башы 8 нче санда.

Гражданнар сугышы елларында, мин әле балачакта, менә хәзер Мөршидә апаның култык астында, кемнәр соң ул бандитлар, дип уйланып торган чагымда, Украина һәм Россиянең башка өлкәләрендә Махно, Дутов, Антонов һәм тагын башка исемле атаманнар акгвардиячеләрдән, караклардан, дезертирлардан отрядлар оештырып совет властена каршы һөҗүмгә чыкканнар. Алар: «Без аклар да түгел, кызыллар да түгел, без үзебезгә-үзебез хуҗа! Без — анархистлар!»— дип, авылларны, бистәләрне кырыштырып йөргәннәр. Асканнар, кискәннәр, талаганнар.

Кызыл Армия аларны тар-мар иткән. Исән калган өерләре төрле якларга таралышып һаман талау белән шөгыльләнәләр. Авылларны яндырганнар, совет власте вәкилләрен үтергәннәр.

Менә безнең хуторга килеп кергән бу бандалар да шуларның бер өере булган.

Мин әле бу турыда бернәрсә дә белми идем шул. Хәзер, әле мин бая әйткәнемчә, Мөршидә апа култык астында гына утырам. Әби бик тиз арада йокыга китеп барды. Бабай да тәрәзә төбенә башын салды. Ә без Мөршидә апа белән күз дә йоммыйбыз, йокы керми.

Беләм, Мөршидә апа үзенең Мохтары турында хәсрәтләнә. Кайчан гына килеп җитәр икән безнең кызыллар, ди-ди иза чигә булыр. Ә мин әниемне сагынам. Аларны мин инде бик күптән күргәнем юк шикелле. Хатлары да килми. Суга төшеп баттылар сыман. Шунда ук, ярый әле китеп котылдылар, дип шатланып та куям. Үги этине, мөгаен, бандитлар үзләре белән алып китәрләр иде...

Мөршидә апа минем башымны күкрәгенә идерде. «Шунда гына йоклап ал,— диде.— Тиздән инде таң атар»

Кинәт безнең өй дерелдәп, калтырап китте. Мин сискәнеп күзләремне ачтым. Әби дә, бабай да куркышып уяндылар.

Бу шулай дөбердәп, безнең хутор янында гына снаряд төшеп шартлаган иде. Менә тагын берсе тирә-якны яңгыратты. Безнең тәрәзә пыялалары зыңгылдап коелды. Ишек ачылды.

— Беттек, аллакай гынам!— дип кычкырды әби. Учлары белән колакларын томалады.

Бабай чатанлап барып ишекне япты. «Моның җилләре генә дә дөньяны куптара,— диде.— Безнекеләр ата шулай. Болары куркытыр өчен генә әле. Менә хутор уртасына берне китереп салсалар...»

Бабай сүзен әйтеп бетермәде. Хутор артында тагын бер снаряд шартлады. «Бусы да шаярып кына,— диде бабай.— Шуннан бел инде, үзебезнекеләр болар!»

— Минем Мохтарым килә!— дип кычкыра-кычкыра Мөршидә апа ишеккә ташланды. Әби аны тотып калды.

— Юләр,— диде.— Кая ашыгасың. Кемнәр киләдер бит әле?— Бер адым да атлыйсы булма.

Без барыбыз да тәрәзәгә ябырылдык. Хутор үз урыныннан купкан шикелле иде. Өйләрдән бандитлар йөгерешеп чыгалар да, атларына атланып баш-аяк сындырып чабалар. Атлары дулап пошкыра, хуҗалары әллә нинди сүзләр әйтә-әйтә кычкырыша.

Кайсыберләре җәяүләп кенә җилдерә. Бабай көлә, нигә көлә? «Әнә, әнә, карагыз,— ди,— берсе яланаяк кына, әнә, берсе ак ыштаннан гына йөгерә».

Әнә тагын берсе... Юк әйтмим, оялам. Әби аны күреп алды да, килбәтсез, нәләт төшкере, дип төкереп куйды.

Бәлки, ул килбәтсез бәндә минем бәрәнемне алып чыккан бандит булгандыр... Яртылаш ялангач кешене танып буламы соң?

Кайсылары хуторның әле бу ягыннан, әле теге яктан утка пешкән күселәр кебек сыпырттыралар. Абыналар, егылалар, торып тагын чабалар.

— Сыздыралар, аяклары җиргә тими,— диде Мөршидә апа шатланып. Мин аңа карадым, ә ул кечкенә генә көзге кисәгенә карый-карый

яулык чите белән йөзеннән корымын сөртә. Төкерекләп-төкерекләп ышкый. Битләре кызара бара, матурая бара. Миңа күз төшереп ала да елмая. Мин дә елмаям.

Әби дә көлә. «Мәче дә шулай кунак килер алдыннан тәпиләрен ялыйялый битен юа»,— ди.

Бабай да көлә. «Ирен кетә ул безнең килен»,— ди. Кызык та инде. Әле генә кайгырышып, куяннар кебек посып кына утырган бу кешеләр инде мәзәкләр дә әйтешә башладылар. Миңа да күңелле иде!

Ә өйгә ватык тәрәзәдән таң нуры агыла. Чынаяклар өстендә алтын чаткылар уйный. Самавыр җәелеп, елмаеп тора, әле мин дә бар, ди сыман.

Хутор яңадан тынып калды. Тузан да басыла төште. Без курка-курка гына капка төбенә чыктык. Карасак, исебез китте: кырны тутырып, гөрләтеп бирегә таба алтын атлар килә! Аларга атланган солдатлар да алтынга бизәлгән төсле. Әнә, берсе иң алдан атыла. Баш өстендә байрак җилферди. Ул байрак та алтын кош төсле, алга ыргылып оча. Арттан гаскәр ияргән. Солдатларның кулларында кылычлары да алтын. Алар ялтырый, яна, ялкын телләре сыман.

Юк, юк, бу гади солдатлар иде. Алтынга бизәлмәгәннәр. Атлары да алтын түгел, байраклары да алтын кош түгел. Кылычлары да алтыннан ясалмаган. Алар иртәнге таң нурында шулай алтын төсле булып күренгәннәр безгә. Бу кешеләр үзләре әнә шул кызыл байрак канатларында җиргә таң алып киләләр иде шикелле.

— Безнекеләр!— диде Мөршидә апа,— безнекеләр!

Кинәт гаскәр икегә аерылды. Бер отряд хутор янынан гөрләтеп уза бирде. Икенчеләре безнең хуторга борылды. Шулар арасыннан бер җайдак туп-туры безнең өйгә таба юл тотты.

Мөршидә апа аңа каршы йөгерде. Ә мин аңардан да элегрәк «Мохтар абый!»— дип кычкырып өлгердем.

Мохтар абый атыннан сикереп төште дә Мөршидә апаны кулыннан тотып алды. Кочаклады, үпте. Нигә үпмәскә? Аның үз хатыны иы ул. Әби дә, бабай да Мохтар абыйны кочаклап сөйделәр.

— Аз гына кичектегез,— диде бабай. Бандитлар әнә, таладылар да качып өлгерделәр.

— Ерак китә алмаслар, безнекеләр аларны куа китте.

Ә Мөршидә апа үзе елый, үзе көлә. Әбинең дә йөзе чыланган. Ә бабай мыш-мыш борынын тарта. Шатлык әнә нишләтә! Карале, Мохтар абыйның да күзләре юешләнгән. И, солдат шундый буламы соң? Шатлык беркем белән дә санашмый икән. Елата!

Миңа нишләргә? Их, Мохтар абыйның атына менеп атланасы иде. Куркам. Тау кадәр ул. Ыжгырып тора. Өстеннән кайнар тир исе бөркелә. Тояклары белән җирне казыган кебек итә. Күзләре ут. Тешләре белән авызлыгын чәйни. Менә, менә хәзер шул тимер кисәкләрен йотып җибәрер кебек. Атланырсың аңа, чөеп кенә төшерер!

## Аксак солдат

Көз салкынча булса да көннәр әле аяз иде.

Җир өстенә үтә зәңгәр гөмбәз корып куйганнар кебек. Шул зәңгәр гөмбәз астында бөтен тирә-як йокымсырап калган. Хуторга яңадан тынлык килде. Юк, бу теге вакыттагы шикелле, күңелгә шом сала торган куркынычлы тынлык түгел иде. Төн йокыларын качырган шикләнүләр бетте. Хәзер беркем дә бернәрсәдән дә курыкмый. Бабай әйтә: «Хөрлек килде, хөрлек!— ди. Аннан соң бераз башын иеп уйланып тора да зарлана, уфтана башлый.— Гомерләр заяга узып китте, китте»,— ди.

— Нәрсә соң ул хөрлек? Гомер узулар ничек була? Олыларның

үзара шулай пошынып сөйләшүләрен гел ишетә торам, әмма төшенмим. Сорарга куркам. Бабамның гадәтен беләм. Кайчакларда ул:

— Күп белсәң, тиз картаерсың, дип тә әйтә. Янәсе, аның кебек ак сакаллы булып. Сиңа әле ак сакал килешмәс, ди-ди көлә ул. Үскәч белерсең, янәсе.

Безнең хутор өстендә кызыл әләм, аягыннан бәйләп куйган кызыл кош кебек очына-очына җилферди. Мин аңа көн дә карап узам. Күңелле булып китә. Ул ялкын шикелле яна. Аны кулга тотып алып бер селкеп җибәрсәң, бөтен дөньяга ут кабыр төсле. Килеп карасын дошманнар, янып бетәргә теләсәләр!

Тик шулай да уйландыра: тагын нәрсә булыр, нинди көн килер?

Кызылармеецлар безнең хуторда озак тормадылар. Беркемгә дә, бернәрсә дә искәртмичә генә атларына атландылар да, тупларын өстерәп, тачанкаларын җилтерәтеп китеп бардылар.

Әби сагышлана. «Мескен оланнар, ди — тагын сугышка китүләредер инде. Аларны бит кайдадыр туганнары, бала-чагалары зарыгып көтәдер».

Бабай тыныч сөйләшә:

— Кайгырма, егетләрне тиздән өйләренә кайтарып җибәрәчәкләр, ди. Тиздән, тиздән туганнары белән дә күрешерләр. Дөньялар тынычланып килә. Аллага шөкер...

Бабай белеп сөйли. Әнә бит, Мохтар абый үзе дә хуторда яшәп калды. Дөрес, ул әле кылычын да салмады, наганы да билендә. Ләкин, мин инде солдат түгел, ди. Аны хуторга башлык итеп куйганнар икән.

Хуторда тагын берничә солдат та бар әле. Алар Бөкре йортында яшиләр. Келәтләр янында чиратлашып сакта торалар. Төнлә хуторны күзәтеп йөриләр. Безгә хәзер куркасы түгел.

Ә беркөнне Мохтар абый безнең өйгә бер аксак солдат ияртеп килеп керде. Солдат култык таякларына таянып та чак-чак сгылмый тора иде. Йөзен сакал-мыек баскан. Иңбашлары шинель астыннан тырпаеп чыккан. Үзе ябык, озын. Муены нечкә. Читтән караганда ул, җиләк бакчасына чыпчыклар куркытыр өчен ике казык белән терәтеп куйган карачкы кебегрәк. Ә күзләре кап-кара күмер төсле, бер янып, бер сүнеп китәләр сыман. Солдат бу сакал, мыеклары белән минем әтиемә дә охшаган иде. Мин әтиемне шундый килешлерәк күреп калдым.

Әллә шуңа күрәме, бу аксак солдат минем күңелемне кузгатты. Мин аны кызгандым. Тиз генә аңа урындык китереп куйдым.

— Утыр, абый, арыгансың,— дидем.

Солдат утырды. Нигәдер сөйләшми торды. Мохтар абый әйтте:

— Менә сезгә бер кунак алып килдем әле. Күрәсездер ул бу хәлендә бер кая да бара алмый. Аягы яралы. Сездә бераз торып ял итсен, хәл алсын, дип рөхсәт сорарга килүебез иде. Хәлиматтәй, нәрсә әйтерсең икән?

— Кунакны беркайчан да кире борып чыгармыйбыз,— диде әби.— Татарда андый гадәт юк. Кунак үзе түребезне тартынмаса, бездән якты чырай, такта чәй, рәхим итегез.

Бабай да сүз катты:

— Мондый авыр заманда кеше-кешегә булышлык кылмаса, ул нигә ярый? Без дошманнар түгел ич, Мохтар энем, иртәгә дә йөзгә-йөз килеп, күзгә күз карыйсыбыз бар ләбаса. Әлбәттә, ызбабыз бер генә тәрәзәле. Гаеп итештән булмасын...

Минем аңлавымча, әби дә, бабай да бу аксак солдат бары тик бездә генә торырга тиеш дип Мохтар абыйны күндерергә телиләр шикелле.

Мохтар абый шатланды. «Сез яхшы кешеләр, рәхмәт,— диде.— Болай булгач сезне дә солдат хезмәтендә дип саныйбыз».

Бабай билен турайтты, күкрәген киерә төште.

— Мин риза,— диде көлә-көлә.— Мылтык тотарга ярамасам да кашыкны шәп йөртәм әле.

Әби дә елмайды.

— Анысын гына булдыра ул карт,— диде.— Булдыра...

Мохтар абый да шаркылдап көлде. «Бездә дә андый солдатлар бар,— диде.— Кашыкны итек балтырында гына тоталар».

Әби тагын әйтә куйды:

— Яраларын төзәтергә шифалы үлән суларым да бар. Эче бора башласа да даруларын табарбыз. Өс-башларын караштырырбыз. Кулларыбыз исән әле, бакчы...

Аксак солдат көлеп җибәрде.

— Нигә көләсең, солдат?— диде бабай.— Әллә татарча да аңлыйсыңмы? Әллә үзең дә татармы?

— Татар.

Бабай авызын ачыбрак калды. Әби аксак солдатны тирә-яклап күзәтеп чыкты. Ул бу кешенең тәгаен татар икәнлеген бар яклап чамаларга тели иде.

— Нигә исегез китте?— диде Мохтар абый.— Безнең дивизиядә татар солдатларын санап кына бетерерлек түгел. Безнең полк командиры да Казан татары.

— Без Себердән, ә син кайсы яктан соң, улым?— диде бабай солдатка кулын биреп.— Күрешеп җибәрик булмаса, үз кешебез икәнсең. Йөзеңә карап кына бер дә танырлык түгел.

— Царицын шәһәреннән ерак түгел бер кечкенә татар авылыннан.

Кинәт мин дә ул шәһәрне исемә төшердем. Без бирегә шул шәһәрне узып килгән идек. Тыңлыйм әле, дидем мин үз-үземә, солдат абый тагын ниләр әйтер икән? Ул нәрсәләр генә белми торгандыр...

И бу тиктормас бабай, әнә тагын сүзгә керешә:

— Ул якларда да татарлар яши дип ишеткәнем булды. Чын икән.

— Синең исемең ничек соң?— диде әби.

— Хәниф Шагалиев.

— Безнеңчә Хәнифулла, димәк, чын мөселманча икән.

Мохтар абый китеп барды. Шушы көннән алып Хәниф абый бездә яшәп калды. Әби аның киемен салырга булышты. Бабай чалгы пәкесен уч төбенә ялт-йолт иттереп ышкып алды да:

— Яле, солдат, кырынып җибәрик,— диде.— Югыйсә, син бу килеш карт маймылга охшап калгансың. Чәчләреңне дә алып ташлыйсы булыр. Бу «урманда» инде «җәнлекләр» йөри башламагае.

Хәниф абый эндәшмәде, тик кенә утыра бирде. Мин аңа карыйм. Ә ул күзләрен кыскалап елмая. Сизәм, без әшнәләр булачакбыз...

Менә аның башы да, йөзе дә ялтырап калды. Минем көләсем килә. Менә хәзер аның баш түбәсенә уч белән чалт иттереп бер сугып аласы да, «Кояш чыкты!»— дип кычкырасы иде. Юк, ярамый, ул яралы. Уйнар чагы түгел аның.

— Син әле егет кенә икәнсең лә,— диде әби, Хәниф абыйның йөзенә карый-карый.— Чынлап, ир-затларны сакал-мыек бөтенләй боза икән. Әнә ничек чибәрләнеп киттең. Карап туймассың йөзеңә.

Хәниф абый оялды, күрәсең, битләре алсуланды. Ул безгә карарга да уңайсызлана иде кебек. И, дидем мин эчтән генә, оялып торган була, үзе солдат, имеш. Их, мин солдат булсам, дип нindидер уйлар корып маташканда гына әби мич янына дәште.

— Сабирулла улым, утын кертәсең бар, гел әйткәнне генә көтеп тормыйлар,— диде.— Су җылытырга кирәк. Хәниф абыеңны юындырып, коендырып чыгарасы булыр. Ә син,— диде бабайга.— Учакны ягып җибәр дә казанга тутырып су сал. Егетне әнә тагаракка утыртып юындырыгыз. Карагыз, сак булыгыз, яралы аягына берүк кагыла күрмәгез. Мин Мөршидә чакырган иде. Шунда барып кайтасым бар.

— Анысын гына булдырырбыз,— диде бабай.— Ул эш безнең кулдан килә...

Әби тиз генә чыгып китте. Эшне белеп йөртә ул. Ир янында ирләр генә калсын дигәндер. Хәниф абый үзе дә әби каршында шәрә килеш тагаракка утырып торырга теләмәс иде. Күрәм, ул да моңа бик риза. Мин аңа күз кыстым. Ул елмайды, башын селкеде. Янәсе, шәп булды әле бу.

Без эшне тиз тоттык. Бабай Хәниф абыйны мунчала белән ышкыйышкый күбеккә батырып бетерде. Хәзер ул, ак мамыкка төргән бала шикелле иде. Мин аның башына су салып торам. Ә Хәниф абый шул ап-ак күбек эченнән кызгылт тәнле, алсу йөзле өр-яңа кеше булып килеп чыкты.

— Менә булды бу,— диде бабай мактанган шикеллерәк итеп.— Гөнаһларыңны да юып төшердек дип әйтер идем дә, гөнаһларың юктыр әле синең, егетем. Чиста тәндә кешенең җаны да саф була. Моны борынгылар шулай әйтеп калдырган.

Хәниф абый рәхәтләнеп көлде. Аңа күңелле иде. Мин дә шатландым. Бу солдат белән без әле әллә нәрсәләр кыландырып бетерербез. Һәм шулай булды да. Ул турыда минем әле язасыларым булыр.

Әнә, әби кайтып керде. Кулына шактый зур төен тоткан иде. Төенне сөтмичә генә өстәлгә куеп торды. Мин башымны сузып төенгә карап төбәлдем.

— Нәрсә, күзләрең янамы? Ашыкма, көтә тор,— диде.— Ә син, карт самавыр куеп җибәр. Кунагыбыз сусагандыр. Мунчадан соң чәй килешә,— дип тә көлде әби.

Бабай гадәтенчә: «Анысын гына булдырырбыз,— диде.— Чәйсез дөнья ямьсез, дигәннәр борынгылар...»

Сизәм, бабайның да күңеле күтәренке. Бу көнне безнең өйгә аксак солдат белән нииндидер шатлык килеп керде сыман. Ә Хәниф абый көзге кебек ялтырап утыра. Йөзе елмайган, күзләре нурлы. Ә миңа рәхәт.

Кечкенә генә хутор читендә, кечкенә генә өй эчендә учак та яна, казан да шаулый, самавыр да гөрли.

## Моңлы җыр

Әби Хәниф абый янына килеп утырды. Җилкәсеннән чәбәкләде.

— Яле солдат,— диде,— яраңны карыйк. Нишләп кенә беткән икән ул? Зурмы, бик тирәнме?

Хәниф абый бер аягын урындыкка күтәреп сузып куйды. Үзе йөзен чытты. Әмма ухылдамады.

— Снаряд кыйпылчыгы тигән иде,— ди.— Бәйләгәннән бирле чишкәнем юк. Нишләгәндер, үзем дә белмим.

Әби яра өстеннән чүпрәк кисәкләрен сак кына, житез генә сүтеп алды. Хәниф абый башын бер якка борып ыңгырашты.

Ярасы зур иде. Аягының тездән түбән, нәкъ балтыр уртасыннан бер кисәк итеп пычак белән каергалап, өзгәләп, тарткалап кисеп ташлаганнар шикелле.

Минем тәнем чемердәп китте. Үз аягым да сызлый башлады кебек. «Яра эчендә тимер кисәкләре юкмы? Ныграк кара»,— диде бабай ерактан гына пышылдап. Ул бу минутта кычкырып сөйләшергә дә курка иде, күрәсең. Хәниф абыйга авыр булыр ди бугай. Әнә, ул болай да җан газабы белән сызлана.

Әби ярага караган килеш озак кына эндәшми торды. Аннан соң яра тирәсендә бармакларын йөртеп алды.

— Ярасы бик тирән, әмма сөяккә зарар килмәгән,— диде. Куркасы түгел солдат, иншалла, төзәлер. Яшь тәндә тире тиз умарлана.

— Тизрәк бәйлә, Хәлимә апа. Бигрәк авырта бит...

— Яхшы итә, сызлаган яра тиз төзәлә. Авыртмаса да, сызламаса да эшләрең шәптән булмас иде синең, Хәниф энем. Борчылма, яраң бераз сулыш алсын. Ул да бит тере шикелле нәрсә, һаман бәйләнгән килеш тончыга. Һаваның да үзенә күрә шифасы бар.

Әллә белеп сөйли, әллә белми генә әйтәме бу сүзләрне әби, әмма

Хәниф абый тынычлана төште. Күрәсең, әби сүзләрендә дә шифалык бардыр.

Әби киштәдән берничә шешә алып килде. Берсеннән учына нин-дидер сыекча агызды. Кулларын шуның белән юган төсле итте. Аннан соң аларны югары күтәреп һавада селкеп киптерде. Тик шуннан соң гына яра тирәләрен ниндидер сыекча белән сөртеп чыкты.

— Хәзер бераз түзәргә туры килер, солдат кеше,— дип сөйләнә-сөйләнә бер шешәдән кып-кызыл яра өстенә тагын ниндидер бер сыекча койды. Ә Хәниф абый бөтен көченә: «Үләм, үләм!»— дип акырып җи-бәрде.

— Үлмисең, үлмисең,— диде әби.— Тагын да катырак кычкыр, җаныңа җиңелрәк булыр.

Хәниф абый елаган кебек итә. Әби елмая.

— Кайберәүләрнең аякларын бот төбеннән үк кисеп алалар, берсе дә үлмәгән, дөбердәтеп яшиләр. Ә бу разбой сала. Көлке димәссеңме? Әллә нинди, андый-мондый дару да түгел әле, шифалы үлән суы гына!

Мин еларга җитешеп Хәниф абыйны кызганып тора идем. Түзмә-дем, тизрәк бәйлә абыйның ярасын, бәлки, сызлавы басылыр, дидем.

— Әле син дә телеңә салынасыңмы?— диде әби.— Кил әле бирерәк, синең авызыңа да бер-ике тамчы тидереп алыйм. Тыкылдавың бетәр дә китәр.

Мин авызымны кысып йомдым да, тизрәк бабай янына йөгердем. Бабай мине тезләре арасына алып кочаклап тотты.

— Сабирулланың теле сызламый ич,— диде.

Әби Хәниф абыйның ярасына ниндидер бик сасы май сөртте. Ыспай гына итеп ак чүпрәк белән бәйләп куйды. «Менә эше бетте,— диде.— Атна-ун көн эчендә төзәлеп тә китәрсең, энем».

Хәниф абый иркен сулыш алды. Мең рәхмәт яусын сезгә, диде. Ул тагын нәрсәдер әйтергә теләгән иде, кинәт тик кенә торган бабай да сүзгә керешеп китте:

— Син, карчык, аңа теге «ни суын» да эчертеп кара әле,— диде, сакалын өстән аска таба сыпыра-сыпыра.— Вәт ул нәмәстә сызлауны бастыра. Бер йотымы да авыруны шундук куып чыгара.

— Өйрәтмә, беләм.

— Онытмадыңмы, дип әйтүем.

— Онытмадым.

Әби яңадан киштәгә сузылды. Андагы шешәләрне шылтырата-шылтырата нәрсәдер эзләде. Шуннан тагын бер шешә алып кулындагы чынаякка ниндидер сыекча салды. Шешәне кире үз урынына куйды. Чынаякны сак кына тотып Хәниф абый янына килде.

—Яле, солдат, менә шушы үлән суын да эчеп җибәр,— диде.— Сихәтле нәрсә...

Хәниф абый чокырны ике кулы белән тотып, башта әбигә карады. Бабайга да, миңа да күз кысып алды. Бабай ни өчендер иреннәрен чә-пелдәтте. Аның да теленә тәм йөгерде бугай.

— Эч-эч, суытма,— диде әби.— Тикмәгә көчен бетермә!

Хәниф абый иң элек авызын ачты, аннан соң күзләрен йомды да берьюлы эчеп җибәрде. Юк, эчеп җибәрмәде, авызына салып кына куй-ды кебек. Беравык тынып торды. Күзләрен кыскалады, зур итеп сулыш алды.

— Менә бу дару ичмасам,— диде.— Шәп! Җаным җылынып китте. Рәхәт, эчемдә май эри шикелле. Әнә, ярамның да сызлавы басылды. Булса да булыр икән шундый дару!

Әби елмайды. «Әллә ни түгел, үлән суы гына»,— диде. Үзе мич янына барып казан асарга керешә.

Булыр сиңа «үлән суы гына! Бабамның теге «ни суы» дип әйтү-ләрен мин инде күптән төшенгән идем. Әби өйдә булмаган арада бабай кайчак шул киштә янында кайнаша. Ашык-пошык кына шешәне ала да авызыннан гына бер-ике йотым эчеп куя. Аннан соң тозга манып икмәк кисәге каба.

— Фу, нәләт,— ди,— әремнән дә әчерәк. Яндырып ала.
Озак та узмый, бабай яшәреп киткән кебек була. Күзләре ялтырап китә. Алай да булмый, бабай әкрен генә җырлый башлый. Күзге алдына басып сакалын сыпыра, йөзен күзәтә, күлмәген рәтли, кулларын як-якка җәеп, биеп китмәкче булып кылана. Мин көләм. «Бабай, нәрсә эчтең син?»— дим.
— Нәрсә булсын, үлән суы, балакаем. Баш авыртуыннан бераз файдасы булмас микән дигән идем. Юк, рәтле түгел икән...
Шунда ул миңа җитди генә карый да:
— Әбиеңә әйтә күрмә,— ди.— Икебезне дә өйдән куып чыгарыр...
Минем исем китә. Нинди үлән суы икән соң ул? Ә бер көнне мин ул үлән суын үзем дә эчеп карадым. Өйдә үзем генә калган чагым иде. Бер шешәдән чокырга аз гына салып алдым да адарына-адарына эчеп бетердем. Башта, чыннан да, су гына шикелле иде. Кинәт сулышым буылып калды. Авызым яна башлады. Телемә дә ут капты сыман. Ниндидер әче тәм тамагыма килеп утырды. Кых-кых итеп ютәллим, төкеренәм, әчемне тотып әрле-бирле йөгерәм, бер иеләм, бер чайкалам, үләм, дип торам.
Шулай да булмады өй үзе зыр-зыр итеп әйләнә башлады. Бер тәрәзә урынына мең тәрәзә күренә. Самавыр да, өстәл дә савыт-сабалар да чаңгылдаша-чаңгылдаша сикерешәләр. Миңа кызык. Шуннан соң мин үзем дә әйләнә-тулгана тапчан өстенә барып аудым. Менә сиңа үлән суы гына!
Хәзер Хәниф абыйның да шундый чагы. Әнә аның йөзе кызара бара, күзләре дә яктыра төште. Елмая, иреннәрен ялый. Тагын бераз гына эчәсе иде ди бугай...
Ялгышканмын, Хәниф абыйга тагын бер тамчы да кирәк түгел икән. Ул, култык таякларына таянып бераз йөреп тә алды. «Бөтенләй савыктым сыман,— диде.— Шифасы бар икән бу даруның. Валлаһидер менә, бииселәрем килеп китте».
— Гармуныбыз юк шул, дигән булды бабай көлә-көлә,— гафу ит, андый затны асырамыйбыз.

— Гармун минем үземдә бар,— диде Хәниф абый.
Әби дә әшеннән туктап калды. Бабай да сәерләнде. «Чамасыннан арттырыбрак «җибәрдеме» әллә бу?», дип уйлагандыр, бәлки.
Ә Хәниф абый күкрәк кесәсеннән кечкенә генә көмеш тартма шикелле бер әйбер чыгарды да җәйләп кына иреннәренә китереп куйды. Кинәт ниндидер нечкә, калын авазлар чыңлашты. Таныдым, авыз гармуны ич бу, әйе, шул — үзе! Безнең авылда да бер егет шундый нәрсәдә уйный торган иде. Исемдә.
Бабай эһем-эһем итеп тамагын кырды. Әллә җырларга җыена? Аның күзләре ачыла төште. Урындыгын шыгырдатып ипләбрәк утырды. «Сыздырып җибәр әле бер,— диде.— Күптән ишеткән юк гармун җырларын».
Әби дә көтә торды. Ул да елмая. Нәрсә килеп чыгар икән, ди бугай. Аның да бик тыңлыйсы килә, күрәсең.
Ә мин Хәниф абыйның аягы янына ук чүгәләдем. Авызына кереп китәрдәй булып, күз дә йоммый карап торам. Ә Хәниф абый миңа күз кыса, янәсе, исләрен китерик әле картларның. Мин дә аңа күз кысам. Тик минем ымлавымны ул аңламый әле. Мин бит аңа: «Яратам сине, Хәниф абый, син яхшы кеше»,— димәкче булам. Минем өчен иң шатлыклы көн бүген.
Ә Хәниф абый әнә инде сыздыра. Ул ниндидер бер моңлы көй уйный. Без хәзер аның үзен күрмибез дә шикелле. Алда урман, урманда кошлар сайрый шикелле. Әнә, каядыр бер чишмә чылтырап ага кебек. Тагын да арырак безнең туган авыл күренә төсле. Әнә безнең йортыбыз. Әнә, читәнгә минем Гөлдерием менеп кунган. Сузып-сузып кычкыра. Әнә кояшлы алан, анда мин җиләкләр җыеп йөрим...
Җыр агыла, ә без селкенмибез дә. Җыр безне сагышка салды, уйга төшерде, туган якларга алып китте.

Бабай иягенә таянган. Күзләре юешләнгән. Ул да бу минутларда бәлки узган елларын исенә төшергәндер. Үз гомерендә нәрсәләр генә күрмәгән ул? Кемнәр белән генә очрашмаган да, кемнәр белән генә аерылышмаган. Җыр шундый ул, күңелне тетрәтә. Әби елап утыра. Ә мин урынымнан да кузгала алмыйм. Мин хәзер гармун көенә кушылып үзем дә җырлыйм кебек.

Гармун тавышы тынды. Әле генә күз алдында безне сихерләп торган күренешләр югалды. Без янә үзебезнең кечкенә генә өебездә моңланышып калдык.

Хәниф абый гармунын кесәсенә тыкты. Авыр сулады. Үзе шунда ук елмайган да булды. Әмма килештереп җиткермәде. Кыланган кебек кенә иде аның бу елмаюы. Беләбез бит, аның да аягы гына түгел, җаны да җәрәхәтле. Сөекле туганнарыннан аерылсын да ди, сугышта үлепкырылып йөрсен дә, яралансын да ди, кайгысыз да, хәсрәтсез дә булсын, имеш. Беләбез, Хәниф абый, син дә сагышланасың...

Көтмәгәндә генә әби сүз башлады. Менә бит тагын тыкшынды. Хәниф абый, бәлки, безгә әллә нинди кызыклар сөйләгән булыр иде әле.

— Синең хатының, бала-чагаларың бармы?— диде әби.— Исемә төшкәндә сорыйм әле.

— Хатыным юк. Сөйгән ярым бар иде. Белмим, көтә микән. Бәлки, өметен өзгәндер инде...

— Көтәргә тиеш, әбәзәтелне,— диде бабай, урыныннан бер кузгалып.— Әбәзәтелне.

— Алай икән,— диде әби сузып кына.— Алай икән. Җәнҗаллы заман шул. Кыз баланың көтәргә вакыты күп булмый.

Әби моның белән генә тукталмас иде әле. Төпченергә бик ярата ул. Бәхеткә каршы чаж-чож килеп самавыр кайнап чыкты. Бабай тиз генә самаварны өстәлгә мендереп бастырды.—«Молодец,— диде.— Нәкъ үз вакытында дөбердәдең».

Сизәм, бабай да әбинең такылдауларына бик үк риза булып утырмаган, күрәсең.

Өстәл тирәсенә җыелышып утырыштык. Әби әле бая гына алып килгән төенне чиште. Шулчак өебез яктырган төсле булды. Ул төендә түгәрәк ай кадәр бер бөтен каравай ята иде. Юк, өй яктырды диеп бәлки чамадан арттырыбрак әйткәнмен. Әмма без шушы каравай янында үзебезне бәхетле итеп тоя идек. Чыннан да, безнең күңелләр яктырып китте.

— Мөршидә килен биреп җибәрде,— диде әби,— иртәгә тагын килергә кушып калды. Безгә — барыбызга да солдат паегы тиешле икән.

Бүген бездә, чыннан да, бәйрәм иде.

## Беркөнне иртә белән...

Беркөнне иртә белән йокымнан уянып китсәм, кинәт сәерләнеп калдым. Өй эче нигәдер яктырып киткән. Салкынрак та сыман. Әкрен генә юрган астыннан чыктым да тәрәзәдән тышка карадым. И-и, ни күрәм? Дөньяны тутырып кар явып куйган. Тагын кыш килеп җиткән! Үзем дә сизмәстән: «Кар яуган, кар!»— дип кычкырып җибәрдем.— Кар яуган, кар!»

Әби дә уянды, бабай да сикереп торды. Хәниф абый бер дә исе китми генә мендәрдән башын күтәреп карады да юрган эченә керебрәк ятты.

— Һушымнан яздырдың, малай актыгы,— диде әби.— Шул кадәр кычкырмасаң. Кар яуган, имеш. Кыш булгач кар ява инде ул. Ямый кая барсын.

Ә бабай иплэп сөйләште.

— Кар ул дөнья күрке,— диде.— Теләсә кемнең дә исен китәрә.

Бабай тагын да нәрсәдер сөйләнде. Ә мин ашык-пошык киендем дә атылып тышка чыктым. Ары-бире каранам, бөтен җирдә кар, кар!

Хутордагы өйләр дә кардан гына әүмәкләп куелган шикелле. Тирә-як ап-ак. Күзләр чагыла. Тып-тын.

Мин карны аякларым белән туздырам. Кулларыма алып йомарлыйм. Авызыма кабам. Аннан соң туп ясыйм да атып җибәрәм. Миңа күңелле! Карга бата-бата йөгерәм. Егылып китәм, ауныйм. Бер җирем авыртмый да, буялмый да. Кулларым да чиста, битемне дә кар юа.

Кинәт туктадым да уйга сабыштым. Исемә төште. Безнең якларда кыш шундый була торган иде. Тездән карга баткан килеш хәзер мин үз туган авылымда шикелле. Әнә, күз алдымда — безнең йортыбыз. Әнә мәчет, тагын да арырак көзге шикелле бозы белән күл ялтырап ята. Ярларына кар тавы өелгән. Малай-шалайлар илерешеп-кычкырышып чана шуа. Тик мин генә анда юк.

Хәер, мин әле ул чакта чанада шуарлык идемме соң? Шулай да карга ятып тәгәрәргә булдырырлык малай идем инде.

Өйгә кайтып кергәч әнием, җилкәмнән умарлап, бер җилтерәтеп алыр иде, имән каерысы шикелле бозланып, укмашып беткән бишмәтемне өстемнән салдырып, кулларымны үз авызына куя-куя җылыта торган иде. Үзе: «Шул карны нәрсә дип беләсез,— ди-ди орыша торган иде.— Әле ашап та карагансың, малай актыгы...»

И әнием, кайда син? нигә болай озак кайтмый торасыз?.. Күзләремә яшь тула. Иреннәрем калтырый. Миңа хәзер бу ап-ак кар да, инде кыш үзе дә кирәкми. Әнием генә кайтып җитсен иде.

Шул арада өйдән Хәниф абый килеп чыкты. Бик сакланып кына атлый. Култык таяклары белән кар өстенә ниндидер бизәкләр төшергән төсле итә. Менә ул минем яныма килеп туктады. Як-ягына каранды. «Кары да нинди бит, актан да аграк, йомшактан да йомшаграк»,— диде, бер иркен сулыш алып.

Ә мин эндәшмим. Хәниф абый иелеп минем йөземә текәлде. «Син нәрсә, агайне,— диде.— Нигә күзләрең җебегән? Ни булды? Борыныңны тот, җиргә төшеп бара ич инде».

— Әниемне сагындым...

— Анысы аңлашыла. Минем дә сагынасы кешеләрем күп. Күрәсең, бер дә еламыйм. Ир кешегә килешми. Түзәм.

Хәниф абый бераз тынып торды. Беләм, аның да күңелендә хәсрәт тыпырчына. Сиздерми генә. Ир кеше имеш. Ул мине үзенә тартып, җилкәмә кулын куйды.

— Сиңа инде ничә яшь?— диде.

— Ун тулып килә.

Хәниф абый көлде. «Мыеклар үстерергә дә озак калмаган икән,— диде.— Егет чакларың килеп яга синең...»

Шатланып киттем. Чыннан да, озакламый миңа да кап-кара мыеклар бәреп чыгар. Өстемә билле камзул киеп җибәрермен. Башымда укалы түбәтәй. Аякларымда ялтыравыклы кәвешләр булыр. Кесәләремдә майда гына куырган симәнкә. Кичләрен кызлар карарга чыгармын.

Хәниф абый уйларымны бүлдерде.

— Әмма,— диде ул,— егет булыр өчен мыеклар үстерү генә җитми. Укый-яза белергә кирәк, энем. Югыйсә, сөйгән ярыңа хатны көндәшеңнән яздырырга туры килер. Ә син әле бер генә хәреф тә таный белмисең.

Кәефем кырылды. Мин укый да, яза да белмим шул. Мәктәпнең әле бусагасын да күргәнем юк. Кая ул укый белүләр.

Хәниф абый сөйли тора.

— Синең шикелле балалар,— ди,— бу чакларда китаплар тотып укырга йөриләр. Ә син менә биредә...

Шул урында, бераз туктальп, тагын читкәрәк чыгып берничә сүз әйтми хәлем юк. Инде ярты гасыр узгач та бу карлы иртә минем әле дә исемдә. Аксак солдатның ул чакта әйткән сүзләре хәтеремә язылып калды. «Синең шикелле балалар бу чакларда инде укырга йөриләр, ә син менә биредә...»— диде ул. Ягъни, менә исеме беркая да билгеле булмаган бер кечкенә генә хуторда. Ул вакытта мин әле бу сүзләрнең мәгънәсен төшенеп җитмәгән идем. Хәзер уйланам.

Ул хуторда инде ничә буын яшәп киткән? Күпме бала туган. Тора-бара алар да картайганнар, үлгәннәр. Берсе дә, бер хәреф тә танымаган. Ул кешеләр санда гына кеше булып исәпләнгәннәр. Тагын йөз ел үтсә дә, аларның язмышлары үзгәрмәс иде. Дөньяның кайсыдыр бер читенә килеп урнашкан зиратка охшаган төбәк бу кешеләрне бишектән алып кабергә кадәр әледән-әле озата торыр иде.

Мине дә шундый язмыш көткәнме? Юк, мине андый язмыш көтмәгән. Исемем белән генә түгел, мин инде кеше булып та яңа чорга аяк басканмын. Бу карлы иртә шул яңа чорның бусагасы булган. Бу аксак солдат шул чорның бер вәкиле. Ул, җилкәмнән тоткан килеш, минем киләчәгемә карап торган. Бу турыда ул чакта мин әле шәйли белмәгәнмен. Минем әле моннан соң да барасы юлларым ерак булган...

Әби ишек ачып кычкырды:

— Чәй әзер, керегез...

Иртәнге аштан соң, Хәниф абый үзенең солдат капчыгыннан ниндидер кәгазь кисәкләре тартып чыгарды. Кулына карандаш алды да мине үз янына чакырды.

— Я, Сабирулла, укырга, язарга өйрәнә башлыйк, вакыт бик җиткән,— диде.

Менә монысы эш,— дип бабай да күзләрен ялтыратты.— Их, яшь чакларым булса, Хәниф туганым, үзем дә синең шәкертең булыр идем. Алдыңа тезләнеп утырып сабак алыр идем. Икмәктер менә. Кыш буе нишләмәк кирәк бу өйдә? Укыган кеше — мең алтын дигән борынгылар...

Беләм, беләм, бабай, мине шулай сөйләнеп укырга кызыктырмакчы. Киреләнмәсме, янәсе, бу керпе баш. Мин киреләнәмме соң! Кызларга кем хат язар? Мин риза, бик-бик теләп риза!

Шушы көннән алып Хәниф абый мине укытырга керешге. Сизәм, ул шатлана. Йөзе ачылып китте. Бөтен гәүдәсе белән җанланды. Ул үзенә эш тапты. Мөгаллимгә тагын нәрсә кирәк! Ә минем күкрәгемдә йөрәгем кош кебек тыпырчына. Мин дә шатланам. Бер әбигә карыйм, бер бабайга. Ә алар йөзләрен киң җәеп елмаешып утыралар. Ни әйтерсең, безнең өйдә мәктәп ачылды ләбаса!

Укытучым алдыма кәгазь бите җәеп салды. Үзе шул кәгазьгә ниндидер билге сызды да, авызын зур ачып:

— Менә бу «А» хәрефе була,— диде.— Яле, әйтеп кара, ничек чыгарырсың икән?..

Мин Хәниф абый авызына карый-карый «А» дип кычкырдым.

— Тагын.

— «А»!

— Тагын.

— «А», «А», «А»!

Мин шулай кычкыра торам, ә укытучым: «Авызыңны тагын да зуррак итеп ач, зуррак»,— дип әйтә тора. Шактый озакка барды бу. А-а-а! дип кычкыра-кычкыра арып беттем. Хәниф абый ник бер генә көлеп карасын. Бик җитди кылана. Укырга өйрәнү — ул, энем, хөрмә ашау түгел, ди.

Хөрмәнең нинди булганын мин беләм инде. Ашап караганым булды ич бервакытны. Тәме әле дә тел очында гына. Әнә, ул хөрмә агачы да тәрәзәдән безгә карап тора. Ботакларына кар кунган. Ап-ак шау чәчәк аткан сыман. Бередән караганда безнең өй стенасына бик матур рәсем элеп куйганнар сыман. Тәрәзә генә димәссең, чын рәсем!

Мин шулай әлеге күренешкә исем китеп утырганда, Хәниф абый әйтә куйды:

Бәхетле шул баладыр,
Кайсы дәресенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олуг күрсә,
Белергә кушканын белсә...

Сискәнеп киттем. Бу нәрсә, нинди сүзләр? Бу юлы инде мин чыннан

да, авызымны «А» дип кычкырганнан да зуррак итеп ачып калдым.

Хәниф абый шул ук сүзләрне тагын кабатлады. «Искә ал, малай,— диде.— Сабак укыганда күзләрең дәфтәрдә булсын, колакларың үрә торсын».

Сәке түрендә тыныч кына оек бәйләп утырган әби дә сүзгә катнашты:

— Бик дөрес, бик дөрес,— диде,— шәкерт ихласлы булырга тиеш. Тырышып укы, улым.

Бабай да тыкшынмый калмады:

— Кара әле, Хәниф энем, син нинди дә бәет әйттең түгелме? Җыр шикеллерәк иде сүзләрең.

— Бәет түгел, Тукай шигыре, бабакаем, Тукай шигыре...

— Шулаймыни? Бик тә дөрес язган Тукай. Аның турында бик күп ишеткәнем бар.

— Ә мин аны күреп тә беләм. Тукай безнең мәдрәсәгә килгәләп китә торган иде. Татарның олы шагыйре.

Бабай бәйләнсә, чәер шикелле, ябыша тора. Әнә тагын:

— Ул шагыйрь дигәнең ничегрәк яши икән соң бу заманда?— дип сорады.— Кызыллар ягындамы, әллә аклар...

— Кызыллар ягында, әлбәттә. Әмма ул күптән вафат инде.

— Шулаймыни?— ди әби авыр сулап.— Беркем дә дөньяга мәңгегә килми шул.

Өй эче беравык тынып торды. Әле генә безнең өйдән мәет алып чыктылар шикелле иде. Мин дә уйланам. Без бит дәресне «А» хәрефеннән генә башлаган идек. Әнә кая килеп чыктык. Тукай шигырен ишеттек. Ул бит минем өчен шушы сүзләрне язып калдырган. Алда бит әле күпме хәреф өйрәнәсе бар. Ул хәрефләр дә миңа әллә нинди шатлыклар алып килер әле. Мин бу хәлемдә, чыннан да, зур, якты мәктәп ишеген ачып кердем кебек.

— Тәнәфес бетте,— диде минем мөгаллимем.— Дәресне башлыйбыз.

Хәниф абый минем кулыма иплән кенә карандаш тоттырды. Инде үзең дә яз, диде. Мин телемне чыгара-чыгара, кәкре-бөкре итеп көчхәлгә «А» хәрефен язып куйдым.

— Инде укып та күрсәт.

— А-а-а!!— дидем мин горурланып, чөнки кәгазь битендә үзем язган хәреф иде.— А, а, а!

— Ә хәзер,— диде Хәниф абый,— шушы үз хәрефеңне бөтен кәгазь битенә тезеп, тутырып язып чык.

— Күп була ич ул.

— Күп кирәк!

— Нигә?

— Күнегергә!

— Шәкерт мөгаллимгә сорау бирми,— диде бабай, мич янында нәрсәдер эшләп маташкан арада.— Сорауны мөгаллим үзе бирә.

Мин карандаш очын бер сындырып, бер яңадан очлап «А» хәрефен, мөгаллим әйткәнчә, кәгазь битен тутырып язып чыктым. Чалышполыш юллар пәйда булды. Дөресрәге, кемнеңдер ары-бире сугылып узган эзләре кебек иде. Үзем дә шабыр тиргә баттым. Ай-һай, бу уку дигәннәре!

Укытучым алып карады.

— Булган бу,— диде,— булган! Менә инде яза да беләсең, егетем.

Әби дә атылып килеп җитте.

— И,— диде,— мин дә шулай яза белсәмче, карачы, бабасы...

Бабай күзлеген борын очына гына атландырып куйды. Кәгазь битен үзеннән ераграк тотып, алга сузды да: «Прәме, килештергән бу малай,— диде.— Өй тирәсендәге читән шикелле булып чыккан. Казык саен, әнә чыпчыклар кунып тора».

— Чыпчык түгел, «А»,— дидем мин.

— Мин дә шулай дип әйтәм ич, улым.
Бабай мине аркамнан чәбәкләп сөйде. Тырыш, балакай, тырыш, диде. Түбәм күккә тиде, әнә, яза беләм икән лә мин. Яза беләм!
Хәниф абый миннән дә бигрәк шатлана. Йөзе гөлт иткән. «Шәкертем бик уңган булып чыкты бит әле,— ди. Самый главный хәрефне үзләштерде. «А»— иң олы аваз! Калганнары берни түгел». Симәнке чирткән кебек кенә булыр, янәсе.



## Мин әле сукыр булганмын

Шул көннән алып китте, китте безнең укулар. Һәр көнне бер хәреф язарга өйрәнәм. Авызымны зур итеп ача-ача, телемне вата-сындыра кычкырып укыйм. Аннан соң тезеп язып чыгам. Кичен мөгаллимем тикшерә, тагын авазлар кычкырттыра.
Йоклаганда төшләремә дә керә. Кәкре-бөкре хәрефләр күз алдымда биниләр. Кайчак мин: «А-ба-га»,— дип кычкырып уянам. Хәниф абый көлә.— Беләсеңме, син нәрсә әйттең?— ди.— А-ба-га, дидең. Абага ул — урманда үсә торган үлән исеме. Менә шулай хәрефләрне бергә кушып әйтсәң, сүз килеп чыга,— ди.
Кызык икән.
— Син тагы «А» хәрефенә нинди исемнәр беләсең?
— Арба, ат!
— Дөрес, инде син арба белән ат рәсемен дә төшереп кара әле. Булдыра алырсыңмы икән?
Бәлки әле мин бу эшкә тиз генә тотынмаган да булыр идем. Әмма элегрәк минем өй стеналарына я күмер, я кызыл таш белән кәҗә, куян, шалкан рәсемнәре сызгалап йөргәнем бар иде. Болай гына, зәвык өчен генә. Шуның өчен миңа шактый эләккәне дә булды. Инде ул гадәтемне онытып килә идем. Ә Хәниф абый үзе рәсем ясарга куша. Нәрсә ди бит, булдыра алырсыңмы, имеш? Гарьләндерде.
Арбаны мин бик тиз төшердем. Өстенә берничә «А» хәрефләре тезеп бастырдым. Янәсе, шул хәрефләрне арбага төяп каядыр илтә баралар. Уйландым, арбасы булгач, аты да кирәк ич аның. Атны да арба янына төшереп куйдым. Хәниф абый рәсемне алып карады. Көлеп җибәрде.
— Син бит, энем, атны башартка җигеп куйгансың. Шәйлисеңме?
— Ул печән ашап тора,— дидем.
Бу юлы укытучым үзе дә көлкегә кала язды.
Шулай итеп, мин һәрбер хәрефкә тиешле үз рәсемнәрен дә ясый тордым. «Б» хәрефенә — балта, «к»га — кашык, «ч»га — чәйнек. Баратора минем «Әлифба»м төрле-төрле рәсемнәр белән тулды.
Укытучым шатланып туя алмый. Башымнан сыйпый-сыйпый иркәли.— Сиңа укырга кирәк,— ди.— Укырга сәләтең бар синең.
— Укыган таш яра,— ди бабай да. Ул шулай сүз арасына сүз кыстырырга ярата.— Менә безнең шикелле күзле сукыр булып кала күрмә.
Бабай кайчакларда үзе дә минем «Әлифба»ны алып караштыргалый. Башын селкеп куя.
— Кара әле, карчык,— ди,— бу малай чәйнекне ничек матур итеп төшереп куйган, самавыры тагын, балтасы, кашыгы дисеңме, үтә китереп төшергән.

Беркөнне әби дә «Әлифба»ны кулына алды, битләрен актарды. Борынын кәгазьгә төртә-төртә нәрсәдер эзләнде. Үзе сөйләнә торды. «Кеше сурәтен төшермәдеңме, улым?— ди.— Ярамый, язык була. Теге дөньяда синнән җан сорап килер. Син мине ясадың, инде җан да бир дип әйтер».
Хәниф абый шаркылдап көлде. «Теге дөньяда җанны бирүче дә, алучы да булмас,— диде.— Ә менә бу дөньяда күпме җан әрәмгә чыкты, күпме корбан бирдек без бу дөньяда?»

— Юкны сөйләмә, карчык,— диде бабай әбигә ачулы караш ташлап.— Бала күңеленә әллә нинди шомнар салма.

Бабай әби кулыннан минем «Әлифба»ны алып миңа китереп бирде.

— Бер дә курыкма, менә минем рәсемне дә төшер. Мин «Б» хәрефенә туры киләм бугай,— дип көлә-көлә үз урынына барып утырды. «Син тик кенә тор»,— диде, әбигә баш бармагын селкеп.

Чыннан да, әби тынып калды. Үз карты белән бәхәсләшми иде ул. Бабай кайчак шулай кырт кисеп куя. Ә мин үрә сикерергә әзер. Миңа канатлар үсә шикелле. Болай булгач, бабайның рәсемен дә ясармын, «Ә» хәрефенә әбине дә төшереп куярмын. Кызык булыр.

Ә хәзер укырга әле, укырга! Дәресләр дәвам итә. Ләкин кайбер көннәрдә туйдыра. Кәефем бозыла. Кабат әниемне сагына башлыйм. Укыйсы килми, эчем поша. Язган чакта хәрефләрем дә кыек-мыек булып чыга. Сүзләрне дә яртылаш кына әйтәм, калган өлешләрен авызымнан чыгармыйча гына чәйни-чәйни йотып җибәрәм кебек.

Хәниф абый миннән теге шигырьне кабат-кабат укыттыра.

— Күрәсеңме, нәрсә әйткән Тукай абыең,— ди.— Сиңа әйткән ул. Тырышып укырга кушкан. Ә син борын салып утырасың.

Аңлыйм мин моны, бик аңлыйм. Ә менә күңел белән нишләргә соң? Әниемне оныта аламмы соң мин! Исемә төштеме, аштан калам, төн йокыларым кача. Мин шулай «кәҗәләнгән» чакларымны безнең өйдә беләләр. Башта матур сүзләр әйтә-әйтә юатып карыйлар. Мин аның саен киреләнә барам. Елыйм. Аннан соң орышалар:

— Тапкан эш, көн саен әни дә әни дип өзгәләнә. Безне кызганмыйсыңмыни? Син бит болай безнең йөрәкләргә дә ут саласың, шул хакта уйлаганың бармы?— диләр.— Хәзер дөньяның әнә нинди чуалган чагы. Кем кая китмәгән, дә, кем кемнән аерылмаган? Кайгырма, үз вакыты белән синең әниең дә кайтып җитәр. Бел дә тор менә.

Бүген дә минем кәефем начар иде. Хәниф абый тиз сизеп алды. «Укыганда күңелне төшермиләр,— диде.— Кайгы зиһенне тарката. Менә язга таба укырга-язарга тәмам өйрәнеп җитәрсең. Ә аннан соң үзең, үз кулларың белән әниеңә хат язарсың. Аның исе китәр, минем улым миңа хатын үзе язган,— дип шатланыр.

И Хәниф абый, рәхмәт сиңа, күңелемне ачып җибәрдең син минем. Мин бит әле бу турыда уйлаганым да юк иде. Каян исеңә төште.

Шул минутта мин иң беренче кабат шатлыкның нәрсә икәнен белдем. Үзем дә сизмәстән: «Әниемә хат язармын, хат язармын!»— дип кычкырып җибәрдем. Йокымсырап утырган әби сискәнеп уянган төсле итте.

— Миннән дә сәлам куярсың,— диде.— Миннән дә!

— Бабайдан да,— дидем мин.

Ә бабай кых-кых итеп көлде. «Хат ул аяксыз илче, тавышсыз хәбәрче,— диде.— Хат дөнья гизә. Аңа киртәләр юк». Димәк, минем әниемә хат барып җитәр. Хатка киртә юк икән. Шатланам. Шатланам, тагы да тырышыбрак сабак укырга ябышам. Ашарга утыргач та өстәлдәге әйберләргә карый-карый исемнәрен әйтәм.

— «И»— әнә икмәк, «к»— әнә кашык, «п»— пычак,— дип сөйләнеп утырам.

Әби куркынып куя. Бер миңа, бер Хәниф абыйга күз ата.

— Кара әле, иптәш мөгаллим,— ди,— әллә синең шәкертең акылга җиңеләеп барамы? Күп укыган кешенең зиһене зәгыйфьләнә диләр бит. Әллә мәйтәм...

Әби кинәт кенә учы белән авызын каплады. Тагын әллә нинди килешмәгән сүзләр әйтеп, көлкегә калуым бар, дип курыкты шикелле. Ә мин төшендем: әллә юләрләнәме бу малай димәкче иде бугай.

И кадерле әбием, борчылма, мин бит шулай укырга, хәрефләр ят-

ларга өйрәнәм. Бер аваз әйтсәм, бер адым алга атлыйм кебек. Бер адым саен әле мин белмәгән, күрмәгән аллы-гөлле чәчәкле дөньяга керә барам төсле. Син дә шатлан, әбием!

## Күңелем адарына



Кар бер эреп бетә, бер яңадан ява. Кайбер көннәрдә җилләр исә. Төннәрендә бураннар улый. Кыш шулай әкрен генә уза тора. Ә без көн саен сабак укыйбыз. Хәзер инде мин сүзләр дә яза беләм, укый алам. Тик менә китаплар гына юк әле бездә. Китапларда нәрсә язылa икән? Укып карыйсы иде тизрәк. Күңелем адарына.

Әле бит әниемә хат язасым да бар. Ә хатны ничек язалар икән? Бик авыр эштер ул. Хат кадәр хатны теләсә кем яза да белмидер әле. Әллә Хәниф абыйдан сорап карыйсымы? Куркам, тагын ул: «Ашыкма»,— дип әйтер.

Мин өстәл янында менә шулай уйланып утырам. Бабай кырынып маташа. Әби керләр уа. Хәниф абый, яралы аягын җылы суга тыккан да, авыз эченнән генә нәрсәдер көйли-көйли мыгырдана. Менә ул миңа карады да: «Күрәм, эчең поша, ахры, синең, малай,— диде.— Карандашыңны иплән кенә очла да, кәгазеңне алдыңа куй. Хәзер үзебез китап язабыз».

— Китап язабыз?

— Әйе, китап язабыз. Нигә исең китте?

Юк, моңа мин генә гаҗәпләнмәдем. Әнә, бабай да башын як-якка боргалап алды. Булдыра алырсыз микән, ди бугай.

Әби дә черкелдәп көлде:

— Языгыз, яз,— ди,— безгә дә укып күрсәтерсез. Нәрсә килеп чыгар икән?

Сизәм, болар шаяртып сөйләшәләр. Мин көтәм, Хәниф абый нәрсә әйтер? Әллә ул да болай гына, сүз юктан сүз булсын дип кенә кылындырамы? Бу малай боекмасын диме? Юк, аның йөзе бик житди иде. Тәрәзәгә күз йөртеп алды. Түшәмгә карады.

— Я, башлыйбыз,— диде.

— Ничек башлыйбыз соң, Хәниф абый?

Укытучым әйтте:

— Син кичә йокыдан кайчан тордың?

— Иртә белән, әбием уятты.

— Менә шулай яза кит: иртә белән мине әбием уятты, диген.

Мин әле ышанмый торам. Китапны шулай яза башлыйлар микәнни?

— Яз, яз,— диде Хәниф абый.— Нигә миңа тәкә шикелле карап торасың. Бер генә дә шаярмыйм, чынлап әйтәм. Китапларның күбесен иртәнге сәгатьтән яза башлап китәләр.

Болай гына була ул, дип уйладым да, карандашымны кысып тотып эшкә керештем. «Мине әбием иртә белән уятты»,— дип язып куйдым.

— Ярый,— диде укытучым,— ярый. Бусы булды дип әйтик. Йокыңнан торгач тагын нишләдең?

— Битемне, кулларымны юдым...

— Анысын да яз.

— Аннан соң чәй эчтек...

— Анысын да онытма, барысын да тезеп чык. Соңыннан безгә кычкырып укырсың.

Борчылган идем. Китапны әнә ничек кенә язалар икән! Төшендем. Яза-яза өстәлгә бөкрәеп иелдем. Башымны кашып алдым. Маңгаемны сыпыргалаштырдым. Борыным белән кәгазьгә төртелеп-төртелеп киттем. Карандашымны да авызыма кабып суыра-суыра имдем. Хәниф абый шикелле түшәмгә дә карапып тордым. Өйдәгеләр эндәшмичә генә уты-

ралар. Язсын, диләр бугай, тыгызламыйк әле. Уен эш түгел ич, китап яза!

Шактый вакыт узды. Мин инде «китабымны» язып чыккан идем. Әмма язган шикеллерәк утыра бирдем. Бетердем, дисәм, миңа үземә үк укырга кушачаклар. Ә мин оялам. Бәлки көләрләр. Бәлки, булмаган бу, дип тә әйтерләр. Кая кереп кысылырга урын тапмассың. Нишләргә?

Урынымнан сикереп тордым да: «Мә, Хәниф абый, үзең укы» — дидем. Үзем кабат өстәл янына килеп йөзем белән түбән капланып утырдым. Сулышларым кысылды. Битемә ут капты сыман. Җир астына убырылып төшермен төсле иде. Хәзер минем язмамны Хәниф абый кычкырып укый башлар. Мин үзем язган сүзләрне ишетеп торырмын. Минем үз тавышым да яңгырар сыман.

Өйдә тынлык. Бабай да колакларын торгызган. Башын сузган. Әбине әйтмим дә инде. Хәниф абый каршысына ук килеп утырган. Хәтта стенага эленгән бишмәтләр дә, бүрекләр дә, үги этинең иске туны да, тыңлыйк әле, тыңлыйк, дип пышылдыйлар кебек. Мич янында солдат кебек кәперәеп торган самавыр да, савыт-сабалар да минем сүзләрне тыңларга җыенганнар диярсең.

Болай буласын белсәм, «китап» язып маташыр идемме соң мин? Әрәм булам ич хәзер мин, әрәм булам... Бармак араларыннан гына карап куям. Хәниф абый ашыкмады. Башта кәгазь битен иркәләгән кебек итеп сыйпаштырды. Өстән аска кадәр күзәтеп чыкты. Елмайды.

Миңа шул гына кирәк тә иде. Эчемә җылы керде. Тынычлана төштем. Укытучым юкка елмаймый. Ул кадәресен генә беләм. Сынаганым бар. Хәниф абый әбигә дә, бабайга да ым какты.

— Тыңлагыз әле, нәрсә язган,— диде,— сезнең онытыгыз Сабирулла. Килештергән, ис китәрлек!

— Укы, укы,— диештеләр картлар.

Алар инде баядан бирле ашкынып көтәләр иде.

— Бу өйдә әле мондый могҗизаның булганы юк иде,— дип тә әйтте бабай.— Әйтсәң, кеше ышанмас.

Хәниф абый тамагын кырды. Ирен очларын сөртеп, бик тәмле бер нәрсә чәйнәп йотарга җыена иде кебек. Аннан соң тыныч кына укый башлады:

«Иртә белән мине әбием йокыдан уята мин битемне кулларымны юам аннан соң чәй эчәргә утырабыз бабай миңа икмәк кисеп бирә, әби чәй ясый, самавыр җырлап тора».

Бабай дәртләнеп куйды.

— Вәт молодис,— дип Хәниф абыйны укуыннан бүлдерде.— Килештергән бит тәки. Сүзләре дә нинди бит, сүзләре!

— Бүлдермә,— диде әби кычкырып.— Тәмен бозасың.

Хәниф абый көлә-көлә миңа карап алды. Тагын укырга керешге:

«Ашап эчкәч амин итәбез әби авыз эченнән генә нәрсәдер сөйләнә бабай аллага шөкер аллага шөкер ди тамагыбыз туйды ди...»

Бу юлы әби үзе дә сүзгә катнашмыйча булдыра алмады:

— Дөрес, бик тә дөрес язгансың, улым. Нәнием минем,— диде.— Рәхмәт төшкере. Амин итми тамак туймый, ризыкны җеннәр йотып бетерә юкса.

Әби әле тагын нәрсәдер әйтергә теләгән иде дә өлгерә алмады. Хәниф абый аны бүлдерде:

— Карагыз әле, нәрсәләр генә язып бетермәгән безнең шәкертебез биредә? Болай гына, уйнап кына башлаган идек ләбаса, ә ул әнкәсенә хат язып чыгарган.

— Хат? Гаҗәп эш,— диде бабай.

— Әйе, әйе, хат язган. Чынлап әйтәм, менә дигән хат булган бу. Ноктaларын, өтерләрен дә үз урыннарына куеп чыксаң — шаккатырлык!

Алары нәрсә тагын? Ноктaлар, өтерләр? Хәниф абый кулына ка-

рандаш алып язып күрсәтте. И, дидем мин эчтән генә, бер генә дә авыр түгел икән. Карандаш очы белән бер төртәсең дә, бер бөтереп кенә аласы.

Ә мөгаллим әйтә: «Бу авыр, бик авыр эш. Хәтта кайбер галимнәр дә тыныш билгеләрен куйганда саташып бетәләр»,— ди.

Мин өстәлдән башымны күтәрдем. Хәниф абыйга текәлеп карадым. Әллә шулай көләме ул миннән? Хат яза беләмме соң әле мин? Юк, укытучымның йөзе җитди. Һич кенә дә көләргә җыенмый.

Менә ул яңадан укырга керешә. Нигәдер аның тавышы калтыранган төсле иде. Сүзләрне дә тотлыга-тотлыга әйтә. Әллә аның су эчәсе киләме? Бармаклары да дерелди. Минем «хат» дигән кәгазь кисәге кош баласы кебек аның кулларыннан очып китәргә җыена шикелле.

Хәзер мин дә Хәниф абый белән бергә үзем язган сүзләрне укып барам сыман.

«Без әлеге бик яхшы яшибез бабай да әби дә мине бик яраталар күзләремә генә карап торалар әби миңа яңа күлмәк белән чалбар тегеп кидерде мин зур үстем инде әле тик мыеклар гына чыкмый тора әх әнием син дә безнең янда яшәсәң нинди күңелле булыр иде бик сагындым үги әти дә гел исемә төшә кайчан кайтып киләсез инде безнең хуторга кызыл әләм элделәр бандитларны кырып ташладык бездә аксак солдат яши Хәниф абый исемле ул мине укырга өйрәтте мин инде яза да беләм бер генә дә еламыйм тизрәк кайт әнием».

Хәниф абый укуыннан тукталды. Ә мин инде үкси-үкси елап утыра идем. Тавышым чыкмый, сулкылдыйм. Күз яшьләремне йота барам. Бәлки, күрмәсләр.

Юк, моны мин үзем язмаганмын, моны нindидер башка бер ятим бала язган кебек тоелды миңа.

Өйдә тынлык. Хәниф абый да минем язуны кулына тоткан килеш уйга калып утыра. Башын түбән игән. Әби яулык чите белән әледән-әле күзләрен сөртә. Бабай сакалын бөтереп авызына капкан. Ул да эндәшми. Бу минутта безнең өйдә нindидер кайгымы, нindидер шатлыкмы булды сыман.

Укытучым минем яныма килде. Йөземә озак карап торды. Аннан соң язуны минем алдыма җәеп салды да:

— Чын хат язгансың бит син, Сабирулла,— диде.— Әниең укыса, шатланып туймас иде.

Мин укытучыма сыендым. Аның кулларын йөземә куйдым. Тынып тордым. Бу шатлыгымны мин әле сүз белән яза да белмим, тел белән әйтә дә белми идем...

Ул көнне мин гел сагынып искә алам. Күпме еллар үтсә дә, онытылмый ул көн. Күзләремнән агып чыккан яшь тамчылары минем алдымнан нindидер караңгылыкны юып төшерделәр сыман. Миңа дөньяның бер якты тәрәзәсе ачылды да, шуннан барасы юлым күренеп тора иде кебек. Ә ул юл мине кая алып барыр икән?

## Көтелмәгән хәбәр

Кояш көннән-көн кызурак яктыра. Инде беренче язгы яңгырлар да сибәләп узды. Анда-монда беренче чәчәкләр дә күренә башлады. Безнең тәрәзә каршындагы теге «хөрмә» тирәге дә ботакларына яшькелт бөреләрен тезеп куйды. Кайчак җил исеп китә дә, ул йокысыннан уянган төсле итә. Тәрәзәгә кагыла. «Исәнмесез, саумысыз?»— дип әйтә сыман.

Дөрес, иртә белән этәчләр кычкырмый әле. Әмма көзгә таба аларның тавышларын да ишетербез. Кош-кортны үрчетергә күп кирәкмени? Йомырканы җылырак урынга, яки бүрек эченә салып куйсаң да, атна-ун көн эчендә чебиләр бәреп чыга. Әнә, безнең өйдә дә бер тубал чебиләр

чөрелдәшә. Миңа да эш артты. Су эчерәм, җим сибәм аларга. Ул сапсары нәниләр кечкенә генә туп шикелле төрле якка коелышып тәгәрәптәгәрәп китәләр. Сикерешеп-сикерешеп өстемә куналар, башыма менәләр. Карандаш очы кебек кенә томшыклары белән битемне чукыйлар. Күзләремә үреләләр. Миңа күңелле.

Бу чакта инде бабай кырга чыгып киткән була. Әби өй тирәсендә кабаланмый гына түтәлләр казый. Башка йорт яннарында да хатынкызлар кайнаша. Алар да кишер, суган чәчәләр, бәрәңге утырталар. Бездә яз ел саен шулай башлана.

Хәниф абыйның да аягы төзәлеп килә. Ул инде бер таягын бөтенләй кулына алмый. Тиздән дөбердәтеп йөрермен, ди. Яз анын да күңелен кузгатты. Йөзе дә яшәреп китте сыман. Хәзер ул елмаеп кына сөйләшә. Озакламый үз авылыма кайтып китәрмен, ди дә сөенеп туя алмый. Ә мин борчылып уйланам, ул киткәч миңа бик күңелсез булыр инде дим. Бездә генә калса ни була? Яшәр идек әле, кем тыгызлый безгә? Әнә бит, Хәниф абый үзе дә нәрсә ди:

— Биредә дә калып яшәргә мөмкин булыр иде. Кем дә тыгызламый. Әмма йөрәк кушмый. Үз авылымда мине бик якын кешем көтә торгандыр...

Нигәдер ул шунда моңаеп та куя. Озак кына эндәшми утыра. Сагышлана, күрәсең. Ә миңа һаман язарга, рәсем ясарга куша.

— Укы, Сабирулла, укы, өйрән,— ди.— Хәзер дөньяга укымышлы кешеләр кирәк. Күп кирәк алар, күп!

Беркөнне өйдә берүзем генә калган идем. Бер ялгызым тик кенә торып буламы соң? Эчем поша башлагач, әби киштәсендә актарынырга керештем. Әби анда үзенең коръәнен ап-ак ефәк чүпрәккә генә төреп тота иде. Ул аны беркем кулына да бирми, мине дә бабайны да якын да китерми. «Мондый изге китапны сезгә түгел, мулла кулына да бирәчәк түгелмен,— ди торган иде.— Муллаларның да ниндиләре булмый».

Белмим, әби үзе ул китапны укый ала иде микән? Күргәнем булмады. Күңелдән генә ниндидер сүрәләр әйтә дә, коръәндә шулай язылган, ди торган иде.

Мин ефәк төенне курка-курка гына сүттем. Менә алдымда күн тышлы, гаҗәп зур, калын китап. Мин аны чак-чак күтәреп, тәрәзә каршына алып килдем. Әкрен генә беренче битен ачтым. Көч-хәлгә хәрефләрен укымакчы булдым. Юк, хәрефләр генә түгел болар, бер-берсенә тоташтырып үреп-үреп куйган чәтрекле бизәкләр шикелле. Өскә, аска әллә нинди билгеләр тезеп чыкканнар. Гаҗәпләндем: кешеләр бу китапны ничек укыйлар икән? Тырыша торгач, ниндидер сүз килеп чыкты. Әмма ул татарча түгел иде. Изге китап әнә нинди була икән, дидем мин үз-үземә. Укыйсың, аңламыйсың. Менә бу кызык иде.

Коръәннең тагын берничә битен ачтым. Кинәт шунда бер язу килеп чыкты. Бу нәрсә икән? Язуны кулыма алып әрле-бирле әйләндергәләдем дә укырга керештем. Әмма тиз генә таный алмый газапландым. Хәрефләре кәкре-бөкре, бер өскәрәк чыгып, бер түбәнрәк төшеп торалар. Кемдер әллә ашыгыпмы, әллә бик үк оста яза белмәгәнлектәнме, сүзләрне бер караудa гына укырлык итмәгән.

Тырыша торгач «хат башы» дип язылган сүзләрне, хәрефләрен кабат-кабат әйтә-әйтә көч хәлгә укып чыктым. Шунда ук төшенеп алдым. Бу — каяндыр әбигә килгән хат иде. Шатландым. Мин дә иң тәүге кабат кулыма хат тотып укый алам менә!

Хатны әнә ничек яза башларга икән. Менә хәзәр беләчәкмен. Чын хат укыйм ләбаса! Хәниф абый күрсә, ул да шатланыр иде. Шәкерте әнә нишләтә...

Күзләрем белән чәнчелеп карый-карый хәрефләргә күнегеп җиттем. Бик кызу булмаса да хатны әкрен генә укый башладым.

«...Сезки хөрмәтле Гатаулла абзыйга, вә янә дә Халимә апага, вә янә дә Сабируллага күптин күп сәламнәр күндерәм...»

Ничек куанмыйсың? Миңа да сәлам язганнар бит. Мин дә кеше рәтенә кергән хәзер. Зур үскәнмен, димәк. Тагын нәрсә язганнар икән. Укыйм әле, укыйм. «Мин исән-сау гына авылга кайтып җиттем. Туганнарым белән күрешергә алла насыйп итте».

Тукта, кем соң ул «мин» дигән кеше? Тизрәк беләсем килде. Хатның соңгы юлларына күз төшердем. Анда: «Бу хатны язучы Заһир дип белерсез»,— диелгән иде. Әһә, белдем, теге вакытта төнлә белән безгә кереп чыккан солдат Заһир абый икән. Әнә, ул авылга кайтып та җиткән.

Хатны тагын укырга керештем: «Шуннан соң да сезгә бу хат белән хәбәр итәм, авылда совет сайлап куйдык, алпаут Мусин качкан дип. Шуннан соң да хәбәр итәм, авылда тормышлар авыр. Корылык дөньяны көйдерде дип. Кырларга саранча явы ябырылды. Күп кешеләр чит якларга таралышып беттеләр дип.

Шуннан соң да тагын хәбәр итәм, Җамалия апа зәхмәтле сырхаудан вафат булды дип. Шуның кайгысыннан Хәйрулла агай телдән калды, дип. Кул-аяклары да селкенмәс булып, урында әҗәл көтеп ята дип...»

Башта бу сүзләрне мин аңламыйчарак укып уздым бугай. Кем соң ул Җамалия апа? Чү, әнием ич ул минем! Хәйрулла — минем үги əти!

Шул минутта мин коелып, бөтен гәүдәм белән шиңеп төштем. Кәгазьдәге хәрефләр терелешеп киттеләр дә, ут кебек янып күзләремә керделәр шикелле. Аннан соң алар йөрәгемә барып кадалдылар сыман. Мин сукрайдым төсле. Бернәрсә дә күрмим, бер нәрсә дә аңламыйм. Хат эченнән кемдер: «Әниең үлде, үлде!»— дип кычкыра, кемдер мине буа шикелле. Юк, хатны артык укый алмадым. Бөтен көчем белән кычкырып елап җибәрдем.

Өйдә беркем дә юк. Миңа куркыныч. Арлы-бирле йөренәм. Күзләремнән шыбырдап яшь ага, авызыма керә. Йотам, эчемдә ут тагын да көчлерәк дөрли шикелле.

Инде нишләрмен? Кая барырмын? Юк, ышанасы килми бу авыр хәбәргә; ышанасы килми. «Булмас, ялган!»— дип кычкырдым. Шунда кемдер, әллә почмак артыннан, әллә сәке астыннанмы: «Дөрес бу хәбәр, дөрес»,— дип миңа каршы тавыш салды кебек.

Әнә, күз алдымда Заһир абый күренә. Иркәләмәкче булып мине кочып алмакчы. Мин читкә тайпылам. «Юк, юк, ялганлыйсың син, ялганлыйсың,— дим.— Әнием үлмәгән, үлмәгән».

Шулчак ишек ачылды. Өйгә Хәниф абый килеп керде. Мин аңа атылып барып сырыштым.

— Әнием үлгән, әнием үлгән,— дидем үксеп елый-елый...

— Чү, чү энем, нәрсә сөйлисең, кем әйтте, кайчан?

Хәниф абый мине кочып алды.

— Тынычлан, тынычлан, балакай,— диде.— Нәрсә булды, кайдан ишеттең?

Минем инде сөйләшергә хәлем юк иде. Өшеп киттем, калтырандым. Хәниф абый мине тапчанга яткырды, өстемә юрган япты.

Минем кулдан хатны алып, янәшәгә утырды. Тиз-тиз хатны укып чыкты, башын түбән салды, сүзсез генә уйланып торды. Күзләрен уды.

— Шулай икән шул, энем,— диде.— Шулай икән. Менә бәла, бер дә көтмәгәндә...

Хәниф абый минем йөземә карады. Башымнан сыйпады. Нәрсә әйтергә дә сүз табалмыйча озак уйланып торды. Ә мин дерелди-дерелди һаман елый бирдем. Бу елаудан инде беркайчан да туктый алмам кебек иде.

— Минем дә әнием, әле мин биш яшьтә чакта ук дөнья куйды,— диде Хәниф абый уфтанып.— Мин дә бик иртә ятим калдым. Андый авыр хәлләр гел булгалап тора, Сабирулла. Язмыштан узмыш юк, дигәннәр олылар.

Хәниф абый аксый-аксый барып чиләктән салкын су эчте. Миңа да китерде.

— Мә, эчеп җибәр, җан кызуларың басылып китәр...

Эчтем. Әмма су җып-җылы иде кебек. Тәме дә әллә нинди әчкелтем.

— Ятим идем шул мин дә,— диде Хәниф абый тагын сүз башлап,— әмма, күрәсеңдер, нужага бирешмәдем. Тырыштым, укыдым, үзем дә укытучы булдым. Син дә өзгәләнмә, энем, түзми нишлисең? Андый кайгылар кемгә килеп китми? Үлем-түшем кайда гына булмый.

Юк, бу сүзләр генә мине юата алмадылар. Үлемне оныттыра торган сүз бармы? Андый сүз юк. Мин моны менә бүген, менә хәзер белдем.

— Кайчан килгән соң бу хат?— дип Хәниф абый хатны яңадан караштырды. Авыз эченнән генә укыштырды.

— Юк, елы да язылмаган, көне дә куелмаган,— диде.— Оныткаңнар, күрәсең.

Без тагын, уйга сабышып, сүзсез калдык.

## Кайгы онытыламы?

Менә әби белән бабай да кайтып керделәр. Әби өстәлдә битләре як-якка ачылып яткан коръәнне күреп алды.

— Бу ни эшегез,— диде ачулы күзләре белән безгә карый-карый.— Кем минем изге китабымны урыныннан кузгатты, кайсыгызның кулы җитте?— Үзе коръәнне кысып алып күкрәгенә кысты.— Шапшаклар, кулларыгыз да юылмаган, тырнакларыгыз да кисмәгән сезнең. Гөнаһын кая итәрсез?

Ә мин урынымнан сикереп тордым да әбигә йөгереп килеп чытырдап ябыштым.

— Әнием үлгән минем, әнием үлгән, үги әти дә телсез калган. Инде нишләрбез?

— Кем әйтте, каян ишеттең?

— Менә биредә язылган,— диде Хәниф абый, кулындагы хатны күрсәтеп.

Әби хатны тартып алды.

— Син үзең укып бирдеңмени балага? Аз гына уең бармы синең, мөгаллим?

— Үзем укыдым, әбием,— дип кычкырдым мин.— Үзем укыдым...

— Үзең?

— Үзем!

Әби урындыкка лып итеп утырды. Кемдер аның тез астына китереп сукты сыман. Түсе китте. Коръән битләрен ачкалап-ачкалап карады. Нәрсәдәр эзләнде.

— Балакаем,— диде мине кочаклап,— гафу ит, юләр әбиенне, мин гаепле, мин! Теләсәң менә ак чәчләремне йолкы, кулларымны тешлә. Мин риза.

Әби елый-елый тагын сөйләп китте:

— Бу хатны без инде күптән алган идек...

— Нигә миңа әйтмәдегез?

— Курыктык, улым, курыктык, йөрәгеңә авыр булыр дидек. Син бит әле бик кечкенә. Мондый авыр хәбәр олыларның да башын агарта, буыннарын сындырып сала.

Әби үзе дә иелеп калды. Куллары белән башын тотты. Нәрсәдер әйтә торды, әмма сүзләре аңлашылмады.

— Дөрес әйтә әбиең,— диде бабай.— Бу хатны без үзебез дә әле күптән түгел генә берәүдән укытып алган идек, улым Сабирулла. Без ул көннәрдә күпме яшь койганыбызны үзебез генә беләбез, олан. Кан йоттык. Сиңа сиздермәскә тырыштык...

Исемә төште. Мин бит ул чакта нәрсәдер сизенгән идем. Әмма мондый кайгылы хәбәр ишетермен дип һич кенә дә уйламаган идем. Хәтерлим, бервакыт әби дә, бабай да нигәдер сагышланып йөри башладылар. Үзара сирәк кенә сөйләшәләр. Миңа карыйлар да уфтанып куялар. Ашау-эчүгә дә талымнары бетте. Йоклаганда да сырхау кешеләр кебек авыр ыңгырашып бер уяналар, бер сызланалар иде. Белдем. Алар әнә шул хатны укып, миңа сиздермичә генә кайгырышканнар икән. Ә хәзер алар минем белән бергә елыйлар...

Хәниф абый нәрсә әйтергә дә белми тора. Таягына таяна-таяна идән буйлап йөренә. Яңадан утыра. Ул әле нәрсәдер көтә шикелле. Мин дә көтәм. Бәлки, Хәниф абый:

— Юк ла, әниең үлмәгән, үлмәгән. Кемдер шаяртып кына язгандыр,— дип әйтер дә, хатны ерткалап мичкә ташлар.

Юк, ул алай әйтмәде.

— Бер нишләр хәл юк, Сабирулла,— диде,— Елап кына үлгәнне терелтеп булмый. Әнә сугышта да күпме кеше үлеп калды. Аларның да синең кебек уллары булгандыр. Авыр, бик авыр еллар.

— Авыр гынамы соң, Хәниф туган,— диде әби.

Хатны яңадан коръән эченә салып куйды: «Аның урыны биредә. Мәрхүмәнең кабер туфрагы җиңел булсын. Амин!»— диде.

Бабай өстәлгә самавыр мендереп утыртты. Әби каяндыр актарынып прәннекләр, конфетлар чыгарып куйды.

— Утыр, балам, чәй эчик, күңелең бераз тынычланып китәр. Эчеңә җылы керер. Әнә ничек агарып калгансың...

— Әйе шул,— диде бабай да,— утырышыйк, Җамалия истәлегенә амин итик.

Хәниф абый алдыма чәй ясап куйды.

— Мондый чакта чәйдән дә шәп нәрсә юк,— диде.— Сулышны киңәйтеп җибәрә.

Алар шулай мине юатырга телиләр иде. Ә минем бер нәрсәгә дә кулым бармый. Чынаякны тотып авызыма китермәкче идем дә, ул да кылтыр-кылтыр итә-итә кулымнан төшеп китте. Юк, миңа хәзер бернәрсә дә кирәкми. Хәзер мин үзем дә беркемгә кирәк түгел. Мин бөтенләй ятим.

Хәниф абый урын түшәде.

— Кил, энем, йокларга ят,— диде,— Әнә, инде төн җиткән. Кайгыны кайгырып кына җиңеп булмый. Ул нәләт йөрәккә бер килеп ябышса, елан шикелле канны суыра.

Йокларга яттык. Хәниф абый мине кочаклап алды. Мин чатырдап аңа сырыштым. Шулай итсәм, минем йөрәгемә теге елан кереп алмас кебек иде.

Йоклыйммы, йокламыйммы — үзем дә белмим. Саташам. Авылга кайттым кебек, әниемне дә күрәм шикелле, менә мин аңа таба йөгерәм, имеш, ә ул миннән ераклаша бара. «Хуш, улым»,— дип кул болгый. Мин: «Әнием, тукта, тукта!»— дип кычкырам. Уянып киттем. Өстемнән юрганымны алып ташладым, өйдә ут алганнар иде. Карасам, бабай минем каршыма ук килеп баскан. Хәниф абый яныма утырган. Әби кулына чынаяк тотып тора.

— Эч, балам, эч,— диде,— хәл керер үзеңә, төн буе саташасың.

Юк, эчмим. Куркам мин ул «үлән суыннан». Исеннән үк күңелем болгана, укшыта. Тагын елый башлыйм. Тагын йоклап китәм, тагын саташам...

Иртә белән мин инде урынымнан кузгала алмадым. Башым авырайган. Гәүдәм тапчанга ябыштырып куйган шикелле иде. Күзләремне як-якка йөртәм. Эндәшмим.

— Болай булса мин дә озак яши алмам,— диде әби.— Мин дә кайгыдан үләрмен, ахрысы...

Бабай да тавыш салды:

— Ә мин нишләрмен синнән башка? Кая барырмын бу картлык көнемдә? Миңа да үләсе генә кала.

— Миңа да тизрәк китәсе булыр,— диде Хәниф абый да.— Китәсе булыр. Нишләрмен сездән башка?

Уйга биреләдем. Ә мин ничек яшәрмен? Әби дә, бабай да булмаса, Хәниф абый да китеп барса? Юк, миңа болай ятарга ярамый. Мин торырга тиеш.

Мендәрдән әкрен генә башымны күтәрдем дә:

— Әбием, бир теге даруны, эчәм,— дидем.

Әби йөгереп килеп җитте. Кашык белән тиз-тиз авызыма үлән суы салды.

— Тагын,— дидем.

— Эч, эч,— диде бабай шатланып.— Эч, улым. Әбиеңнең кулы шифалы. Хәзер терелеп китәрсең.

— Әби булдыра ул,— диде Хәниф абый да.— Әнә минем ярамны ялт иттерде.

Мин әкрен генә торып утырдым. Өстәлдә әле кичәге табын җыештырылмаган иде. Олылар үзләре дә аш-суга бармак белән дә кагылмаганнар, күрәсең. Кайгы шундый ул. Кешене тамактан калдыра.

Хәниф абый әйтеп куйды:

— Әле бит белеп булмый,— диде.— Бәлки, Сабирулланың әнисе бик каты авырып йокыга гына киткән булгандыр. Ә күршеләре аны инде үлгән дип уйлаганнардыр да тизрәк хат язганнардыр. Карасаң-торсаң, ул әле исәндер бәлки...

— Әйе, әйе,— диде бабай да,— андый хәлләр дә булгалый. Исеңдәдер, карчык, әле теге вакытта, без шахтада эшләгән чакта бер хатын күз ачмый ун көн йоклап ятты. Аны да башта үлгән дигәннәр иде. Хәтта кабер дә казып кайттылар. Ә ул үлгән дигән кешебез нәкъ унынчы көнне урыныннан сикереп торган да, көлеп тә җибәргән.

— Исемдә, исемдә,— диде әби.— Үзем барып күреп кайткан идем.

Мондый хәлләр, бәлки, кайчан да булса, кайсыдыр бер җирдә булгандыр, бәлки, булмагандыр да. Ләкин моңа ышанасым килде. Бәлки, чыннан да, минем әнием турында бу авыр хәбәрне Заһир абый ашыкпошык кына язып салгандыр. Бәлки, хат безгә килеп җиткәнче әнием үләр дип уйлагандыр.

Әле генә җанымны тетрәткән хат кинәт кенә юкка чыкты сыман. Әле ул язылмаган да, миңа әле килеп тә җитмәгән төсле иде хәзер. Әнием әнә шул «озак йокысыннан» уянып китте дә, яңадан күңелемә кереп урнашты. Мин аны шулай тере килеш йөрәгемдә саклап калдым. Аның белән кайчан да булса күрешермен кебек иде. Шул өмет кайгымны басты, тынычландырды мине.

Берничә көннән соң, Мохтар абый безнең ишегалдына ат җиккән арбада килеп туктады. Өйгә кереп тормады. Безне үз янына чакырып алды. Йортка чыктык. Мохтар абый тезгенне Хәниф абыйга тоттырды.

— Бу, сиңа, солдат,— диде,— синең бит әле ерак юлга чыгасың бар.

— Бөтенләйгә, миңамы?

— Бөтенләйгә, бөтенләйгә, Хәниф дус. Армиядән атлар кайтарттык. Алар өчен дә сугыш бетте. Иртәгә шул атларны җигеп сукага чыгабыз. Ә монысы сиңа, солдат, арбасы-ние белән.

— Сүз тидермәсләрме соң, иптәш комиссар?

— Тидермәсләр, язуы бар. Сиңа да штабтан документлар килде. Теләсәң бүген үк кайтып китә аласың. Хәер, анысы үз эшең, үз вакытыңа кара. Яраң төзәлеп беткән булса, ашыксаң да ярый. Хәрәкәттә бәрәкәт дигән картлар. Язгы җир, әнә, орлык көтеп тилмерә.

— Анысы шулаен шулай да, ничектер уңайсызрак кебек. Ат чәлдереп кайткан димәсләрме?

— Димәсләр, борчылма. Сиңа гына түгел, якын-тирәгә китүче башка солдатларга да атлар бирергә рөхсәт ителде. Сугыш бетте бетүен дә, иген чәчәргә дә кирәк бит әле.

— Аңлыйм,— диде Хәниф абый,— аңлыйм, иптәш комиссар. Кылычлы фронттан — сукалы фронтка, димәк...

— Дөрес.

Хәниф абый атны маңгаеннан сыйпады. Муенын чәбәкләде.

— Нихәл, солдат, яшәп буламы?— диде. Ат сүз аңлаган шикелле, башын чайкады. «Яшибез әле»,— дип әйтте сыман. Әле ул елмаеп та куйды кебек. Колакларын торгызды.

Шунда миңа авыр уй килде: тиздән Хәниф абый китеп барачак. Мине кем укытыр соң? Күңелсез булып китте. Хәниф абыйга карыйм. Ә ул бер генә сүз дә эндәшми. Өйдә тынлык, әби дә дисбесен тарта-тарта иреннәрен селкетеп тик кенә утыра. Нәрсә буласы икән бу өйдә? Мин нииндидер куркуга төштем. Тикмәгә түгел бу, тикмәгә түгел...

## Ирләрчә сөйләшү

Хәниф абый юлга җыена башлады. Вак-төяк әйберләрен капчыгына сала тора. Үзе ашыкмый гына сөйләнә.

— Рәхмәт, Хәлимә апа,— ди.— Мине аякка бастырдыгыз. Оныласым юк. Гомергә бурычлы мин сезгә.

— И таптың сүз, Хәнифулла, нинди бурыч булсын ди, каян килгән бурыч ул? Без кешеләр ләбаса, алла бәндәләре. Бер-береңә булышуыгыз эштер.

— Әйтмә дә,— диде бабай да сүзгә кушылып.— Сусаган кешегә су бирү бурыч буламыни? Син бит ярдәм сорап безнең өебезгә килеп кердең. Менә безне күрми генә узып киткән булсаң, үпкәләр идек. Таныштык, белештек. Туганлаштык дияргә дә ярый. Күңелебезгә хуш килдең. Үзеңә, солдат, мең рәхмәт!

Әби тагын эләктереп алды:

— Әнә, баланы укытып чыгардың, ул эш түгелмени? Карасаң-торсаң, без әле үзебез сиңа бурычлыбыздыр.

— Укытучы эше шундый, Хәлимә апакай. Теләсә кайчан, теләсә кайда да укытучы ул.

— Беләбез, һөнәрең — тормыш тоткасы, Хәниф улым. Мөгаллимнәр дөньяны агартучылар. Аларга рәхмәт сүзе дә әз, җиргә кадәр баш иеп сәлам бирү дә әз.

— Миңа бер рәхәт кенә булды сезнең өйдә. Көннәр тиз үтте. Яра сызлаулары да сизелми калды. Шәкертем бик тырыш иде шул. Күңелемне бер генә дә боектырмады. Укуны су кебек эчеп барды. Хәзер инде менә китәсе вакытларым да килеп җитте.

Хәниф абый миңа карап алды, елмайды. Янәсе, ишет, сине мактыйм. Ә мин чак кына еламыйм. Мөмкин булса, аның шинель итәгенәябышып, китмә, китмә, дип ялварыр идем. Мин аңардан башка ничек яшәрмен, дип уйлана-уйлана өзгәләнәм. Бу бит миңа тагын бер кайгы, тагын бер хәсрәт.

Бабай идән буйлап арлы-бирле йөренеп алды. Бер тукталды, бер кузгалды. Нәрсә әйтер икән? Көтеп торам. Бәлки, ул Хәниф абыйны үгетли башлар: «Беркая да китмисең, Хәниф улым, китмисең,— дияр.— Бездә начармыни? Син бит инде үз балабыз кебек. Әнә Сабируллага абый булырсың. Сиңа дигән матур кыз да табылыр. Өйләнерсең, хуҗалык итәрсең, үз җиреңдә булыр. Яңа йорт салып куярсың. Әнә бит нинди хәр заман килде... Әнә, безнең кар түбәле тауларыбыз да бар. Җәйләрендә чишмәләргә барып чыксаң, яннарыннан китә алмассың. Безнең якларда шиңми торган чәчәкләр дә үсә, кайбер агачлар бер генә дә яфракларын коймыйлар...»

Шулай мактансын иде бабай, мактансын иде. «Бездә генә кал, бергә-бергә яшәүләре күңелле дисен»,— иде.

Юк, бабай алай әйтмәде.

— Нишләмәк кирәк,— диде ул,— нишләмәк кирәк, дөньяда һәркемнең үз нужасы бар. Бездән фатиха, юлларың якты булсын, улым Хәнифулла, үз туганнарың белән көрешергә язсын...

И бабай, бабай, минем хакта оныттыңмыни? Мине укытучымнан аерасың бит. Мин Хәниф абыйны сагынырмын, кайгырырмын. Сез мине ничек юата алырсыз икән? Андый юанычлы сүзләр, бәлки, сезнең телегездә дә юктыр.

Чү, әби нәрсә әйтер икән? Ул Хәниф абыйны бик ярата. Бәлки, аны бездә калырга күндерә алыр. Әбинең теле иплe. Бик тә килештереп әйтә белә.

Көтәм. Юк, әби тел ачарга да җыенмый. Бер бабайга карап ала, бер миңа, бер Хәниф абыйга. Өйдә тынлык. Олылар шулай сүзсез генә үзара нәрсәдер ымлашалар кебек. Дөрес сизенгәнмен. Әмма моннан соң нәрсә буласын мин әле төшенми торганмын.

Кинәт Хәниф абый әйтә куйды:

— Әллә Сабируллаcreateны да минем белән җибәрәсезме?

Тукта, дөрес ишетәмме? Чыннан да, Хәниф абый мине үзе белән алып китәргә телиме? Әнә, ул сөйли тора. Ә мин ташка әверелдем сыман. Миңа китереп-китереп сугалар кебек, мин тоймыйм да, сизмим дә.

— Сабирулла хәзер минем үз улым шикелле,— диде тагын Хәниф абый.— Борчылмагыз, өстен-башын карармын, укытырмын, чын кеше итәрмен ул баланы. Бер генә дә җәбер күрмәс. Аңа беркем дә бармак белән дә кагылмас.

— Юк,— дидем мин бөтен көчем белән кычкырып.— Юк! Мин әбиемне дә, бабамны да яратам. Китмим!

Үзем йөгереп килеп әбием култык астына кереп йомарландым.

— Мине яратмыйсыңмы?— диде Хәниф абый.— Көтмәгән идем. Алданганмын...

— Сине дә яратам, Хәниф абый. Үзең бездә кал. Беркая да китмә!

Әби мине кочаклап алды. Маңгаемнан үпте. Йөземне сыпырды. Өс-башымны рәтләде. Күлмәк төймәләремне каптырды. Үзе еламый да кебек, күзләреннән яшь тамчылары йөзенә яңа җыерчыклар сызып төшәләр сыман. Әби авыр уфтанып сулады да:

— Без дә сине бик яратабыз, улым,— диде.— Йөрәгебездә син безнең. Әмма гафу итә күр, балакай. Сиңа Хәниф абыең белән китәргә туры килер. Бу хакта без инде Мохтар абыең белән дә, Мөршидә апаң белән дә киңәштек. Алар да риза булдылар. Син дә, улым, безнең сүзебезне кире какма. Шулай кирәк, заманы шундый...

Юк, әбидән булмады. Әнә ул ничек сөйләшә. Мин бабай янына атылып килдем. Ләкин бер генә сүз дә әйтергә өлгермәдем. Бабай мине үз каршына бастырды да:

— Әйдә, ирләрчә сөйләшик әле,— диде сүзен башлап.— Тыныч кына тыңла. Кәҗәләнеп маташма. Мин сиңа хәзер барысын да аңлатып бирермен.

— Менә, менә, шулай кирәк, ирләрчә сөйләшү булсын,— диде Хәниф абый.— Уен эш түгел бу. Үзе теләсә генә, үзе риза булса гына...

— Уйлап кара, улым,— диде бабай тагын сүзгә керешеп.— Бүген без бар, иртәгә кем белсен, булырбызмы, юкмы? Хәниф абыең сине уллыкка алмакчы. Бар, улым, бар, бездән фатиха. Бу чит якларда югалып калма. Без инде дөнья кешеләре түгел. Ә сиңа әле яшәргә кирәк, яшәргә!

Бабай да мине кочып сөйде. Аның йөзе җитди иде. Күзләре кысыла төшкән. Бераз ачулы да шикелле.

Олылар инде үзара күптән сүз берләштереп куйганнар, күрәсең. Хәзер генә төшенеп алдым. Әнә, әби тагын сүз башлады:

— Без сине,— диде ул,— беркайчан да, беркая да җибәрмәс идек. Үзебезгә дә бик-бик кирәкле син, улым. Әниең киткән чагында әйтеп калдырган иде. Алай-болай булып, кайтмый калсак, зинһар өчен Сабирулланы ташламагыз, дигән иде. Ничек кенә булса да укытыгыз, дип тә әйтте. Без әниеңнең әнә шул васыятен үтибез. Аның каршында бурычлы булып каласыбыз килми, язык була. Хәниф абыең сиңа бәхеткә очраган кеше. Иншалла, аның карамагында әрәм булмассың, балакай.

— Белдеңме инде, Сабирулла?— диде Хәниф абый.— Менә уйла. Миңа сүз әйтәсе дә калмады.

Нәрсә булды миңа? Күзләремнән әле генә атылып чыгарга торган яшьләрем каядыр эчкә кереп югалдылар. Мин хәзер үзем дә житдиләндем. Гәүдәм турая төште, башым күтәрелде. Әллә ничек үсебрәк киттем шикелле. Миңа инде кәҗәләнеп торырга оят иде.

## Саубуллашу

Бүген мин бик иртә уяндым. Әмма өйдәгеләр миннән дә иртәрәк торганнар икән. Әби мич янында кайнаша, нәрсәдер пешереп маташа. Өйгә таба исе чыккан. Бәлки безне әби соңгы кабат озату алдыннан коймак белән сыйларга җыенадыр.

Бабай белән Хәниф абый йортка чыгып киткәннәр. Алар әле кичә үк, арбаны җайлыйсы, тәгәрмәчләрен майлыйсы булыр, дип сөйләшкәннәр иде. Атка да су эчерергә, солы салырга кирәктер. Барасы юлларыбыз ерак бит безнең, бик ерак...

Мин әле урынымнан тормый гына ятам. Тәрәзәгә карыйм. Тәрәзәдән миңа да алача карап тора. Ул ап-ак чәчәк аткан. Башына челтәр бизәкле, үтә күренмәле шәл ябынган купшы хатын шикелле. Туйга килгәнмени?

Исемә төште. Тәүге кабат биргә аяк баскан көнне иң беренче кабат мин шул алачага килеп кагылган идем. Җимешләрен хөрмә дип белгән идем. Ә ул үзенең очлы энәләре белән кулларымны чәнчеде. Каян килеп чыктың әле син, усал малай, дип әйткән иде шикелле. Мин аның бер җимешен өзеп алып авызыма каптым. Әчесеннән йөзем сытылды. Төкердем. Тәмсез иде ул хөрмә! Мин елый яздым. Ә алача башын селкә-селкә көлеп җибәрде сыман. Авызың пештеме, малай, янәсе. Ачуым килгән иде аңа ул чакта.

Тора-бара ул чәнечкеле агачка ияләштем. Көз көне аның җимешләренә дә бал тәме керә. Ул бит әле безнең йортыбызның күрке дә иде. Безнең өйне шул агачка карап кына да әллә каян таныйлар. Ә миңа ул бу чит якта дустым шикелле иде.

Ә менә бүген мин китеп барырмын. Ә дустым кала. Менә шушы тәрәзә каршысында, бәлки, әле ул озак еллар үсеп торыр, яфракларын кояр, чәчәк атар. Ә мин нишләрмен? Кайда булырмын, тагын миңа шундый дуслар очрармы? Уфтанам, сызланам.

— Тор, улым, тор,— дип әби яныма килеп утырды да йөземә җылы учларын куйды. Гәүдәмне сыпырды.— Үс, үс,— дигән булды көлә-көлә.

— Мин инде зур.

— Әйе, улым, син быел йөгерә-йөгерә үстең. Бабаң да шатланып туя алмый. Чын егет булып килә, ди. Әнә, укырга да өйрәнеп алдың. Тырышкан ташка кадак кага, диләр. Белеп әйткәннәр. Тырыш булсаң беркайда да югалмассың, улым.

Хәзер әби инде елый башлар дип уйлаган идем. Мин китәмич. Андый чакта кем яшь түкми? Әмма әби еларга җыенмый да. Ул бик җитди сөйләшә.

— Үзең яхшы булсаң, сине дә кешеләр үз итәрләр. Хәниф абыеңны тыңла, бер генә сүзен дә кире какма. Ул олы кеше, мөгаллим.

Әби шулай сөйләнә тора, миңа нәсыйхәт, киңәшләр бирә. Ә мин аның кипшенеп, бөрешеп беткән йөзенә карый-карый уйланам. «И минем кадерле әбием, дим эчтән генә, миннән башка сез ничек яшәрсез икән? Сезне кем карар? Сырхау аяктан екса, кем су бирер сезгә? Кем ашатыр, кем эчерер?»

Хәзер минем үземнең елыйсым килә. Кычкырып елыйсым килә. Бәлки, мин елаган да булыр идем әле. Кинәт бабай белән Хәниф абый өйгә керделәр. Хәниф абый шаяртып кына миңа бармак янады да:

— Минем улым әле йоклый икән,— диде.

Их, минем улым, дип әйтте бит ул. «Минем улым!» — диде. Миңа бик рәхәт булып китте. Урынымнан сикереп тордым да ашыга-ашыга киенә башладым. Әтием күрсен, «мин тырыш малай!».

Бабай кулларын юарга кереште. Әби табын әзерләде. Хәниф абый:

— Атны җигеп куйдык инде,— диде.— Юлга иртә баштарак чыксаң көн озынрак була, диләр.

Шул арада безгә Мохтар абый белән Мөршидә апа да килде. Берҗәбергә чәй эчәргә утырыштык. Бабай безне кыстый-кыстый сыйлады:

— Юлга тамак туйдырып чыгалар. Әле сез бара-бара бер генә көн узмас.

Әби сөйләшми. Беләм, ул хәзер бер генә сүз әйтсә дә елый башлар. Минем күңелемне дә кузгатыр. Шуңардан курка ул. Мөршидә апа чәен эчеп урыныннан торды да, үзе белән алып килгән төенне Хәниф абый кулына китереп тоттырды.

— Менә сезгә юл азыгы,— диде.— Солдат паегы, үз өлешең, Хәниф туган.

Күреп алдым, төендә ике каравай башларын як-якка төртеп яталар. Тагын ниндидер вак-төяк әйберләр дә бар иде әле анда. Әби дә ашъяулык җәеп, нәрсәләрдер шунда сала-сала сөйләнде: «Менә монысы бездән булыр,— диде.— Бик тәмле кабартмалар. Чәен дә бераз куйдым, тозын да. Юлда берсе дә артып калмас әле».

Кинәт минем телемә сүз килде.

— Кирәкми, кирәкми, әбием, үзегезгә нәрсә кала соң?— дидем.

Шулай әйтүем булды, әби елап җибәрде. Мине күкрәгенә кочып сөйде.

— Рәхмәт улым, олы җанлы кеше син. Безнең турыда да кайгыртасың икән, гүзәлем минем. Безгә инде әллә ни күп кирәкми улым. Күп кирәкми...

— Анысы инде Сабирулла синең хәсрәт түгел,— диде Мохтар абый.— Бабаң да, әбиең дә бүген үк үзебезгә күчеп килерләр. Сиңа гына димәгән, безгә дә әби-бабай кирәк. Тиздән әнә безгә дә бала киләсе бар.

Нинди бала, каян килә? Уйландым. Маңгай астыннан гына Мөршидә апага карадым. Сизми-белми торганмын, әнә ничек үзгәргән ул. Битенә сипкелләр чәчрәгән, иреннәре турсайган, күзләре шешеп чыккан шикелле. Күлмәге гәүдәсен кысып алган. Корсагы бүрткән. Түзмәдем көлеп җибәрдем.

— Нигә көләсең?— диде Мөршидә апа,— пәри малае, әллә дөньяда бер сиңа гына яшәргә дигәнме? Башка малайларның да туасы бар әле. Көнләшмә, ул сиңа абый дип әйтер.

Олылар көлештеләр. Ә мин оялдым, битем кызып китте. Мин әле мондый сүзләрне беренче кабат кына ишетәм. Бәлки, йөгереп-качып та киткән булыр идем бирердән. Шул минутта бабай сүз башлады:

— Я, балалар, инде җыена башларга вакыт. Юлчы кешенең юлда булуы хәерле. Барасылары ерак...

Хәниф абый Мохтар абыйны кочаклап биленнән кысты. «Рәхмәт, иптәш комиссар,— диде.— Онытасым юк».

Аннан соң әби алдына килеп башын иде. «Сезгә, Хәлимә апа, бер сүз дә әйтә алмыйм. Сездән күргән кадерне аңлата торган сүз юк кеше телендә». Хәниф абый әбинең йөзеннән үпте.

— Ичмасам,— диде,— шундый чакта бүләк итеп бирергә бер генә нәрсәм дә юк.

— Анысы өчен борчылма, Хәнифулла, Сабирулланы кеше итеп чыгарсаң, бүләгең шул булыр.

— Өстемә алган бурычым. Бер дә шикләнмәгез, без әле сезгә хатлар да яза торырбыз. Әллә нинди ят илләргә китмибез ләбаса.

Ә мине олылар туп шикелле кулдан-кулга йөртеп сөйделәр.

— Абыеңны тыңла, әйткән булсын,— диде бабай.— Киттем дә, болардан ычкындым димә. Безнең колаклар ерактан да ишетә. Белеп тор, малай.

— Тыңлый ул, тыңлый,— диде Хәниф абый.— Улы атасын ихтирам итмәсә...

— Язык була, язык була,— диде әби.— Колагың ишетсен, балакаем. Хәзер инде ул еламый. Йөзенә елмаю чыккан. Җыерчыклары да җәелгән кебек. Янәсе, бер дә борчылмый. Оныгы китсә ни дә, китмәсә ни... Беләм мин сине, кадерле әбием, беләм, шулай кыланып кына маташасың бит син. Миңа кайгыңны сиздерергә теләмисең. Озатканда тыныч булсын бу бала дисең...

Мин дә елмаям. Синең дә бәлки, йөрәгең тынычланыр, кадерле әбием! Оныгың бәхетле булыр дип уйла.

Бабай инде бер сүз дә эндәшми. Нигәдер иреннәрен генә кыймылдата. Мөршидә апа арбага әйберләр куя тора. Үзе: «Юлыгыз ун булсын, уң булсын»,— дип сөйләнә. Мохтар абый ат тирәсендә йөренә. Камытын кузгаткалап карый. Ыңгырчакны күтәргәләп рәтли. Атны маңгаеннан сыйпый.

— Барысы да рәтле, инде утырышыгыз,— диде ул Хәниф абыйга дилбегәне тоттырып.— Хәерле юлга, солдат!

Мин дә арбага менеп утырдым. Хәниф абый дилбегәне җайлап кына, әкрен генә тартты да: «На, малкай,— диде,— киттек!»

Без әкрен генә китә тордык. Олылар безнең арттан килә-килә кул болгап калдылар. Мин шунда алачага күз ташладым. Әнә ул да безне озата. Ап-ак тубал башын ия-ия безгә: «Хушыгыз, хуш!»— дип әйтә сыман. Мин дә аңа: «Бәхил бул, дустым алача!— дим.— Бәхил бул!»

## Дала моңы

Без сөйләшми генә шактый озак бардык. Сүз дә табылмады. Күңелләребез дә әллә ник төшенке иде. Туганнардан, дус-ишләрдән аерылышу кешене шулай уйга сала, күрәсең. Мин борылып-борылып артка таба карыйм. Безнең хутор инде күренми дә. Алда әле беркем дә, бернәрсә дә күзгә чагылмый. Тирә-якта шыр ялангач дала. Баш өстендә генә әлеге шул кырлар дусты — тургай сайрый. Кая гына барсаң да шул нәни кош очрамый калмый икән. Бәлки, игенчеләрне көтә торгандыр. Ә игенчеләр кайда? Кырлар буш. Ә тургай әнә үз урынында! Бу якларда сугышлар булган дип тә тормаган, кан коелган, кеше үлгән дип тә тормаган, үз вакытында килеп җиткән!

Мин ерак-еракка алга таба күз ташлыйм. Анда офык. Офык буенда нииндидер көмеш төсле дулкыннар йөгерешә. Әллә анда нииндидер диңгез бар микән? Әллә анда дөньяның чите микән? Кызык.

Белмим, бу чакта Хәниф абый нәрсә уйлагандыр. Ә мин кайчандыр менә шулай туган авылымнан чыгып киткән көннәремне исемә төшердем. Ул вакытта без «хөрмә» үскән илгә юл тоткан идек. Ә хәзер шул илдән китеп барабыз. Кая барабыз? Белмим әле.

Берчак Хәниф абыйның сөйләгәне булды: «Безнең авылмы? Безнең авыл бөтен Россиядә бердәнбер авыл»,— дип мактанган иде. Аның мәчете генә дә илле чакрымнан күренә, имеш. Авылның бер ягында таш буа, суында балык мыжгып ята икән. Иртәрәк барсаң, әле йокысыннан уянып өлгермәгән балыкларны ялан кул белән генә тотып аласың, ди. Тирә-якта бакчалар, бакчалар, имеш. Ул кавын, карбыз дисеңме, корсакларын кояшка куеп, тәгәрәшеп яталар икән. Авылда сабан туйлары да була, ди. Олылар көрәшәләр, малайлар ат чабыштыралар. Башта килгәнгә аллы-гөлле сөлге бирәләр, ди...

Хәниф абыйның бу матур сүзләренә ышандым да, ышанмадым да. Чөнки минем инде хөрмә илендә «хөрмә» ашап бер тапкыр авызым пешкәне булды.

Ат, әнә, салмак кына атлый бирә. Арбаның арткы ягына чыпта белән ябылып куелган мичкәдә су чапылдый. Әйтерсең лә шул чыпта астына кемдер кереп яткан да, нәрсәдер сөйләнеп бара сыман. Каранам, берәр җиреннән су агып чыкмыймы? Бабай: «Далада коелар сирәк очрый, суны кадерләп кенә тотыгыз» дигән иде. Юк, беркаян да акмый. Мичкә таза. Арбада тагын корымланып беткән искә чәйнек. Таныйм, без ул чәйнектән пароходта чәй эчкән идек. Ә хәзер ул әнә арбада борыны белән төртелә-төртелә йокымсырап бара. Арба артында иске калай чиләк дыңгырдый. Хәзергә безнең байлык шул гына әле. Кинәт:

— Я,— диде Хәниф абый, йокысыннан уянган төсле итеп, күзләрен уа-уа.— Нигә борыныңны салындырдың, егет? Әллә бик күңелсезме? Баядан бирле авызыңа су кабып барасың?

— Синең үз борының да, Хәниф абый, бик кәпәрелеп тормый әле,— дидем мин көлә-көлә.— Авызың да бикле кебегрәк.

— Анысы дөрес. Юл кешене уйга сала энем, менә хәзер күңел ачып җибәрик әле.

Хәниф абый кесәсеннән авыз гармунын кулына алды. Фу, фу, итеп тишекләренә өрде. Учы белән сыпырып куйды. Миңа калса, гармунчы шушы кечкенә генә, ялтыравыклы затны иркәләп йокысыннан уятырга тели иде кебек.

— Җырлый да белсәң, Сабирулла, без хәзер парлап әйттерер идек. Их, малай...

— Җырлый белмим шул, Хәниф абый, белмим...

— Зарар юк, өйрәнерсең әле, дөнья ул нәрсә генә өйрәтми.

Хәниф абый иплән кенә, озак-озак итеп сулыш алды да гармунын авызына куйды. Кычкыртып карады. Тынып торды, нәрсәдер уйлады. Һәм кинәт ниндидер көй яңгырап китте. Бик моңлы җыр иде ул. Бу чиксез дала мондый авазны, бәлки, беренче кабат ишетә булыр.

Ат та үзенең адымнарын шул көйгә килештереп атлый. Колакларын торгызды, башын чайкап куйды. Шәп! дип әйтте сыман. Тәгәрмәчләр шыгырдавы да ишетелми. Юл буенда үскән үләннәр дә бер күтәрелеп, бер селкенеп куялар.

Ә Хәниф абый уйный бирә. Күзләрен йомган, йөзе кызарган, кашлары сикерә. Менә ул туктады, гармунын кулына тоткан килеш авызын ачып калды. Әле аның авызыннан да каядыр кысылып калган көйләр чыгып тора иде кебек.

— Булдырдык бит, Сабирулла, Шәп чыктымы?

— Шәп!

Хәниф абый рәхәтләнеп көлде.

— Җыр белән теләсә нишләп була, энем. Кайгырсаң күңелне ача, дәртләндерә, биетә дә...

Без икебез дә уйландык. Җыр әле безнең күңелләрне һаман тибрәтә иде. Бу чакта сүзсез тору үзе бер рәхәт.

Бераздан соң Хәниф абый гармунын учында чөеп сикертте.

— Әтием бүләк иткән иде,— диде.— Бик күптән. Әле синең кебек малай чагымда ук. Озак йөрттем мин бу нәнине үзем белән. Ә хәзер инде сиңа бүләк итәм, мә, Сабирулла, ал!

Кинәт сискәнеп киттем. Ничек булды әле бу? Хәниф абый миңа үз гармунын бирә. Каян килде аңа бу уй? Нишләп болай кылана? Аптырап торам. Алыргамы, алмаскамы?

Алсам, ул гармунны мин бары тик кесәмә салып кына йөртермен. Алай ни файда? Уйный белмим ич. Бу бит сайрый торган кошны караңгы читлеккә ябып куйган кебегрәк булып чыга. Алмасам да өркәм. Әтием урынына калган якын кешемне рәнҗетермен дә, ул ачуланыр төсле.

Хәниф абый гармунны кулъяулыгына төрә башлады. Әллә бирмәскә уйлыймы? Тиз генә сузылып гармунны тартып алдым. Кара, миңа дигән бүләкне кире җыештырып маташа...

Хәниф абый көлде.

— Әллә бик ялынып дип белдеңме?— диде.— Мондый әйберне хәзер сатып алам дисәң дә табалмассың. Кадерләп кенә сакла. Тотканда кулларың юган булсын. Авызында да бер генә валчык та асрама...

— Ничек уйныйлар соң бу гармунда?

— Башта кычкыртасың, сызгыртасың. Шунда бервакыт үз күңеленә ошаган бер тавыш килеп чыга. Аннан тагын берсе, тагын берсе... Шул тавышларны бергә куша-куша җыр туа.

— Син мине, Хәниф абый, үзең өйрәт.

— Авыз гармунында беркем дә, беркемне дә өйрәтә алмый. Үзеңә газапланырга туры килер, энем. Әлбәттә, бик теләсәң генә.

— Телим, бик телим!

— Теләү генә җитми шул. Сагыш кирәк, уй кирәк.

Мин бу сүзләрне аңламый торам. Сагышны беләм белүен. Кайгырып елаганым да бар. Ә гармунда сагышны ничек итеп уйнарга? Нәрсә сөйли Хәниф абый, ничек төшенергә?

Билгеле, мин гаҗәпләнгән идем. Нәрсә әйтергә дә белмичә, Хәниф абыйның йөзенә күзләремне дә йоммыйча карыйм. Ул сизенде. Үзе дә миңа исе китебрәк карады. Бәлки, «бу түмгәккә» ничегрәк аңлатырга соң моны, дип тә уйлагандыр.

— Беләсеңме,— диде ул соңрак.— Менә әле хәзер генә мин гармунда сыздырдым...

— Бик матур сыздырдың Хәниф абый.

— Матур булмый хәле юк. Чөнки мин бу чакта үземнең бик якын кешемне исемә төшердем, аны сагынып уйнадым.

— Ә мин әнием турында уйландым.

— Менә, менә, үзең дә сизенгәнсең, энем. Сагыш дип әнә шуны әйтәләр инде.

Кинәт ат сөртенеп алды. Арба да безне дырт иттереп бер селкетеп куйды.

— Арды, күрәсең, хайван,— диде Хәниф абый.— Әнә инде төш вакыты да җиткән. Бераз ял итеп аласы булыр. Кояш та сүрелә төшәр. Чамасыз кыздыра.

Без юлдан шактый читкәрәк чыгып туктадык. Биредә әремнәр биегрәк тә, куерак та иде. Сирәк-мирәк кенә яшел үләннәр дә күренгәли. Шулар арасында кып-кызыл тюльпан чәчәкләре ялкын шикелле үреләүреләнип яналар сыман. Ераккарак күз ташласаң, далага кемдер кызыл палас җәеп салган диярсең. Миңа күңелле.

Хәниф абый атны туарды. Йөгәнен дә салдырды, камытын да. Ат ялангач калды сыман. Мин аңа карадым да исем китте. Бигрәк ябык икән безнең атыбыз. Ничек кенә тартып бара ул безнең арбаны? Ничек егылмый да, ничек түзә мескен? Сусагандыр, ачыккандыр...

Юк, ул әле алай ук мескен түгел икән. Менә ул аякларына ныграк басып, гәүдәсен турайтты, алга таба сузылды. Башын югары күтәрде, күзләрен ялтыратып тирә-якка каранды. Күренә, сугыш газапларыннан соң ул да бу киң даланы, кояш астында әлсерәп яткан бу тынлыкны үлеп сагынган. Тыпырчына, тизрәк мине ирекккә җибәрегез, дип тә әйтер иде әле теле булса.

Хәниф абый учак ягарга әзерләнә калды. Мин тизәк җыярга киттем. Биредә урман түгел, сыңар куак та үсми. Чыбык-чабык каян килсен? Бу якларда кышын да өйләрне тизәк ягып җылыталар. Моңа беркем дә гаҗәпләнми. Гадәтләнгәннәр. Кыр учагында тизәк бигрәк тә кызу яна. Зәп-зәңгәр төтене ниндидер хуш ис тарата!

Кипкән, иске тизәк кырда шактый күп иде. Кайчандыр биредә малтуар көткәннәр. Ә хәзер тын бушлык биредә. Җир өстендә тояк эзләре ниндидер бизәкләр кебек тезелеп ята. Мин бу эзләрне таныйм. Биредән атлы гаскәр узган. Ул тояк эзләре бер карасаң тирән кырлы тәлинкәләргә

охшыйлар. Кызыл тюльпаннар шул савытларда үсеп утыралар шикелле. Беләм, беләм, сугыш эзләре бу. Монда тамган кан урынында, әнә, кызыл чәчәкләр яралган.

Мин чиләккә тизәкләр җыям. Адым саен я атылган гильза, я обоймасы тулы патроннар таба торам. Барысын да кесәләремә, куен эченә сала барам. Алар бик матур, күзне чагылдыра. Алмас җиреңнән алырсың.

Әмма Хәниф абый мине моның өчен әләктереп тә алды, селкеп тә салды.

— Әллә бу нәмәрсәләрне уенчык дип белдеңме?— диде кашларын җыерып.— Болар бит кеше үтерә торган нәрсәләр. Күрмисеңмени, очлары нинди, кайрап куйган төсле. Ярый әле учакка салып өлгермәдең, я син, я мин күзсез кала идек ләбаса. Алар теләсә кайда да ата, үтерә.

Әй орышты, Хәниф абый мине, әй орышты! Йөзем кызарып чыкты. Оялдым да, курыктым да.

— Соңгысы булсын,— диде.— Ул «уенчыклар» белән без «уйнаган» да җитәр. Бәлки, боларның берәрсе минем кулдан да үткәндер. Без бит биредән сугыша-сугыша бер генә кабат узмадык.

Мин эндәшмәдем. Башымны түбән идем дә тик кенә тора бирдем. Инде еларга җитешкән идем. Хәниф абый минем борыныма бармагым белән чак кына тиеп алды да:

— Ярар, узган эшкә — салават,— диде.— Әнә, чәйнек дөберди, әйдә, чәй эчәргә утырабыз.

## Дошманнар белән очрашу

Тагын юлга чыктык. Инде кояш күктән офыкка таба тәгәри башлаган иде. Нииндидер шәһәр сыман бер кечкенә генә төбәкне читләтеп кенә узып киттек.

Ат әкрен генә атлый бирә. Кайчак, әллә эче пошыпмы, башын чайкап, йөгереп китәргә маташып карый. Ләкин Хәниф абый дилбегәне тарта.

— Ашыкма, ашыкма,— ди.— Юл озын әле. Атлап кына барсаң да без бик риза.

Шулай алга таба барган саен, мин әле я бер елга, я урман күренә башлар дип өметләнәм. Юк, алга барган саен дала һаман киңәя, офык чикләре һаман ераклаша кебек. Хәниф абый авылына без беркайчан да барып җитмәбез шикелле тоела.

Тагын нииндидер чатыр авыллар, хуторлар аша уза тордык. Төннәрен кырда кундык. Ә бүген без инде өченче көн юлда идек.

Хәниф абый ара-тирә сөйләнеп куя:

— Бу — калмык җирләре,— ди.— Биредә иген икмиләр. Сарык үрчетәләр, ат асрыйлар.

Белеп әйтте Хәниф абый. Озак та узмады, каяндыр сарыклар көтүе килеп чыкты. Артларында атка атланган чабан да күренде. Көтү әкрен генә безнең алдан узып китте. Без дә бара тордык. Бервакыт артка әйләнеп карасам, нигә бер генә сарык күренсен. Көтү үзенең чабаны белән бергә каядыр китеп югалган. Бу сәер иде. Нииндидер могҗиза булып алды сыман. Әнә, тагын атка атланган берничә җайдак җир астыннан калкып чыктылар да бераздан янә җир астына төшеп киттеләр сыман.

Ничек була бу? Кинәт кенә күренәләр дә, кинәт кенә юкка чыгалар? Бу гаҗәп тә, куркыныч та. Калмык җирләрендә әнә нинди хәлләр бар икән. Мин як-ягыма каранам. Тагын ниләр булыр биредә? Хәниф абый сизенә. Мине тынычландырырга тели.

— Биредә,— ди,— кайчандыр тирән, киң елгалар агып яткан. Диңгезгә койганнар алар. Биредән бит диңгез дә ерак түгел. Шул елгалар

акканнар-акканнар да, бер заман сулары кибеп беткән. Алар урынында тирән уелдыклар хасил булган. Биредә аларны балка дип атыйлар. Әле генә без күргән сарыклар да, җайдаклар да шул балкаларның берсеннән чыгып, икенчесенә төшеп киттеләр. Ә син, юләр, әллә нәрсәләр уйлап бетергәнсең әле...

Икебез дә көлештек. Хәниф абый белән рәхәт миңа. Эчем пошып боега башласам, ул гел шулай берәр кызык сөйләп җибәрә. Күңелле була.

Менә без дә бара-бара шул балка дигән коры елга яры буйлап түбәнгә таба юнәлдек. Түбәнрәк төшкән саен без ниндидер яңа дөньяга керәбез кебек. Җирдә ямь-яшел үлән. Арырак күзгә шикелле түм-түгәрәк күл җәйрәп ята. Тагын да арырак урман күренә.

— Менә шушы урман аша узабыз да, тагын ярга күтәреләбез,— диде Хәниф абый, шатлана-шатлана.— Аннан соң инде безнең авылга да күп калмый. Төш чагынарак барып та житәрбез. Кызыклар буласы, малай. Дуслар белән очрашырбыз. Минем шәкертләрем инде буй үстереп, мыек йөртә башлагандыр. Тиз генә танып та булмас үзләрен.

Мин дә шатланып җилкендем. Миңа да күңелле иде.

— Теге апаны да күрербез әле,— дидем.— Әйеме, Хәниф абый?

Ә Хәниф абый яшәреп киткән кебек булды. Йөзе яктырды. Күзләрендә чаткылар ялтырады. Авызын киң җәеп елмайды. Беләм, минем соравымны бик яхшы төшенде ул. Әмма үзе генә еллар буе саклап йөргән серне бу юлы да үзендә генә калдырырга тели иде. Нәрсә лыгырдый бу малай ди торгандыр әле эчтән генә.

Мин бит аның теге вакытта әбигә: «Авылда минем сөйгән кешем бар»,— дип сөйләгәнен ишеткән идем инде. Онытмадым, Хәниф абый, онытмадым...

Ә Хәниф абый белмәмешкә салынды.

— Нинди апа, ни сөйлисең син, малай?— диде көлә-көлә.— Башың тишек икән синең. Эләктереп калгансың бит, ә...

— Үзең әйттең ич гармун уйнаганда. Аны уйлап сагышланам, дидең.

— Андый серне йөрәктә генә саклаулары кыен шул, үзең әйтмәсәң, күзгә карап беләләр. Әйе, Сабирулла, ул апаңны да күрәсебез бар. Синә җиңги буласы кеше ул. Белеп тор.

Хәниф абый авызын җыя алмый. Елмая, көлә. Мине кочаклап-кочаклап иркәли, аркамнан чәбәкли.

— Яшибез, улым, яшибез әле,— ди. Дилбегәне тарткалап атка да эндәшә тора.— На, на, малкай, хәзер кызурак барсаң да ярый.

Без инде урман эченнән бара идек. Ат нигәдер пошкырына, як-ягына карана, колакларын уйната. Әллә куркамы? Әллә нәрсә дә булса сизенәме? Мин дә шигәйдем. Хәниф абыйга якынрак елыштым. Ул үзе дә күзләрен кыса-кыса алга карый, бүре мазар күренмиме, ди бугай. Ат юкка гына пошкырмый.

Кинәт артта мылтык аткан тавыш ишетелде. Карасак, анда атка атланган өч-дүрт кеше безне куа киләләр иде. Берсе: «Стой! Стой!»— дип кычкыра. Үзе кылычын болгый.

Хәниф абый дилбегә белән ат сыртына сыптырды.

— Бандитлар!— диде.— Бандитлар килә!

Ат бөтен көче белән алга ыргылды. Хәниф абый тагын да ныграк куды. Арба җиргә тияр-тимәс бара. Ат тоягы астыннан тузан, балчык чәчри.

— Ят, башыңны күтәрмә,— диде Хәниф абый миңа.— Бандитлар болар, бандитлар!

Мин арбага сузылып яттым. Тагын аттылар. Хәниф абый ары-бире чайкалып торды да кулларыннан дилбегәне ычкындырып минем өстемә авып төште. Мине күкрәк астына алып, башыма кулларын куйды. Ул мине

шулай бандит пулясыннан саклап калмакчы иде, күрәсең. Мин аңа: «Хәниф абый, Хәниф абый»,— дип кычкырам. Ә ул эндәшмәде. Ат дулый-дулый чаба. Әмма бандитлар безне куып життеләр. Алга чыгып юлны бүлделәр. Ат туктады.

Бандитларның берсе атыннан сикереп төшеп арба янына килде. Хәниф абыйны йөзе белән үзенә әйләндереп чалкан яткырды. Шунда мин аның күкрәк тирәсеннән агып төшкән канны күреп алдым. Күзләре йомылган иде. Мин бөтен көчем белән кычкырып елый башладым. «Хәниф абый, Хәниф абый»,— дип әйтә-әйтә өзгәләндем.

Бандит мине читкә этеп жибәрде. Хәниф абыйның фуражкасын салдырып алды. Йолдызын йолкып-өзеп чыгарды да кесәсенә салды. «Минем пуля алдамый, нәкъ тиешле бәндәсен килеп тапкан,— диде.— Әнә кем, кызылармеец! Ха-ха-ха!»

Дуслары да көлештеләр. Ә бандит Хәниф абыйның кесәләрен актарды, документларын алды. Карады, укыган булды.

— Болары да ярап торыр,— диде.— Хәзер безгә дә фамилияләр алыштырырга вакыт житеп килә. Ха-ха-ха!..

Бәлки, ул гармунны да умарлаган булыр иде. Бәхеткә каршы, Хәниф абый бүләге минем үз кесәмдә иде.

Берсе, дөл-дөл бүрек кигәне, битенә чорнала-чорнала үсеп беткән озын сакаллысы, миңа ут күзләрен чекерәйтеп карады-карады да:

— Бу малай белән нишлибез соң?— диде.

Минем жаным инде тәнемнән чыгып киткән шикелле иде. Мин үлеме, тереме? Үзем дә белмим. Боларның кычкырыша-кычкырыша сөйләгән сүзләрен дә чак-чак кына ишетәм. Хәзер миңа китереп суксалар да тоймас идем кебек. Бәлки, бу башкисәрләр мине дә үтереп ташларга телиләрдер...

— Бала белән кем сугыша?— диде тагын берсе.— Бернинди файдасы юк.

— Әйдә, юлында булсын. Советларга сабак! Күрсеннәр, аларны да шундый көн көтә. Белә торсыннар.

Моны теге озын сакаллысы әйтте. Үзе камчы белән суга-суга безнең атны куа барды. Ат йөгерде. Ә бандит үз дуслары янына китеп барды.

Мин Хәниф абыйны кочакладым. Йөзеннән сыйпадым: «Хәниф абый, уян, уян»,— дидем. Ул әле миңа йоклаган кебек кенә күренә иде. Юк, ул уянмады. Әмма үлгәнме ул? Үлгән булса да, мин әле ышанмый идем.

## Нишләргә, кая барырга?

Ат әкрен генә атлый. Башын бора-бора арбага карый. Ни булды дип сорый шикелле. Ни булды? Мин дә бернәрсә аңламыйм. Бу авыр төшме, әллә өндә дә шундый хәлләр буламы?

Әле бит менә хәзер генә без киң дала буйлап, тып-тыныч кына бара идек. Баш өстебездә тургайлар сайрады. Күк йөзе зәп-зәңгәр иде. Кояш балкый иде. Алдыбызда нindидер иркен капка ачылган төсле иде. Без шул капкадан нindидер олы дөньяга, әле мин белмәгән, моңа кадәр мин күрмәгән дөньяга кереп бара идек шикелле.

Хәзер барысы да бетте. Инде нишләрмен? Кая барып тукталырмын? Кем мине каршылар? Ничек яшәрмен? Берсеннән-берсе авыррак уйлар килә тора. Елый да алмыйм хәзер. Бөтен гәүдәм сулкылдый. Күзләрен йомып хәрәкәтсез яткан Хәниф абыйга карыйм да: «Тор, тор!»— дип кулыннан алып тартам. Кинәт ул селкенеп-селкенеп китә. Чү, әллә тереләме? Тынып көтәм. Юк, аны шулай арба кага икән...

Башымны күтәреп алга карадым. Әнә, мәчет манарасы күренә. Хәтерләдем, Хәниф абый, безнең мәчет манарасын юлчылар бик-бик ерактан күреп алалар, дигән иде. Һичшиксез, бу шул авыл. Их, Хәниф абый да исән булса, хәзер без нишләмәс идек! Аны бит авылда сагынып

көтә торганнардыр. Ә мин менә арбада аның үле гәүдәсен алып киләм...

Авылга кердем. Инде урам буйлап барам. Кая тукталырга? Якягыма каранам. Әнә, бер капка башында кызыл әләм җилферди. Шәйләдем. Бу безнең хутордагы шикелле «Совет» йорты, күрәсең. Кызыл әләмне теләсә кая элмиләр.

Атны шунда таба бордым. Килеп җитеп тукталдык. Йорт каршына бер төркем кешеләр җыелган иде. Берничә агай-эне арба янына йөгерешеп килделәр. Берсе Хәниф абыйны танып алды.

— Әй, егетләр,— диде кычкыра-кычкыра.— Мөгаллим Хәниф кайткан ләбаса!

Тагын нәрсәдер әйтмәкче иде дә, кинәт сулышы буылды сыман. Куркынып артка чигенде. Икенче берәве Хәниф абыйның әкрен генә йөзен сыпырды. Як-якка салынып яткан кулларын күкрәгенә рәтләп куйды.

— Кайтуын кайткан да шул, безгә түгел, гүргә,— диде ул, башыннан бүреген сала-сала.— Әрәм иткәннәр явызлар безнең мөгаллимне, әрәм иткәннәр...

Бер карт Хәниф абыйны йокысыннан уятырга теләгән кебек әкрен генә төрткәләде.

— Тор, улым, тор,— диде.— Авылыңа кайтып җиттең ич...

Кемдер:

— Тормый инде ул, тормый,— диде, арба яныннан китә-китә барып.— Вафат.

Тиз арада шунда берничә хатын-кыз да күренде. Алар еракτан гына башларын суза-суза мәеткә карыйлар. Нәрсәдер сөйләшә-сөйләшә елашалар. Мин бары тик: «Кешесе дә нинди иде бит, нинди иде!»— дигән сүзләрне генә ишетеп калдым.

Өйдән ашыга-ашыга бер яшь кенә ир чыкты. Ул буе-сыны белән минем Мохтар абыйга охшаган иде. Билендә наганы да бар.

— Әйдә әле,— диде ул, мине арбадан күтәреп алып.— Өйгә керик. Ничек булды бу каза, кемнәр һөҗүм итте? Сөйләрсең.

Өйдә дә бер төркем кешеләр утыра иде. Маңгай астыннан гына күзәтеп чыктым. Биредә безнең хутор кибетчесе Баязитка, минем бабайга охшаганнары да бар. Алар берсен-берсе бүлдереп сораштылар. Мин елый-елый сөйләдем.

— Безне юлда бандитлар куа килделәр,— дидем,— аттылар, Хәниф абыйны үтерделәр. Кесәсеннән язуларын да алдылар...

— Сиздегезме,— диде бер агай.— Бандитларның хәлләре хөрти. Ялган документлар җыештырырга керешкәннәр. Фамилияләрен алыштырып җәзадан котылмакчылар.

— Сугыш бетте дә бит, әнә, бандитлар һаман котырына әле. Авылга патрульләр куярга кирәк,— диде тагын бер олы агай.

Алар үзара тагын нәрсәдер сөйләштеләр. Аңламадым. Мин инде бик арыган идем. Теге наган таккан кеше башын иеп, маңгаен сыпыра-сыпыра уйланды да:

— Мәетне экспертизага озатасы булыр,— диде.— Үзе үлмәгән, үтергәннәр аны. Тикшерми-нитми җирләргә рөхсәт юк.

Бер карт бик кычкырып сөйләште:

— Юк инде, Гарифҗан улым,— диде.— Синең ул әкеспәртизаң үзе бире килсен. Сугышларда йөреп-йөреп үз авылына кайткан солдатны тагын әллә кайларга алып китәргә ярамас. Үз туфрагыбызда ятсын.

— Мәетне бер тәүлектән дә артык тотарга шәригать кушмый,— диде тагын бер агай.— Язык була.

— Шәригать буенча бәлки шулайдыр да, әмма дә ләкин закон буенча алай килеп чыкмый, агай-эне,— диде теге Гарифҗан исемле кеше.

Синеңчә.— диде ул тагын.— мәетне тиз генә юасың да, тиз генә кабер казыйсың да, тиз генә күмеп тә куясың. Бетте, китте. Бүген мөгаллим Хәнифне, ә иртәгә бандитлар тагын бер кешебезне үтерсәләр, язык кемгә төшәр? Бандитларга бик кулай килеп чыга бит. Алар үтерә тора, ә без күмә барабыз...

Гарифҗан агай урыныннан торды. Тәрәзәдән карады.

— Әнә,— диде.— Хәнифнең тәненә пуля кереп калган. Ул пуляны кем, нинди мылтыктан аткан? Аны каян беләбез? Ул бит бандитның үз имзасы, аны таный белүчеләр бар... Юк, тикшермичә булмый. Мәетне уездга алып китәрләр.

— Хак сүз,— диде тагын берәү.— Тикшерергә, бандитларның эзенә төшәргә!

Гарифҗан агай кемнедер чакырырга кушты. «Атны алыштырып җиксен дә юлга чыксын,— диде.— Мондый эшне кызу тоталар. Ашыгырга кирәк».

Аннан соң мине баштанаяк күзәтте. Мин дә аңа карадым. Бераз өйдә тынлык булып торды.

— Исемең ничек соң синең, егет? Каян килдегез, әтиең-әниең бармы, кайда алар?— дип Гарифҗан агай миңа бер-бер артлы сораулар яудырды. Мин сөйләп бирдем. Тик соңыннан гына исемемне әйттем.

— Шулай,— диде Гарифҗан агай.— Ераклардан килгәнсең икән. Нишлибез соң?

Ә мин каян белим? Мин нишли алам? Мин бер сүз дә эндәшмәдем. Тирә-яктагы кешеләргә күз ташладым. Бәлки, җавап бирерләр. Юк, алар да тып-тын утыралар иде.

— Сездән сорыйм бит, авылдашлар. Бу малайны кая илтәбез?

— Үземә алам!— диде чандыр гына йөзле бер олы агай.

— Ике хатынга бер бала үстерергә әллә ни кыен булмас,— диде шунда утыручыларның берсе көлә-көлә.— Байлыгың да аллага шөкер. Бөлмәссең.

— Юк, беркемгә дә бармыйм,— дидем мин телгә килеп.— Хәниф абый үзендә торырга алып киткән иде. Мине аның әбисенә илтегез.

Ни өчен әбисенә дип әйттем? Чөнки, Хәниф абый: «Әнием күптән үлде»,— дигән иде. Бәлки, әле я әбисе, я апасы исәндер дип уйладым.

— Хәниф абыеның беркеме дә юк шул, улым, бирердә,— диде Гарифҗан агай.— Төпләнеп өлгерә алмады, сугышка китеп барды.

— Миңа бирегез, миңа,— диде тагын бер агай.— Үз улым итеп асрармын. Минем өйдә алар инде дүртәү тәгәрәшеп үсеп киләләр. Бишенчесе дә артык булмас.

Шул арада мин дә аңа карый-карый уйландым. Бу кеше минем бабай шикелләрәк иде. Бүреге генә башка төрле, ә бишмәте ала-кола ямаулы. Мин аңа барыр идем, бәлки...

— Юк,— диде Гарифҗан агай теге кешегә.— Синең ояң болай да тулып ашкан. Авыр булыр...

Күрәм, бирердәге кешеләрнең күзләре ялтырый. Җанланып киттеләр. Әнә, тагын берсе тырпалана. Ул да: «Миңа бирегез, бу малайны» дип әйтергә җыена бугай. Теге чандыр йөзле кеше мине кулымнан тотып алды. «Әйдә үземә,— диде.— Синең берьюлы ике әниең булыр».

Барысы да берьюлы көлештеләр. Гарифҗан агай әйтә куйды:

— Кара, белеп тор, Мифтах агай, егетне җәберләмә. Тикшерә торырбыз. Батрак итә күрмә, ул кечкенә әле.

Батрак кем ул? Белми, идем әле. Без урамга чыктык. Мин ашыга-ашыга тирә-якларга карандым. Хәниф абыйны инде алып киткәннәр иде. Мин елап җибәрдем.

— Елама,— диде бу Мифтах дигән кеше.— Елама. Үлгән икән — үлгән инде. Бернишләр хәл юк. Үзе гаепле. Сугышка үзе теләп китте. Кызылармеец була, имеш. Ярлыларга власть ала, имеш. Әнә, алган...

Мин уйлана барам. Кибет хуҗасы, юан корсаклы теге Баязит исемә төште. Ул да бит кызылларны мыскыл итеп сөйләнә торган иде. Йолкышлар, власть алмакчылар, үзләренең рәтле чалбарлары да юк ичмасам, ди-ди көлә иде.

Бу Мифтах атлы бәндә дә шулайрак кылана түгелме? Мин инде үземнең иртәгәсе көнемнең нинди буласын сизенә идем шикелле. Әмма миңа хәзер барыбер. Хәниф абыйның фаҗигале үлеме мине бирткән иде. Күңелем тулып, ташып тора.



## Ят бусага

Килеп җиттек. Тыкрык чатында шактый зур йорт. Коймалары биек. Капкасы түбәле, челтәр-бизәкле, зәңгәр буяулы. Кайсы ягы беләндер безнең хутордагы Бөкре әфәнде йортына да охшый иде кебек. Ә хуҗаның кем икәнлеген мин белмим әле.

Менә ул әкрен генә җил капканы ачты. Без эчкә уздык. Күрәм, бирдә бер генә тәрәзәле, кечкенә генә тагын бер өйчек бар. Тагын да арырак — лапаслар. Арткы якта алмагач бакчасы. Уртада кое. Әмма йортта бер генә мал-туар да күренми. Хәтта тавыклар кыткылдаган тавышлар да ишетелми. Моның маллары кайда икән, дип уйлап куйдым.

Хуҗа мине зур йортка кертеп тормады. Бер тәрәзә каршына туктальп:

— Әй, бире чыгыгыз әле,— дип кычкырды.

Тиз арада йөгерешә-йөгерешә, ишеккә бәрелә-сугыла ике хатын килеп чыкты. Берсе шактый карт, икенчесе яшь кенә, бик матур иде.

— Менә сезгә малай алып кайттым,— диде хуҗа, авызын ера-ера.— Советтан бирел җибәрделәр. Сездән булмады, урамнан бала ияртеп килдем. Буш капчыклар!

— Үз гаебеңне миңа ташлама, әнә, баланы яшь хатыныңнан сора,— диде карт хатын.— Тапкан сүз, сездән булмады, имеш, ә үзең бик булдыклымы соң?

Хуҗа җавап бирел өлгермәде. Бәлки, әле ызгыш та кузгалган булыр иде. Яшь хатын боларның сүзләрен бүлдерде:

— Кем соң бу бала, кайдан килеп адашкан бу якларга?— диде, мине күзәтә торып.— Бигрәк чибәр малай.

— Исеме Сабирулла, мөгаллим Хәниф белән ияреп килгән каяндыр...

Хуҗаның шулай әйтүе булды, яшь хатын кинәт агарынды. Кулларын күкрәгенә куеп йөрәген ниндидер бәладән каплап торырга теләгән кебек итте. «Мөгаллим Хәниф?»— диде ул исе китеп, бик тә гаҗәпләнеп, күзләрен бик тә зур ачып. Беркадәр алга сузылып, нихәл итәргә дә белмәгән төсле аптырап: «Хәниф, Хәниф»...

— Шул, шул, Хәниф инде, Хәниф,— диде хуҗа күзләрен чекерәйтеп, йөзен сырландырып.— Хәниф, Хәниф...

— Үзе кая соң?

— Үземе? Үзе теге дөньяда, шалт иттергәннәр аны. Әнә, теләсәң, мәетен барып кара. Рөхсәт итәм. Әмма кабат минем өемә кайтып керәсе булма. Исеңә төштемени сөйгән ярың? Кара син аны, иреннән дә оялмый. Тел ача...

Яшь хатын өнсез калды. Ул хәзер егылып китәр төсле иде. Хуҗа тагын кычкырынды:

— Бар, өйгә кер. Онытгыңмыни кем хатыны икәнлегеңне? Мин сине алмаган булсам, әле дә хәер теләнеп йөрер идең. Миңа рәхмәт әйт, ахмак!

Сизеп алдым. Бу яшь хатын хуҗаның икенче хатыны икән. Әнә, иреничек ачулана. Хәниф абыйның исемен әйткән өчен генә дә авызыннан ут ата.

Белдем хәзер, Хәниф абый әнә кемне сагынып, әнә кем өчен сагышланып гармун сыздырып уйнаган икән. Әле бит бая гына юлда килгәндә дә ул: «Мине авылда Галиям өзгәләнеп көтә торгандыр»,— дигән иде. Әнә кем булган икән аны өзгәләнеп көткән Галиясе! Юк, Хәниф абый, юк! Көтмәгән ул сине, көтмәгән. Алдаган ул сине, алдаган. Әнә, иргә чыккан. Әгәр син тере булсаң, Хәниф абый, нишләр идең бу хәлне күреп, нишләр идең? Янар идең, көяр идең бу хурлыктан!

Ачуым килде. Мөмкин булса, мин хәзер ул хатынның чәчләренә барып ябышкан булыр идем. Нигә Хәниф абыйны әрәм иттең, ник вәгъдәңне боздың дип бәйләнер идем.

Шунда тагын миңа бер уй килде. Ни өчен хуҗа Хәниф абыйны «шалт иттергәннәр» дип әйтте? Үтерелгән кешене, минем яраткан мөгаллимемне мыскыллау түгелме соң бу? Бу бәндә үзе кем? Күңелемдә шик уянды. Кая килеп эләктем мин?

Яшь хатын теләр-теләмәс кенә өйгә кереп китте. Ул боекты. Йөзе шиңде. Гәүдәсе дә түбән таба иңә төште. Җилкәләре калтыранды, ул елый иде.

Карт хатын болдырда кала торды. Ул әле бик үк карт та түгел кебек. Сыны-буе да төз. Йөзе ачулы, күзләре боз кисәкләре шикелле. Кайчан да булса ул бер генә тапкыр елмайды микән? Бәлки, туры килмәгәндер бу ир янында, сизелеп тора. Ул хәзер ир хатыны түгел, бу йортта бары тик эш башкаручы гына.

Менә хәзер дә ул хуҗаның әмерен көтә иде. Ире әйтте:

— Кунакны Кадыйр янына урнаштырыгыз.

— Көтүче катынамы?

— Әллә түргә алып керер идеңме?

— Уллыкка алдым дисең түгелме соң?

— Аңлый белергә кирәк, тел нәрсә тыкылдамас. Заманы шундый. Ялчы дигән өчен авызыңны пешерерләр.

Аннан соң хуҗа минем буй-сынымны тагын күздән кичерде.

— Сиңа ничә яшь?

— Унберенче китте.

— Бик шәп, иртүк Кадыйр белән көтүгә чыгарсың. Соңрак үзең генә йөри башларсың. Тамагың тук булыр, көзгәрәк өс-башыңны да карарбыз. Үсә төшкәч, эш хакы да алырсың. Менә шулай бервакытны баеп та китәрсең, энем. Ха-ха-ха!

Хуҗа тешләрен ыржайтып көлде. Ә минем тәнемә салкын йөгерде. Яңадан үзебезнең кечкенә генә хуторны исемә төшердем. Бабай, әби күз алдыма килде. Бигрәк тә Мохтар абыйны сагындым. Их, ул биредә булса боларның кирәген бирер иде. Юк шул, ул еракта, бик еракта. Ә Хәниф абый исән булса, мине бу бәндәләр кулына бирер идеме соң? Ул бит миңа укырсың, кеше булырсың, дигән иде.

Хәзер инде минем елыйсым килми. Минем бу хуҗа белән дә, аның хатыннары белән дә талашасым килә. Ничек талашалар? Нәрсә әйтәләр бу чакта? Андый сүзләрне мин әле белми идем. Карт хатын мине житәкләп, теге кечкенә генә тәрәзәле, кечкенә генә өйгә ияртеп алып китте. Кердек:

— Менә шунда Кадыйр белән бергә яшәрсез,— диде ул.— Тиздән кайтып җитәр. Хәзер көтүдә әле.

Мин шыр ялангач, яртылаш караңгы бүлмәдә калдым. Бүрәнә ярыклары тешсез карчык авызы шикелле ачылып торалар. «Нихәл, малай, бездә торырга килдеңме?»— дип ыржаялар. Бер почмакта киң тапчан. Ала-кола юрган, каешланып беткән мендәр кисәге. Урта буйда кыек-мыек аяклы агач өстәл. Берничә урындык. Бер стенада киштә, киштәдә берничә савыт-саба. Биредә яшәүче хуҗаның җиһазлары әллә ни күп түгел икән шул.

Ике кешегә бүлеп торасы да түгел, бер кешегә дә чак кына

житәрлек. Юк, әле күрми калганмын. Әнә бер почмакта лакан, майланып-каралып беткән сөлге дә элеп куйганнар. Минем көләсем килде. Бу сөлгенең үзеннән кулга тап төшеп кала торгандыр.

Менә шулай мин бүген ят бусага аша атлап, ят өйгә килеп кердем. Кичкырын теге Кадыйр исемле көтүче үзе дә кайтып житте. Мине күреп әллә ни исе китмәде. Исәнме, дип күрешкән булды да, чыбыркысын стенага элеп куйды. Лакан алдына барып кулларын юды. Эре-эре генә атлап өстәл янына килеп утырды. Ул үзен биредә, чыннан да, хужа итеп саный иде, күрәсең. Ә мин әле килмешәк кенә бит. Кая миңа мондый дәрәжә? Ул көтүче, ә мин аның ярдәмчесе генә.

— Бик шәп,— диде ул, миңа карый-карый.— Көтү артыннан йөгерә-йөгерә жаным чыгып бетә. Инде икәүләп йөгерербез. Аякларың авыртмыймы?

— Юк, авыртмый.

— Исемең ничек?

— Сабир.

— Ә мин Кадыйр. Абый дисәң дә ярый.

— Абый дияргә, сиңа әле мыеклар да чыкмаган. Килешми.

— Чыгар әле, чыгар.

— Чыккач әйтермен.

Без икебез дә бер-беребезгә карашып көлештек. Кадыйр, чыннан да, миннән иң күбе ике-өч яшькә олырак иде булса кирәк, әйтерең бармы, абый дияргә куша.

Без шулай сөйләшеп торган арада өйгә яшь кенә бер кыз килеп керде. Ул безгә кечкенә аш китергән. Ашы нәрсә диген? Тары боткасы, бер ике-өч кисәк икмәк. Башы кителгән чүлмәктә катык. Аннан соң кыз тәрәзә янына барып кемнәндер шикләнгән кебек итеп башын суза-суза каранды да, яңадан безнең янга килеп, алъяпкыч астыннан бәлеш кисәкләре чыгарып кулларыбызга тоттырды.

— Соңрак ашарсыз, яшерегез,— диде.— Апа биреп жибәрде.

Кыз тиз генә чыгып китте. Кадыйр елмайды.

— Бу кыз минем сеңелем Гөлгенә,— диде.— Минем әле апам да бирелә тора. Күргәнсең, хужаның яшь хатыны ул.

Мин ашавымнан туктап калдым. Бу бик, бик сәер иде бит. Үзе көтүче, сеңелесе ялчы, апасы хужаның икенче хатыны. Гажәпләнмәссеңме? Бернәрсә дә аңламыйм, башым чатный. Ничек була соң бу?

Кадыйр аңлатырга керешге.

— Безнең әти күптән вафат инде. Без әни кулында өчәү калдык. Беребез дә эш тотарлык түгел идек. Үзебез ярлы, үзебез ятим...

Кадыйр нигәдер тынып торды. Ә мин уйландым. Шул минутта бу көтүче минем дә туганым булып китте сыман. Шул өч ятим янында мин дүртенчесе кебек. Кадыйр белән мин әле генә очраштым. Ә ул инде минем бик күптәнге танышым шикелле. Мин дә аңа үзем турында сөйләрмен бервакыт, ул да мине ят итмәс. Ул үзе дә миннән ким дә, артык та түгел.

Кадыйр ботканы кашыгы белән әйләндерә-әйләндерә алып бер-ике капты да табакны читкәрәк этеп куйды.

— Әллә ни ашыйсы килми әле,— диде.— Жаным көя.

Мин нәрсә әйтергә дә белмәдем. Чыннан да, әллә аның ашыйсы килмиме? Әллә сырхаумы? Соңыннан белдем, аның жанын көйдерә торган сагышы да бар икән. Ул тагын сөйләп китте:

— Әти үлгәч, әни дә авыруга сабышты. Бер көн аяк өстендә, өч көн ах-ух урында ята. Ә без аның янына жыелышабыз да карга балалары шикелле кырылдаша-кырылдаша елашабыз. Нишләсен мескен әни, ул да үксеп елый. Ашарга кирәк бит, каян аласың? Ярый әле күршеколаннар анысын-монысын кертә торалар иде.

Көннәрдән беркөнне апам менә бу йортка килеп көннекчә эшкә ялланды. Хужаларның керләрен уа, идәннәрен юа. Аңа кичен бер кисәк

икмәк, әчегән катык, кайчак өсте алынган сөт биреп җибәрәләр. Эш хакы, янәсе. Апам шулай бире килә-китә йөри торды. Менә шул арада Караколакның күзе төшә минем апама...

— Кем ул Караколак?

— Кем булсын, бу йортның хуҗасы — Мифтах. Кушаматы шундый аның.

Мин көлдем. Кызык бит. Әле бая гына хуҗаның йөзенә карап тордым ләбаса, ике колагының берсе дә кара түгел. Ни өчен Караколак булсын ди ул?

— Бер дә көлмә,— диде Кадыйр йөзен сытып.— Колагы кара булса, аңа андый исем дә кушып тормаслар иде, бәлки. Җаны кара аның, җаны! Менә үзең дә белерсең әле.

Кадыйр еларга җитешеп ачуланды. Лач иттереп идәнгә төкерде. «Явыз ул, явыз»,— диде. Шул явыз дигән сүз Кадыйр авызыннан чыгып идәнгә чәчрәп төшеп, җәелеп ятты сыман. Мин дә җирәнеп төкердем.

— Ул Караколак минем апамны сөйгән ярыннан аерып алып әрәм итте,— диде Кадыйр сүзен яңадан башлап.— Әрәм итте!

Мин аңламыйм әле бу сүзләрне. Кадыйрның үзеннән сорарга да куркам. Бигрәк авыр сүз әйтте бит ул. Әмма сорарга кирәк булмады. Кадыйр сөйли торды:

— Шулай такы-токы гына булса да, үз оябызда яши идек әле. Беркөнне безнең өйгә бер карчык килде. Аны Караколак җибәргән. Минем апамны үзенә хатынлыкка димләргә кушкан. Без аны дөбердәтеп куып чыгардык.

— Кызымның ярәшкән кешесе бар,— диде әни теге карчыкка.— Сугыштан кайтканын көтәбез...

Шуннан соң менә Караколак безгә үчләнеп каныкты. Апамны бусага янына да җибәрмәс булды. Янәсе, ачка интегеп дөмексеннәр. Безнең хәлләр көннән-көн бетәшә бара иде. Әнием берчак бик озак эндәшми ятты. Уйланды да уйланды. Бер иртә белән апамны үз янына чакырып алды.

— Бернишләр хәлем юк,— диде.— Балакайлар. Башка чара калмады.

Әнием елый-елый апамны әлеге шул Караколакка иргә чыгарга бу юлы инде үзе димләде.

— Шулай язган, күрәсең,— диде авыр уфтанып.— Гафу ит, кызым, үзем теләп әйтмим бу сүзләрне, нужа әйттерә, нужа куша. Беләм, сиңа үтә авыр булыр. Үзем дә ут йотам. Сине түгел, алла мине каргасын. Синең алда мин гаепле.

Әнием күзләрен йомып озак кына тынып торды. Аннан соң бик авыр көрсенеп сулады да: «Беләм, син Хәнифне көтәсең, кызым,— диде.— Кем белсен, ул исәнме, кайтырмы? Сугыштаниләр булмый...»

Юк, әнием бу сүзләрне дә үзе теләп әйтмәде. Бары тик апамны гына шулай тынычландырырга тели иде ул. Тагын: «Бәхетеңә чыккан өлешеңдер»,— дип тә сөйләнде әнием.

Апам яулык читен чәйни-чәйни, өзгәләнә-өзгәләнә елады. Ул бит Хәниф абыйны үлеп ярата иде, саргая-саргая көткән иде. Кавышырга насыйп булмаган икән шул, булмаган...

Миңа бик сәер иде. Әле бая гына кулына чыбыркы тотып, чалбар балакларын тезенә кадәр сызганып, башына яньчелеп беткән эшләпә кигән, ялан аяклары белән шап-шып иттереп баса-баса бире килеп кергән бу малай әнә ничек олыларча сөйләшә белә икән. Ул хәзер минем алда ничектер үсебрәк китте. Җитди ир кешегә охшабрак калды сыман.

— Менә хәзер бергә яшәп торабыз,— диде ул иң ахырда.— Әнине узган ел җирләдек...

Инде караңгы төшкән иде. Без икебез янәшә тапчанга сузылышып яттык. Юрган ябынып тормадык, болай да бу кечкенә өйдә эссе иде.

## Галия апа гаепле түгел



Иртә белән безне хуҗаның карт хатыны уятты.

— Торыгыз, тор!— диеп акырынды. Янгын чыкканмыни? Бәлки әле янгында да алай кеше куркытырлык итеп кычкырмыйлардыр. Ә менә минем әбием алай итми иде. Ул әүвәл минем башымнан сыйпап, йомшак кына итеп аркамнан чәбәкләр иде: «Тор, улым, әнә, чыпчыклар да уянган инде»,— дип әйтер иде. Ә бу әнә ничек итә. Тавышы да ирләрнеке сыманрак. Пөзеннән әле төн шәүләсе дә китеп бетмәгән.

Ул безгә ашарга да алып кергән иде.

— Тизрәк, тизрәк тыгыныгыз да эшегездә булыгыз,— диде. Терлекләрне иртәрәк кырга чыгарып өлгерергә кирәк. Чыклы үләнне бик яратып ашый алар. Сөтләре дә күбрәк була.

Кадыйрга аерата әйтте:

— Сабирны үзеңнән калдырма, бергә йөгерегез, өйрәнсен. Кырларны да күрсәтә бар, белә торсын.

Мин хуҗаның яшь хатынына юкка гына ачу тотып калганмын. Ул түгел, менә бу карт хатын усал икән. Сөйләшүләреннән сизеп тордым. Күз карашларыннан төшендем.

Кадыйр ашык-пошык җыенды. Чыбыркысын алды. Миңа кечкенә генә капчык тоттырды. Капчыкка нәрсәдер салганнар иде. Киттек. Авыл читенә чыктык. Бераз гына арырак бер йорт күренде. Тирәсе киртәләр белән уратып алынган. Анда сыерлар, сарыклар мыжгый иде.

— Бу безнең лапас,— диде Кадыйр адымнарын тизләтә-тизләтә.— Җәен мал-туарны шунда тотабыз. Тавыкларны да шунда асрыйлар. Җим сибәсе түгел, калдык-постык белән тукланалар. Йомырка да салалар.

Якынрак килә төшкәч, берничә хатын-кыз да, ир затлары да күзгә чалынды. Ерактан булса да танып алдым. Хуҗаның яшь хатыны да биредә иде.

Әнә хуҗа үзе дә күренде. Кадыйр йөгерә башлады.

— Син дә калышма,— диде минем чабуымнан тартып.— Хуҗа шулай куша, әйдә!

Без бик иртә торган идек ләбаса, ә хуҗа бездән дә иртәләгән. Әнә, ул инде безне каршылап тора. Ә мин уйланам. Безнең якларда бу Караколак шикелле байларны кызыллар пыран-заран китерделәр. Әнә Гамзат бай дигәне Төркиягә качып өлгерде. Кибетче Баязит та сызды. Бөкре әфәнде дә каядыр себертте. Ә биредә Караколак-Мифтах дөбердәтеп яши. Ялчылар да тота. Гаҗәпләнмәссеңме?

Әмма мин бу чакларда дөньяда ниләр булганын белмәгәнмен. Соңыннан белдем, илдә НЭП чыккан вакытлар икән бу.

Без шактый ерак китеп бардык. Сыерлар тирә-юньгә таралышып үләнгә ябырылдылар. Кадыйр бөтенләй ачылып китте. Биредә иркен. Беркем күзәтми дә, эш кушып бәйләнми дә. Теләсәң нишлә, йөгер, сикер, теләсәң бие. Кычкыр, җырла. Беркем дә тыймый. Кадыйр шат, көлә, елмая. Менә ул миңа чыбыркысын тоттырды.

— Яле, шартлатып кара әле,— диде.— Ничегрәк чыгар икән?

— Була ул,— дидем. Чыбыркыны Кадыйр шикелле итеп һавага селкеп җибәрдем. Кая ул шартлау, чыбыркы минем үз гәүдәмә елан кебек бөтерелеп уралды. Егыла яздым. Кадыйр көлде.

— Өйрәнәсе бар икән әле сиңа,— диде.— Берьюлы гына булмый ул.

Мин тагын, тагын маташып карадым. Юк, чыбыркы шартламый. Кайчак каеш очы белән битемә тиеп китә дә, пешереп ала. Чыннан да, елан чага диярсең.

Кояш инде офыктан аерылды, күтәрелә бара. Аяк астында чык тамчылары җемелди. Кырдан әрем исе аңкый. Сыерлар үлән җыештыра-җыештыра әкрен генә алга китә бирәләр. Без дә алар артыннан ашыкмый гына атлый торабыз. Сөйләшәбез.

Кадыйр әледән-әле Хәниф абый турында сораша.

— Син аны кайчан күрдең, кайда очраштыгыз?— ди.— Сөйлә әле, Хәниф абыйны мин дә бик ярата идем. Ул бит минем апамның сөйгән кешесе иде.

— Беләм.

— Каян беләсең?

— Хәниф абый үзе сөйләгән иде. Ул мине укырга-язарга да өйрәтте.

— Безне дә укыткан иде.

Без бу авыл мөгаллимен икебез дә бер төрлерәк беләбез икән. Әмма Кадыйр Хәниф абыйның сугышта яралануын, бездә дәваланып ятканын, үз авылын сагынып сагышланган чакларын белми иде. Мин барысын да, барысын да сөйләп бирдем. Хәниф абыйның бу авылда яшәгән бер сылу кызны ничек өзелеп яратканын да әйттем.

Кадыйр башын түбән салып бик озак сүзсез генә барды. Ул нәрсәдер уйлый иде.

— Беләсеңме,— диде соңрак,— ул сылу кыз минем апам Галия. Яратты ул Хәниф абыйны. Теленнән бер генә дә төшерми иде. Үзе әллә ни чибәр дә түгел, гармунын бер сыздырып җибәрсә, йөрәгемне җилкендерә, ди торган иде.

Кадыйр минем күзләремә карады, янәсе, мин ышанаммы, юкмы?

— Әйе шул,— диде тагын сүз башлап.— Хәниф абый шикелле тагын кем генә шулай оста уйный белде икән? Авызында кош сайрата диярсең.

Хәниф абыйның гармунда ничек уйнаганын мин белмимме? Аның гармуны да минем кесәдә бит әле. Кадыйрга күрсәтергә курыктым. Тартып алыр да бирмәс дип уйладым.

Инде төш җитте. Кояш кыздыра. Сыерлар үзләре йөгерешә-йөгерешә елга буена килеп җыелыштылар. Аларны су эчерергә вакыт җиткән иде. Без дә бер куак астына кояштан ышыкланып утырдык. Кадыйр минем кулымнан капчыкны алып, чишеп җибәрде. Аннан бер шешә сөт тартып чыгарды, бөкесен ачып тәмләп карады.

— Фу,— диде,— әчеп беткән.— Тоныккан сөт салган, нәләт төшкән карт аждаһа.

Шунда ук шешәне авызы белән түбән иде. Сөт җиргә агып бетте.

— Нишлибез, нәрсә эчәрбез?— дидем мин исем китеп.

— Борчылма, әмәлен беләм.

Кадыйр нindидер бер куак астыннан шактый зур калай савыт табып алды. Йөгерә-йөгерә сыерлар арасына кереп китте. Озак та узмады, теге савытны тутырып сөт алып килде.

— Үзең сыер көт, үзең сөт тә эчмә, имеш,— диде көлә-көлә.— Мин гел шулай итәм.

— Сизмәсләрме?— дидем.

— Сыер әләкли беләмени?

Без көлештек. Яңа сауган сөткә каты-моты икмәк кисәкләрен җебетеп тамак туйдырдык. Бәрәңге дә сөт белән бик килешә икән.

Кичке якка сыерлар азындылар, төрлесе-төрле якка таралыша башлады. Кайсысы авылга таба юнәлә. Кайберләре тагын да ераграк китәргә чамалый. Кадыйр чыбыркысына эш күп булды. Мин дә йөгерә-йөгерә арып беттем. Табаннарыма ут капты кебек. Кояш яңадан офык сыртына төшеп утырды. Без дә көтүне авылга таба куа киттек.

Тагын төн булды, тагын таң атты. Көннәр шулай уза торды. Кадыйр хуҗа белән каядыр китеп барды. Нindидер машина алып кайтачаклар икән.

Бу төнне мин өйдә ялгыз идем. Инде йоклыйм дигәндә генә минем яныма Галия апа килеп керде. Ут алып тормады. Сизмәсеннәр дигәндер. Беләм, ул бит ят күзләрдән кача-поса гына килгән. Бүлмә караңгы иде. Галия апа мине капшынып тапты. Кочаклап алды, йөземнән үбә-үбә күз яшьләре белән чылатып бетерде.

— Сабирулла, җанашым,— диде әкрен генә.— Миңа Кадыйр барысын да сөйләде. Хәниф абыеңны күз алдымда күргән кебек булдым. Рәхмәт, бәгырем. Инде миңа да сөйлә. Тагын ишетәсем килә. Ул бит минем күңелемдә гел тере шикелле.

Мин сөйләдем. Ә Галия апа калтырый-калтырый елап утырды. Үзе гел минем йөземне сыйпаштырды. Аның куллары шундый җылы, йомшак, үземнең дә елыйсыларым килеп торды.

— Хәниф абыйны кая илттеләр соң?— дип сорадым. Аның турында минем дә беләсем, бик беләсем килә иде.

Галия апа бернәрсә дә белми икән. Сорарга курка. Ә кешеләр бернәрсә дә әйтмиләр аңа. Бераүләре кызганыптыр бәлки, бераүләре үзләре дә куркалардыр бәлки. Сагалып йөрүчеләр азмыни? Тотарлар да Караколакка әләкләрләр.

— Соңгы минутта йөзен дә күрә алмадым ичмасам,— дип өзгәләнде Галия апа.— Гафу итәрлек түгел мине, гомергә онытылмаслык хәсрәтем ул минем.

Озак кына сөйләшми тордык. Бүрәнә ярыгында чикерткә кычкыра. Минем аны тотып аласым килә. Тынсын иде, болай да күңелсез безгә.

Галия апа тагын да сүз башлады:

— Син яхшы йортка эләкмәдең, Сабирулла. Хуҗа явыз кеше. Сине уллыкка алам дигән була. Алдый ул, алдый. Ышанма. Ул сине сынамакчы. Түземлеге нинди икән? Янәсе, ач тотып карарга кирәк, эшләтергә, каршы сүз әйтсә, җәякләргә! Шуннан соң күз күрер, ди...

Галия апа минем кулыма кәгазьгә төргән ниндидер ашамлык тоттырды. Тагын үпте, кочаклады. «Хәзергә хуш, сау бул,— диде.— Үзең генә бел».

Уйланып калдым. Әнә мин кем кулына килеп эләккәнмен икән? Караколак мине үз улы итмәкче! Инде нишләргә миңа? Инде нишләргә, нишләргә дип үз-үземнән сорыйм. Их, үзеңә-үзең җавап та биреп булсачы...

Мин хәзер көтүгә ялгыз йөрим. Менә бу яшелле-сарылы кырлар да, әнә ул сыерлар да, әнә теге авыл да, Караколак үзе дә, аның карт хатыны да әбием сөйләгән әкиятләрдәге җен-пәриләр шикелле күренә миңа. Менә бервакыт Каракаш-батыр бире килеп чыгар да боларның барысын да пыран-заран китерер кебек. Минем күңелдә ниндидер өмет яши әле. Мин нәрсәдер көтәм.

Шулай уйлана-уйлана чирәм өстендә утырам. Тирә-юньдә сыерлар әле бу якка, әле теге якка кила-китә үлән чүплән йөри бирәләр.

Ә мин Хәниф абый гармунында уйнамакчы булып маташам. Бернинди дә көй чыкмый. Ниндидер калын-нечкә тавышлар гына чыңлый. Миңа шулай да ярый хәзергә. Барыбер эч пошканын баса, күңелемне ача...

Чү, нәрсә булды? Бик матур уйнап җибәрдем бит әле мин. Хәниф абый әйтмешли, сагышлы җыр ич бу. Уйный беләм, димәк.

Тагын уйныйм, тагын да моңлырак көй яңгырый ләбаса. Үземнең дә исем китә. Кай арада өйрәнеп алдым шулай матур уйнарга?

Әллә гел аны уйлап, кайгырып йөргәнгәме, кинәт күз алдыма Хәниф абый килеп чыкты. Мине танымаган төсле итеп озак-озак гаҗәпләнеп карап торды. Кулларын як-якка җәеп елмайды.

— Тырышсаң, була ул,— диде.— Әнә ничек көйле уйныйсың, сагышың бар, күрәсең, йөрәгеңдә...

Аннан соң иплэп кенә каршыма килеп утырды. Сыздыр, сыздыр, мин дә тыңлыйм әле, диде.

Мин уйный торам, әллә гармун тавышын ишетепме, әнә әбием дә бабайны җитәкләп килә. Ә бабай минем кәдрә бәрәнемне бавыннан әләктереп алган. Ашыга-ашыга атлыйлар. Әби еректан ук сөйләнә-

сөйләнә килә. «Оныгым минем, ускәнем, ди, булдырасың бит, булдырасың. Безгә дә җыруны тыңларга рөхсәт ит, балакай».
Юк, мин эндәшмим. Авызым буш түгел. Җырым өзелеп калыр. Соңыннан сөйләшербез. Башымны селкәм: «Тыңлагыз, тыңлагыз»,— дим. Янәсе, рөхсәт итәм.
Тукта, нәрсә ул? Офык ягыннан аккош очып килә. Очмый, әкрен генә йөзә шикелле. Менә ул нәкъ минем каршыма килеп кунды. Шунда ук кешегә әверелде. Карасам, ни күрәм? Минем үз әнием лә.баса, әнием! Зәп-зәңгәр күлмәктән. Чәчләре дулкын-дулкын булып җилкәсенә агып төшкән. Йөзе ап-ак, күзләре балкып яна. Әнием миңа нәрсәдер әйтергә тели...
Кинәт баш өстемдә нәрсәдер чыжлап китте. Нәрсәдер сыртымны пешереп алды. Сискәнеп уяндым. Сикереп тордым. Алдымда минем хуҗам — Караколак! Атка атланып килеп җиткән. Кулында камчы уйната. Аты ян-тирәмдә зыр-зыр әйләнгәли. Чак кына таптап үзмый.
Ә хуҗа кычкыра:
— Сыерлар кая, сыерлар? Көтүне таратып бетергәнсең. Мин синең йокыңны ачармын, бетле хәерче!
Хуҗа минем аркама камчысы белән тагын бер сызып алмакчы иде, иелә-иелә ат астына кереп өлгердем. Биредә миңа камчының очы да тиярлек түгел иде. Әмма икенче кизәнүендә камчы минем аркамда тагын бер эзен калдырды.
Хуҗа һаман акрына:
— Сыерлар кая, сыерлар кая?
Ә тирә-юньдә бер генә сыер да күренми иде. Артта да, алда да юк. Үзем дә шүрләдем. Җир йотканмы әллә аларны?
— Беркая да китмә, шунда тор,— диде дә хуҗа атын чаптырып китеп барды.
Беркая да китмә, диде Караколак. Ә мин кая китә алам соң? Мин хәзер кәҗәләрне бәйләп куя торган казык кебек. Кая китереп утыртсалар, шунда басып торырга тиешмен икән. Әмма хуҗам миңа уй салды. Бу турыда әле мин, бәлки, тиз генә шәйли алмаган булыр идем. Чыннан да, миңа беркая да китмәскәме? Ә китсәм? Дөньяда юллар азмыни?
Тиз арада хуҗа сыерларны төрлесен төрле яктан җыештырып куып алып килде. Атыннан төште.
— Күпме игенне таптаганнар, күпме зыян килгән,— диде ул камчысын минем баш өстендә чыжлатып.— Хакын кем түләр? Бәлки, синең акчаң күптер, йолкыш! Совет сиңа эш хакын түләргә куша. Син инде ул акчаны ун ел буена алдан ук алдым дип бел...
Хуҗа тагын әллә нәрсәләр әйтеп бетерде. Янады, куркытты. Ә минем аркамда камчы эзләре яна. Әмма авыртуын сизмим. Еламыйм да, эндәшмим дә. Караколакның йөзенә дә карамыйм. Нигә еларга? Караколак кызгана беләме? Нигә эндәшергә? Ул минем сүзләремне аңлармы? Кем йөзенә карарга? Бу аждаһа йөзенәме?

## И гармуным минем, гармуным...

Ләкин хуҗаның сүзләре бетмәгән икән әле. Ул миңа якынрак килде. Мин чигендем. Ул мине тотып алды.
— Бая мин синең кулыңда ниндидер бер уенчык күреп калган идем,— диде күзләрен чекрәйтеп.— Кая ул? Китер бире!
Мин, әлбәттә, ул Хәниф абый бүләген моның кулларына тиз генә чыгарып тоттырырга җыенмый идем. Хуҗа минем кулларымны артка каерып, кесәмнән гармунны умарлап чыгарды.
— Әһә, менә нәрсә икән, гармун! Каян урладың? Кемнекен?
— Урламадым. Хәниф абый үзе бүләк итеп бирде...

Кинәт үз телемне үзем тешләп өзәрдәй булдым. Ычкынды бит, уйлабрак өлгермәдем. Хәниф абый исемен нигә әйттем әле мин моңа? Юләр! Әнә Караколакның чәчләре үрә басты. Күзләренә ут кабынды. Шыкырдатып тешләрен кысты.

— Әһә,— диде,— әнә кем гармуны икән. Белдем хәзер. Ул явыз шушы нәмәстәсе белән бөтен авыл кызларын котыртып бетерде. Кызыл почмак ачкан булды. Яшьләрне анда шул гармунда уйнап аздырды. Беләм, беләм ул мәлгуньны...

Караколак минем мөгаллимемне шулай яман сүзләр белән телгәли. Укытучы мәлгунь буламы? Ачуым чыкты. Мин дә керпе шикелле энәләндем. «Их, дидем эчтән генә,— Мохтар абыйга әйтәсе иде. Ул бу бәндәнең арт сабакларын укытыр иде. Ничек кенә әле».

Мин Караколакка чытырдап ябыштым.

— Тимә гармунга, тимә!— дип кычкырдым.

Ул көлде:

— Ә, шулаймы?— диде.— Хәниф абыеңның бүләгеме? Менә карап тор...

Хуҗа мине читкә этеп җибәрде. Үзе минем гармунны учына умарлап, йөзен кызартып, бүрттереп бөтен көченә шытырдатып кысты.

Гармун үлеп бара торган кош кебек ниндидер нечкә генә аваз салды. «Коткарыгыз, коткарыгыз»,— дип ялвара иде сыман.

Караколак аны тагы да катырак кысты. Кулын бер әйләндереп тулгандырып алды да гармунны һавага атып җибәрде.

— Менә нәрсә кирәк аңа,— диде, үзе дә башын югары күтәреп күзәтә торды.

Гармун, чыннан да, кош баласына охшап китте. Очты-очты да кинәт канатлары каерылды, башы да өзелеп җиргә төште. Үлде минем гармуным, үлде!

Хуҗа атына атланды.

— Гармуның тю-тю,— диде, минем тирәмдә әйләнгәләп.— Моннан соң Хәниф абыеңны да онытырсың, сыерларны да яхшырак көтәрсең.

Ул тагын нәрсәдер мыгырдана-мыгырдана авылга таба китеп барды.

Ә мине уйлар алды. Хәниф абыйны онытаммы соң мин? Юкны сөйлисең, Караколак! Их, үсеп җиткәч синең белән бер очрашасы иде. Мин синең бу сүзләреңне исеңә төшерер идем.

Мин анда-монда аунап яткан гармун кисәкләрен җыештырырга керештем. Кайсын гына табып алсам да, алар инде яраклы түгел иде. Ә менә җиздән ясалган бер кыйпылчыгы әле таза. Гармунның бу нәкъ тавыш чыгара торган өлеше. Дөресрәге, гармунның үзе. Башка кисәкләр аны бизәр өчен генә, авызга куеп уйнарга җайлы булсын өчен генә кирәк булганнар.

Мин шул җиз кисәкне авызыма куеп өрдем. Карасана, тавыш бирә, чынлап уйный, баягыдан бер дә ким түгел. Шатланам. Тыпыр-тыпыр, сикерә-сикерә куанам. Гармуным уйный, уйный! Тик бу юлы аның тавышы бала елаган төслерәк иде.

Кич булды. Көтүне авылга куып киттем. Кыйналган, арыган, талган килеш йортка кайтып кердем. Биредә инде минем гармуным турында беләләр иде.

Кадыйр бәйләнә калды.

— Сөйлә, сөйлә,— диде.— Нинди гармун, каян алдың? Бик кызык бит.

Мин сөйләп бирдем. Әмма кырда булган «бик кызык» турында бер генә сүз дә әйтмәдем. Бу «өлкән көтүче» я көләр, я кызганыр, дип уйладым. Ә минем көлкегә дә каласым килми, үземне кызгандырырга да теләми идем. Кесәмнән теге гармун кисәген алдым да, еларга җитешеп, Кадыйрга бирдем.

— Менә, ул бүләктән нәрсә генә калды,— дидем.— Җизнәннең

куллары тимер икән. Тотып бер генә кысты.

Кадыйр гармун кисәген арлы-бирле әйләндереп караган арада, авызын Караколак авызы шикеллерәк итеп кыеклатты.

— Жизни, жизни,— дип көлде.— Каян килеп жизни булсын ди/ул миңа? Апамнан бала таптыра, ә үзеннән бала булмый икән. Апамның бер хатынга елый-елый зарланганын ишетеп торган идем. Жизни имеш. Кирәге бар иде бик...

Кадыйр әлеге җиз кисәкне авызына куеп әкрен генә кычкыртты. Әллә ул да уйный беләме? Исем китте. Бу юлы миңа гармун тавышы бик моңлы җыр кебек ишетелде. Юк, бәлки, бу моңлы җыр да булмагандыр. Әлеге шул төрле-төрле тавышлар гына булгандыр. Бары тик минем күңелем генә ул төрле-төрле тавышларны моңлы җыр итеп ишетергә теләгәндер.

Кинәт ишек ачылып китте. Өйгә Галия апа ашыгып килеп керде. Йөзе борчулы иде.

— Нишлисез, балалар, нишлисез?— диде.— Мифтах абыегыз ишетсә, тагын җәнҗал чыгарыр. Ярый әле ул хәзер каядыр чыгып китте. Куегыз ул уенны.

Мин дә, Кадыйр да тынып калдык. Галия апа шул гармун кисәген үз кулына алып карый башлады. Җайлы гына, йомшак кына сыйпады.

— Каян алдың моны, Сабирулла?

Минем өчен Кадыйр җавап бирде:

— Хәниф абый гармуны...

Галия апа кинәт буйга озынайды шикелле, аннан соң тагын да кечкенәрәк булып китте. Нәрсәдер әйтергә теләде, сүз табалмады бугай. Ул минем алдыма килеп тезләнде, тезләремнән кочаклап алды.

— Сабирулла, бәгырем, бу әйберне миңа бир,— диде.— Гомер буе саклап кына тотармын. Беркемгә дә күрсәтмәм, беркемгә дә бирмәм. Йөрәгем янганда кычкыртып куярмын. Хәниф белән сөйләшкән кебек булырмын...

Галия апа үксеп елый. Аның инде тагын сөйләшерлек хәле калмаган иде. Яшькә чыланып беткән күзләре белән миңа карап тора. Кешегә бүләк биргәндә нәрсә әйтәләр? Мин мондый сүзләрне белми идем. Ә Галия апа күз дә йоммый һаман миңа карый, җавап көтә.

Мин эндәшмәдем. Башымны селкеп кенә ымладым. Галия апа аңлады. Җиз кисәген куен эченә салып куйды.

— Рәхмәт, нарасый, рәхмәт!— диде.— Апаңны кызгандың. Онытмам.

## Юл чакыра

Һәр көнне иртә белән сыерларны көтүгә куа барганда мин олы юл аша узам. Тукталам да шул юлга озак-озак карап торам.

Кайсы тарафларга алып бара икән бу юл дип уйланам. Әнә бит кешеләр арбага утырып та, җәяүләп тә, ялгыз-ялгыз да, төркем-төркем булып та каядыр китеп баралар. Аларны ачлык каядыр куа шулай.

Ә нигә миңа да шул олы юл буйлап китеп бармаска? Бара-бара туган якларыма да килеп чыгармын, бәлки? Уйлар артыннан уйлар килә. Күңелем җилкенә. Юл мине каядыр чакырып тора сыман.

Нәрсә көтәм биредә? Мин дә ач ямшим ләбаса. Караколак миңа баш күтәрергә дә ирек бирми. Көтүдән кайтып җитүем була, йортта эш куша. Ачуы килсә, җәяkләргә дә күп сорамый. Мин синең әтиең урынына калган кеше, ди. Син ялчы түгел, минем улым, ди. Суксам да, төртсәм дә хакым бар, миңа совет та бер сүз дә әйтә алмый, ди. Минем өстән әлеккләргә барам дисәң, бар-бар, әмма кабат минем йортыма кайтасы булма, ди. Миңа ничек яшәргә соң биредә?

Ә «өлкән» көтүче Кадыйр нишләр? Хәер, ул хәзер минем белән көтүгә

чыкмый. Аны хуҗа кайларгадыр үзе белән алып йөри. Я кырларга тирес чыгарырга куша.

Бер йортта торып та үз апасын һәм сеңелесен атналар буе күрми. Мин аны кызганам. Ул бит бу йортка «тышаулап» куелган. Аның гомере дә, бәлки, менә шушы йортта узар. Ә миңа нихәл итәргә? Әйтмим, үзем генә беләм.

Мин менә бүген дә олы юлга чыгып бастым. Сыерлар үлән чүпличүпли болынга таба китә бардылар. Бу сәгатьтән соң алар мине беркайчан да күрмәсләр. Караколак инде үзе сыерларын эзли-эзли тирләп пешә-пешә йөгереп йөрсен әле. Их, тешләрен кыса-кыса ачуланып әллә нинди яман сүзләр әйтеп бетерер. «Тотып алсам мин сине, шайтан баласы, муеныңны борып алып дөмектерер идем»,— дияр.

— Юк, дөмектерми генә тор әле, кулың җитмәс, Караколак...

Кечкенә генә капчыгымны җилкәмә салдым да, соңгы кабат авыл ягына карап алдым. Хуш, исән бул, димәдем. Ә менә Галия апаны кызгандым. Ул бит мине ярата иде. Мескен хатын. Китүем турында аңа әйтәсем калган икән. Бәлки, ул миңа юлга азык та биргән булыр иде. Ярый, мин китәм, ә менә ул, Караколак йортында ничек гомер итәр? Газапларга ничек түзәр?

Шулай уйланып торган арада юл өстендә бер төркем кешеләр күренде. Араларында хатын-кызлар да бар.

Мин дә аларга иярдем. Нәрсә булса шул булыр, дидем. Киттем.

Бара-бара бер агай артка әйләнеп карады.

— Һай,— диде кинәт кычкырып.— Безгә бер малай ияргән ләбаса. Каян килеп чыккан?

Юлчылар туктадылар. Минем тирә-ягыма җыелыштылар.

— Кая барасың син, малай?— диде берсе.— Кара син аны, лырт-лырт йөгертә генә...

Чыннан да, мин кая барам соң? Нәрсә дип җавап бирергә?

— Ә сез, үзегез кая барасыз?— дидем, сорауга каршы сорау биреп.

— Без, энем, Ташкент якларына китеп барабыз...

— Нигә?

— Нигә булсын, икмәк алырга.

— Мин дә шунда барам.

Юлчылар көлештеләр. Ә берсе:

— Авыз ермагыз әле,— диде.— Тапканнар кемнән көләргә. Нужасы булмаса, шул яшеннән җилкәсенә капчык асмас иде. Ятим бала, күрәсең.

Каян белеп алды. Миңа сөйлисе дә калмады. Юлчылар бер-берсенә карашып бераз тынып тордылар. Мине баштанаяк күзләп чыктылар. Күрәсең, минем ятимлегем йөземә үк язылып куйган шикелле булгандыр.

— Исемең ничек синең?— диде тагын бер шактый олы агай.

— Сабир.

—Әллә Казан губернасыннан китереп ташладылармы үзеңне бу якларга?

— Әйе. Шуннан,— дидем.

Хәер, туган җиремнең кайсы якларда икәнлеген мин үзем дә рәтләп белми идем.

— Әнә, кайлардан килеп адашкан бу мескен бала,— диде тагын бер юлчы.— Кайтам дисәң дә тиз генә барып җитә алмассың. Анда да ачлыктан кырылалар икән...

— Ярый, аллага тапшырдык,— диде теге олы агай.— Киттек. Станциягә шактый ерак әле.

Без кузгалдык.

— Әлегә кадәр кая йөрдең дә, нәрсә эшләдең?— диде бер яшь кенә хатын, минем йөземә карый-карый.— Бик кечкенә бит әле син, балакай.

— Әнә теге авылда яшәгән идем мин,— инде еракта калып барган авыл ягына кул төртеп күрсәттем.—Әнә ул авыл.

— Нишләдең соң син ул авылда?

— Бер хуҗада сыерлар көттем. Куып чыгарды. Теләсәң кая китеп югал, күземә күренмә, диде.

Әлбәттә, мин бу юлы бераз алдаштым. Качып киттем дип әйтергә курыктым. Андый кешене төркемгә кем кертә?

Быел бу якларда да игеннәр уңмас дип сөйләшәләр инде. Әнә җәй уртасы. Җиргә әле бер генә тамчы да яңгыр яуганы юк. Ачлык шомы бу авыл кешеләрен дә хафаландыра башлады.

Бервакыт Караколак өендә дә минем өчен өстәлгә кашык куелмас иде. «Караколак мине куып чыгарды»,— дип әйткән сүзләрем раска киләчәк иде. Бу юлчыларны алдавым өчен, миңа үкенәсе дә, оялясы да түгел иде.

Шунда тагын бер юлчы сүзгә кереште:

— Кара җан икән ул синең хуҗаң.

— Караколак диләр аны.

— Белеп кушканнар аңа ул кушаматны.

Юлчылар үзара һаман гәпләшеп бара бирәләр.

— Менә бит,— диде берсе,— Совет властен сугышып, кан коеп алдык. Тигезлек булыр, дидек. Ә байлар әнә нишлиләр, көпә-көндез ятим баланы куган да чыгарган.

— НЭП заманы хәзер,— диде тагын кемдер.— Байлар канат җәя. Хәзер аларга ялчы тотарга да рөхсәт итәләр. Әнә, кибетләр ачып җибәрделәр, тагын әллә нәрсәләр эшләп маташалар. Гөрелдәтеп сәүдә итәләр...

Без шулай бара торабыз. Юлчылар ниндидер яңа законнар турында кызып-кызып сөйләшәләр. Минем аңлавымча, әлеге Караколакның миңа бармагы белән дә тияргә хакы булмаган. Ул миңа ай саен эшем өчен акча түләргә тиешле икән. Кышын мине мәктәптә укытырга да кушылган аңа. Ә мин боларның берсен дә белми идем. Хәзер инде кирәге дә юк. Мин юлда...

Менә бервакыт пар ат җиккән тачанка безне куып җитеп, юл тузаннарын уйнатып узды да, алга чыгып кинәт туктап калды. Тачанкага ике солдат утырган иде. Картузларында кып-кызыл йолдыз ялтырый.

— Стоп!— диде бер солдат, тачаңкадан сикереп төште дә.— Стой!

Юлчылар туктадылар. Ә мин куркып киттем. Нәрсә булыр? Солдат бил каешына кыстырган наганын тартып алып, безгә төзәп тотты.

— Кая барасыз?

— Икмәк алырга, Ташкентка,— диде бер юлчы.— Күрмисезмени?

— Кемдә корал бар?— дип кычкырды солдат.— Кемдә корал бар? Хәзер үк минем кулыма китереп тапшырыгыз!

— Нинди корал, каян килсен ул безгә?— диде бер юлчы кулларын як-якка җәеп.— Без ач кешеләр...

Әмма солдат бу сүзләргә генә ышанмады. Ул күзләрен кысып йөзләребезгә усал итеп карый-карый барыбызны да тенти башлады. Кесәләрне капшады. Капчыкларны актарды.

— Без Губчека вәкилләре,— диде.— Бандитларга каршы көрәш отрядыннан. Уйлыйм ки, тагын аңлатып торырга кирәк түгелдер.

— Әллә безне бандитлар дип беләсезме?— диде юлчылар арасыннан тагын берәү.— Ачлыктан качып барабыз. Менә без кемнәр!

Солдат шулай юлчыларны берәм-берәм тикшерә-тикшерә миңа килеп китте.

— Ә син?— диде,— син кая болай тәпи-тәпи йөгерәсең?

— Ятим ул, ятим,— диде теге яшь кенә хатын.

— Син дә икмәк алырга барасыңмы?

— Әйе,— дидем мин.— Икмәккә!

Солдат көлеп җибәрде.

— Син,— диде ул, икмәкле җиргә җитә-җитә тәнеңдә жаның да калмас. Аннан соң сиңа икмәк тә кирәк булмас.

Юлчылар тагын көлештеләр.

— Анысы дөрес,— диде берсе.— Ул әле оясыннан яңа гына очып чыккан кошчык.

Солдат кулларын җәеп мине тотып алыйм дигәндә генә, мин мәче кебек бөтерелдем дә тегенең култык астыннан атылып чыгып йөгердем. Әмма тачанкада утырып торган солдат сикереп төшеп, мине куып житте, тотып алды.

— Синең кебекләрне генә тоткан бар безнең,— дип көлә-көлә мине арбага китереп салды.— Юләр, тик кенә ят шунда.

Мин куркуымнан телсез калдым кебек. Селкенә дә алмыйм. Солдат куллары тимер кебек каты иде. Хәзер инде бередән генә карап ятам. Теге солдат наганын кире бил каешына кыстырып куйды да:

— Ярый, туганнар,— диде.— Хәерле юл сезгә. Әйләнеп кайтырга насыйп булсын...

Аннан соң картузын салып кулына тотты. Юлчыларга иелеп баш иде.— Хушыгыз,— диде.

Юлчылар да сүзсез генә баш иделәр. Берсе, ап-ак сакаллысы:

— Рәхмәт, улым, яхшы сүзең өчен,— диде.— Котыбыз алынган иде, үзебезнекеләр икәнсез.

Солдат тачанкага менеп утырды.

— Киттек,— диде иптәшенә.

Тегесе, дилбегәләрне тартып, арткарак тайпылып куйды. «Һай!»— дип бер кычкырды. Атлар башта сикерешкән кебек итеп арт аякларына басып күтәрелделәр дә дөбердәтеп алып киттеләр. Ә мин: «Җибәрегез мине, җибәрегез!»— дип кычкыра-кычкыра тыпырчындым. Кабат мине авылга алып кайталар, ахрысы. Курыктым.

— Авылга кайтмыйм, кайтмыйм,— дип елый башладым.

— Тыпырчынма,— диде бер солдат.— Авылга кайтырга уйламыйбыз да. Юләрләнмә. Туры станциягә җилдерәбез. Аннан шәһәргә озатырбыз. Әллә кайларга китеп икмәк эзләп йөрисе түгел. Сиңа дигән икмәк балалар йортында. Бәлки анда ак калач та бирәләрдер әле...

Икенче солдат көлде. «Шәйләдеңме,— диде.— Шәһәрдә яшәрсең». Шул арада ул минем борыныма да чиертеп алды. Мин дә көлеп җибәрдем. Авылга бармыйбыз икән. Караколак көтә торсын... Чыннан да, мин бирегә кабат кайтаммы соң? Юк, юк! Мин бу ике сүзне үз-үземә ант биргән шикеллерәк итеп әйттем.

Әмма ашыкканмын. Миңа әле ул Караколак белән тагын очрашырга туры киләчәк. Билгеле, бу турыда да язмыйча булмас...

Ә хәзер мине ике солдат тачанкага утыртып үзләре белән каядыр алып китеп баралар.

Шактый озак бардык. Атлар йомшак кына, биегән төсле итеп кенә атлый бирәләр. Тачанка сиртмәсе бишек шикелле чайкала. Рәхәт. Солдатлар тәмәке кабызып җибәрделәр. Берсе минем башымнан сыйпады.

— Минем дә өемдә синең тикле бер шельма калды,— диде.— Үскәндер инде. Күптән күргән юк үзен. Сагындыра шайтан малай...

— Менә бандитлар белән исәп-хисапны төгәллибез дә кайтабыз туган якларга. Инде озакка бармас,— диде икенче солдат.— Башлар исән-сау булсын.

Бандитларны мин дә беләм бит. Беләм генә түгел, үз күзләрем белән күргәнем дә булды. Солдатлар шулай үзара сөйләшеп утырганда мин дә сүзгә катнаштым.

— Минем дә Хәниф абыйны алар үтерде,— дидем.— Явызлар.

Солдатлар исләре киткән кебек бер-берсенә караштылар. Шунда берсе:

— Хәниф, Хәниф,— дип әйтә-әйтә уйланды. Ул шул Хәниф исемле кешене исенә төшерергә тели иде, күрәсең.

Аннан соң кинәт кенә иптәшенә төртеп алды да:

— Беләбез аны, беләбез,— диде.

Иптәше дә әйтә куйды:

— Теге мөгаллим Шагалиевмы әллә?

— Әйе, әйе, ул үзе минем Хәниф абыем,— дип кычкырдым солдат абыйның күзләренә керердәй булып. Тагын нәрсә әйтер икән? Көтә тордым. Солдат абый сөйләп китте: «Без, энем, синең ул Хәниф абыең белән якыннан танышлар, дияргә була. Аны больницага алып килгән чакта ул, чыннан да, үлгән шикелле һушсыз калып яткан. Каны чамасыз күп аккан булган. Докторлар да аны үлгән дип белгәннәр башта. Соңрак тәненә укол кадагач, мөгаллим күзләрен ачкан. Тизрәк аңа кан салганнар. Ул аңына кайткан. Ярасы шактый авыр дигәннәр иде. Әбер заманны безнең командир аның үзен күреп, сөйләшеп чыкты. Безгә бит бандитларның кайчан, кайда һөҗүм иткәнлекләрен белергә кирәк иде».

— Әнә син кем икәнсең, малай. Хәзер белдек,— диде икенче солдат.— Хәниф абыең синең хакта бик кайгырып сөйләгән иде.

— Хәниф абый исән исән!— дип адарына-адарына солдат абыйның кулларына ябыштым.— Хәзер кая соң ул?

— Менә анысын әйтә алмыйбыз, энем. Гафу ит. Аны кайсыдыр шәһәргә госпитальгә озаттылар бугай. Әллә Саратовка, әллә Царицынга...

Солдатлар тагын үзара нәрсәдер сөйләшә-сөйләшә бардылар. Ә мин уйга биреләдем. Ни әйтсәң дә, миң бит бер дә көтмәгәндә генә шатлыклы хәбәр ишеттем. Шикләнергә урын калмады. Хәниф абый исән. Әгәр үлгән булса, аның мәетен авылга кайтарып җирләгән булырлар иде. Ә авылда мондый хәбәр беркемнән дә ишетелмәде. Юк, укытучым Хәниф Шагалиев исән! Бәлки, әле без күрешербез. Шул өмет минем күңелемә килеп керде. Мин шат идем...

Өметләрем мине алдамады. Шактый вакытлардан соң миңа яңадан Хәниф абый белән очрашырга язган икән. Бу турыда да берчак сөйләрмен. Моңа кадәр әле җәй үтеп, көз җитәсе бар. Тагын нәрсәләр генә, тагын кемнәрне генә күрмәм әле мин.

*Дәвамы киләсе санда*

## Нури Арсланов

### Яшенле төндә

Яшен, кабыналмаган учак төсле,
Бер яна, бер сүнә:
Әле балкып китә җирнең өсте,
Әле төнгә дүнә.

Зевс үзенең күген күкрәткәндә,
Хозыр айкый камчы:
Ут сүндереп йөри микән әллә,—
Коела миллиард тамчы.

Хозыр-Ильяс белән Зевс күктә
Тартышалар имеш.
Ни кадәрле тартышмасын, күптән
Икесенең бер эш:

Икесе дә коя яңгырларын
Җиргә-игенлеккә.
Яшеннәрне, күкләр даңгырдавын
Юрыйк иминлеккә.

Дипломатлар да нәкъ шулай булсын,
Бәхәстән тәм тапсын:
Күктәй күкрәп, әйдә, нәгърә орсын,
Яшен булып атсын;

Янгын булып кабынмасын гына,
Койсын изге яңгыр.
Җиһан халкы, тезгенне ал кулга,—
Җирне исән калдыр!

*1983*

### Кырын карап

Кояш чыга кырын карап тәрәзәмә:
Корт иле бал җыя ахры кәрәзенә,—
Гөжләп тора, чәчәкләрдә балкый чыклар,
Чыр-чу килә сыерчыклар да чыпчыклар...

Гаҗәп матур дөнья! Кырын караса да...
Ул сизми дә, җанга күпме яра сала:
Яралардан чыныгып, янып-көеп яшә,
Шулай яшәү җанны гүзәллеккә дәшә.

Баксаң һәрни яшәгәндә кирәк икән,
Фәкать бәхет кенә җирдә сирәк икән...
Белми кеше сирәк бәхетнең дә кадерен,
Борчымаса күп яралар йөрәк-бәгърен.

Йөз чытмадым язмышыма кырын карап,
Посарга җай эзләмәдем борылгалап,
Халкым белән тоташ кыя булганга мин —
Ни булса да какшамаслык булды зәмин!

Кызлар гына үрти хәзер кырын карап;
Зур кояштан китеп алып алтын тарак
Бирсәң иде шул кызларның кулларына! —
Шатлансыннар әйдә бәхет нурларына

Һәм әйтсеннәр әйдә: «Әллә бу саташа?!.»
Юк, саташу түгел, карыйм кояш аша:
Энҗе чыклар бизәсеннәр иртәгезне,
Мин гел сөйдем сезнең назны, иркәгезне.

Кашлар — җәя, керфекләр — ук сезнең, шуклар,
Уятсыннар һаман күңелне шул уклар:
Хәят чишмәм әйләнмәсен бер дә бозга,
Сезнең матурлыкка карап кызыга-кызыга.

Ачык тәрәзәмнән кояш чыгышын күрәм,
Кояш белән бергә балкыйм, күтәреләм.
Җир караткан көнгә күңел тәрәзәмне,
Гүя шуңа дөнья белән мин дә мәңге!

*1983*

## Монгол аты

Бала чакта мин бәйгеләр күрдем!
Сикереп менә идем ияргә:
Өлгералмый иде атым-күңелем
Тояклары җиргә тияргә.

Чегәннәрдән бер ат сатып алдык,—
Колагирем әле дә исемдә,
Яшәп булсын имеш, хәйран калдык,
Шул кадәрле ядрә тисен дә:

Чүпли идек — муены тулы кургаш,
Борчак булып баткан, сибелгән,—
Исән кайткан бит әй шул тинтәк баш
Тәнге «ауга» киткән җиреннән...

Мин дә киттем, ләкин башка «ауга»
Кырык беренче елның көзендә,

Илем белән каршы чыктым яуга,
Нәфрәт, өмет иде күземдә.

Нинди генә хәлләр булмый монда!
Атышларның тыныч чагында
Чакырттылар штаб батальонга;
Юлда бер ат йөри чабында,

Монгол аты, пони дисәң — зуррак,
Асау күренә — йома колагын...
Үтеп барган булып тезгеннән «һап!» —
Тотып алдым дала кунагын.

Карулашкан була; сикереп менгәч
Каулау-фәлән бер дә көтмәде,
Аякларым җиргә тияр-тимәс,
Алып очты, исе китмәде.

Кем белән бит шаяртмакчы, тапкан!
Чабып барган көйгә ялтара,—
Татар-монгол дигән тарих таккан
Безнең исем гүя ят аңа.

Тынды малкай, кыланмады юкка.
Тынар дидем бер көн даулар да:
Без кидергән тимер авызлыкка
Буйсынырлар әле яулар да!

Буйсындылар! Ә мин һаман атта.
Кырык еллык иминчелектә
Җитмешләрдән уздым, тыныч чакта
Яшәп була икән ничек тә.

*1984*

## Кинҗә [1]

Нарасыйда казакъ иле мәкян бирде,
Еллар узды, акын диеп чапан бирде,
Картлыгымда җырларымны нәшер итеп,
Ил күзендә абруй бирде вә дан бирде.

Андый бәхет бик үк килми бүтәннәргә.
Казанда да гөлләрем күп түтәлләрдә!
Рәхмәт инде сезгә, дуслар, Идел-йортның
Изге йөген күтәргәнне күтәргәнгә.

Үз халкым дип көйдем, сөйдем Казанымны,
Мин Иделдән ауласам да язарымны,
Ала-Таудан яшәсәм дә еракларда
Онытмадым киң күңелле казагымны.

И дивана да мин, уйлыйм, китә исләр,—
Далаларым миннән калса имеш нишләр?!.

[1] Кинҗә — гаиләдә кече бала.

Шушы илнең бер үз иткән кинжәсемен,
Ничек итеп суынсын ди җылы хисләр!

Йөргәнем бар кымыз эчеп кызма гына,
Тәмам төшеп дастаннарның тозагына,
Айлы төндә алты бакан[1] атынганда
Гашыйк булып сылу казакъ кызларына.

И мөкатдәс зәңгәр хыял далалары!
Еш кузгала татлы йөрәк яралары:
Атка менеп җилләр белән ярышканда
Без булганбыз икән әкият балалары!..

Күкләреңдә мин йолдызлар җемен беләм,
Күкрәгеңдә күкрәп үстем җылың белән.
Акыннарның әйтешенә тыйнаклык хас,—
Төгәллимен җырымны үз җырың белән:

«Әнә ерак тау башыннан күч киләде,
Күч артыннан бер тайлак[2] буш киләде;
Төшкәндә син исемә, хәйран илем,
Мөлдерәп ике күздән яшь киләде...»

## Эзоп теле

Телен ачкан Эзоп җанварларның,
Кинаягә азык күренсә.
Эзоп теле белән язганнарым
Төрле җәнлек булып терелсә,

Керсә әгәр халык йөрәгенә,
Яманнарга нәфрәт уятып,—
Мин үкенмәс идем йөргәнемә
Кулларымда каләм уйнатып.

Бер шаян, бер усал Эзоп теле:
Ничек язсаң да СИН җаваплы! —
Һәр хак сүзнең җирдә кала өне,
Кешеләргә булса яраклы.

Эзопка соң, ярлы акыллыга
Әллә ансат булган дисезме?!.
Язмыш саран булган алтынына,
Ләкин биргән үлмәс исемне.

*1984*

## Ни җил, ни буран

ЭЛЕГИЯ

Төн. Тышта якты. Түшәктән торам;
И быелгы кыш — ни кар, ни буран.
Тәрәздән карыйм: күктә Ай гына,
Саргайган ул да гел яктыртудан...

Минем күк ул да тын, япа-ялгыз:
Янда ни җиңги, ни шаян балдыз...
Нурлы булса да йөзләре моңлы:
Исәпкә бар да, калдым ди сансыз.

Дәстерхан япкан өстәлдә шәраб,
Җамнар мөлдерәп торалар карап;

---

[1] Алты бакан — таган.
[2] Тайлак — яшь дөя.

Мине үртәпме Ай кызы Зөһрә
Кылана күктә йолдызлар санап.

Кемне көтәмдер, күз алмыйм юлдан,
Бер җан иясе... Тып-тыныч урам...
Чү, кинәт чаттан килеп чыгар күк;
Ләкин күңелдә ни җил, ни буран...

*1984*

## Каратургай [1]

*Қартурғай,*
*Өштың зурға-й-й,*[2]
*Бичара, чырылдадың җиргә қунмай!*

*Бөек казакъ акыны Акан сирә*

Киң далалар буйлап, атын каулап,
Акан чыккан иртә таңнарда,
Җыры белән күңелләрне аулап,
Кошы белән төлке ауларга.

Җирән-чичән кебек чая иргә
Үчеккәннәр данга комарлар.
Кул салганнар туйда Колагиргә[3] —
Чабышкының юлын буганнар...

Буалмаган биләр тик ир юлын,
Шагыйрь Акан калган мәйданда;
Тыялмаган язмыш дала улын,
Ул ант иткән мәңге сайрарга!

Ярышлардан Колагиргә килгән
Бүләкләрне, төрле тарафтан,
Уртаклашып ярлы-ябык белән
Хатом-Тайдай илгә тараткан.

Акан сире дип йөрткәннәр аны:
Халык ягына баскан бизмәнгә,
Халык моңын, сагышын, халык зарын
Җырга мәрҗән итеп тезгәнгә.

Бәхетсезлек гел корса да тозак,
Ул җырлаган бәхет турында,—
Көн килер дип өметләнгән озак...
Әнә бүген аның кулында

Тагын ау беркете — иске дусты,
Ул яраксыз инде сунарга:
Картлыгыннан сукырайган кошны
Чыгарган тик һава суларга.

Каратургай дигән кушаматка
Кыран бөркет күптән күнеккән.
Шонкарлыклар калган инде артта,—
Азат инде ул күн бүректән...[4]

---

[1] Каратургай — сыерчык. Шагыйрь үз бөркетен шулай атаган.
[2] Зурга — көчкә. Казакъча.
[3] Колагир — шагыйрьнең чабышкысы.
[4] Күн бүрек — томага — ау кошының күзләрен каплар өчен киертелә. Кошны ауга очырганда гына салдырыла.

Акан җырлый, бөркет тыңлап бара,
Шул кадәрле уртак уйлары.
Каратургай канат җилпеп ала,
Шагыйрь сыкрый... Язмыш уйнавы

Җан тетрәтә,— шуннан җырлар туып,
Нечкә хисләр кылдай тартыла.
Якты яшьлек баеган кояш булып
Төшкән инде офык артына...

Корамса диләр атамны,
Акан диләр атымны.
Каратургай — шоңкарым,
Колагирем — толпарым,
Без өчәү бергә идек,
Ауларда йөргән идек.
Колагирем колады[1] —
Чукмар екты поракны:
Җан ачынды, тынмады,
Гомер буе җылатты...
Атсыз батыр яу чапмас,
Күзсез бөркет ау тапмас...
Күзнең күреме беткән,
Көннең күреге[2] беткән.
Җир яшел түгел инде,
Караңгы күгең инде,
Караңгы уңың-сулың,
Киселде, шоңкар, юлың...
И-һе-һей, Каратургай!
Киселде, шоңкар, юлың...

Җырлаган ди шулай Акан сире,
Тараткан ди җилләр ул көйне.
Бәрәкәткә тулсын иде җире,
Иминлектә булсын киң иле!

Кош талпынган кинәт, әсәрләнгән,
Биек күккә килгән мәнәсе...
Элеккедәй киереп канат җәйгән,—
Язмышыннан килгән көләсе:
Күтәрелген бөркет болытларга
Каратургай булып бөтерелеп,
Карап калган кешеләр карт шоңкарга
Сокланып һәм шиккә өртелеп.

Акан тойган үзенең картлыгын да
Кинәт шушы бөркет хәлендә:
Ул сискәнеп киткән кара шомга,
Боз чымырдап үткән тәнендә.

Акан сизгән Каратургай уен,
Яшьләр тәгәрәп төшкән күзеннән...
Кылыйм дисә горурлык үз туен
Калмый икән катрә түземнән.

Горур җанга яшәү ник зарланып?
Киртә бармы рухы көчлегә! —
Кара яшен булып йомарланып
Төшкән бөркет ташлар өстенә...

1983

---

[1] Колады — егылды, ауды.
[2] Күреге — күрке.

**Вакыйф Нуруллин**

# ИКЕ УРАМ АРАСЫ

ПОВЕСТЬ

**Я учился не только у тех,**
**кто из рам золоченых лучился,**
**а у всех, кто на паспортном фото**
**и то не совсем получился.**

***Евгений Евтушенко***

## Сүз башы



Илле яшь — гомер тавының иң биек ноктасы. Шуннан соң адәм баласы таудан түбән төшә башлый. Кайберәүләр ул таудан ипләп җайлап, ашыкмыйча гына төшә. Ә кайберәүләр бик тиз юырта: алтмыш тирәләрендә үк финиш сызыгын үтеп, авырмый да картаймый да торган җиргә — дөнья мәшәкатьләреннән, шатлык һәм кайгылардан, ызгыш-талашлардан, бер-береңнән көнләшүләрдән, алдашулардан икейөзлеләнүләрдән, ялагайланулардан азат булган мәңгелеккә китеп баралар.

Безнең токымда тауны әкрен ипле төшүчеләрдән мин белгәне тик бер Солтан[1] бабай гына. Аның ничә ел яшәгәнен төгәл генә әйтү кыен, чөнки туу турындагы таныклыгын аңа тик үзенең әйтүе буенча, чамалабрак кына язып биргәннәр. Шул таныклыгы буенча туксан өченче яшендә вафат булды ул. Ләкин, ул хәтерләгән вакыйгалардан чыгып фикер иткәндә, таныклыгында язылганнан биш-алты яшькә олырак булырга тиеш иде. Хәер, туксан икесе дә аз түгел бит инде... Аннары килеп, әнием дә җитмешкә җитеп үлде. Шулай булгач, әни ягыннан минем хәлләр бөтенләй үк өметсез түгел. Ә менә әти ягыннан мактанырлык эш юк.

Хәзерге заман күзлегеннән караганда бик үк ышанасы да килми: бер гаиләдә унике бала булган безнең әтиләр. Тугызы — малай. Өчесе — кыз. Ләкин шуларның иң озак яшәде дигәне дә утыз тугызынчы яшендә вафат булды. Минем әтидән унбер яшькә кече Миңнулла абый иде ул. Колхоз председателе булып эшли иде. Колхозы алга барсын өчен җаны-тәне белән тырыша иде. Хаклы булуына инанган чагында район башлыкларына да баш бирми: аяк терәп сөйләшә торган иде. Ләкин озак эшли алмады. Бөтен күңелен биреп эшләп йөргәндә яраткан эшеннән чыгаруны күтәрә алмаган булса кирәк, бер көнне иртән кибеткә эшкә барырга дип киенә башлаган җиреннән йөрәге ярылып (хәзергечә әйтсәк, инфарктган) кинәт кенә үлеп киткән иде ул. Мин ул чакта университетта укый идем.

Больницаның баш врачы Иванов Миңнулла абый белән әле сугышка кадәр, Нәҗем бабай авырган заманнан ук таныш, шуңа аның башыннан кичкән хәлләрне әйбәт белә иде. Абыйның йөрәген карагач әйтте:

---

[1] Солтан авылында гомер кичерде ул. Шуңа без аны Солтан бабай дип кенә йөри идек. Чын исеме — Мөхәммәтфатыйх.

— Хаксызга рәнҗетелү менә ни эшләтә кешене! Абыең бөтән тыныч рак җирдә эшләсә, бу йөрәк әле тибәр дә тибәр иде. Хо-хо-хо-хо! Без, врачлар, кешене саклау, аны мөмкин кадәр озаграк яшәтү өчен тырышабыз. Ә кешеләр үзләре бер-берен ашап, безнең хезмәтне юкка чыгарып баралар...

Әнә шулай, бәйгедә вакытта йөрәге ярылган чабыш аты шикелле, кинәт кенә үлде дә китте безнең абый. Бүгенге көннең алдынгы председательләре белән очрашканда һәм аларның фидакарь хезмәте турында уйланган чакларымда мин һәрвакыт Миңнулла абыемны күз алдыма китерәм. Һәм, бүгенге уңышларыбыз өчен без әңә шул абыем кебек кешеләргә бурычлы, бу уңышлар алар башлаган эшләрнең табигый дәвамы дип, куанып һәм горурланып куям.

Әлбәттә, безнең абый да фәрештә түгел иде. Житәкче буларак хөрмәт итсәм дә, миңа аның бик үк ошап бетмәгән яклары да бар иде. Ул хакта алда сүз булыр әле. Монда мин аны әтием белән бертуган, унике бала арасында чагыштырмача иң озак (утыз сигез ел) яшәгән кеше буларак кына телгә алып киттем. Ә калган унбер баланың унысы балигъ булганчы ук вафат булып беткәннәр. Тап-таза, туп шикелле тәгәрәп йөри торган җирләреннән я берәр чир эләгеп, яисә берәр төрле бәхетсезлеккә юлыгып, үлә барган алар. Әбиебезнең баланы күп табуы да әнә шуңа бәйләнгән: берсе тормаса, берсе торыр дигән өмет белән гомер иткәннәр, күрәсең.

Унике баланың Миңнулла абыйдан кала иң озак яшәгәне — минем әти. Бу якты дөньяда нибары егерме дүрт ел яшәгән ул. Миңа хәзер илле яшь. Мин аннан ике мәртәбә олырак. Ләкин бу формаль яктан гына шулай. Беркем дә үз атасыннан олы була алмый!

Мин әтиемнең төсе-бите, буе-сыны нинди булганын белмим. Чөнки ул үлгәндә миңа өч яшь кенә булган. Автобиографик әсәрләрендә: «Мин үземне-үзем ике яшьтән белә башладым», «Мин дүрт яшьтән шигырь чыгара башладым», — дип язучылар бар. Бәхәсләшмим, бәлки андый кешеләр дә була торгандыр. Минем әти 1938 елда ук үпкә авыруыннан үлгән. Мин аны хәтерләмим. Әтинең фоторәсеме дә калмаган. Ул елларда авыл җирендә фотоаппаратлар юк, паспорт алырга кирәк булган кешеләр районга яисә Казанга барып кына рәсемгә төшеп кайта торган булганнар. Ә безнең әти, андый хаҗәте булмагач, төшеп тормаган. Шуңа мин аның кыяфәтен белмим.

Ләкин бу әле мин әтисез яшәдем һәм яшим дигән сүз түгел. Гомерем буе әтиле булып яшәдем мин. Хәзер дә шулай яшим. Әнием сөйләгәннәрдән, әтине белгән кешеләр сөйләгәннәрдән чыгып, мин аның сурәтен бала чактан күңелемдә үзем тудырдым. Кечерәк кенә буйлы, чандыр гәүдәле, коңгырт кара күзле, куе кара кашлы, гел балкып, нур сибеп тора торган ачык йөзле, дөньядагы һәр яңалык белән танышып баручы һәм һәрвакыт кешеләргә ярдәм итәргә әзер торган сизгер һәм акыллы, егерме дүрт яшьлек ир-егет ул. Ә мин аның янында тугыз-ун яшьлек малай гына. Элек тә шулай иде, хәзер дә шулай. Мин олыгайган саен ул да рухи олыгая бара. Мин аның белән һәрвакыт сөйләшәм: кайгыларым булса — кайгымны, шатлыгым булса — шатлыгымны уртаклашам. Киңәш кирәк чагында да аңа мөрәҗәгать итәм. Ул мине беркайчан начарлыкка өйрәтми. Гел акыллы киңәшләр генә бирә. Чөнки ул мине яратә, хәлемне бөтән теләсә кемгә караганда яхшырак аңлый... Шул ук вакытта таләпчән дә. Ялгыш эшләр эшләп ташлаган чакларымда бер дә кызганып тормый: маңгайдан тирләр бәреп чыкканчы «пешекли...» Шундый әтием булганга мин куанып-горурланып йөрим. Тик менә яшьли, бик яшьли китеп барган шул...

Әтинең әтисе Нәҗем[1] бабай да әллә ни озын гомерле булды димәс идем. Илле дүртенче яше белән генә бара иде үлеп киткәндә. Кырык икенче елны үлде ул. Мин аны бик яхшы хәтерлим. Биле, биленнән дә

[1] Чын исеме Нәҗметдин

бигрәк аягы сызлап интекте. Аягының балтыр сөяге авырта, берничә урыннан тишелеп, үлекләп тә тора иде. Шуның сызлавына түзә алмыйча: «У-у-у-у! У-у-у-у!» — дип кычкырып, күз яшьләре белән елап яткан чаклары әле дә күз алдымда. Андый чакларда мин аны кызганып: «Елама инде, бабай. Елаган кешенең гомере кыскара диләр бит!» — дип үзем дә елап җибәрә торган идем. Ул чакта инде безнең үз әбиебез (Миңнеҗамал атлы булган ул) дөньяда юк, ә үги әбиебез Мәһиәсма әле яшь, колхоз эшенә йөри иде. Шуңа күрә, бабаңа кирәк әйберләрен апкилерсең, кирәк булмаганнарын апкитәрсең дип, көн саен әни мине эшкә китешли бабайларга алып килеп калдыра, Мәһиәсма әби кич эштән кайтканчы миңа бабай янында булырга туры килә иде. Ә бабай кузгалып йөри алмый, әле тегесен, әле монысын сорап кына тора. Шуңа аның яныннан ярты сәгатькә дә китеп булмый иде. Бабайны бик яратсам да, бала бит: урамга, иптәшләр янына уйнарга чыгасы килә. Иптәш малайлар, уч иткән шикелле, нигәдер гел безнең бабайлар өе тирәсендә уйныйлар. Аларның ни сөйләшкәннәренә хәтле ишетелеп тора. Үзләре килеп тә, әйдә инде Вакыйф, чык инде уйнарга, дип ымсындырып китәләр. Мин бабай яныннан китмәскә тырышам. Ләкин кайчакларда тәкатем бетә дә тегеләр янына чыгуымны тоймый да калам. Ә бер тапкыр шулай малайларга ияреп су коенырга төшеп киткәнмен дә, онытылып, озак ук йөреп кайтканмын. Бабайның нәкъ шул вакытта тышка чыгасы килгән, аңа чиләк куючы булмаган... Моның өчен ул көнне кич әнидән бик каты эләкте. Шуннан ары мин, ничек кенә кызыксам да, малайлар янына бөтенләй чыкмыйча, бабайны саклап кына утыра башладым.

Мин инде бу эшкә тәмам күнегеп беттем, күпме утырсам да риза, тик бабай гына терелсен, дип тели идем. Ләкин ул көннән-көн ябыгасулыга барды һәм көзен, мәктәптә укулар башланырга торган көннәрдә, үлеп китте.

Шуннан ары күп тә тормады, Миңнулла абый Әшнәктән килен алып кайтты. Үги әби белән яшь килен нигәдер бер-берсен башта ук өнәмәделәр. Тора-бара аларның бу өнәшмәүләре бер-берсен күралмауга әйләнде. Тегеләр ызгыша башлаганда, Миңнулла абый килен ягында кала иде. Шуңа күрә Мәһиәсма әби түзә алмады, аерылып үз авылларына — Олы Әшнәккә китеп барды. Аннары Миңнулла абыйны да сугышка алып киттеләр, төп йорт белән безнең ара бөтенләй диярлек өзелде. Чөнки җиңги Равил энем белән минем үзләренә килгәнне өнәп бетерми иде...

Әби-бабайларыбыз һәм туган-тумачаларыбыз хакында мин белгән нәрсәләр кыскача менә шул. Күргәндерсез, алай озын гомерле, нык нәселдән түгел мин. Шуның өстенә тагын 1979 елда үзем дә теге дөньяга китеп барудан чак котылып калдым.

Алда сөйләячәк хикәятемне нәкъ әнә шул вакыйгадан башлап китмәкче булам да инде.

## Үлем белән йөзгә-йөз

Январьның егерме җидесе, бик нык салкын, агачларга мүл бәс булып зыкы сарган иртә иде. Казанка болының аксыл-сыек томан баскан. Тирә-як тып-тын. Күрәсең, салкын булгангадыр, боз өстендә балыкчылар юк. Чаңгычылар да әле чыкмаган. Казанка яры буенда керәшә оялары шикелле тезелешеп утырган дача өйләре салкыннан туңып, кечерәебрәк калган сыман күренә. Чаңгылар да әйбәт шуммый. Башка көннәрне ныклап торып таяклар белән бер этеп җибәрсәң, унар метр шуып бара иделәр. Бүген ике-өч метр да бара алмыйлар: салкын кар, магнит шикелле, чаңгы табаннарын ябыштырып-тартып тора. Ярый,

анысына ис киткән юк: мин ушышка чыкмаган. Миңа атна буе эштә утырып ойый башлаган тәнне һәм сөякләрне язып, сулыш юлларын киңәйтеп кайтырга гына кирәк. Ә салкын куркыныч түгел: кулда «Рабочая одежда» кибетеннән алынган әйбәт тире бияләй, өстә ике кат йон свитер, башта колакларын артка каерып бәйләгән эт тиресеннән теккән җылы бүрек.

Казанка аркылы салынып ята торган, шәһәрнең Совет районын Ленин районы белән тоташтырачак күпергә[1] килеп җиттем. Миңләгән чаңгычылар йөреп шомартып бетергән чаңгы эзе шул күпернең уң як баганасы янынннан гына уза. Менә мин шул күпер баганасы янындагы ярга килеп җиттем һәм, елга өстеннән шуып кына үтәргә исәпләп, ике таягым белән дә берьюлы бик ныклап этеп җибәреп, боз өстенә төшеп киттем...

Я рабби! Шул минутларны күз алдыма китергәч, менә хәзер дә тыным кысылып, тәннәрем чымырдап куйды. Ничек исән калуыма әле дә шаклар катып утырам... Минем чаңгылар елга өстеннән шуып кына үтеп китәргә тиеш, башка чакларда гел шулай була торган иде. Ә бу юлы боз өстенә шуып төшүем булды, чаңгыларым, кардан шуып барганда көл сипкән жиргә туры килгәндәй, кинәт шып туктады. Ә үзем, алга сөрлегеп китеп, чак кына егылмыйча калдым. Калуын калдым, ләкин шул арада чаңгыларым бозга бата башлады! Тик шунда гына мин елга өстендәге боз эреп, күе кар боткасына әверелгәнен абайлап алдым. Белмим, ничек башыма ул уй килгәндер: бил тиңентен баткач, таякларымны тиз генә салып, үз турыма «ботка» өстенә аркылы куйдым да, боз астына китмәс өчен, шуларга тотынып тора башладым. Ләкин болай озак тору мөмкин түгел: туксан сигез килолы гәүдәм акрынлап таякларны да «ботка»га иңдерә башлаган иде. Шул «ботка» аша үтеп, чиста суга чыккан чаңгыларым да бик нык комачаулый, чөнки агым аларны аска суыра иде. «Болай булса беттем бит мин!» — дип уйлап алдым да, бер кулым белән чаңгы таякларына тотынган хәлдә, икенче кулымны «ботка» аша суга тыгып һәм бер үк вакытта аягымны да күтәрә төшеп, секунд эчендә бер чаңгының йозагын ычкындырып, тиз генә өскә тартып алдым. Аны боз «ботка» өстенә таяклар янына куеп, шуңа тотынып тору исәп. Ул арада киемнәрем дә юешләнеп өлгергән һәм, авыраеп, аска тарта башлаган иде. Шулай да чаңгының файдасы булды, аңа тотынып торырга була иде әле. Ә үз көчем белән генә ярга чыгу турында уйларга да ярамый: кыймылдый башлау белән «ботка» убылып, төпкә китәчәк идем.

Мине хәзер коткарса, тик читтән кемнеңдер ярдәме генә коткара ала иде. Шуңа өметләнеп, тилмереп як-ягыма карандым. Ләкин күз күреме жирдә бер жан иясе дә юк иде. Шәһәр ерак түгел, бәлки тавышымны ишетеп килерләр дип ярдәм сорап кычкырмакчы булган идем, ләкин, күрәсең куркудан шулай булгандыр, тавышым чыкмады, тавышым качкан иде. Ул арада агым су астындагы чаңгыны һаман аска тарта, гәүдәнең авырлыгы мин тотынып торган чаңгыны акрынлап һаман «ботка»га иңдерә бара иде. Шулай итеп, белә торып батып барам, ләкин котылып калу өчен бернинди чарам юк. Ә нинди дә булса бер нәрсә уйлап табарга кирәк, үлемгә көрәшсез бирелергә ярамый иде. Бөтенләй үк батып киткәнче, икенче чаңгыны да өскә алып калырга кирәк иде миңа. Ләкин беренчесен алган чакта чак кына төпкә китүдән калган курку шулкадәр зур, акылым телисә дә, су астына кулым бармый иде.

Мең энә белән берьюлы чәнечкәндәй, су салкыны тәнне дә бик нык чеметтерә башлаган иде. «Мондый чакта кешене көзән жыера», дип әйтәләр, шундый хәл була калса, бер чаңгыга тотынып кына калып булмаячак. Күп куйганда да дүрт-биш минуттан су төбенә китәчәкмен!» дигән коточкыч уй ярып үтте миемне. Һәм шунда, ахыры ни белән бетәрен дә уйлап тормастан, дөресрәге, инстинктив рәвештә, икенче чаңгымны ычкындырырга үрелдем. Ләкин, үч иткәндәй, бер талпынуда гына ыч-

[1] Ул күпер инде күптән төзелеп бетте (Автор)

кындыра алмадым. Инде батып китәм дигәндә генә кулымны алып, тагын теге өстәге чаңгыга ябыштым. Берәрсе килеп чыкмасмы дип, тагын як-ягыма карап алдым. Ләкин анда беркем күренми, әйтерсең, бар җан иясе үлеп беткән иде. Минем аяныч хәлне күреп һәм шуңа борчылып булса кирәк, баш өстемнән генә ике ала карга очып үтте үтүен, ләкин алар мина ярдәм итә алмый иде шул...

Су салкыны тәнгә генә түгел, йөрәккә үк үтә башлаган иде инде. «Үләм икән болай булгач!» Бер-ике секунд эчендә бөтен гомерем күз алдымнан узып китте. Хатын һәм балалар искә төште. Бигрәк тә балалар кызганыч иде.

Ичмаса алар башлы-күзле булганчы гына да яшәп булмас микәнни? Ятимлекнең нәрсә икәнен мин бик яхшы беләм. Балаларым да ятимлеккә дучар микәнни? Нигә гел безнең нәселгә генә килеп тора икән бу ятимлек? Язмышыбыз шундый микәнни?.. Юк, алай булырга тиеш түгел. Каяле, тагын бер тырышып карыйк әле...

Тагын кулымны суга тыктым да җан ачыйгысы белән чаңгыны тарткан идем, ниһаять, ычкынды теге каһәр суккан йозак. Икенче чаңгыны да өскә тартып чыгардым да ике чаңгыга тотынып тора башладым. Аякта чаңгы булмагач инде агым ул кадәр үк суырмый иде. Ә менә су салкынына чыдар әмәл юк. Батуыма күп булса ун-унбиш минут үткәндер, ә салкын инде үзәкләргә үтеп керде. Шушылай тагын ярты сәгать торырга туры килсә, көзән җыерып төпкә киттең дигән сүз. Үзеңнең үләчәгеңне белеп, аңлы хәлдә шул үлемне көтеп торудан да авыр нәрсә юк икән ул! Үләсемне беләм, ләкин аннан котылу өчен бернинди әмәл юк. Ә иң аянычы шул минем кайда, ничек үлгәнне беркем белми калачак. Чаңгы шуарга дип чыгып киткән тап-таза кеше, җир упкандай, кинәт кенә юкка чыгачак. Җәй көне булса, ичмаса гәүдәне табарлар иде дә зиратка илтеп күмәрләр иде. Ә болай... балалар, туган-тумачалар килеп карар өчен каберең дә булмаячак бит. Озакламый язгы ташулар башлана. Шул ташулар гәүдәне әллә кайларга агызып алып китәчәк. Ярый әле суга батып үлгәнне соңыннан ачыклый алсалар. Андый чакта төрлечә юрыйлар бит ул. Әллә нинди имеш-мимеш гайбәтләр китереп чыгарырлар... Их, дөнья! Менә шушылай кинәт кенә юкка чыгу өчен килдем микәнни мин сиңа? Яшәлгән дә шикелле булмады бит әле. Язып утыра торган повестьны гына булса да тәмамлыйсы иде. Шактый кызык әйбер булырга тиеш иде. Һәр хәлдә, үзем өчен иҗади бер яңа адым булыр шикелле иде. Болай булгач, дөнья күрмичә кала инде ул... Нәзаһәт белән, балалар белән саубуллашып калып та булмады ичмаса.

Әнә шулай эчтән үт үрсәләнеп, чарасызлыктан гаҗиз булып, үлем көтеп торган чагымда башта шыгырт-шыгырт кар шыгырдавы, аннары мыдыр-мыдыр кешеләр сөйләшкәне ишетелгән шикелле булды. Өметләнеп тирә-ягыма каранып алдым, әмма берәү дә күренми. Ул арада аяк тавышлары да ераклаша барган шикелле иде. Алар да мине күрми китеп барса — беттем. Бу юлы тавыш каян килгәндер, кычкырып җибәрдем. «Эһә-һәй! Люди! Спаситеее! Тонуу!» Ишеттеләрме икән – юкмы икән дип, тыңлап тора башладым. Хәзер инде аяк тавышлары да, сөйләшкәннәре дә ишетелми, дөнья тагын тып-тын калган иде. Ялгыш кына ишеткән шикелле булдым микәнни ул тавышларны? Үлем алдыннан була торган саташу гына булды микәнни?

Үземне-үзем белештермичә, тагын кычкырып җибәрдем. Тагын тыңлап тора башладым. Әһә, күрәсең, иңкүлеккә төшкән булганнардыр да, шуңа гына ишетелми торгандыр, аяк тавышлары да, сөйләшкәннәре дә бу юлы якындарак ишетелә иде. Дүрт-биш минут үткәч, мин шуып төшкән яктагы яр өстеннән:

— Держись, мужик! Не суетись! Сейчас что-нибудь придумаем. Сейчас вытащим!— дип эндәшкәннәре ишетелде. Кем эндәшкәнен күреп булмый, чөнки артка борылып карарга мөмкинлек юк, борыла башласам батып китәчәк идем.

Шулай да эчкә жылы керде: «Ничек тә коткаралар инде, болай булгач! Коткарып кала алмаган тәкъдирдә дә минем кайда һәм ничек үлгәнне күреп калачаклар». Хәзер су салкыны да тәнне ул кадәр үк яндырмый шикелле.

Тегеләрнең берсе яр буенда мине юатып-тынычландырып торган арада бүтәннәре кар өстеннән нәрсәдер сөйрәп алып килделәр дә, бер-беренә киңәш бирә-бирә, нидер эшли башладылар. Нигәдер бик озак маташкан шикелле тоелды миңа. Ниһаять, минем уң ягымда киң генә бер такта башы пәйда булды. Тегеләр миңа шул такта өстенә менеп, үрмәләп чыгарга куштылар.

Күрәсең, эшкә ярардай бер әйберне дә исраф итмәскә кечкенәдән үк өйрәнелгәнгәдер, чаңгыларны да үзем белән алмакчы булган идем. Ләкин ярдан: «Ты што там! Тебе жизнь дорога или лыжи! Бросай ты их к чортовой матери?»— дип кычкыргач, аларны шунда боз боткасы эчендә калдырырга туры килде. Ә үзем, коткаручылар салган такталар өстеннән үрмәләп, ярга чыктым. Чыктым һәм, кинәт хәлем китеп, аңымны җуйдым...

Аңыма килгәндә мин күпер төзүчеләр вагонындагы сәкедә ята идем. Мине коткаручылар, дүрт ир-ат, шушы күперне төзүчеләр булып чыкты. Ул көнне күпер баганасына бетон китерелергә тиеш, шуңа күрә, шимбә булса да, аларның эшкә килешләре икән. Алар инде мине анадан тума калдырып чишендергән һәм, мәш килеп, кайсы аякны, кайсы тәнне ышкый, ә берсе, авызны көчләп ачтырып, аракы йоттырырга азаплана иде. Нәкъ әнә шул аракы эчесенә тончыгып өнемә килдем дә мин.

Аннары алар, исән каласың килсә, шушының тамчысын да калдырмыйча, эчеп куясың, югыйсә эчеңә салкын йөгерәчәк тә үпкәң шешәчәк, дип, бер стакан кайнар сөт эчерделәр.

Вагонда болай да салкын түгел, юан асбест торбага спираль тимер чыбык урап ясалган электр миче очкыннар чәчеп кызып тора. Минем киемнәрне шул мич тирәсенә киптерергә куйганнар, алардан бөркелеп пар күтәрелә.

Төзүчеләрнең өчесе яшьләр, берсе минем чамада иде.

— Ну, агай-эне, бәхетең бар икән, без туры килдек!— диде шунысы, минем татар икәнне сизеп булса кирәк, үзебезчәләтеп.

— Рәхмәт инде сезгә, кордаш. Мең рәхмәт. Мин сезгә гомерем буе бурычлы булачакмын.

— Юкны сөйләмә, нинди бурыч ди ул! Син шунысын әйт: хәлең ничек? Эчеңә бераз жылы кереп киттеме?

— Тирләтә дә башлады инде.

— Шулаймы? Алайса бик шәп! Тир чыга башласа — суык эчеңә китми, тышка чыга дигән сүз ул! Кыш суга батуның бит аның куркынычы баткан чагында гына түгел. Аның иң хәтәре — судан чыккач үпкә шешү. Күпме кеше шулай, котылдым дип өенә кайткач, воспаление люккидан үлеп китә. Ә менә вакытында тәнен әйбәтләп ышкып, булса — жылы аракы, булмаса — сөтле мәтрүшкәле чәй эчеп, тир чыгарып калган кешеләргә берни булмый...

Шуннан соң күпер салучы егетләрнең берсе шәһәргә, безнең фатирга барып, миңа коры кием-салымнар алып килгәнен, ул безгә барып кергәндә әле эшкә китәргә өлгермәгән хатынымның коты алынып, үзе дә минем янга, күпер салучылар вагонына килгәнен, күпер төзүчеләр тир чыккач берни дә булмый дисәләр дә, салкын тиеп, авырып ятуларым хакында озаклап сөйләп тормыйм. Ләкин ул чакта, көн салкын булуга карамастан, күпер төбендәге Казанка бозының нигә шулай эреп боткага әйләнгәнен әйтеп китү кирәк дип саныйм.

Сәбәбе бик гади булып чыкты аның. Күргән кешеләр беләдер: Казанка аша салынган яңа күпернең бетоннан коелган баганалары берсе-берсе алты почмаклы авыл өе юанлыгы бар. Әнә шул баганаларның берсен, елганың нәкъ уртадагысын, коеп йөргән көннәр иде ул. Җомга көнне китерелгән бетонны төзүчеләр опалубкага койганнар, вибраторлар белән

әйбәтләп тыгызлаганнар һәм тигезләгәннәр дә, бетон салкында туңып таркалмасын, тиешенчә ныгысын-катсын өчен, тыштан брезент белән каплап брезент эченә шәһәрдән торба буйлап китерелгән кайнар пар җибәреп калдырганнар. Төн буе килеп торган шул пар җылысы белән багана тирәсендәге, нәкъ менә чаңгы эзе үтә торган турыдагы боз эреп боткага әйләнгән. Карап торышка ул урын елга өстенең башка җиреннән һич тә аерылып тормаганга, шуның өстенә әле көн дә яктырып бетмәгәнлектән мин, берни абайламыйча, барганмын да төшкәнмен. Менә шул.

Ләкин монысы соңгы елларда гына булган хәл. Ә хәзер аңарчы булган вакыйгаларның кайберләрен күздән кичереп китик әле.

## Сугыш. Күршеләр. Миңнулла абый. Җиңгиләр һәм гармун.

Безнең үз өебездән сугышка киткән кеше юк иде. Ләкин сугыш авырлыгын бездән дә күбрәк татыган, аның тизрәк җиңү белән бетүен әни белән миннән дә ныграк теләгән кеше булдымы икән?

Шушы җөмләне яздым да гаҗәпләнеп туктап калдым. Ничек инде «бездән дә күбрәк татыган кеше...» Нигә булмасын, ди! Ачтан үлүчеләр генә дә күпме бит. Илбасарлар кулында интегүчеләр, концлагерьларда җәберләнүчеләр күпме булды! Без бит, шөкер, ачтан үлмәдек, ялангач та йөрмәдек. Шулай булгач хәлләре безнекеннән мөшкелрәкләр күп, бик күп булгандыр ул елларда. Ләкин барыбер әлеге җөмләне үзгәрешсез калдырырга булдым. Чөнки һәркемнең үз хәле хәл булды ул чакта.

Минем әни ул елларда фермада эшләде. Иртәнге сәгать биштән чыгып китә, кичке сигездә әйләнеп кайта. Әгәр инде җидедә кайтса, бүген иртә кайттың, дип куанышып бетә алмый торган идек Равил энем белән. Колхозның өч йөз илле баш сарыгын, йөздән артык сыерын, танасын-бозавын тик ике кеше — минем әни белән Гөлбаһар апа карый. Шул малларны ашату-эчертү, асларын җыештыру, тиресләрен түгү, сыерларны саву, кыш көннәрендә сарыклар бәрәнләгәндә, сыерлар бозаулаганда бәрән-бозауларны җылырак бинага алып кереп урнаштыру, коры салам белән генә җан асраганга сөтләре булмаган, шуңа бозау-бәрәннәрен имчәкләренә якын китерергә дә теләмәгән сыер-сарыкларның бозау-бәрәннәрен имезләкләндерү өчен фермада төнге дежурда тору — барысы да алар вазифасына керә иде. Ә бит әле, шулар өстенә, безнең үз сыер-сарыкларыбыз да бар. Дөрес, әни әзерләп киткән печәнне («син күп саласың, әле ул печәнне май башына кадәр җиткерергә кирәк»,— дип әни миңа тезмәдән үземә алырга рөхсәт итми иде) малларга мин салам. Абзарны җыештырып, тиресләрен дә түгәм. Иртәгә иртән ягарга утынын да кисеп куярга тырышам тырышуын. Кулыннан килгәнчә Равил энем дә булыша. Әмма йорт-җирдә алардан башка эшләр дә бетәсе түгел, әнигә дә җитәрлек калып торган иде.

Ә шулай да иң кыены эш түгел. Иң кыены — заем, налог түләргә акча табу, бәрәңге түләвенә бәрәңге җиткерү иде.

Әйтерсең, алдан заказ биреп шулай эшләнгән: авылда без рәттән торган дүрт йортның һәркайсында икешәр малай идек. Яшь араларыбыздагы аерма да бик аз: бер-ике ел гына. Ә менә әтиләр мәсьәләсенә килгәндә алай түгел. Тегеләрнең әтиләре бар. Барысы да сугышта. Башта барысының да хатлары килеп торды. Әниләребез бергә җыйналып, ул хатларны кычкырып укыйлар. Шунда без-малайлар да тыңлап торабыз. Хатлардан аңлашылганча, сугышта да эшләр җиңелдән түгел. Немесләр безнекеләрне бик хәтәр кыса. Аларның машиналары да, ату кораллары да күп. Ну шулай да безнекеләр бик каты каршы тора. Үлсәләр дә немесләрне Мәскәүгә кертмәячәкләр! Алай гына да түгел, тиздән фашистларның үзләрен куа башларга тиешләр икән. Так шту, безнең әниләр монда артык хафаланмасыннар: соңгы чиктә җиңү барыбер безнең якта булачак. Чөнки

иптәш Сталин үзе шулай дип әйткән. Рас ул әйткән икән, значыт, шулай булачак инде ул...

Ул хатларны укыгач, ач тамакларыбыз туйгандай булып, күңелләребез күтәрелеп китә торган иде. Ләкин кырык икенче ел ахырында Фәрзетдин белән Харисның этисе Гыйльметдин абыйдан башта хат килү туктады, аннары ниндидер бер «Н биеклеге өчен сугышканда геройларча һәлак булды»,— дип язылган уч төбе хәтле генә кәгазь җибәрделәр.

Аннары Миңнеәхмәт белән Исмәгыйльнең этисе Мөхәммәтвафа абый турында да шундыйрак хәбәр китерделәр. Әле дә бик яхшы хәтеремдә, ул көнне Маһисәрвәр апа ипи салган иде. Вафа абыегыз истәлеге итеп, авыр туфрагы җиңел булсын дип, теләк теләп ашагыз дип, безнең ише сигез малайны җыйнап, шул икмәк белән сыйлады.

Рәфкать белән Рашатның этиләре Габдулла абыйдан андый хәбәр булмаган иде булуын. Ләкин кырык өченче ел башында аннан да хат килү туктады. Ә хатыны Маһисара апа колхоз хисапчысы булып эшли торган кайнишеннән, Рәүф абыйдан, Габдулла абый хезмәт иткән часть командирына сорашып хат яздыргач «хәбәрсез югалды», дигән җавап килде.

Шулай итеп, без, рәттән торган дүрт йортның сигез малае, барыбыз да әниләребез белән генә калдык. Ләкин тормыш хәлләренә килгәндә тегеләр белән безнең арада шактый гына аерма да бар иде. Тегеләрнең хуҗалыгына бернинди түләү салынмый. Заемга язылу да мәҗбүри түгел. Сугышта үлгән этиләре өчен хәтта аларның үзләренә пенсия килеп тора. Чөнки алар — фронтовик балалары.

Әйе, читен иде безгә ул чакларда. Шуңа да сугышның тизрәк бетүен һәм безнекеләр җиңеп кайтуын Миңнеәхмәтләргә, Фәрзетдиннәргә һәм Рәфкатьләргә караганда да ныграк көттек шикелле без.

Аннары килеп, этинең энесе Миңнулла абый да сугышта иде бит әле. Дөрес, ул безгә хат язмый. Киткән шәпкә бер-икене генә язды да шуның белән бетте. «Җиңгәгез язмаска кушкан»,— дип сөйләде авыл халкы. Ихтимал, шулай да булгандыр. Миңнулла абыйның безгә туган итеп каравын җиңги нигәдер яратмавын, кечкенә булсам да, чамалыйм, тик моңа бик үк ышанасым гына килми иде: «Ничек инде ул үз иреңнең якын туганнарын туган итмәскә мөмкин, ди?» Ләкин, кызганычка каршы, сизенүем дөрес булып чыкты. Чөнки җиңгинең безне яратмавы соңыннан конкрет фактлар белән дә расланды. Ул хакта алда сүз булыр әле.

Әйткәнемчә, абыйдан безгә хат килми иде. Ләкин без аның исән-сау икәнен ишетеп-белеп торабыз. Авыл бәләкәй булганга, бездә махсус хат ташучы юк. Хат җибәрәсе кеше Кече Әшнәккә авыл советына бирәр йомыш белән баручыга биреп җибәрә, килгән хатларны Әшнәккә барган кеше алып кайта. Җиңги үзе әйтмәсә дә, хат алып кайткан кешеләр абыйдан хат булганын безгә әйтә торганнар иде. Аннары җиңгинең үзенең дә сер уртаклаша торган кешеләре бар: Миңнулла абыйдан килгән хатлар хакында аларга сөйләми калмый. Ә алардан безгә дә килеп ирешә. Без шунысына да бик канәгать булып, абыйдан үзебезгә хат килгән шикелле куанышып яши идек. Чөнки, сөйләүләренә караганда, абыйның хәлләре зарланырлык түгел: полк командирының шәхси адъютант-пешекчесе булып йөри икән ул анда. Авылыбызда иң зур укымышлы (җиде класс бетергән!) һәм дөнья хәлләреннән иң хәбәрдар кеше — колхоз хисапчысы Рәүф абыйның сөйләвенә караганда, әгәр безнең Миңнулла абый хезмәт итә торган полк алай-болай ялгыш дошман кулына эләкмәгән тәкъдирдә (ә алай булу ихтималы юк, чөнки фашистлар безнең гаскәрләрне сугыш башында, кырык беренче елда гына әсир итәләр иде) хәзер хәлләр үзгәрде, хәзер безнең Кызыл Армия гаскәрләре үзләре фашистларны хәтта дивизияләп-дивизияләп әсир итәләр! Шулай булгач, Миңнулла абыйның исән-сау кайтуына бернинди шик булырга тиеш түгел. «Малы тово,— ди Рәүф абый,— күкрәк тутырып орден-медальләр дә тагып кайтмасын әле абыегыз. Патамушты, рас пулк камандарының пувыр

әдүтәнте булып йөри икән, значыт, ордин-медальләр дә пачти үз кулында була инде аның».

Рәүф абый шактый «белеп» сөйләгән булып чыкты. Кырык алтынчы елның мартында безнең Миңнулла абый исән-сау әйләнеп кайтты. Орденнары юк юк иде югын. Ләкин сигез медаль, бер гвардия значогы тагып кайткан иде. Ә аңарчы (кырык бишнең башында) бер тапкыр ун көнгә кунакка да кайтып киткән иде хәтта. Шул чакта Равил белән миңа бүләк итеп ялтырап торган атлас тукыма да алып кайткан иде. Әни безгә шуннан күлмәк тегеп биргән иде. Ләкин, күрәсең, складта бик озак ятып бозылган булгандыр, күлмәкләребез озакка бармады: бер юганчы да түзмичә, сыерылып төштеләр.

Кырык бишнең җәендә, сугыш беткәч, Кече Әшнәктән хатлар, почта кәгазьләре һәм газеталар алып кайткан Әсмабикә апа әнигә: «Килендәшеңә дә, сезгә дә Миңнулладан пусилке кәгазе барые. Юлда туры килде дә икесен дә килендәшең алып калды»,— дип әйткән иде. Ләкин җиңги үзе аны-моны әйтмәгәч, әни аннан сорашып йөрмәде.

Ә Әсмабикә апа дөрес сөйләгән булган. Моны миңа 1946 елда сугыштан кайткан көннәрдә үк абый үзе әйтте.

Ул көнне абый мине үзләренә утын кисешергә дәшкән иде. (Унбер яшемдә генә булсам да, ул эштә тәҗрибәм бар, беренче класста укый башлаганнан бирле мичлек утынны үзем кисеп килә идем.) Шунда, эш арасында ял итеп алырга туктагач, сорады абый миннән:

— Син, энем, пәлтәңне нигә бер дә киеп йөрмисең? Әллә туздырдыңмы инде?— ди.

Мин аптырап калдым:

— Нинди пәлтә турында сорыйсың син, абый? Менә шушы өстемдәге бишмәтемнән башка, минем бернинди пәлтәм булганы юк бит!

— Как это «булганы юк»! Әмин посылка белән җибәргән пәлтә кая китте?

— Нинди пәлтә ул, абый?

— Мин бит сиңа менә диган пәлтә салган идем.

— Ә безгә бернинди посылка да килгәне юк, абый. Узган ел Әсмабикә апа әнигә ниндидер кәгазь бар, диде, тик аны җиңгәчәгез алып калды дип әйткән иде әйтүен. Тик безгә бер нәрсә дә килгәне булмады.

Мин шушы сүзләрне әйткәч, Миңнулла абый никтер уйга калып, чиста зәңгәр күзләрен бер ноктага текәп, байтак кына эндәшми торды. Аннары ялт кына өйләренә кереп китте дә, бик хәтәр җилтерәтеп, җиңгине минем янга, утынлыкка алып чыкты. Качып китмәсен дигәндәй, җиңеннән тотып торган килеш сорады:

— Әйт менә шушы малай каршында: мин посылка белән җибәргән пәлтәне кая куйдың?

Абый алып чыккан чагында куркуыннан каны качып, җиңгинең йөзе ап-ак булып калган иде. Хәзер кинәт мәк чәчәге шикелле булып кызарып китте. Ни әйтергә белмичә, беркавым абыйга карап, өнсезләнеп торды. Ләкин бу хәл күпкә бармады, ул үзен кулга алып, чәрелдәргә тотынды:

— Өтәләндереп өйдән алып чыккач, әллә бер-бер хәл булганмы дип торам. Ә син гел дә пүчтәк нәрсә өчен тузынып йөрисең икән! Мине монда апчыгып тормыйча, өйдә генә сорарга да буладырыедыр бит аны. Кайда булсын, әнә, өйдә, сандыкта ята ул пәлтә!

— Ә сиңа ничек килеп эләкте соң ул? Мин бит аны Мәгъсүмә җиңги исеменә салган идем!

— Анысын мин карап тормаганмын шул. Фамилияләребез бер булгач, исеменә игътибар итмәгәнмен. Син аларга пусилке җибәрерсең дип кем уйлаган?

— Шулаймыни? Шуны да уйларга ярамагач, тубал кадәр шушы башыңның нигә кирәге бар аның? Башың уйламаса да, күзең чыкмаган бит, күрергә тиеш идең! Күзгә карап ялганлап торма ичмаса, дөресен әйт:

комсызландым, шуңа ятимнәр хакын үземә алып калдым диген!

— Ярар ла инде, Миңнулла, юк өчен хатын-кыз шикелле вакланып торма. Дөньяң харап булмаган, сатып эчмәгән ләбаса мин ул пәлтәне. Әйдә, бик кирәк дисең икән, хәзер апчыгам да бирәм!

— Саткансың шул,— диде абый, җилкенеп өйгә кереп барган җиңги артыннан кычкырып.— Дөньядагы иң кадерле нәрсәне — намусыңны саткансың син!

Без, бүленеп торган эшебезне дәвам итеп, бер пүлән кисәргә дә өлгермәдек, култыгына сары төстәге балалар пәлтәсе кыстырып, җиңги әйләнеп чыкты. Гомердә булмаганча йомшак-ягымлы итеп:

— Мәле, энем, киеп җибәр әле!— диде.

Өстемдәге бишмәтемнең рәте әллә ни түгел, итәк-җиң очлары чукланып беткән, терсәк турлары ямалган иде. Бүтән кияр әйберем булмаганга гына киеп йөри идем мин аны. Төсе әллә ни дан булмаса да, нык, калын материалдан тегелгән яңа пәлтәне күргәч, куанычымнан тыннарым кысылып, тәннәрем чымырдап китте. Күңелем белән мин инде аны киеп, иптәш малайларның исләрен китереп кайтырга да өлгергән идем. Ләкин Миңнулла абый шулай бик хәтәр тотынгач, җиңги кызганыч булып китте миңа. Ничек итеп булса да, аның хәленә керәсе, аңа ярдәм итәсе, ничек тә эшне зурга җибәрмичә калдырасы килә иде.

— Кирәкми миңа бу пәлтә!— дидем мин.

Миңнулла абый да, җиңги дә, ни булганын аңламыйча, гаҗәпләнеп калдылар. Алар шулай торган арада мин, үземчә, боларны үзара килештерү юлын уйлап таптым:

— Абый, син җиңгигә ачуланма, җәме! Бу пәлтәне моңарчы бирми торып, дөрес иткән ул. Мин аны барыбер кимәгән булыр идем.

Җиңги куанып миңа карап куйды да, абыйга мөрәҗәгать итеп:

— Менә, вәт, күрдеңме инде! Энекәш үзе үк әйтеп тора: «Кимидерием мин аны»,— ди.

Ләкин абый аның бу сүзенә алай бик эреп китмәде.

— Кияме-кимиме, анысында синең эшең булырга тиеш түгел иде! Энекәшкә дип җибәргән әйберне нигә сандыгыңа салып куйдың?

— Нәрсә соң син һаман бер сүзне чәйнисең? Салса ни булган? Салган да беткән инде. Онытылган. Бала булып, бала бер сүз әйтмәгәндә, аның өчен дөнья сасытып кычкырышасы юк инде ир кешегә!

Үзен җиңүче санап, аягына нык басып, җиңги өйгә кереп китте. Ә абый, ни әйтергә белмичә, уйланып калды. Аннары без тагын утын кисә башладык. Пычкы тартуның рәтен беләм дисәм дә, Миңнулла абый белән рәттән эшләрлек көчем юк. Шуңа күрә ике-өч пүлән кискән саен ул мине ял иттереп ала иде. Чираттагы ял вакытында бу миңа тагын бер мәсьәлә китереп куйды.

— Карале, энем, сорарга да онытып торам икән, гармун уйнарга өйрәндеңме син?

— Гармун булса өйрәнгән булыр идем дә, гармун булмагач ничек өйрәнәсең инде аны?— дидем мин, аның бу соравына гаҗәпсенеп.

— Ә сезгә гармун да килмәдемени?

— Кем җибәрсен ди аны безгә?

— Әһә, шулаймы? Әйдәле, җиңгәң янына керик әле!

Тагын минем аркада ачуланыша башлыйлар икән дип куркуга калдым:

— Әгәр җиңгине орышасы булсаң, кермим абый.

— Әйдә, әйдә, бу юлы орышмыйм. Бу юлы иплап кенә сөйләшәбез без аның белән.

— Миннән башка гына сөйләшегез алайса.

— Юк шул, имынны син кирәк!

Без килеп кергәндә, җиңги, берни булмагандай, тыныч кына бәйләү бәйләп утыра иде.



*Т. Хажиәхмәтов рәсеме.*

— Нәрсә, ашыйсыгыз килдеме әллә? Аш өлгермәгән әле. Өлгергәч үзем дәшәрием,— диде ул, орчыгын бөтереп җибәреп.

— Юк, ашыйсыбыз килми,— диде Миңнулла абый, шулай ук бик тыныч итеп.— Сөйләшәсе сүз бар.

Җиңги шикләнеп, абыйга карап алды:

— Әйдә, сөйләшик алайса.

— Мин җибәргән гармунны кая куйдың син?

Җиңги тагын дерт итеп, агарынып китте:

— Һе, «кая куйдың?» Кая куйыйм? Май алырга акча кирәк булды да — саттым. Кешеләрнеке кебек сыерыбыз юк бит безнең.

Миңнулла абый сугышка киткәндә аларның сыерлары да, алты-җиде баш сарыклары да бар иде. Печән җыючы юк, аннары мәшәкате дә бик күп, бер башыма нигә кирәк ул миңа дип, җиңги үзе бетергән иде ул сыерны. Дөресен генә әйткәндә, аның сыер асрарга мохтаҗлыгы да юк, чөнки ул сугыш елларында завхоз булып эшләде һәм нәрсә теләсә — шуны ашап яшәгән иде. Шуңа аның Миңнулла абыйга биргән җавабы минем өчен бик сәер тоелды. Миңнулла абый үзе дә ул җаваптан канәгать түгел иде булса кирәк:

— Син миңа әкият сөйләмә, яме! Сугыш елларында синнән дә рәхәт яшәгән кеше безнең авылда гына түгел, бөтен Татарстанда берничә генә булгандыр. Син миңа шунысын әйт: мин җибәргән гармунны нигә шушы энекәшкә бирмәдең?

Күрәсең, бүтән акыллырак җавап таба алмады булса кирәк, җиңги аңа балаларча турыдан-туры җавап бирде:

— Бирәсем килмәде дә бирмәдем, менә шул! Аңладыңмы!

Әйе, узган ел «Миңнулладан Мәгъсүмәләргә посылка белән гармун килгән, әмма килендәше аны аларга бирмәгән»,— дигән имеш-мимешләр йөргән иде авылда. Тик аңа әни дә, мин үзем дә әллә ни игътибар итмәгән идек: халык ни сөйләмәс. Инде ачыкланды: белеп сөйләгән булганнар икән. Нигә бирмәде икән соң җиңги ул гармунны безгә? Мин бит аңа бернинди начарлык эшләгәнем юк. Киресенчә, ни кушса да үтәргә җан атып торам. Чөнки туган тиешле кеше ич ул безгә. Тик нигәдер безне бар дип тә белми. Ярый, пәлтәсен бирмәсен дә ди. Анысын, бәлки, булачак малаена яисә бүтән бер туганына дип саклап тоткандыр. Ләкин гармунны шулай бездән яшереп нигә сатарга иде икән аңа? Һич югы, арзанрак бәягә безгә сатсын иде инде! Гармун дигәндә җанымны бирергә әзер торуымны белми микәнни ул? Гармун булса, бу дөньяда миңа бүтән берни кирәк булмавын чамаламады микәнни? Чамаларга тиеш иде, аз гына башы булса. Чөнки минем кушаматым да «Гармун» бит. Бөтен авыл малае, ачулары килгән чакта мине «Гармун» дип үрти. Чөнки Нәҗем бабай мине бик яраткан. Колхозның ат караучысы булган ул. Бәләкәй чагымда, әле юньләп аягыма йөри башлаганчы ук, мине күтәреп үзе белән кәнүшнигә алып бара торган булган. Шулай бер дә бер көнне мине кәнүшнигә күтәреп алып барган чакта Әхмәтгали абый әйткән аңа:

— Ай-һай, Нәҗметдин абый, яратасың да инде оныгыңны: гармун урынына күтәреп йөрисең! дигән.

Әнә шуннан йогып калган миңа «Гармун» дигән кушамат.

Кушаматым бар, ләкин гармуным юк. Ә гармунлы буласым килә, бик килә иде. Гармунлы буласы булганмын икән дә бит, әнә, җиңги бирмәгән миңа абый җибәргән гармунны. Ни эшләтәсең аны!

Мин генә түгел, Миңнулла абый да берни эшләтә алмады ул көнне җиңгине.

— Аңладым,— диде ул җиңгигә, бик гади нәрсә турында сүз барганлай тыныч кына.— Бик яхшы аңладым мин синең кем икәнеңне. Ичмаса менә хәзер дөресен әйтеп бирүең өчен рәхмәт үзеңә!

Аннары без абый белән ишегалдына чыгып, кисәсе утынны кисеп бетердек. Җиңги пешергән итле ашны ашадык. Ул көнне бүтән әрепләш-

мәделәр. Табын янында әйбәт кенә сөйләшеп утырдылар. Мин тамакны туйдырып кайтып киткәндә — гомердә булмаган хәл!— җиңги хәтта: «Бүтән көннәрдә дә килеп йөр, энем»,— дип ачык чырай белән озатып калды. Гармунны миңа бирмичә сатып җибәргән өчен башта хәтерем калган булса да, әнә шул якты йөзен күргәч, мин аны яратып, абый белән шулай тиз татулануларына сөенеп кайтып киткән идем. Ләкин, кызганычка каршы, алар барыбер бәхетле була алмады. Аның сәбәпләре байтак иде. Ләкин монда ул хакта сүз озайтып торасым килми. Мин бит әле ничек итеп гармунлы булуым хакында да сөйләмәкче идем.

Безнең әни русча белми иде. Шуңа күрә үзебезнең Балык Бистәсеннән ары барганы юк һәм, мылтык терәп үк мәҗбүр итмәсәләр, бармыйм да, аллаһы боерса, дия иде ул. Дөрес, соңыннан, Равил белән мин үсеп житеп, тормыш корып читтә яши башлагач, Казанга гына түгел, Пермьгә кадәр үк барып, елдан артык торып кайткан чаклары булды аның. Ләкин анысы инде заманалар үзгәргәч булган башка статья. Анда ул энекәшнең үз машинасына утырып, әби булып, оныкларын карарга барды. Ә теге елларда Казанга барудан да коты чыгып тора торган иде. Ләкин барырга кирәк. Елына бер генә тапкыр булса да бармыйча булмый. Чөнки киемсалым, керосин-тоз алырга, заем һәм налогларны түләргә акча кирәк. Аны я ит, я май яки йомырка сатып кына табарга мөмкин иде. Сатар өчен, әлбәттә, Казанга барырга кирәк. Чөнки авыл җирендә аларны алучы юк. Хәзер генә ул, мал асрарга иренеп, авыл халкы итен дә, йомыркасын да шәһәрдән ташып ашарга өйрәнеп китте. Теге елларда һәр йортта сыербозау, кәҗә-сарык асрыйлар. Ә хезмәт хакын колхозчыларга хәзерге шикелле акчалата түгел, натуралата, ягъни, ашлык белән түлиләр, анда да әллә ни мактанырлык булмый, бер хезмәт көненә дүрт-биш йөз грамм чүпле бодай яки арыш белән калган еллар күп иде.

Әйе, авыл халкы елына бер тапкыр булса да Казанга бармыйча кала алмый. Кайберләре (тана-бозаулары, үрдәк-казлары булганнары) хәтта елына өчәр рәт бара торганнар иде.

Ә минем әни шикелле кыюсыз-юаш кешеләр үзләре бара алмыйча, сатасы ит-майларын, йон-йомыркаларын туган-тумачаларына биреп җибәреп саттыра яки сату-алу белән махсус шөгыльләнүчеләргә, дөресен генә әйтсәк, спекулянтларга авылда ярты бәясенә генә сатарга мәҗбүр.

Нигәдер безнең әнине бик еш алдап китә иде ул спекулянтлар. Бервакыт сабын дип үзле балчык сатып киткәннәр, ә берсендә гамәлдәге акчалар урынына Николай патша акчаларын биреп киткәннәр иде. Һич онытасым юк, шул чакта әни-җанкисәгем: «Ни хәлләр генә итим икән, заем түләргә акча кайлардан алыйм икән хәзер? Ник бу кадәр бәхетсез булды икән башкайларым!»— дип үксеп-үксеп елаган иде.

Ичмаса Казанга барган чакларында безнең әйберләрне дә алып барып сатар иде, дип Миңнулла абыйның сугыштан кайтуын ике күзебезне дүрт итеп көтеп алган идек без. Ниһаять, ул кайтты. Кайтуына атна-ун көн үтүгә, Казанга барырга җыена башлады. Көздән үк суеп куйган танабыз, унбиш кадак атланмаебыз бар, шуларны сатарга кирәк иде. Әни сүзен тыңлап, абый аларны да алып барырга булды. Түлисе түләүләребез күп җыелган, шуларны түләргә акча бик кирәк иде. Ләкин, әни белән безнең исәп буенча, тана белән май акчасы аларга гына бетәргә тиеш түгел, шактый гына артып та калырга тиеш иде.

Монда мин, төп темадан читләшебрәк булса да, бернәрсәне ачыклап китүне кирәк дип саныйм. Кече-кечкенәдән гармунчы буласым килә иде минем. Рәүф абыйның гармунын кулга бер тотып карар өчен генә дә әллә ниләр эшләргә әзер идем. Гармуным булса, иптәш малайларның «гармун» дип котыртуларына исем китмәс шикелле иде. Гармунчы булырга теләвемне әни дә белә, гармун алып бирергә каршы түгел, тик мөмкинлегебез генә юк иде. Минем гармун уйнарга өйрәнәсе килүемне Миңнулла абый да чамалый: аларга утын кисешкән көнне, җиңги миңа

дип җибәргән гармунны юкка чыгаруын белгәч: «Ярар, энем, гармунчы булырга теләгең бар икән, ничек тә берәр җаен табарбыз»,— дип өметләндереп куйган иде. Минә хәзер җае чыгарга тора бит әле: тана акчасы белән май саткан акча түләүләргә генә китеп бетәргә тиеш түгел, гармунга да калырга тиеш!

Бу уемны мин әнигә дә әйттем. Ләкин ул бик алай күтәреп алмады: «Белмим шул, улым, гармуннар алырлык ук булыр микән? Түләүдән артып кала торган булса, абыеңа без лутчы Равил белән синә өс-баш киемнәр алып кайтырга әйтик. Бишмәтләрегез бик тузган бит, ямау өстенә ямау салынган»,— дип мәсьәләне икенче якка борып җибәрде. Ул хаклы: Равил белән минем өс-баш бик сәләмә, тик әниебезнең тырышлыгы — тишелгән саен әйбәтләп ямап торуы аркасында гына кеше арасында кеше төсле булып йөри идек. Шуңа ул чакта әни белән тарткалашып тора алмадым: «Әй, әни, әгәр гармун алып бирсәң, мин шул иске бишмәт белән йөрергә дә бик риза!»— дип әйтү белән генә чикләндем. Һәм бүтән ул хакта сүз кузгатырга җөрьәт итмәгән дә булыр идем. Ләкин абый иртәгә Казанга чыгып китәсе кичне, әни белән мин тана итен чана белән аларга алып менеп («алып менеп» дип шуңа әйтәм, чөнки алар авылның уртасында, без авылның түбән очында тора идек) биргәч, Миңнулла абый миннән: «Ә сиңа Казаннан нәрсә алып кайтыйм, энекәш?»— дип сорады. Мин нәрсә дип әйтим? Әлбәттә, минем теләк бер генә иде: «Гармун алып кайта алсаң, әйбәт булыр иде, абый!»— дидем. Белмим ничек шулай булгандыр, әни дә: «Үзең карарсың инде, наным: мең дә биш йөз җитмеш сигез тәңкә түләү түлисебез бар, базарлар уңышлы булып, шул түләүләрдән калырлык акча чыгара алсаң, очсызлырагын гына булса да, берәр гармун кисәге апкайтсаң апкайтырсың инде».— диде. Миңнулла абый үзе дә: «Какой вопрос, апкайтам, апа, эбизәтельне апкайтам!»— дип бик ышандырып киткән иде. Тик минә кайтуы гына әллә ни дан булмады.

Биш кешегә өч олау белән киткән иде алар. Безнең әйберләр дә булгач, Миңнулла абый бер үзенә бер олау белән киткән иде. Биш көн дигәндә башкалар әйләнеп кайтты, ә абый юк. Кайтучылардан сораган идек, белмибез, күрмәдек, без колхоз базарында саттык әйберләребезне, ә ул «Фатирга Фатих абыйларга керәм, аларга Чихыф базары якын»,— дип шунда калганые, диделәр. Бер-бер хәл булмаса гына ярар иде дип, без бик нык куркуга төштек. Шөкер, берни булмаган: киткәненә сигезенче көнне кичке сәгать җиделәрдә кайтып төште бу. Инде бүтән малайлар уеннан таралышса да абый кайтканны күрми калмагаем дип, мин әле һаман урамда, алар өе тирәсендә чуала идем. Кайтып килгәнен күрүгә каршысына йөгереп барып, чанасына менеп утырдым. Абый үзе дә сагынган булган ахрысы, кочаклап ук алды. Суган исе һәм җиңелчә генә аракы исе килә иде аннан.

— Ник болай озак йөрдең, абый?— дидем мин, түземсезләнеп.— Синең белән киткән кешеләр өченче көн үк кайтты бит инде!

— Булды инде, энекәш,— диде абый, хәйләкәр һәм салмыш кешеләргә хас булганча канәгать елмаеп.— Булды инде эшләр!

Аның кайда һәм ниләр эшләп йөргәнен без ул чакта да, соңыннан да белә алмадык. Авыл халкы арасында төрле имеш-мимешләр йөрде: кайсылары Казанда бер шома хатынга юлыккан икән дә, шуның куенынннан ычкына алмыйча шулай озак йөргән икән дип, кайсылары ит сатып торганда үзенең полк командирын очраткан да шуның өендә кунак булып яткан икән, дип сөйләделәр. Казанга китәргә ниятли икән, үзенә эш юллап йөргән, диючеләр дә булды. Чынысы гына ничек булгандыр — шайтан белсен.

Ул көннәрдә әнинең күз яшьләре түгеп, хәсрәткә батып йөргәне хәзер дә бик яхшы хәтеремдә. Хикмәт менә нәрсәдә иде. Теге көнне абыйның чанасын ишегалларына кертеп тугардык та мин аның атын кәнүшнигә илтә киттем. Кайтышлый безгә кагыла кит, дип дәшеп калган

иде ул. Мин кәнүшнидән кайтып кергәндә җиңги белән абый, үзара бик төксе генә сөйләшеп, бер-беренә карамыйча гына, табын янында утыралар иде. Мин килеп кергәч абый, ясалмарак кына куанган булып:

— Булдымы? Илтеп кайттыңмы атны, менә молодец!— дигән булып, тиз генә урыныннан купты һәм, карават астыннан алып, миңа биш планкалы зур бер гармун тоттырды:

— Мә, энекәш, сиңа бу! Бар, өегезгә апкайт та уйна рәхәтләнеп!

Моңарчы безнең авылда бер Рәүф абыйның гына гармуны бар. Ул аны бик сирәк, бәйрәмнәрдә, кунак җыйган-чакларында гына уйный. Аның уйнаганын тыңлап торыр өчен генә дә әллә ниләр бирерлек булып, өй турларында тыңлап тора торган идем. Уйнап карау турында әйткән дә юк инде, хәтта шуны тотып кына карасам да дөньяда иң бәхетле кеше булырмын шикелле тоела торган иде. Инде менә көтмәгәндә кулыма гармун килеп кергәч, шатлыгымнан хәтта беркавымга телсез-өнсез калдым. Шуннан соң гына, ниһаять:

— Кем гармуны соң бу, абый? Син аны миңа ничә көнгә бирәсең?— дип сорадым.

— Юләр, кемнеке булсын — синеке! Мин аны сиңа дип Казаннан алып кайттым!

— Рәхмәт инде алайса, абый!— дидем дә, кая басканымны да белмичә, өйгә очтым. Ул минутларда дөньяда миннән дә бәхетлерәк кеше булмагандыр.

— Менә, әни!— дидем мин, куанычымнан тыннарым бетеп кайтып кергәч.— Миңнулла абый миңа гармун алып кайткан!

Төчергәләнеп чаңгы таягына тәгәрмәч бөгеп утырган җиреннән сикереп кубып, Равил дә минем каршыга килеп басты:

— Ник сиңа гына булсын, икебезгә дә дип апкайткан ул аны!

Аның белән бәхәсләшеп торыр чак түгел иде: күңелемнән, тот капчыгыңны, дип уйласам да:

— Ярар, ярар, икебезгә дә булыр. Тик тавышланма гына!— дидем.

Шуның белән Равилнең күңеле булды. Ә әни нигәдер куанмады. Киресенчә, хәвефләнебрәк калган иде ул.

— Нигә сөенмисең, әни? Миңнулла абыйга гармун алып кайтырга үзең әйтеп җибәргән идең бит.

— Әйтүен әйткәнием анысы. Тик ни хаккарак алды икән соң ул моны?

— Әй, әни, алгач ни хакка алса да ярый инде ул! Бәлки ул аны, үз акчасына алгандыр да, теге чакта миңа дип фронттан җибәргән гармун урынына булыр дип, бөтенләй бушка бирмәкчедер.

— Ай-һай, балам, алай итәрме икән Миңнулла. Теле белән сезнең өчен үлеп торса да, гамәле белән әллә ни бөтәйткәне җук аның безне. Сөенергә бик алай ашыкма әле син, берәр хикмәте чыгып, кире илтеп бирергә туры килмәгәе аның бу нәмәстәкәен.

Әнинең болай дип әйтүе миңа ул көнне бик сәер тоелган иде. Ләкин ул хаклы булып чыкты.

Миңнулла абый гармунны алуын, чыннан да, миңа дип алып кайткан. Ләкин ул аны, тана акчасын гына түгел, хәтта унбиш кадак маебызны саткан акчаны да тиенenә кадәр тыгып, ике мең дә алты йөз тәңкәгә алып кайткан иде.

Әни аңа: «Казан базарында җиде-сигез йөзгә дә әйбәт кенә яңа гармуннар алып була дип сөйлиләр бит, ныным. Нигә шул тирәдәгесен генә алмадың? Нигә шушындый кыйбатлысын апкайттың? Житмәсә әле яңа да түгел, уйный-уйный басмалары ашалып беткән»,— дип иплән кенә ризасызлыгын белдереп караган иде, ләкин абыйга ошамады: «Һы! Син, апа, әйберне таный белмәсәң, тик кенә тор инде, яме!— диде ул, гөлт итеп кабынып.— Дөрес, яңа гармун түгел бу. Әйе, уйный-уйный басмалары да ашалган. Ну бит тагын йөз ел уйнасаң да берни булачак түгел аңа. Киресенчә, уйнаган саен ачыла гына барачак. Чөнки телләре көмеш

аның. Татарстанның атаклы гармунчысыннан алдым мин аны. Махсус заказ биреп, Бараксинның үзеннән ясаткан булган. Ә син, панимаешь, кыйммәт булган, имеш! Бик беләсең килсә, мәгәричен үз акчама алып эчердем әле мин аны, сезнең акчагыз җитмәде. Ну, ярый, мин алай вакланып йөри торган кеше түгел, анысын синнән түләтеп тормам, энекәшләр үземнеке бит. Ә син, панимаешь... Бик беләсең килсә, ике мең алты йөз генә түгел, биш мең алты йөз тора торган гармун бу! Бүген Казан базарына алып чык — бүген кулга да тидермичә өч меңгә җибәреп була моны!»

«Алай булгач, әллә илтеп сатып кына кайтасыңмы, аным?»— дип тәым кагып караган иде әни. Тик абый ишетергә дә теләмәде: «Юк инде, апа, бер алып, бер сатып йөрергә мин сезгә маклер түгел. Алган — алганда кала ул. Менә күрерсең, малайларың уйнарга өйрәнгәч, сөенеп бетә алмассың әле»,— диде дә әнинең: «Аптыраганнан әйтүем инде, түләүләрем бик күп бит, аларны ни белән түлим икән соң?»— дип елый башлавын бөтенләй ишетмәмешкә-күрмәмешкә сабышып, китеп үк барды.

Безнең әни алай хөсетле кеше түгел. Һәркемгә хәер-хак һәм гел яхшылык кына тели торган риясыз, саф күңелле изге җан иде. Ләкин әнә шул көнне: «Кем сораганые соң синнән ул гармунны шул тикле кыйбат хакка апкайтырга?! Мең газап белән үстергән тана акчасы белән түләүләремне түләрмен дип өметләнеп җөридерием бит мин. Нишлим инде менә хәзер? Кайларга гына барып бәрелим дә, ни хәлләр генә итим?!»— дип абыйны каргый-каргый елады.

Ул гармунны әни ярты бәясенә генә булса да сатарга итеп караган иде. Үзебезнең авылдан да, күрше авыллардан да сорап килүчеләр булды. Ләкин берсе дә алмады. Бәясен ишетүгә, сигез йөз сумга өр-яңа гармун алабыз без дип, шундук борылып китеп баралар иде. Дөрес, Укмас кешесе «җиде йөз иллегә бирсәгез алам бу иске тубалны»,— дип сатулашып караган иде каравын. Анысына әни үзе риза булмады: «Ике мең дә алты йөз түләп алган әйберне сиңа алай очсызга биреп җибәргәнче, балаларым уйнар ичмасам!»— диде ул теге кешегә. Шуннан соң, «гармун сатасыз икән»,— дип килүчеләрне: «Юк, сатмаска булдык инде!»— дип борып кына җибәрде.

Миңнулла абый ул гармунны чыннан да шулай кыйммәт бәягә алган идеме икән — анысын әйтә алмыйм. Ләкин безнең әнигә коточкыч кыйммәткә төште ул. Чөнки аның мәшәкате алда сөйләп киткәннәр белән генә бетмәде. Гармун алгансыз да расхутлы булгансыз икән дип, беркем дә безнең түләүләрне чигермәде.

Берәр атна шулай аһ орып, аптырап йөргәннән соң әни, әҗәткә акча биреп торуын сорап, сугышта үлгән ире өчен шактый зур пенсия алып килүче һәм үзе дә сату-алу белән шөгыльләнүче М. апа катына барган. Әнинең гозерен тыңлагач әйткән теге апа:

— Әҗәткә бирә алмыйм, үпкәләмә, Мәгъсүмә,— дигән.— Ә менә колагыңдагы алканы сатарга уйласаң, ул чакта килешергә булыр.

Әни аптырап калган. Ни өчен дигәндә, аның ул алкасы гади алка гына түгел, Чулпан йолдыз шикелле булып, әллә кайдан җемелдәп тора торган бриллиант кашлы алтын алка иде. (Хәзер андый алкалар кибеттә өч мең, өч мең ярым тора. Анда да гел булмый, танышлык белән генә тиенәләр андый алкаларга!) Ләкин хикмәт аның алтын булуында гына түгел. Хикмәт аның истәлекле тарихында. Безнең әнинең әнисе (Солтан әби) бик яшьли — нибары утыз ике яшендә үлеп киткән. Әнә шул Солтан әби әнигә васыять итеп, минем төсем итеп сакла, кызым, дип калдырып киткән алка иде ул.

Монда миңа, сезнең нәсел байлар нәселе түгел бит, андый зиннәтле алка әбиеңә кайдан килгән, дип сорау бирүләре мөмкин. Әйе, бай булмаган безнең бабайлар. Солтан бабайның атасы Әсфәндияр бабай гомере буена җәен иген иккән, кышын бүре һәм төлке ауларга йөргән. Унсигез бүре

алган. Ә төлкеләрен инде санаган да юк. Солтан бабай шулай ук үзенә тигән иманада иген иккән һәм, кыр эшләреннән бушаган чакларында, Казан — Чистай арасында ямщик чапкан. Әйтүенә караганда, алай бик зур төшемле булмаса да, шактый файдалы кәсеп булган ул. «Кешеләрнең төрлесе туры киләдерие, улым. Кайберләре тиешле урынына илтеп куйгач, төрле сәбәп тапкан булып, сөйләшенгән хакын да тулысынча түләмичә кала. Ә кайберләре сөйләшенгәннән тыш та унбиш-егермешәр тиен бирел китә торганнарые»,— дип сөйләгәннәре хәзер дә исемдә әле. Бервакыт мин аннан: «Алай булгач, ник бер дә баемадың соң, бабай? Акчаны шактый күп эшләгәнсең бит?— дип сораганым да булды. «Анысы шулай,— диде ул,— зарлана алмыйм, кергәләгән чаклары булды кулга акчаның. Тик ул акча дигән нәрсәнең бер бик хикмәтле ягы бар, улым. Безнең ише гади халык кесәсендә озак торырга яратмый ул: күпме керсә, шул хәтле үк чыга да бара. Әйтик, ямщик чабар өчен нәрсә кирәк? Иң элек теләсә кайчан җигеп чыгып китәргә кимендә бер пар яхшы ат кирәк. Аннары — алар юлга чыгарга һәрвакыт әзер торырга тиеш. Ул заман байлары бик алай теләсә кем атына утырырга атлыгып тормый, сайлабрак кына кыланаларые. Алар синең атыңа утырып барсын дисең икән, ямщик чаба торган атларың һәйбәт булырга тиеш. Ә атны тәндә тотар өчен солы сатып алырга кирәк. Збруең, чанаң-арбаң юньле булырга тиеш. Аларын да буш бирмиләр, сатып алырга туры килә. Казанга кеше илткәндә — Казанда, Чистайга барганда — Чистайда кунарга туры килә. Фатир хакы түләмичә булмый. Әмма алары гына бер хәл әле. Иң яманы шул: ул елларда ат урлау бик күп була торганые. Ямщик атларына аеруча кызыгалар. Пример, мин үзем гомеремдә ике тапкыр пар ат урлаттым. Шул ямщик чабып Казанга барган җирдә фатир кергән йортның ишегалдыннан апчыгып киткәннәрие икесендә дә. Урланган ат урынына ат алмыйча булмый бит инде: тагын акча кирәк. Менә шулай итеп, әллә ни баеп булмады, улым. Әле үзем исән калганга шөкер итеп утырам. Ул елларда ямщик чабучыларны еш кына үтергәләп торалары. Үтерәләр дә атларын алып китәләр. Бервакыт Никкүчтем чокырын узып барганда минем каршыга да чыкканнарые. Үктәбер ахырлары, җир шакаеп туңган, әмма кар яумаган, шуңа күрә арба белән йөрергә туры киләдерие. Каткак юлдан дыңгырдыңгыр Никкүчтем тавын төшеп, үргә менә генә башлаганыем, юлның сул ягыннан, куаклар арасыннан, ике юлбасар килеп чыктылар да төпкә җиккән атның башыннан тотып алмакчыларые. Әмма минем атлар, җаны кисәкләрем, ят кешеләр икәнен сизеп, пошкырышып торып уң як читкә тайпылдылар да выжлатып теге юлбасарлар яныннан үтеп киттеләр. Шул чакта, юл буендагы агач ботагы күзгә кергәние дә шуннан мантый алмыйча, бер күзем шушылай сукыраеп калды, улым. Ул чакта мин утырып барган кеше бер Казан фабрикантының хатыны булып чыкты. Казанга барып җитү белән зур гына брачка алып кереп, минем күзне шул брачка күрсәтеп тә караганые. Әмма брач әйтте, юк, кадерлем Наталья Петровна, саклап калып булмый бу ямщикның күзен, чөнки күзнең алмасы ук җыртылган, диде. Һәйбәтләп даруладды, бәйләде дә, өегездә менә шушылай-шушылай итеп үзең дәваларсың дип, даруын биреп җибәрде. Ә теге Наталья Петровна дигәне юлбасарлар кулына эләкми калуына шул тикле куанганые, бичара: башта кат-кат рәхмәт укыды, аннары, хатыныңа бүләк итәрсең дип, ул чактагы акча белән алтмыш тәңкәлек (ә ул елларда алтмыш тәңкәгә менә дигән ике ат алып буладырые) бриллиант кашлы алтын алкасын салып бирде. Ул алканы башта мәрхүмә әбиең тагып йөргәние, инде менә әнкәң тагып йөри хәзер...»

Әнә кайларга ук барып тоташкан иде әни колагындагы теге алкаларның тарихы! Менә ни өчен М. апа, сат миңа, дигәч, аптырап калган иде безнең әни. «Юк, булмый, сата алмыйм, әниемнән калган бердәнбер истәлек ул минем»,— дип борылып кайтып, тагын атна-ун түзеп карады. Ләкин көн аралаш Кече Әшнәккә авыл советына чакыртып: «Недоимкала-

рыңны кайчан түлисең, Нәҗимова? Син нәрсә, сыерыңны дәүләт бәясеннән итлеккә илтеп тапшырганны көтәсеңме әллә? Давай, ничек тә чарасын тап, түлә түләүләреңне»,— дип кыса башлагач, бүтән чарасы калмады: әни теге алкаларын әлеге шул М. апага мен дә бер йөз илле алты тәңкәгә — нәкъ дәүләткә түлисе түләүләребез бәясенә сатып кайтты. Анысын да бик сыкрап, шуннан кимгә һич бирә алмыйм М. җаным, югыйсә түлисе түләвемә җитми, дип, әни бик ялваргач кына биргән иде әле.

Әнә шундый зур мәшәкатьләр тудырды безгә Миңнулла абый алып кайткан «көмеш телле» гармун. Әле аның шунысы гаҗәп: безнең Миңнулла абыебыз Казаннан кайткан кичтә үк колхоз идарәсенә барган да: «Энекәшләргә биш планкалы, көмеш телле гармун апкайттым әле. Ике мең алты йөз сум акча каян килеп, кая китмәгән, миннән булсын яхшылык. Энекәшләр бик шәп минем, уйнасыннар рәхәтләнеп!»— дип «борчак сибеп» утырган.

Күп тә үтмәде, Миңнулла абыйны колхозга председатель итеп сайлап куйдылар. Бераз шапырыну гадәте барлыгын белгәнгә, әни белән без сүз сөйләп, вәгъдә биреп йөри торган буш куык кына булып чыкмас микән безнең бу абый, дип башта аның председатель булып эшли алуына шикләнебрәк караган идек. Күрәсең, ходай биргән сәләте булган, әйбәт кенә эшләп китте ул...

Чамасыз зур кыйммәткә төшсә дә, ахыр чиктә гармун алу барыбер Равил белән минем файдага булды: икебез дә уйнарга өйрәндек!

Шул гармун аркасында мин кеше арасына үз яшьтәшләремә караганда ике-өч ел алданрак керә башладым. Рәүф абый инде өйләнгән, авылда бүтән гармунчы юк, берәрсе кунак-төшемле мәҗлес үткәрсә, гармун уйнарга мине дәшәләр, аулак өйләргә мине чакыралар. Гармуным зур, үзем әле кечкенә булганга, өйгә килеп, гармунымны күтәреп алып баралар, китереп куялар. Үземнән олыраклар белән аралашып, шуларга иптәш булып йөргәнлектәндер, кызлар исе дә минем борынга яшьтәшләрем Миңнеәхмәтләргә,Фәрзетдиннәргә караганда иртәрәк,җиденче класста укыганда ук керә башлады. Ул хакта да алда сүз булыр, ә хәзер аңарчы булган һәм күңелемә тирән, бик тирән уелып калган кайбер хәлләр турында сөйләп үтәргә телим.

## Казанга беренче бару

Теге чакта Равил белән без гармунлы булдык, анысы бик әйбәт. Ләкин шул гармун вакыйгасы безнең әнинең Миңнулла абыйга ышанычын да бик нык какшаткан иде. Мин моны менә нәрсәдән чыгып әйтәм. Бер көнне шулай кайсыбыздыр, Равил иде бугай, кичке аш ашап утырганда Миңнулла абый хакында сүз чыккач: «Әй, әйбәт тә инде безнең абый; бүген мине атына утыртып авыл башына хәтле алып барды!»— дигән иде. Әни аңа болай дип җавап бирде:

— Әй, улым, улым, яшь шул әле син, күп нәрсәне аңлап бетермисең...

Күңелен бераз бушатканнан соң әни миңа әйтте:

— Вәт, улым, шулай эшләр. Әтиегезнең иң якын туганы, аз булса да ярдәме тияр дип, ике күзебезне дүрт итеп көтеп алган абыегыздан да фәтвә чыкмады. Аңа ышанып, моннан ары әйбер сатарга җибәреп булмас. Син инде зур: унөченче яшең белән барасың. Синең яшьтән үз көнен үзе күрә башлаган кешеләр бар дөньяда. Мин сиңа алай ук бул дип әйтмим, әмма, кешеләргә ияреп, ит-май сатарга Казанга йөргәли башларга кирәк булыр моннан ары. Русча яхшук браматлыйсың. Акча саный беләсең. Белмәгән нәрсәләреңне үзең белән рәттән сатучы олылардан сорарсың, алар ярдәм итәр.

Әнинең «русча браматлыйсың» диюендә хаклык бар. Безнең авыл

урман буена урнашкан. Зур түгел ул урман, өч йөз илле гектар гына. Урманның икенче ягында, бездән нибары бер километрда гына, Ильиновка дигән рус авылы. Шул авылның бер кешесе, дәдә Никулай, безнең колхозда тимерче булып эшли. Аның Нәтүлке (Анатолий) исемле нәкъ минем белән бер елгы малае бар һәм ул малай, әтисенә ияреп, көн саен диярлек безнең авылга килеп йөри. Әнә шуның белән бик дус идем мин. Көннәр буе бездә кайнашабыз: булган ризыкны бергәләп ашыйбыз, әни кушып калдырган эшләрне бергәләп эшлибез, бергә уйныйбыз. Безнең авылда кызык беткәч, Равилне һәм бүтән иптәш малайларны ияртеп, Ильиновкага барып, рус малайлары белән уйнап кайтабыз. Нәтүлкенең әнисе эштә булганда әбисенә сулар да алып кайтып бирәбез. Шулай бергәләп йөри торгач, мин Нәтүлкедән русчага да өйрәнгән идем бераз. Шуңа күрә мине русча сөйләшү мәсьәләсе ул кадәр куркытмый. Ә Казанга барасым бик килә, аны күрергә әллә кайчаннан бирле хыялланам. Олылар сөйләгәннәрдән чыгып,Казан кремлендә Сөембикә манарасын, Батан бакчасындагы филләрне, арысланнарны, юлбарысларны, маймылларны, ак аюларны карап йөргәннәрем, Казан циркында клоуннар кыланганнары, колхоз базары янында кораштырылган күчмә циркта мотоцикл белән стенада йөргәннәрен карап утыруларым төшләремә кереп йөдәтеп бетергән иде инде. Шуңа әнинең әлеге тәкъдименә биш куллап риза идем:

— Була ул, әни! Ә кайчан барасы соң анда?

— Көзсез булмас әле, улым. Сарык бәрәннәре исән-сау үсәсе бар әле аңарчы. Шуларның түшкәсен алып барырга туры килер.

Ул елны ике сарыкка өч бәрәнебез бар иде. Тизрәк үссеннәр, симезрәк булсыннар дип, Равил энем белән без аларны аеруча нык тәрбияли башладык: кич көтү кайтканнан соң, әниләре белән бергә дәү чишмә буйларына, колхозның алма бакчасы тирәләренә (безнең өй авылның түбән очында, кырыйдан өченче, алма бакчасына якын гына иде) алып барып та берәр-икешәр сәгать ашатып кайтабыз. Алар безгә шул кадәр нәләшкән — тагылган шикелле арттан ияреп йөриләр.

Әни ашлы суларны, бәрәңге кабыкларын гел шул бәрәннәргә бирә торган иде. Бәрәннәрнең үз әнкәләре дә, нәкъ безнең әни шикелле, бик тә бала җанлы: тегеләр кайчан теләсә — шунда имезәләр. Ә бәрәннәрнең оятлы юк; инде үзләре сарык булып килүгә карамастан, сәгать саен диярлек, әниләрен чөя-чөя имәләр иде. Тик, тәкә белән йөргәннән соң, сентябрь башларында гына туктады алар имүдән. Алар ул чакта инде әниләреннән аерып алырлык та түгел иде. Мин аларның шулай тиз үсүләренә чын күңелемнән куанып йөрим, чөнки Казан тикле Казанга барганда симезрәк ит белән бару әйбәт бит инде. Хәзер генә ул итнең «маталышка»ларына хәтле барысын да биш тәңкәдән кулда да тотмыйча алып бетерәләр. Ул елларда мал түшенең арт саны белән ал санының бәясе ун-унбиш сумга аерыла — арт саны кыйммәтрәк йөри иде.

Ниһаять, мин җәй буе түземсезләнеп көткән көн килеп җитте. Октябрьның унсигезендә Казанга барырга җыена башладык. Безнең авылда мин белә-белгәннән бирле колхоз умарталыгында умартачы булып эшләүче, үзе тәмәке тартмаса да, тарткан кеше шикелле бик каты йөткерә торган (аның йөткергәне җәйге тын кичләрдә урмандагы умарталыктан авылга кадәр ишетелә торган иде), тыныч кына сөйләшкәндә дә тавышы гөрелдәп чыга торган, ачуланган чакларында исә котларны ала торган калын тавышлы Хафиз карт бар иде. Үзе умарталыкта, малае Рәүф абый колхозда хисапчы булып эшләгәч, аларның матди хәлләре әйбәт, беркайчан ит-балсыз тормыйлар. Алай-болай йомышы төшеп өйләренә кергән кешедән дә кызганмыйлар: я бал ягып ипи, я берәр төрле мич ашы тоттырып чыгаралар. Әгәр инде Хафиз картка утын кисешсәң, я көтүдән кайтмый калган сарыкларын алып кайтып бирсәң, ул чакта табын янына ук утыртып, туйганчы сыйлап чыгаралар.

Шуңа мин аларга ярдәм итәргә атлыгып торам. Хафиз карт үзе дә ми-

не якын итә: «Атаңа ошагансың, атаң шулай ярдәмчел кешие, мәрхүм»,— дия иде ул миңа. Аннары картның тагын бер бик кирәкле һөнәре бар: мал суярга оста иде ул. Ир-аты булмаган кешеләр, Казанга алып барасы малларын аннан суйдыртырга тырышалар. «Эшен бик чиста эшли, аннары кулы да бик җиңел: ул суйган итне чират торып алып бетерәләр»,— дип сөйлиләр иде.

Хафиз картлар сарыкны безнең шикелле ике-өчне генә түгел, унар-уникешәр баш асрый. Таналары-бозаулары да була. Үзләренекеннән тыш, яз саен берәр бозау сатып алып та үстерәләр. Каз-үрдәкне авылда иң күп асраучы да — алар. Шулкадәр сугымны, әлбәттә, үзләре генә ашап бетерә алмыйлар, Хафиз карт елына ике-өч тапкыр Казанга ит белән барып кайта.

Теге чакта безнең әни Хафиз картның Казанга җыенганын белгән дә, үзе белән сөйләшеп, мине аңа ышандырып җибәрергә булган иде.

Хафиз карт өч түш ит алып барасы иде, башта аларның сарыкларын суйдык. Белмим, кайда шул кадәр өйрәнгәндер: сәгать ярым дигәндә, ул инде өч сарыкның өчесен дә суеп элеп куйган иде. Аннары безгә киттек. Аларның сарыкларын суйганда мин Хафиз картка сарык аякларын бәйләшеп, кулын юарга җылы су, үпкә-бавырларын куярга табак-савытлар апчыгып, хәтта сарыкларның эчәкләрен дә савышып, булышып тордым. Ләкин үзебезнекеләргә чират җиткәч якын да бара алмадым: шулкадәр кызганыч иде бәрәннәр! Иренүдән түгел, кызганудан гына шулай булуымны белгәч, Хафиз карт та: «Бер син генә түгел, дөньяда андый кешеләр була ул. Бар, алайса, бүтән эшләрегезне карый тор»,— дип мине өйгә кертеп җибәрде. Ә аңа әни белән Равил ярдәм итешеп тордылар. Казанга барасы булгач, әни инде күптәннән каймак җыеп килгән, ике чиләк каймагы бар иде. Хафиз карт ишегалдында бәрәннәрне эш иткән арада мин, гөбегә салып, шул каймактан май яза тордым...

Казан бездән җитмеш сигез чакрым. Ат белән барган чакта иртәнге дүртләрдә кузгалалар да кичке җиделәргә көне барып керәләр. Ә соңгы елларда, атлар сирәгәеп калганлыктан, үгез җигеп йөриләр, шуңа көнендә барып җитеп булмый, кичтән үк юлга чыга башлаганнар иде.

Мин ул елны дүртенчедә укыйм. Отличник үк булмасам да, «өч»лем юк иде. Шуңа минем Казанга баруыма укытучы Мәрьям апа да каршы килмәде. Колхозның бик дәү һәм бик тыныч холыклы, ләкин бик ялкау Черчил исемле үгезен җигеп кичке уннарда ук тәвәккәлләп чыгып киттек Казанга. Бер олауга без биш кеше: Хафиз карт белән миннән калганнары хатын-кызлар иде. Безне йөк авырлыгы куркытмый: ялкау булса да, Черчил күпме төясәң дә җен урынына сөйри, тик арбаң гына чыдасын да көпчәкләрең генә түзсен! Әмма ашавын да бик күп ашый иде.

Шуны истә тотып, авылыбыздан унбиш чакрымнар чамасындагы Куастау кырына туктап, төнге сәгать бердә шайтаным да йөрми, беркем күрмәс әле дип, үзебезнең колхоздан алып чыккан печән өстенә солы кибәненнән егерме данә солы көлтәсе дә төядек. «Азыклы ат арымас», дигән борынгылар. Базарның нинди туры киләсен, Казанда ничә көн торырыбызны кем белгән. Бәлки, берәр атнага ук сузылыр. «Даваегыз, давай, күбрәк төягез!»— дип бу эшкә Хафиз карт үзе җитәкчелек итеп торды.

Кибән яныннан хәвефсез-хәтәрсез генә кузгалып киткән идек. Әмма күп тә бармадык, артыбыздан иярле атка атланган, иңенә мылтык аскан бер кеше килеп чыгып, юлыбызга аркылы төште:

— Стой, буду стрелять!

Ләкин безнең Черчил андый гына кычкырганнарны күп ишеткән: ыжлап та бирмичә, баруын дәвам итте. Аның велосипед руле шикелле булып ике якка тырпаеп торган, ләкин велосипед руленнән биш мәртәбә юанрак мөгезеннән шүрләп, тегенең аты читкә тайпылып калды. Шуннан ары, үгезне туктатырга тырышудан мәгънә чыкмаслыгын аңлап, теге кеше арба артына, безнең янга чыкты:

— Ешше раз говорю, стой! Остановите своего быка, иначе буду стрелять!— дип кычкырды.

Хафиз карт та, хатын-кызлар да шүрләп калганнар иде: тып-тын гына атлый бирделәр. Мылтыклы тагын бер кат кычкырды һәм һавага атып җибәрде.

Өч хатын-кызның өчесе дә чырыйлап кычкырып, Хафиз картка сыендылар. Хәтта Черчил дә сискәнеп китеп, калын тавыш белән «ooh!» дип кисәк кенә мөгрәп, туктап калды.

Хафиз карт нигәдер:

— Җитәр сәнә! Нәрсә ул кадәр чырылдашасыз!— дип, үзенә елышкан хатын-кызларны орыша башлады.

— Сүң ир кешегә сыенмыйча, кая барыйк без, пәрәми! Урысча беләсең бит, сөйләш инде шул урыс белән. Телеңне җоткан шикелле торма!— дип Хөсниҗамал апа чәчрәп чыккач кына, ниһаять, атлы кешегә эндәшергә җөрьәт итте:

— Ыфчум дилы, знакум? Зачим шумиш? Зачим астановиш нас? Што мы плохой делали?

— Вы украли колхозные овсяные снопы!

— Чава-чава? Какой сноп?— диде Хафиз карт, бу юлы инде батыраебрак.

Җайдак безнең йөккә төртеп күрсәтте:

— Ты што, мужик, прикидываешся дураком?!

Җайдак мылтыгын корып куйды. Мылтык көпшәсе белән безнең арбадагы солы көлтәләренә төртте: «Вот эти снопы! Думаешь, я не видел што ли? Если час же не отвезете и не сложите обратно их на местó в стог — я сдам вас в милицию!

Милиция сүзе чыккач хатын-кызларыбызның котлары алынып, өчесе тиң шыңшырга һәм белгән догаларын укырга тотынганнар иде. Ләкин Хафиз картка бу ошамады: бар ачуын алардан алырга теләгәндәй, бик каты итеп:

— Җиттеме сезгә, юкмы? Чырылдашмагыз, туктагыз хәзер үк!— дип кычкырды.

Аның тавышы шул кадәр ачулы чыкты, хәтта җайдак та бер мәлгә шүрләп калды. Шул моменттан файдаланып, Хафиз карт аның янына барды да, йомшак кына итеп:

— Видиш, знакум, бабы как пугалис. Видиш, как плакают. Давай будем гаварит чалавически...— дип тегеңә пышылдап кына нидер әйтте.

Аның ни әйткәнен мин ишетмәдем, ләкин күп тә үтмәде, җайдак шундук йомшарып:

— Ладно, ладно, так и быть уж, уговорил. Только, давай, быстрее,— дип атыннан төште. Ул арада Хафиз карт тиз генә арба янына килеп, хатын-кызларга тыныч кына алга атлый торырга кушты, ә үзе йөктән юл азыгы тутырган брезент сумкасын алып, башта теге кешегә зур гына бер кисәк ит һәм калай кружка тоттырды... Агай кыстатып-тормады:

— Ну, мужик, бывай, желаю тебе хорошего базара!— дип кружканы каплап куйды. Сулышы буылып, беркавым тын ала алмыйча торды. Тик шуннан соң гына умырып-умырып ит ашарга тотынды.

Хафиз карт тагын берне салып бирмәкче иде, агай риза булмады.

— Нет, хватит. Много будет. Спасибо тебе,— дип, атына менеп атланды да чаптырып болын ягына таба китеп барды.

— Ничек шулай тиз җайлый алдың син аны, Хафиз абый?— дидем мин, баш китәрдәй булып тоелган эшнең шулай ансат һәм безнең файдага хәл кылынуына исем китеп.

— Бөтен хикмәте менә шушында, олан,— диде карт, флягасына ымлап.

— Хикмәт дип инде. Аны бит колхоз милкен каравылларга куйганнар, ә ул шул милекне хәмергә сатып китте.

— Ва-пирвых, аны беркем бернинди каравылга куймаган. Төнге ат көтүчесе ул. Ва-втарих, безнең солы кибәне яныннан чыгып барган чагыбызга случайны туры килде дә, шуннан файдаланып үзенең махмырлап торган башын төзәтеп китте. Ә асылда, син дөрес әйтәсең, малай: сатучылар күбәйде калхуз малын. Менә без бу калхуз көлтәләрен чәлдердек. Ә безнең калхузныкын бүтәннәр чәлдерә...

— Ә урлашмыйча гына булмыймыни соң?

— Була, ник булмасын.

— Алайса ник урлашалар?

— Тәртип юкка.

— Ә нигә юк соң ул тәртип?

— Ул тәртип шуңа юк, чөнки тәртипсезлек эшләүчеләрне җавапка тарту юк. И һәм, җавапка тарту дигән нәрсәне гамәлгә кертми торып, тиешле тәртип булмаячак та!

Безнең хатын-кызлар инде шактый җир китеп өлгергән иде. Черчилне кызурак атлатып, без дә алар артыннан киттек.

Күктәге сыек һәм биек болытларны ачык-алсу төскә манып, таң сызыла башлаганда без инде Колай болынына килеп җиткән идек. Мишә буенда тукталып, Черчилне тугарып, берәр сәгать ашатып-эчереп, ял иттереп алырга булдык. Арба артыннан җәяү барганга гына сизелмәгән икән: туктагач шактый салкын булып чыкты. Таң җиле дә исеп куйгач, отыры салкынайтып җибәрде.

Хафиз карт, тәҗрибәле кеше, өстенә тышлы тун, аягына чусинке кигән: әллә бар аңа суык, әллә юк — уйлап та бирми. Ә минем өстә бер кат чалбар, ямаулы иске бишмәт, аякта чабата гына. Шуңа күрә калтырата ук башлады.

Олылар, арбадан төенчекләрен алып, ризыкларын ашарга утырдылар. Кеше ашаганда ашарсың дип, әни миңа бавыр белән ипи биреп җибәргән иде. Ләкин бу суыкта ул салкын бавырны ничек итеп авызга алмак кирәк?.. Хатын-кызлар да шактый җылы киенгән: аякларында тула оек белән чабата, өсләрендә телогрейка, башларында мамык шәл. Алар, әнә, Мишә ярына аякларын салындырып утырганнар да, үз өйләрендәгедәй иркенләп, төнлә безнең котны алган ат көтүчесе турында көлешә-көлешә сөйләшеп, рәхәтләнеп ашап утыралар.

Хафиз карт, йөк өстенә менеп утырып, бисмилласын әйтеп, брезент сумкасындагы ризыкларны чыгара башлады. Кеше ашаганны карап тору килешми дип, аннары тик тору бик нык туңдыра да башлаганга, мин яр астына төштем дә, шундагы вак ташларны җыеп, читләре инде боз белән челтәрләнгән, ләкин әле ныклап туңарга өлгермәгән Мишә суына атып уйнарга тотындым. Биш-алты таш кына аткан идем, Хафиз карт мине үз янына дәшеп менгерде дә, читтәрәк утырган хатын-кызлар ишетмәслек, әмма карышып торырга урын калдырмаслык итеп:

— Мәле, малай, тотып куй әле шушы чәйне: эчеңә әзрәк җылы кереп китәр, туңып үләсең бит югыйсә! — дип, үзенең теге алюмин кружкасын сузды.

Чәе бик аз, кружканың төбендә генә иде. Кичтән туйганчы яңа суйган бавыр ашап чыкканга, тамак та кипкән иде, аны-моны уйлап тормадым, тоттым да бер тында эчеп җибәрдем тегенең чәен. Эчеп җибәрүем булды, башта авызым өтелеп китте, аннары бик озак сулышым капланып торды. Тик шуннан соң гына, ниһаять, сүз әйтә алырлык хәлгә килдем:

— Чәй түгел бит бу, Хафиз абый! Нәрсә эчердең син миңа?

— Тышш, шаулама! — диде ул миңа, авызымны каплардай булып.— Курыкма, бер дә, хәзер бетә аның әчеттергәне. Суык тимәскә, дару урынына гына ул.

Шулай дип сөйләнә-сөйләнә ул минем кулга бер кисәк ит һәм ярты телем ипи тоттырды. Аннары:

— Каяле, мин дә бераз җибәрим әле,— дип, кружканы тутырып диярлек салып, үзе эчеп куйды да:— Ә хәзер, әйдә, әйбәтләп ашап алыйк,— дип ашарга тотынды.

Үзем ул биргән ризыкларны ашыйм, ә үзем ни булганын тиешенчә төшенеп бетә алмыйча, шаккатып утыра идем. Аракы эчкән кешеләрне дә, исерекләрен дә байтак күргән бар, ә үземнең ул нәрсәне авызыма алганым юк, алырга җыенмый да идем. Менә хәзер, һич көтмәгәндә, кружка төбендәген эчтем бит, ахмак! Нишләтер икән инде ул мине?..

Бер яктан әнә шул уй борчый, икенче яктан Хафиз картның кружкалап спирт эчүенә һушсыз калган идем. Мин бит аны бөтенләй изге кешегә санап йөри идем моңарчы. Аны безнең авылда гына түгел, тирә-як авылларда да беләләр. Шәкерт абзый дип үлеп торалар. Үлем-җитем булганда мәет өстендә ясин чыгарга яки коръән укырга аны дәшәләр. Шул ук вакытта ул безнеңчә укый-яза да белә, чөнки заманында чит җирләрдә төрле эшләрдә эшләп йөргән, шактый мәгълүматлы кеше иде. Кыяфәте дә бик шәп: ап-ак түгәрәк сакаллы, зур коңгырт күзле, дәү, әмма үзенә бик килешеп торган борынлы, сәламәт кызыл чырайлы, ике метрга бик аз гына тулмаган озын һәм нык гәүдәле мәһабәт кеше иде ул. Халык арасында авторитеты да зур. «Хафиз карт шулай дип әйткән», «Шәкерт абзый шулай дип әйтә икән»,— дип, ул сөйләгән сүзгә гаять зур әһәмият бирәләр иде.

Картның тик бер нәрсәсен өнәп бетермиләр: эчә икән дип сөйлиләр иде. Мулла кеше ничек эчсен икән, юк сүздер ул, дип күп кеше моңа ышанмый. Мин үзем дә шул ышанмаучылар ягында идем. Ә ул, әнә, әле хәзер генә ничаклыны эһ тә итмичә каплап куйды. Менә шуңа шаккатып, авызымны ачып калган идем. Шулчак Хафиз карт, яр буенда үзара гөр килеп утырган хатын-кызларга таба ымлап:

— Аларга сиздерә күрмә, малай, май кап, яме! Мондый салкын чакларда дару урынына азрак кына тотып кую пигамбәрләрдән калган гадәт ул!— диде.

Аның бу сүзләре белән килешмәсәм дә, бәхәсләшеп тормадым. Дөресен генә әйткәндә, миңа хәзер дингез тубыктан: чымыр-чымыр итеп, хәмер бөтен канга таралган, хәтта башка ук менеп җитеп, миләрне миңгерәтә, күз алларын әлҗе-мөлҗе китерә башлаган иде. Шунысы хикмәт: миңа хәзер тамчы да суык түгел, киресенчә, эсселәтеп җибәрде. Хәтта Мишәгә төшеп, су коенып чыгасыларым килә иде. Аннары, армиягә алынган егетләр шикелле итеп, кычкырып җырлыйсым килә башлады. Тик яр буенда утырган Хөснижамал, Гөлбаһар, Мәүлиха апалардан арусынмыйча һәм Хафиз карт кисәтеп куйганга гына тыелып тора идем.

Хафиз карт ит янына тавык та пешереп алган икән, шуңа тотынды.

— Ничек суң, җылынып киттеңме?— диде карт, ярты тавыкны сыптырып, «гуук!» итеп кикереп куйгач.

— Әйт әле, Хафиз абый, моның гөнаһсын кая куясың инде син, ә?— дидем, алдап эчергәне өчен аңа җенем чыгып.

Карт дерт итеп китте:

— Нинди гөнаһ ул? Нәрсә сөйлисең син, ахмак баш!

— «Эчкән бер гөнаһлы булса, эчергән кеше мең гөнаһлы»,— дип гает намазында вәгазь сөйләгәндә үзең әйткән идең түгелме соң? Мин бит гомердә авызыма аракы алган малай түгел.

Карт яшен тизлеге белән арбадан сикереп төшеп, үңәчемнән каптырып алды:

— Тукта яхшылык белән! Тагын бер генә шундый сүз әйтсәң — буам да үтерәм.

Аның күзләре нурсызланган, йөзе шундый усал — котыңны алып, йөрәкне ярырлык иде. «Чыннан да үтерер бу!»— дип, шүрләп куйдым да:

— Бетте, бетте Хафиз абый, гафу ит,— дидем.— Син гаепле түгел, үзем гаепле. Дөрес әйтәсең, син бит минем авызыма коймадың, үзем эчтем.

— Һыы, шулай диген аны! Әтү тузга язмаганнарны лыгырдап маташасың!— Бастырык озынлыгы кулы белән әле һаман үңәчемнән тотып тор-

ган килеш, ул мине каты гына итеп бер селкеп куйды:— Мотри, кара аны, эчкәнеңне берсенә дә сиздерәсе булма!

Карттан куркудан шулай булгандырмы, аракы эчкәннекеме — мине шул чак бик нык укшыта башлады. Яр буендагы таллар арасына чабып кереп, ашказанын бушатып чыктым. Шуннан соң бераз җиңеләеп киттем...

Без Самасыр (Самасырово) авылын үтеп, аэропорт тирәләренә килеп җиткәндә инде төш авышкан иде. Юл авыр: көндез җебетеп җибәргән дә туң балчык арба көпчәкләренә ябыша, болай да ашыкмый торган Черчил, таеп егылудан куркып, сакланып кына атлап бара. Менә бер вакыт, кинәт күктән иңгәндәй, безнең өстән генә ике канатлы бер аэроплан килеп чыкты. Безнең авыл халкын аэроплан белән әллә ни шаккаттыра алмыйсың анысы. Кырык өченче елны, ягулык бензины бетеп, бер аэроплан безнең авыл башына ук килеп төшкән иде. Җил алып китмәсен өчен, аны менә шушы Хафиз картларның бакча башындагы тополь агачына бәйләп куйганнар иде. Районга барып, очучылары бензин юллап алып кайтканчы ике тәүлек шунда торды ул аэроплан. Аны каравылларга бала-чаганы ярата торган Хәнәфи абыйны куйганнар иде. Рәхәтләндек шул чакта аэроплан карап. Хәнәфи абый аэроплан эченә үк кертмәде кертүен, әмма тышыннан тотып караганга бер сүз әйтмәгән иде...

Анысы шулай. Ләкин ул чактагы аэропланны Черчил күрми калган, күрәсең. Чөнки менә хәзер, өстебезгә аэроплан килеп чыккач, ипләп кенә, йоклатып кына барып яткан җиреннән кинәт коерык чәнчеп, юл буендагы чокырга сикерде. Чокыр шактый текә һәм сикәлтәле иде. Безнең арба башта бер якка янтайды, аннары, күчәрдән кендеге чыгып, капланып ук китте. Бу шул кадәр тиз булды ки, бишебезнең беребез берни эшли алмыйча калдык.

Ә аэроплан инде безнең турыдан үтеп, шактый югары күтәрелергә өлгергән иде. Арбаның алгы күчәре чокырда яткан ташландык сука тимеренә эләгеп, Черчил дә туктап калган һәм Хафиз карт йодрыгы хәтле булып киңәйгән борын тишекләре белән еш-еш сулап, куркуыннан кан баскан кызгылт күзләрен мөлдерәтеп, ачуланмагыз инде, иптәшләр, гаеп миндә, гомеремдә күрмәгән коточкыч зур тимер кош өстемә килә башлагач, ни эшләгәнемне үзем дә сизми калдым, дигән сыман безгә карап тора иде.

Кыяфәте бик шәп, бик көчле күренсә дә, Хафиз карт ир-ат эше белән алай бик алыш-биреш иткән кеше түгел. Һәрхәлдә, мин аның, үгез дип әйтмим, ат туарып, ат җиккән чагын да күргәнем булмады. Ат җигеп тегермәнгә яки урманга утынга барганын шулай ук хәтерләмим. Бүкән янына берәр төрле йомшак әйбер куеп, шуңа тезләнеп чыбык-чабык утыннарны кисә. Ләкин кулына пычкы тотып юан агач кискәне юк иде аның. Андый эшләрне ул салырга ярата торган ир-атларны кушып эшләтә дә соңыннан ачы бал белән сыйлап җибәрә. Яки минем ише өч-дүрт малайны дәшеп, шуларга кистерә дә ахырдан я кәрәзле бал биреп, я итле аш ашатып җибәрә торган иде.

Менә хәзер, йөгебез авып, арбабыз капланып яткан чагында да каушап-югалып калды Хафиз карт. Үзе башлап йөрисе урынга:

«Ни карап торасыз? Даваегыз, үгезне апкилегез! Арбаның йөген бушатыгыз!»— дип әмер биреп торудан ары уза алмады.

Ярый әле кырык беренче елдан, ире сугышка киткән көннән ат җигеп йөреп, ирдәүкәләнеп беткән Хөсниҗамал апа бар иде арабызда.

— Син суң, Хафиз абый, нигә башыңа бүрек киеп йөрисең, үгез җигәргә дә кодрәтеңнән килмәгәч! Әйдә, укаң коелмас, булыш әзрәк!— дип пыр тузып ачуланса ачуланды, ләкин үгезне алып килеп тугарып җигүне дә, арбадагы йөкне бушатып төяүне дә ул башлап йөрде.

Арба ауган чагында итләргә әллә ни зыян килмәгән. Хатын-кызларның икешәр-өчәр йөз йомыркалары булган икән, шуларның барысы да диярлек чәрдәкләнеп беткән иде.

— Булмаган бәхетне чүкеп ясыйсыңмыни аны!— дип әлеге шул Хөснижамал апа тагын бер җилпенеп алды да, шундук кайтып төшеп: — Әй, ярар ла, гел Казан халкына гына ашатырга димәгән, үзебезнең дә тамак бар ич, хәзер бозыла торган чак түгел. Кызым Сөембикә белән рәхәтләнеп атна буе йомырка тәбәсе ашарбыз нчмаса,— дип ватык йомыркаларның кабыкларын алып атты, чиләгенең өстен һәйбәтләп бәйләп куйды.

Аңа карап, башкалар да шулай эшләде. Хафиз картның да алтмышлап йомыркасы булган икән, ләкин ул алай вакланып тормады: ватык йомыркаларын чиләге-ние белән канауга тибеп кенә төшерде.

Шуннан соң Казанга кергәнче дә, Казанга кергәч тә Черчилне Хөснижамал апа башыннан гына тотып барды.

Олылар Казан да Казан дип сөйләгәч, мин аны биек-биек таш йортлардан гына гыйбарәттер, һәр йорты үзенә бер төрле зиннәтле сарай шикелле матурлап эшләнгәндер дип күз алдыма китергән идем. Әмма ул мин көткәнгә караганда күп кайтыш булып чыкты. Ул чакта ничек аталганын хәтерләмим, Казанга без хәзерге Гадел Кутуй урамыннан килеп кердек. Ә ул урамдагы өйләр барысы да дип әйтерлек бер катлы агач өйләр, безнең авыл өйләреннән әллә ни артык түгел иде. Бар булган аермалары шунда гына: күбесенең тирә-ягына такта-токтадан яссы түбәле бәләкәй генә куышлар әмәлләгәннәр дә шуларга морҗа чыгарганнар. Нигәдер алар миңа чикләвек кишәнкесендәге бер зур кишәнке янында булып та, аҗаган алганлыктан, үсмичә корып калган вак чикләвекләрне хәтерләттеләр. Без хәзерге Красная Позиция урамына (ул чактагы исемен әйтә алмыйм) кергәч, каршыбызга бәләкәй генә җиңел машина килгәне күренде. Минем йөк машиналарын күргән бар. Кырык дүртенче-кырык бишенче елларда, сатып алырга бәрәңге эзләп, Казаннан безнең авылга «Студебеккер»лар белән дә бик күп тапкырлар килгәннәр иде. Без ул кешеләргә: «Фәлән апаларның сатлык бәрәңгеләре бар, әйдәгез, үзебез күрсәтәбез өйләрен!»— дигән булып, машиналарына утырып барган чакларыбыз да булды. Ә минә «лүхкавай машина» дигәннәрен киноларда күргән булсам да, үзләрен шушылай якыннан күргәнем юк иде әле. Нинди маркалы машина булгандыр, анасын әйтә алмыйм, Казанга кергәч иң беренче очраган ул җиңел машина бик бәләкәй, уенчык шикелле генә тоелды миңа.

Үзе кечкенә булса да, хәйран тиз йөри икән: выжлатып кына үтеп китте. Әллә безнең үгезне куркытыр өчен, турыбыздан үткәндә «тууут-тууут-тууут!» итеп хәтәр генә кычкыртып та китте әле. Юл килеп арыгангамы, әллә мине алай гына өркетә алмассың, мин үзем дә синең хәтле бар, дип уйлагандырмы: Черчил аның кычкыртуын колагына да элмичә, үз көе белән атлый бирде...

Арча кырындагы балчык күперне чыккач, андый «лүхкавай»лар безгә бик еш очрый башлады. Мин хәзер аларның үзләренә игътибар итмим, «тууут-тууут» итеп кычкырткаңнарына сискәнеп, таптап китмәгәйләре дип котым алынып, як-ягыма карап барырга да чак өлгерә идем. Монда инде урамы да чиста, өйләре дә зур һәм биек, трамвайлар да йөреп тора, монысы — мин күптәннән күрергә хыялланып йөргән чын шәһәр иде.

Аннары без сулга борылып, тар гына урамнар аша барып, тау астына, елгага төштек. Безнең авылда андый елгага кеше түгел, кәҗәләр дә төшми, ә монда шул елга эченә хәтта менә дигән икешәр катлы йортлар салганнар һәм алар шундый еш салынган — бер-берләренә орынып ук торалар иде. Мин нигә болай иттеләр икән дип сорагач, Хафиз карт:

— Авылда гына кадерен белмибез җирнең, шәһәрдә бик кадерле ул, олан!— дип җавап бирде.

Без шул елга төбенә диярлек утырган кечерәк кенә бер катлы йортка тукталдык. Хафиз карт миңа юлда килгәндә үк: «Сезгә туган тиешле Фатыйх атлы кешеләргә керербез фатирга. Исемен алдан ук хәтереңә алып куй. Хатыны Фатыйма исемле. Синең тирәләрдәге малайлары да бар.

Анысының исемен оныттым. Баргач үзең сорарсың. Кара аны, үзенне тәртипле тот: килеп кергәч Фатыйх абыең белән дә, Фатыйма апаң белән дә һәйбәтләп, кул биреп күреш. Тиешле-тиешсез урынга утырма, әйберләренә кагылма»,— дип искәртеп-кисәтеп куйган иде.

Күрәсең, бала-чаганы бик үк яратып бетерми торган кыркурак кешеләрдер дип, курка-курка гына барган идем. Ләкин шикләнүем нигезсез булып чыкты. Без барып кергәндә Фатыйх абыйлар кичке аш ашап утыралар иде. Шундый чакта безгә берьюлы биш кеше килеп керсә, мин үзем, мәсәлән, кочак җәеп каршы алыр идек дип әйтә алмыйм. Әмма Фатыйх абый үзе дә, аның җәмәгате Фатыйма апа да безне: «Әйдәгез, әйдә! Мактап кына йөрисез икән: аш өстенә туры килдегез!»— дип, күптән көткән кунаклары килеп кергәндәй куанып каршыладылар. Ә инде минем Нурулла малае икәнне белгәч исә болай да якты йөзләре тагын да нурланып китте:

— Их, дөньялар! Атаң үлгәндә өч яшь тулган гына иде әле сиңа. Инде җегет булып җиткәнсең. Их, атаң исән булса, сөенеп туя алмасые, мәрхүм!— дип Фатыйх абый аркамнан да сөеп куйды хәтта. Аннары икенче бүлмәдә дәрес әзерләп утырган малаен чакырып чыгарды да: «Менә, улым, безгә туган тиешле Нурулла абыең малае бу. Бер-берегезне белеп торыгыз: туганнарны белеп торырга кирәк»,— дип аның белән дә таныштырды.

Малае Мәхмүт исемле икән. Мәхмүт минем белән танышуына әллә ни шатланмады шикелле. Әтисе әйткәннәрне тыныч кына тыңлап торды да, бер сүз әйтмичә, үз бүлмәсенә кереп китте. Юл килеп шактый нык арыган идем. Төенчекләребездәге ризыкларыбызны хуҗаларның электр плитәсендә җылытып ашап, маңгайдан тирләр чыкканчы чәй эчкәч, чишенеп-нитеп тормыйча гына, биштәр капчыгы булганы — биштәр капчыгын, сатарга дип алып килгән йоны булганы — йонын баш асларына салып, хатын-кызлар тезелешеп идәнгә ятты. Хафиз карт белән миңа хуҗалар үзләре ягындагы диванга урын җәйгәннәр иде. Ләкин Хафиз карт ятарга ашыкмады. Тамагын кыргалап, әзрәк сөйләшеп аласы сүз барые, диган булып һәм шул ук вакытта фләгәсе бар икәненә дә ым кагып, ул Фатыйх абый белән кухня якка кереп китте. Ә мин барып мендәргә башымны кую белән йоклап киттем. Хафиз карт кайчан килеп яткандыр — анысын да тоймадым.

Ләкин туйганчы йокларга мөмкинлек булмады: иртәнге сәгать биштә үк торып, аннан-моннан гына тамак ялгап, берәр стакан чәй эчтек тә базарга, ит сата торган рәттән урын һәм үлчәү алып калырга ашыктык. Алай да таманга гына килде әле: без барганда әйбәт урта урыннарны алып бетергәннәр, безгә кырыйдагылары гына калган иде.

Белмим, Хафиз карт әгъвәләгәндерме, үз теләге булгандырмы, миңа ит сатышырга Фатыйх абый да менгән иде. Ничекләр итеп кенә сатармын икән ул ике түшкәне, гомеремдә бер тапкыр да андый эш белән булашкан кеше түгел бит, дип Казанга килгәндә юл буе ут йотып килгән идем. Фатыйх абый итне кулыма да тоттырмады:

— Син, олан, акча гына алып торырсың, сатуын мин үзем карармын,— дип, үлчәү янына басты.

Хөсниҗамал апалар, Хафиз картлар берәр түшкәләрен дә бетерә алмый калдылар, ә бу инде ике түшкәне дә ялт иттереп куйган иде. Моңа хәтта Хафиз карт та исе китеп:

— Мин үзем дә начар сатучы түгелием ләбаса, ничек булды соң әле бу?— дип сорагач, Фатыйх абый мыек астыннан гына елмаеп куйды да:

— Шәһәр халкының бер гадәте бар: әйбер алганда танышлык белән, белгән кешесеннән алырга ярата ул. Ә мине, двурник булып эшләгәнгә, ярты Казан белә,— дип җавап бирде.

Аның әле шунысы да бар: безнең итнең килосы уртача егерме алты сумнан, ә Хөсниҗамал апаларныкы һәм Хафиз картныкы тик егерме өч сумнан гына чыккан иде!

Берсе уникe, берсе унөч килолы бәрән түшкәләреннән төп-төгәл алты йөз илле сум акча чыкты ул чакта.

«Бүтәннәре миндә торып торсын, монысына күңелеңә ошаган әйберне алып ашарсың. Бар, чыгып әзрәк базарлар карап йөр дә кайтып ял итә торырсың»,— дип, егерме сум акча тоттырып, Фатыйх абый мине ит лабазыннан чыгарып җибәрде. Үзе безнең хатын-кызларга ярдәм итешә калды.

Халыкның умарта күче шикелле кайнап торуын һәм андагы әйберләрнең күплегенә исем китеп, базарны ике рәт әйләндем. Теге егерме сумның ун тәңкәсенә бер әфлисун алып ашадым да тагын лабазга кердем: Фатыйх абыйларга үзем генә кайта белмим, иртән караңгыда килгәнлектән, юлны искәрең кала алмаган идем.

— Әйдә, алайса үзем кайтарып куйыйм,— дип Фатыйх абый мине ияртеп чыкты да:— Әниең бер-бер нәрсә алырга кушмаганыемы соң?— диде.

— Юк, алай атап бер нәрсә дә алырга кушмады. «Өч йөз җитмеш сум заем түлисебез бар, шуннан артып калса гына үзеңә берәр нәрсә алырсың шунда»,— дип кенә әйтте.

— Алай булгач, әйдә, талчукка барып, ике йөз тәңкәсенә берәр әйбер карыйк!— дип ул мине җәяүләп кенә бүтән базарга алып китте. Анысы әллә ни ерак түгел икән. Анысында кеше без ит саткан базардагыдан да күбрәк: ерып йөргесез иде. Я, хода, ниләр генә юк иде анда! Казан талчугында атаң белән анаңнан кала барысын да, хәтта күгәрчен сөте дә табып була дип сөйлиләр иде авыл картлары, тәки дөрес икән.

Фатыйх абый анда да үзен бик иркен хис итә, танышлары очрап кына тора иде. Ләкин миңа нәрсә алырга кирәген тәгаен генә белми иде булса кирәк. Миңа яраклы пальтоларның бәяләрен дә сораштырып карый, чалбарга, бүрекләргә дә күзе төшә иде.

— Әйт, кайсысы бигрәк кирәк сиңа?— диде ул, шулай әүле-тәүле бераз йөргәч.

Ул шушы сорауны биргәндә бер татар агае:

— Сапук каму нады? Сапук бири, дарма дам!— дип кулына миңа ярарлык кына кирза итек тотып, яныбыздан үтеп бара иде. Үзебездән алты чакрымдагы Олы Әшнәккә укырга йөргәндә яз-көз айларында чабатага су үтеп бик интектергәне исемә төште дә:

— Иң кирәге әнә шул кешедәге шикелле итек инде аның, Фатыйх абый!— дидем.

Итек хуҗасы башта өч йөз сораган иде. Фатыйх абый сатулаша торгач ике йөзгә төште. Мин инде, булды болай булгач, алырга була икән дип сөенеп куйган идем. Ләкин Фатыйх абый алырга ашыкмады, сатулашуын дәвам итте. Ахырдан шул ук ике йөзгә, ләкин мәгәричен теге кеше исәбеннән алырга сөйләштеләр. Минем чабатаны шундук салдырып атып, итек кидерделәр.

Аннары, беркая да тукталмыйча, Фатыйх абыйларга кайттык. Инде авылдашлар да итләрен сатып кайткан. Фатыйма апа зур бер казан бик әйбәт итле аш пешереп куйган иде.

Шул ашны ашадык та йокларга яттык.

## Әти белән очрашу

Ләкин мин бик озак йоклый алмыйча яттым. Ул көнне дөньяда миннән дә бәхетле кеше юк, чөнки минем теләсә нинди пычракны ерып йөрсәң дә бер тамчы су үткәрми торган күн башлы кирза итегем бар иде. Башта шуның куанычыннан йоклап булмады. Аннары...

Хатын-кызлар урынга яту белән, ул кичне дә Фатыйх абый белән Ха-

физ карт кухня якка керделәр дә чәй эчә-эчә базардан алган тәэсоратлары белән уртаклаштылар. Аннары таныш-белешләре хакында гәпләшә башладылар. Шунда ничектер минем эти хакында сүз китте. Сүзне Хафиз карт башлады. Имеш, яшь кенә булса да, минем эти Хафиз картка иң кыен вакытында — аны колхозга алу-алмау мәсьәләсе каралган чагында колхозга кирәргә ярдәм иткән.

— Әй бит аңа минем ишене яклаудан бернинди файда юк, киресенчә, ул үзенә тап төшерергә генә мужытые. Шулай булуга карамастан, ул мине калхузга алырга кирәк дип яклап чыкты и, һәм, аның сүзенә ышанып, мине калхузга алдылар. Патамушты авыл халкы аны хөрмәт итә, аңа ышанадырые,— диде Хафиз карт.

Аның сүзен Фатыйх абый җөпләп алып китте:

— Бер караганда прәме гаҗәп инде, Хафиз кордаш. Нурулланы әйтәм, дөньяда тик егерме дүрт ел гына яшәп калды, мәрхүм. Үлгәненә инде тугыз ел вакыт үтте. Ә онытылмый бит миңә: кешелеклеге белән, ярдәмчеллеге белән һаман күңелдә тора. Кемнең кем булуын кешенең җирдә күпме яшәве хәл итми шул. Бөтен хикмәт кешенең бу дөньяда ни эшләп, үзеннән соң нинди яхшылык калдырып китүендә!

— Хак сүз әйттең, Фатыйх дус. Әйе, егет кешие Нурулла, мәрхүм. Үз эше торып торса тора, кешегә ярдәм итмичә калмас иде. Бер елны шулай минем җәмәгатем Мәрфуга бик каты авырып китте. Күрәм, өшкереп-төкереп, үлән төнәтмәләре эчереп кенә игә килерлек түгел. Тәкатьсез булып эче авырта моның. Сизәм, булнискә илтмичә булмый. Ә вакыт бик соң: төнге ўнбер тулып килә. Буранлап тора. Үзең беләсең, Слабатага бездән җегерме ике чакрым. Мәрфуга өчен борчылып, үземнең дә баш авырта башлады. Авыртмаса да, андый ерак юлга бер башым ат җигеп чыгып китә торган кеше түгел мин. Үземнең олы малай Габдуллага әйтеп караганыем: юк, бармый: «Төнләтеп ничек чыгып китим? Аннары барып та төннә кемгә күрсәтим, кая куйыйм мин ул әнине? Урысча белүем дә бик чамалы»,— ди. Дөрес әйтә анысын. Нишләргә хәзер?Мәрфуга да бик кызганыч. Аптырагач, туктале, мин әйтәм, Нурулла янына барып карыйм әле. Район җирендә танышлары бар, урысча да белә: заманында авылдан берүзе йөреп Илиновкада урысча сабак укыган егет. Шулай да төн уртасы бит. Бу вакытта нишләп кеше бимазалап йөрисең дип әйтмәгәе дип, шикләнебрәк кенә бардым мин моның катына. Йокысыннан уятып гозеремне әйтүгә, була ул Хафиз абзый дип, минуты белән торып, киенә башлады. Ярты сәгать дигәндә атын җигеп, Мәрфуганы Слабатага алып та китте.

Үзе генә куркыр дип, иптәшкә Габдулланы җибәрмәкче булганыем, аның миңа бер хаҗәте юк, атка авыр итеп йөрмәсен дип, үзе генә чыгып китте. Иртәнге сәгать сигезләргә кайтып та җиткәние инде. Төнләтеп, бүлнисннең баш врачы Ивановның үзен уятып алып килгән. Суңыннан, Мәрфугага операция ясагач, Нуруллага әйткән Иванов: «Маладис, Назимов, бик белеп уяткансың син мине,— дигән.— Тагын бер генә сәгатькә соңга калсак та, эш узган буласы икән: сукыр эчәгесе шартлый язган абыстаегызның,— дигән.— Ну хәзер куркыныч үтте инде, ун-унбиш көннән абыстайны алырга килергә мужете»,— дип әйтеп җибәргәние.

И һәм шулай булды да: ундүртенче көнендә үк апкайттык Мәрфуганы.

Ә бит Нурулла шул чакта тәвәккәләп төн уртасында алып китмәгән булса — Мәрфугасыз калганыем.

— Әле син аны әйтәсең,— дип ялгап китте Фатыйх абый.— Кешегә андый гына ярдәм итүне исәпләп тә тормыйдырые ул. Миңә хәзер син мине тыңла! Монысы минем күз алдымда, шушы Казанда булган хәл. Утыз җиденче ел, Нурулланың үләренә бер ел калган вакытлар. Ул чакта әле аның үлеме турында башка да килерлек түгел. Япь-яшь, артык таза булмаса да, типсә тимер өзәрдәй нык, сәламәт. Кайбер кеше көлгән чагында да нигәдер салкын, нурсыз була. Ә моның ачулы чагында да

үзе балкып, нурлар уйнап торырые. Июнь ахырлары тирәсендә берүзе бер сыер житәкләп килеп керде бу безгә. Сыерларның тәнгә кәй, сөтне самай күп бирә торган чагы. Нишләп бу вакытта алып килдең моны, олан, мин әйтәм. Көзгә таба, тән кунгачрак апкилсәң килере күбрәк булырые, ә болай баш урынына баш алырлык акча җыя алырсың микән? «Ничава, Фатыйх абзый,— ди бу.— Күпме булса да булыр, ну алып килмичә ярамады: бик азгын нәрсә булып чыкты. Көндезен көтүдә иген басуына чабып, көтүчеләрне йөдәтеп бетерә, ә кичен өйгә кайтмый, эзләтеп интектерә. Шуның өстенә тагы соңгы вакытларда сөзгәләккә дә әйләнә башлады. Бер көн саварга дип килгән чагында шундый итеп күзләрен акайтып, читәнгә китереп терәгән Мәгъсүмәне. Бәхетенә каршы, үзе нечкә булуы аркасында, мөгез арасына туры килеп кенә исән калган Мәгъсүмә. Шуннан тоттым да, андый-мондый хәл китереп чыгарганчы дип, алып килдем менә. Миңа аның акчасы кыйммәт түгел, миңа хатынның сәламәтлеге кадерле!»— ди.

Күрәсең, гел урлашып ашап йөргәнгәдер, җәйге чиллә вакыты булуга карамастан, ите дә әйбәт кенә булып чыкты сыерының. Бура кебек сыер алырлык акчасы чыкканые. Сыер итеннән яхшы гына акча җыйгач, куанганые ул. Күрәчәге булганга шулай ашкынгандырмы, иртәнге дүрттә үк чыгып китте. Минем ише двурниклар урам җыештыра башлагач, бишләрдә-алтыларда кузгалса ни була инде шунда. Юк, тыңламады. «Иртәрәк кайтып житәргә кирәк, Мәгъсүмәнең тагын бер малай апкайтыр вакыты житеп килә, дөнья хәлен белеп булмый, ул анда берүзе генә бит»,— дип чыгып китте.

Китүен китте, әмма мин көрәгем белән себеркемне күтәреп эшкә чыгып барадырыем, сөмсерен кырып кире кайтып килә бу. Күзе кара янып шешеп чыккан, бөтен бите кан. Нишләдең, ни булды дип каршына килсәм: «Берни булмады, Фатыйх абый, барысы да тәртиптә: акчаны бирмәдем мин аларга!»— ди.

Таламакчы булганнар икән моны. Шәһәр читенә житкәч, каршысына икәү килеп чыкканнар да, башта тартырга тәмәке сораганнар. Нурулла тартмыйм дигәч, ялганлыйсың бит, каяле, карыйк, дип кесәсенә тыгыла башлаганнар. Сыер саткан акчасы кесәдә бит моның. «Юк!— ди бу тегеләргә.— Кесәгә кермисез! Кесәгә кертмим!» Шулай ди дә тегеләр яныннан китмәкче була. Тегеләр җибәрми. Шуннан китә тартыш-сугыш. Тегеләр икәү, бу бер үзе. Урамда беркем юк. Әле кешеләр тормаган. Кычкырудан, ярдәм көтүдән файда юк. Ә тегеләр очраклы хулиганнар гына түгел, урлашу-талау белән күптән шөгыльләнүче тәҗрибәле юлбасарлар булырга кирәк: шәп сугышалар, аяктан егарга тырышалар Нуруллаңы. Ә аңа егылырга ярамый. Егылса — бетте! Шунда күңеленә бер уй килә: «Туктале,— ди бу,— мин дә ялгыз түгел бит: сыер тикле сыер белән икәү ләбаса без!» Шул фикер башына килүе була, көче икеләтә артып китә дә бер юлбасарның касыгына тибә. Аһ итеп, анысы сыерылып төшкән арада икенчесенең иягенә баш белән биреп ала да кире шәһәргә сыпырта.

Артыннан куып карыйлар. Ну, бар, тотарсың инде аны бер ычкынгач!..

Шуннан мин аны үзебезнең Шамски бульнисендәге таныш брачка алып барып, яраларын дарулатып, бәйләттереп кайттым. «Ялгызың гына юлга чыкма, тагы берәр төрле казага очрарсың. Сезнең якка кайтучылар булыр әле. Шуларны көтеп тор, шулар белән кайтырсың»,— дигәнием мин аңа. Риза булмады. «Бу кыяфәтемне күрә торып, хәзер миңа кем кагылсын? Кесәмдә сыер саткан акча барын кем белсен? Мин бүген ничек тә кайтып житәргә тиеш!»— дип иртәнге сигездә тагын чыгып китте.

— Ә бит ул чакта сыер саткан акчасын барыбер алып кайтмаганые ул!— диде шунда, моңарчы гел «ыы» «ыы» дип, Фатыйх абзыйның сүзен җөпләп утырган Хафиз карт.— Юлда талап алдылар дип үземә сөйләде! Нужәли икенче тапкыр таладылар икән?

— Һыы, шулай дип сөйләде инде алайса, ә? Юк, Хафиз коргын, чуртым да таламаган аны икенче кат! Ә акчасын, син дөрес әйтәсең, өенә бер тиенен дә алып кайтмаган.

— Кая куйган?

— Менә бөтен хикмәт тә шунда шул. Синең белән миңа бәлки бик сәер булып тоелыр, әмма Нурулла ул чакта акчасын Илиновка урысы Фидыр Иванычка биреп кайткан.

— Ник алай иткән?

— Мужыт хәтерлисеңдер, бер елны әлеге шул Фидыр Иваныч дигән урысның өе җанганые.

— Кәк же! Хәтерлим, хәтерләмиләрме соң? Безнең бөтен авыл халкы барды анда ул чакта. Умарталыкта булганлыктан, дөрес, мин үзем бара алмадым. Ну янгын шәүләсе бөтен урманга күренеп торды.

— Менә, Нурулла Казаннан кайтасы көнгә каршы төндә булган хәл инде бу, Хафиз кордаш. Нурулла Илиновкага килеп кергәндә өе генә түгел, бөтен азык төлеге, мал-туары янып беткән Фидыр Иваныч, кайгысыннан ни эшләргә белмичә аптырап, авыл читендәге часаунә каршына килгән дә, җылый-җылый чукынып: «И, аллам-аллам! Нигә миңа җибәрдең бу казаны? Биш баламны ни эшләтим мин хәзер? Кайда тотыйм мин аларны, ни ашатыйм?»— дип ялварып тора икән. Нурулланы күреп алгач: «Видишь, сынок, видишь, что стало? Хоть по миру иди сичас»,— дип аны кочаклап елый башлаган. Үзең дә беләсең булыр, Нуруллага ул үз туганы күк якын кеше бит инде. Патамушты Илиновкада урысча сабак укыган елны ул шуларда фатир торып укыганые. Шуннан Нурулла, тегене кызганып, сыер саткан акчасын чыгара да бирә. Фидыр Иваныч башта алмый. «Мин бит аны барыбер түли алмыйм, Нурулла»,— ди. «Түләргә дип бирмим мин сиңа, ярдәм итеп, бөтенләйгә бирәм!»— ди Нурулла. «Ә аның өчен мин сиңа ни эшләргә тиеш булам соң?»— ди Фидыр Иваныч. «Синнән мин шуны гына үтенәм,— ди Нурулла.— Бу турыда, зинһар, беркемгә әйтмә, яме!» «Ну бит, алай ару түгел бит инде ул!»— ди аңа Фидыр Иваныч. Соңыннан Нурулла аны барыбер күндерә. Менә шулай, Хафиз кордаш. Шундый эшләр.

— Карале син аны, ә?— диде Хафиз карт, исе китеп.— Ә бит ул чакта авылда Нурулла бер атна эчендә бер сыер акчасын эчеп бетереп кайткан да, урлатып кайттым дигән була икән, дип сөйләгәннәр иде.

— Син, җүләр, шуңа ышанганыеңмы?

— Халык шулай дип сөйләгәч, ышанмыйча кая барасың?

— Менә шулай шул: халык сөйли, кеше сөйли дип, әллә нинди гайбәтләргә ышанабыз без. Шуның аркасында әллә кемнәрнең тормышы бозыла, кешеләр бер-беренең кан дошманына әйләнеп бетәләр. Шуның аркасында хәтта илләр белән илләр арасында сугышлар чыгуга барып җитә. Белмим, кайчан туктар икән бу адәм балалары бер-бере хакында гайбәт сатудан?

— Син үзең болай тыңлап торышка хәйран акыллы сөйлисең, Фатыйх. Ә каян беләсең соң син аның тучны гына ничек булганын? Бәлки Нуруллаunion Казанда берәр нәмәрсәсе булгандыр да сыер акчасын ул шуңа...

— Тукта!— дип кычкырып куйды Фатыйх абзый, Хафиз картка сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмичә.— Әгәр минем өемдә кунак булып утырмаган чагың булса, Нурулла хакында бу кәфер сүзең өчен, билләһи дип әйтәм, хәзер мин синең авызыңны сугып ярадырыем. Эһ тә итмичә ярадырыем! Мин беләм, заманында, Казанда водоканалда эшләгән чагында, син үзең чит нәмәрсәләр белән кайнаштырдың. Үзеңә әйтмәгәч тә, сизмәде дип уйлама, бик сизеп йөрдем. Булды андый шухыр-мухырларың, булды. Хәзер генә сакал үстереп, мулла булып йөргән буласың син. Ярый, үзеңне үзең беләсеңдер, мин синең тормышыңа катнашмыйм. Әмма дә ләкин, пажалысты дип әйтәм, син Нуруллага кагылма инде ул яктан. Башымны кисәргә бирә алам...

— Хуш... Синеңчә дә булсын ди. Ә соң, аның сыер акчасын имынны Фидыр Иванычка биргәнен син каян алай бик тәгаен беләсең? Син бит аны үз күзең белән күрмәгән, гупчи Казанда булгансың син ул чакта!

— Дөрес әйтәсең, әйе, Казанда ием. Ну бит минем авыл белән кендек өзелмәгән. Авылдан берәрсе килеп миңа фатирга керми калган көннәр, ай-һай, ничәү генә була икән ел тәүлегендә? Теге чакта, Нурулла акчасын урлатып кайткан икән, дигән сүз безгә дә бик тиз ишетелде. Ну мин бит беләм: урлатмады ул акчасын! И һәм талап та ала алмадылар. Казаннан акча белән чыгып киткәнен үзем күреп калган кеше ләбаса мин! И уйлый башладым мин шуннан: «Юк, мин әйтәм, монда шту-ты не так!» Хәтерендәдер, ул елларда сезнең авыл кешеләре кыш көнс, колхозда эш азрак чакта, Чистайдан Казанга спирт ташый торганнарые. Нурулла да йөргәләде анда. Анысын син үзең дә беләсең. Шул чакларда ул фатирга гел безгә төшә торганые. Тек, вәт, бер шулай иплән кенә сөйләшеп утырган чагыбызда сорыйм мин моннан: «Синең узган җәй сыер саткан акчаң хакында төрле имеш-мимешләр йөри, әйт әле, энем, дөресен генә: нишләттең син ул акчаны, кая куйдың?»— дим. Сизелер-сизелмәс кенә кызарып китте бу. Хәйләкәр генә елмаеп, беркавым сыный карап торды. Шуннан ары әйтә бу миңа: «Син, Фатыйх абый, сер саклый беләсеңме?»— ди. «Беләм!»— мин әйтәм. Шуннан бу миңа акчасының тиенен дә югалтмавын, өе янган Фидыр Иванычка бурыч итеп түгел, бөтенләйгә биреп кайтканын әйтеп бирде. «Ә талап алып калдылар дип, Мәгъсүмәне тынычландырыр өчен генә әйттем мин аны»,— диде. Вәт шул, Хафиз кордаш. Әтү син, ачу китереп, каян беләсең дип шикләнеп торган буласың? Запумни: ялгышлык белән кайбер хаталар эшләп ташларга магу, ну беркайчан да ялган сүз ишетмәссең миннән. И һәм ялган сүз сөйләүчене үзем дә яратмыйм...

Фатыйх абзый белән Хафиз карт әле тагын үзара серләшүләрен дәвам иттеләр. Ләкин мин инде аларны тыңлап тормадым: әтинең сыер сатуы хакында әни сөйләгәннәрне искә төшереп, шул турыда уйланып яттым.

Әйе, ул хакта әнинең Равил белән миңа әллә ничә кат сөйләгәне бар. Чөнки без аны үзебез сорап сөйләтә торган идек. Аның сөйләвенә караганда, әтинең ул чакта Казаннан кайтып керүе менә болай булган.

Июнь аеның ахырлары. Миләрне кайнатырлык эссе көн. Кояшның төшлекне үтеп барган чагы. Авыл тып-тын һәм буш. Олылар көндезгене ашап эшкә китеп беткән, бала-чагалар — буада су коенуда. Үзебез карап йөрибез дип, олырак малайлар мине дә, бәләкәй арбага утыртып, су буена алып төшеп киткән. Көннең кызу булуы безнең әнигә бигрәк тә читен. Чөнки ул әле дөньяга килмәгән, ләкин әледән-әле тибенеп, үзенең барлыгын сиздереп тора торган Равил энем өчен дә суларга тиеш. Шуңа ул колхоз эшенә бара алмый. Шул ук вакытта эшсез торырга да өйрәнмәгән. Салкынчарак урынга — җир идәнле оялдыбыздагы сәкегә тәрәшле каба көйләгән дә йон эрләп утыра. Исәбе Вакыйф улына һәм туачак баласына (кыз булса бигрәк тә әйбәт буласы!) берәр пар оекбаш бәйләү.

Ә күңелендә — әти. Чөнки киткәненә инде дүртенче көн. «Базар әйбәт чакка туры килсәм, өч көннән кайтып та житәрмен»,— дип киткән. Базары әллә ни булмаган булса да, бүген кайтып җитәргә тиеш. Тик исән-сау булсын да, бәла-казага гына юлыкмасын.

Әни шуларны уйлап утырганда, шыгырдап капка ачылганы ишетелә. Вакыйф улымны китерделәр бугай дип уйлап куя әни. Менә хәзер килеп керәчәк дип көтә. Бер минут үтә шулай, ике минут үтә, ләкин оялды ишегенә килүче юк. Ишегалдында йөргәннәре дә сизелми. Бу ни булды соң, әллә берәрсенең эте кереп, гавыкларга болгатканны ашый башладымы дип, әни ишек алдына чыгып караса, аһ итеп, куркып китә. Ишегалдына кергән кеше — безнең әти икән ләбаса! Тик аның битләре кара янып-күгәреп беткән. Шул хәлендә әнигә күренүдән уңайсызланып булса кирәк, ни эшләргә белмичә басып тик тора. Аннары, гаепле кеше сыман, кыюсыз гына елмаеп куя. Кулында — ашъяулыкка төрелгән ниндидер зур гына төенчек.

— Нихәл, әнисе? — ди ул, телгә килеп.— Кертәсеңме өйгә? Танышмы мине?

— Ник юк сүз сөйлисең син, этисе?!— ди әни, этинең әлеге соравына үпкәләп.— Ниткән танымау ди ул? Ниткән кертмәү ди? Кер әйдә, кер тизрәк!

Әти әле һаман кыюсызланып торгач, әни аның янына үзе килә дә кутырлаган битләрен, маңгайларын сыйпап, елап җибәрә:

— Ни булды сиңа, Нурулла? Нишләттеләр сине?

— Елама, әнисе,— ди әти.— Зыян юк. Тирене текмәгәннәр, төзәлер. Бер дә уйламаган җирдән килеп чыкты шунда.

— Ни булды соң, ник әйтмисең, Нурулла?

— Юлбасарлар белән чәкәләшеп алырга туры килде. Сыер акчасын талый башлаганнар иде.

— Һи, син дә инде, шул акча өчен тарткалашып торалармы соң? Тизрәк бир иең дә китеп барыең шунда!

— Алар бит миннән башта акча сорамадылар. Казан урамын чыгып барганда капыл гына каршыма төштеләр дә кыйнарга тотындылар.

— Ничек котылдың соң үзләреннән?

— Котылуын болай ярыйсы котылдым анасы. Үзләрен дә буш итмәдем. Ну менә сыер саткан акчаны коткарып калып булмады.

— Ярар, этисе, юк өчен борчылма. Кадалып китсен акчасы. Исән калганыңа сөен. Баш исән булса, сыер урынына сыер табылыр. Әнә, танабыз бик матур булып үсеп килә. Син киткәч көтүдән үгез дә ияртеп кайтканые. Бер дә аптырама: илдә чыпчык үлми, ничек тә яшәрбез әле.

Әнинең шул сүзләреннән соң этинең күңеле йомшап китеп, күзеннән яшь бәреп чыга.

— Әй, әнисе,— ди ул,— әле ярый син әйбәт. Әле ярый син бар бу дөньяда мине юатырга. Ачуланырсың дип юл буе ут йотып кайтканыем. Рәхмәт инде сиңа! Югалган артыннан югалып булмый, нишлисең бит. Әйдә, керик, чәй кайнатып җибәрик әле дә эчик әле бер рәхәтләнеп.— ди. Өйгә кергәч мин юк икәнен күреп:

— Ә улыбыз кайда?— дип сорый.

— Кайтыр, этисе, кайтыр. Миңгарыйф белән Барый су буена аптөшеп киткәннәрие.

— Кайтсыные инде тизрәк. Сагындым.

— Сагынуын сагынгансың да бит, кая, куян күчтәнәче алып кайттыңмы соң малаеңа?

Әни аның кулындагы төенчекне алмакчы була. Әти кинәт каушапкызарып кала:

— Ни бит әнисе, бу безнең әйбер түгел бит. Күршебез Габдуллаларның чүлмәк-кашыклары бу. Көтү чираты бүген аларда икән, шушы чүлмәк белән көтүчеләргә кырга аш илткән булганнар. Юл уңае туры килгәч, көтүчеләр миңа биреп җибәрде. Син аны кертеп бирерсең инде, яме. Ә куян күчтәнәченә кызыл билле прәннек алганыем да юлбасар белән якалашканда ташлап калдырып китәргә туры килде. Үзең берәр нәрсә уйлап тап инде шунда малайга куян күчтәнәченә. Я буяп, йомырка пешереп бир. Я ипигә ягып май...

Әнинең әйтүенә караганда, ул миңа шул көнне ипигә ягып каймак ашаткан...

## «Үтерәсең бит, Зәки абый!»

Безнең авылда Зәки абый исемле бер кеше бар иде. Кырык дүртнең язында Качкалак урысы Дәде Сирги белән авыл көтүен көтәргә алынды. Шуннан бирле ул «урынны» бүтән беркемгә дә биргәне юк. Я күрше авылдан, я үз авылыбыздан бер ярдәмче таба да ала, яздан кара көзгә кадәр —

кырда. Көтүне шәп көтә. Малларны туйдырып алып кайту өчен әллә ниләр эшләргә әзер. Үзебезнең кырда азык ягы сыегайса, көтүне күрше колхозлар кырына алып кереп ашатып чыгарга да күп сорап тормый. Шуның өчен ярата аны авыл халкы. Шуңа күрә көтү хакын кызганмыйлар.

Шул ук вакытта үз дәрәҗәсен дә бик белә Зәки агай. Үз өе һәм гаиләсе (хатыны һәм җиде баласы) булса да, өйләрендә түгел, бәлки чираттан, ягъни өй борынча йөреп ашый. Коры-сарыга, сөтле яки «кысыр» ашка гына канәгать түгел. Чират үзләрендә булган йортта аңа иртән әбизәтелне йомырка белән каймак, төш вакытында итле аш ашатырга, ә кичен берәр төрле таба ашы пешерергә кирәк. Югыйсә табынны ташлый да кайтып китә.

Ләкин соңгы елларда андый күңелсез хәлнең булганы юк. Зәки абыйның шундый «карахтерын» белгәч, берәү дә йөз кызартырга теләми. Соңгы тавыкларын суйса суялар, ләкин итле ашсыз калдырмыйлар. Үзләреннән чиҗат китәсе кичтә кайберләре хәтта хәмерен яки ачы балын да салып бирә. Ә ул нәрсәләрнең бер төреннән дә баш тартмый Зәки агай.

Тик шунысы бар: эчкәнен буена сеңдерә белми. Белмим, нигә андый сәер кешедер ул. Өстәлгә чыгарсалар, тизрәк эчәсе килеп тәкатьсезләнүдән хәтта тавышлары ук бетеп кала. Ә менә шул стаканны каплап куюы була — бөтенләй икенче кешегә әверелә дә китә. Иң элек куе соргылт кашлары маңгаена менеп утыра. Болай да зур, чәркә хәтле соры күзләре тагын да зураеп, калайланып чыга. Һәм, ике-өч минут та үтми, инде көрмәкләнергә дә өлгергән теле белән:

— Рәхмәт, парин. Кашшыбутерсен ,шулайые, парин. Рәхмәт сиңа! Кашшыбутерсен рәхмәт, җәме!— дип һаман бер сүзен тәкърарларга тотына.

«Кашшыбутерсен»— кояш орып үтерсен дию. Ул аны нигәдер әнә шулай кыскартып әйтә. Беренче ишеткән кеше хәтта аңлый да алмый. Сыйлаучысы ир-атмы, хатын-кызмы — аңа барыбер:

— Кашшыбутерсен рәхмәт, парин! — ди ул.— Валла дип әйтәм, синнән җүнне кеше юк безнең авылда. Нәселегез белән шундый душа кешеләр сез! Кая, тагын кечкенә генә сал инде, парин...

Салып бирсәләр, тагын мактый башлый. Мактый-мактый да тагын печтик кенә салып бирүне сорый. Шуннан тәмам ойый да, утырган җирендә сыерылып төшеп, йоклап китә. Уятырга тырышудан файда юк — барыбер уянмый. Ә менә иртән көтү куар вакыт җиткәндә исә, бер минутка да соңармыйча, үзе сикереп тора. Хуҗадан сорап алып, бер чүмеч әйрән суы эчә дә алдына эчемлек куйсаң да әйләнеп карамыйча:

— Юк, парин, булмый. Эшкә барасым бар. Эш бик җаваплы бит минем. Дүрт йөз баш малны туйдырып алып кайту — шутке түгел ул сиңа!— дип, көтүенә китеп бара.

Ә инде ярты стакан белән генә калдырсалар — бетте! Кинәт кенә кашын маңгаена сикертеп куя да:

— Аллаң булам, салып бир, парин, ярты гына стакан?— ди.

Бу аның кешеләрчә әйтелгән соңгы сүзе. Шуннан ары ул башта хуҗаның үзе белгән бөтен кимчелеген, аның хакындагы бар гайбәтне тезеп санап чыга. Аннары аның ата-аналарын, бала-чагаларын, туган-тумачаларын тетеп сала. Андый чакта сүзләрне сайлап тормый: сигезәр катлап, җелекләреңә үтәрлек итеп сүгә.

Моны ул йорт хуҗасы хатын-кыз булганда шулай эшли. Йорт хуҗасы ир-ат булганда — тактикасы башка.

— Әһһә, шулаймы? Бирмисеңме?— дип кенә әйтә дә, бик хәтәр җилпенеп, тегеләрнең өеннән урамга чыгып китә. Беркавым баргач, артына әйләнеп карый, йорт хуҗасы аның артыннан капка төбенә чыккан булса, тагын бер-ике йорт арасы арырак китә. Аннары туктый. Кечерәк биштәр капчыгы кадәр кызыл сатин тәмәке янчыгын чыгарып, үзалдына нидер сөйләнә-сөйләнә, тәмәке төреп кабыза. Бу — аның зур «концерт»ка әзерләнүе. Шуннан соң китә инде хәлләр! Иң элек ул теге саран хуҗаның авто-

биографиясен «сөйләп» чыга. Аннары туган-тумачаларын сүгәргә керешә. Шул ук вакытта капкасын күзәтеп тора. Нервысына түзә алмыйча, хуҗа килеп чыга калса — тиз генә сыпырту ягын карый. Андый чакта аягы да аксамый. Ләкин бөтенләй үк кайтып китми: хуҗа куып җитмәслек ара калдырып туктый да:

— Әһһә, үзеңнең кем икәнеңне әйтеп бирү ошамадымы, аллаң булыйм! Эчеңә тидеме? Шулай була ул саранлансаң!— дип тагын котырыбрак тотына. Булганын да, булмаганын да сиптерә генә. Бер сүзне унар тапкыр кабатлый.

Зәки абый концерт күрсәтә, дип, андый чакта бөтен авыл малае шул тирәгә җыела. Бу хәл аңа бер дә ошамый:

— Ник җыелдыгыз? Аю биетәләрме әллә монда, аллаң булыйм!— дип, кулына ни эләксә шуны тотып, аларны куып китә һәм берәрсен тотып кыйнамыйча калмый. Анда да кем эләксә шуны түгел, өйләрендә ир-ат булмаган малайларны кыйный. Өйләрендә ир-ат булган малайларга кул тидерергә курка: төнәткәннәре бар.

Бервакыт Сабир абый малае Хәбирнең эченә тибеп еккан чагында Сабир абый күреп алып, кирәген бирде аңа. Прәме урам уртасында чалбарын төшереп, каеш белән ярды. Шуннан соң әтиле малайларга бик алай тими башлады ул.

Әтиле малайлар моны белә һәм исерек вакытында тегене башлап алар котырта. Ә аның женен чыгарырга күп кирәкми: «Зәки абый, кашшыбутерсен маладис кеше син!»— дию бик җиткән. Бу сүзләр аңа Хисам бабайларның ата күркәсенә кызыл яулык күрсәткәннән дә яманрак тәэсир итә.

Ләкин шунысы бар: котыртуын яклаучылары булган малайлар котыртса да, кыены безгә — ятим малайларга эләгә! Бер елны шулай, мин икенчедә укыганда бугай, колхозчыларның гомуми җыелышын җыеп авыл көтүен, гадәттәгечә, Зәки абыйга бирергә килешкәннәр иде.

Ул көнне иптәш малайларым белән мәктәптән кайтканда Зәки абый инде урамда, Әхмәтгали абыйлар турында, чираттагы «концертын» биреп тора иде. Көтмәгәндә эчкә тибә торган гадәтен белгәнгә, без аның яныннан үтеп китәргә шикләнеп, туктап калдык.

Ә ул Әхмәтгали абыйны сүгепме сүгә. Безгә гаҗәп: ни булып бетәр дип көтәбез. Озак көтәргә туры килмәде. Әхмәтгали абый ажгырып өйләреннән килеп чыкты да тегеңә саллы гына бер утын агачы томырды. Тигән булса, үтермәсә дә, имгәтми калдырмаячак иде. Ләкин, бәхетенә каршы, Зәки абый читкә тайпылып котылды. Һәм, тагын берәр агач җибәрмәсен дип, ун-унбиш метр арырак элдертте.

Шул уңайдан кайтып китсә бик шәп буласы иде. Ләкин үз кирелеген итмәсә, Зәки буламыни ул? Туктап, үзенә чак кына тими үткән утын агачын алды да капка төпләрендә тыныч кына карап торган Әхмәтгали абыйга янарга тотынды бу:

— Әһһә, аллаң булыйм, син мине үтермәкче булдыңмы әле, Озын тәре. Көтүчегә кул күтәрдеңме? Кашшыбутерсен, төрмәдә башыңны черетәм мин синең!..

Үзенең шул сүзләреннән кодрәтләнеп, теге утын агачын тотып, ул Әхмәтгали абыйга таба килә башлады. Ә үзе һаман Әхмәтгали абыйны кимсетә торган нахак сүзләрне сиптерүен дәвам итә.

Әхмәтгали абый — авылыбызның иң тыйнак, иң сабыр, иң риясыз кешеләреннән берсе. Һичкайчан чәчрәп чыкмас. Мактанмас. Күбрәк башкалар сөйләгәнне тыңлап торыр. Белмәгән эше юк. Бүтәне турында әйтмим инде, тәрәзә рамнарына кадәр ясый. Пыяласын да үзе куя. Гомерендә бер тапкыр да пыяла ватканы яисә ялгыш кискәне юк, диләр. Аларның челтәрләп ясалган тәрәзә наличникларын беренче тапкыр күргән кеше өй турларында хәйран калып, беркавым туктап тормыйча үтми. Дөрес, Әхмәтгали абый сугыш вакытында әсирлектә булган анысы. Ә инде

жае туры килү белән аннан качып, үзебезнең якка чыккан һәм сугыш ахырына кадәр, партизаннар белән бергә, фашистларга каршы сугышкан. Шулай булгач ничу иде Зәки абыйга кешенең авырткан җиренә тияргә!

Теле бик ачы булса да, безнең кыше бала-чаганың котын алып торса да, ир-атлар белән тартышырлык көче юк шул Зәки абыйның. Андыйларга кул күтәреп каршы сугарга йөрәге җитми аның. Бу юлы да шулай булды: кар өстенә барып төшкән җиреннән торырга тырышмады да ул. Бүреген салып, пеләшен ялтыратты да:

— Мә-мә, сук! Пажалысты! Кашшыбутерсен сук! Җавабын судта бирерсең!— дип чыелдарга тотынды.

— Тынынны чыгарма, кабих!— дип Әхмәтгали абый тагын кизәнде, ләкин, кулын пычратып торасы килмәде булса кирәк, өйләренә кереп китте.

Зәки абый шуннан соң гына аягына басты:

— Бәхетең инде, өеңә кереп котылдың. Кашшыбутерсен, иманыңны укытадырыем!— дип тагын әтәчләнергә тотынды.

Ул арада тамаша карарга унлап малай җыелып өлгергән, якынтирә йортларның өлкәннәре дә кайсы капка төпләренә чыгып, кайсылары тәрәзәдән карап торалар иде. Шуны сизеп алгач, кабат килеп чыкмагае дип, Әхмәтгали абыйлар капкасына карый-карый, ләкин тагын да кычкырыбрак сүгенә-сүгенә Зәки абый без басып торган якка — өйләренә кайту уңаена килә башлады. Бүрек колаклары, карга канаты шикелле булып, атлаган саен җилпенеп килә. Бүтән малайлар аның шул кыяфәтеннән шырык-шырык көлеп тора, ләкин минем көләсем килми, чөнки ул миңа кызганыч иде.

— Зәки абый, борының канаган бит, киемнәреңне буяганчы сөртеп ал,— дип тә чын күңелемнән әйткән идем мин аңа.

— Әһһә, аллаң булыйм, шулаймыни, наным? Кил әле монда, кил!— дип, кул изәп, ул мине үзе янына чакырды.

Мин аны үзенә берәр ничек ярдәм итәргә дәшә дип уйлаган идем. Ләкин килеп җитүем булды — эчемә китереп тә типте. Ул янә тибәргә талпынды. Шунда мин, котым алынып:

— Зәки абый, тимә, үтерәсең бит!— дип кычкырып җибәрдем. Ни эшләгәнемне үзем дә белештермичә, тегенең солдат чолгавычы урап кигән ботинкалы аягыннан тотып алдым да, җан ачуым белән балтыр итен тешләдем.

Хәзер инде авыртуына чыдый алмыйча ул кычкырып куйды. Өтәләнеп, тешләнгән җирен уарга тотынды. Миңа шул гына кирәк тә иде: ялт кына тордым да, артка да карамыйча, сыпырт өйгә!..

Шуннан соң Зәки абый «концерт» биргән чакларда бүтән малайлар аны «Кашшыбутерсен» дип үчекләгәндә мин ерактан гына карый торган булдым. Яисә бөтенләй өйгә кереп китә идем. Ачуы чыгып, үзен котыртучы малайлар артыннан куа башлаганда мин инде капканы эчтән бикләп, мич башына ук менеп утырган булам. Кыскасы, үземә бәйләнергә һичнинди сәбәп калдырмый идем шикелле. Ләкин ул һаман миңа үч саклап йөргән икән.

Минем Олы Әшнәктә алтынчы класста укый башлаган ел. Ноябрь урталары. Якшәмбе. Мәктәп балаларының көтеп алган кадерле көне: таң тишегеннән торып, мәктәпкә барасы юк. Туйганчы йокларга була. Тик өйрәнелгән гадәт буенча иртәнге алтыда барыбер уяныла. Яланаяк кына тышка чыгып керәсең дә, ярый әле мәктәпкә барасы юк дип, тагын җылы урынга чумасың.

Ләкин ул көнне кабат йоклап китә алмадым. Чөнки әле кичә кичен генә соргылт-кара булган дөньяны ап-ак итеп, кар явып киткән иде. Әберенче кар яуган көн минем өчен — һәрвакыт бәйрәм. Дөньяның бар авырлыклары, кешеләрнең бар явызлыклары, бар кайгы-хәсрәтләре әнә шул ак кар астында күмелеп калган да моннан соң алар үзара гел аңлашып, ярдәмләшеп кенә яшәрләр, бәхетле булырлар шикелле тоела.

Аннары килеп, кар явуның безгә. Олы Әшнәктә укучы малайларга, практик әһәмияте дә бар: чаңгыда йөрергә мөмкинлек туа. Ә чаңгыда йөрү — җәяү йөрүгә караганда бик күпкә җиңел. Һәрхәлдә, минем үзем өчен шулай. Тау башыннан кош урынына очып төшүе үзе ни тора!

Ә таулар бездә җитәрлек. Мин белгән бүтән авыллар барысы да үзәнлектә, су буенда урнашкан. Качкалак, Үшемкә, Солтан, Чүкәй, Кече Әшнәк, Корноухово, Ильиновка, Йәзен — барысы да су буенда. Безнең Зәңгәрләне ни хикмәттер, тау башына салынган. Тау башында булу, бер яктан начар түгел: ни әйтсәң дә, биектән дөнья күбрәк күренә. Ләкин бик зур уңайсызлыгы да бар: суны ярты чакрымнан ташыйсы. Су ягыннан болай да мактанырлык түгел бездә. Нибары өч чыганак: Дәү чишмә, Кечкенә чишмә, Урманасты чишмәсе. Язын шул чишмәләрнең суын бөяп буа ясыйлар да, коенырга ярый үзе. Урыны-урыны белән хәтта ат йөзәрлек җирләре була. Җәйнең эссе көннәрендә шул буада сәгатьләр буе су коенып ятабыз.

Тик шунысы уңайсыз: су буеннан авылга менеп җиткәнче тән кибеп өлгерә дә тагын коенасы килә башлый. Анысы да бер хәл булыр иде әле. Иң читене — су ташуы авыр. Авыл җирендә сыеры-танасы һәм дүрт-биш сарыгы булмаган кеше бик сирәк. Әйбәтрәк ашаткан чакларда бер сыер гына да көненә дүртәр чиләк су эчә. Маллары күп булган кешеләр, көненә унар көянтә су алып менәбез, дип сөйлиләр.

Безнең терлек алай күп түгел: бер сыер да ике баш сарык. Шулай да дүрт көянтә су китә көненә. Әнине кызганып, соңгы җәйдә суны Равил белән икебез ташыдык. «Икебез» дип болай гына, ул да миңа ияреп йөргәнгә генә әйтү. Ул әле бәләкәй. Инде «җиткән егет» булсам да, үземә дә авырга туры килә: кәҗә майларын чыгара авылга менеп җиткәнче.

Шулай да, авылыбыз тау башында утыруның иң уңайсыз ягы бу түгел әле. Иң яманы — янгын куркынычы икән. Моны без быел җәй бик яхшы аңладык. Урак өстендә нибары бер-ике сәгать эчендә авылның сигез йорты кара күмергә әйләнде. Янгын чыккан йортның түбәсен ялкын әле ялый гына башлаган иде халык җыелып өлгергәндә. Колхозның насос куелган арбасын, атка да җигеп тормыйча, ун минут дигәндә алып килеп җиткәннәр иде. Барыбер берни эшли алмадылар. Чөнки — су юк иде. Янгын мичкәсен тутырып, буадан су алып менгәндә ут инде өченче йортка күчеп өлгерде.

Балык Бистәсеннән килеп җиткән янгын машинасының да файдасы булмады. Насосның «эчәгесе» буага түгел, буа юлының чирегенә дә җитмәде...

Авылны тау башына салуның аяныч нәтиҗәсе иде бу.

Безнең авыл белән Әшнәк арасында, инде әйткәнемчә, озын һәм шактый биек тау. Авылдан барганда чакрым чамасы тау менәсе. Әшнәк ягыннан күтәрелгәндә тавы бераз сөзәгрәк. Ләкин озын: чакрымнан да артык. Безнең як тавын менгәндә йөкле атлар бишәр-алтышар тапкыр туктап ял итә-итә менә. Әшнәк ягы тавын менгәндә аларга бер туктап ял итү дә җитә. Йөкләре җиңелрәк булганда туктап та тормыйлар. Җәй көннәрендә шул араны җәяү йөрүне берничек җиңеләйтеп булмый: тау менгәндә дә, тау төшкәндә дә үз аягың белән атлап үтәргә кирәк. Ә менә кыш көне, чаңгы белән йөргәндә, эш җиңеләя: Әшнәккә барганда — Әшнәк тавын, кайтканда — үзебезнең тауны чыжлатып кына шуып төшәсең! Һәм, гомумән, шакыраеп каткан кара җир өстеннән йөрүгә караганда кар өстеннән йөрү рәхәтрәк бит инде.

Мәктәпкә барасым булмаса да, кабат йоклап китә алмавымның сәбәбе, инде әйткәнемчә, әнә шул беренче кар алып килгән шатлыкка бәйләнгән иде. «Тор, энем, әнә кар яуган анда»,— дип Равилне уяттым да әни пешереп куйган Хәппи төшен[1] тиз-тиз генә ашап, икебезнең дә чаңгыларны хәстәрли башладык.

[1] Әрчеп һәм урталай ярып, майлы табада кыздырылган бәрәңгене безнең якта шулай атыйлар — (В. Н.)

Ләкин бу эш алай ансат булып чыкмады. Без, адәм балалары, әйбернең кадерен кирәк чагында гына беләбез. Кирәге юкта без аның хакында баш ватып тормыйбыз: кайда туры килсә — шунда калдырып китәбез. Үткән яз, кирәге беткәч, мин дә чаңгыларны табанын-табанга китереп, тиешенчә бәйләп куймаганмын. Оялды артына сөялгән килеш калган да җәй буе шунда торып, калҗаеп беткәннәр иде. Ә бит аны миңа Әхмәтгали абый ясап биргән иде. Ике кадак май биреп ясаткан идек без аны. Кибет чаңгысына караганда да әйбәтрәк шуа торган өрәңге чаңгылар иде алар. Ә хәзер аларның утыннан бүтәнгә ярарлыгы калмаган. Ник җыеп куймадың, дип әнигә үпкәли башлаган идем, ул: «Әй, улым, улым, ничек оялмыйча шул сүзне әйтәсең? Миндә сезнең чаңгыгыз кайгысы гынамыни? Үзең җыеп куярга кирәгие вакытында!» — дип җавап бирде.

Ул хаклы иде.

— Ачуланма инде, әни, аптыраганнан әйтүем,— дидем мин.— Кем уйлаган аны бер җәй эчендә шушы тикле нык калҗаерлар дип?

— Инде мәктәбеңә ничек йөрерсең икән соң?— диде әни, минс кызганып.

Ә миңа аның шул соравы гына кирәк тә:

— Тагын Әхмәтгали абый янына барып карарга туры килер инде, әни.

— Баруын барырсың да, бушка ясамый бит ул. Теге чакта да авызыбыздан өзеп ике кадак май биргәниек.

— Мин яңа елга кадәр май ашамам, әни. Минем өлешне бирербез без аңа.

Әни үзалдына елмаеп куйды:

— Алайлар итмәбез инде итүен. Син дә көн саен унике чакрым җир йөрисең бит. Ярар, җан биргәнгә җүнен бирер әле: ничек тә бәхилләтербез. Бар инде алайса, Әхмәтгали абыең янына барып кара. Бәлки әле ясаган чаңгысы ук бардыр.

Әни ризалык биргәнгә башыбыз күккә тиеп, Равил энем белән шундук Әхмәтгали абыйларга чаптык. Равил дә миннән ким куанмый, чөнки минем чаңгым булса, мин мәктәптән кайткач, ул да шуачак бит инде!

Ләкин безнең куаныч күпкә бармады. Әхмәтгали абыйның ясап куйган чаңгысы юк, ясарга да җыенмый иде.

— Колхозның алты чанасын китереп ташладылар, шуларны үрәчәлисем бар. Сезнең ише малай-шалай җәй көне атлар кәнүшниенең тәрәзәләрен ваткан, шуларга пыяла куярга кушалар. Хөсниҗамал апагызга тырма, Гөлбаһар апагызга килсаб ясап бирәсем бар. Үзең син болай әйбәт җегет, ясавын ясармын мин сиңа чаңгы. Ну әнә шул вәгъдәләшкән эшләрне эшләп бетермичә тотына алмыйм, энем, гаеп итмә, яме,— диде ул.

— Кайчанрак бетәр икән соң синең ул эшләрең, Гали абый?

— Ун-унбиш көнгә барыр әле.

Унбиш көн минем өчен бик озак шул. Олы Әшнәккә ничек кар ерып йөрмәк кирәк? Әшнәк белән безнең авыл арасында кыш көне юл бөтенләй булмый. Атлылар да, җәяүлеләр дә Олы Әшнәккә барасы булганда Кече Әшнәк аркылы, әйләнечтән йөриләр. Алай йөри башласам, миңа унике чакрым урынына көн саен ундүрт чакрым җир йөрергә кирәк булачак.

— Бәлки, башта миңа чаңгы ясап бирерсең, Гали абый? Тотынсаң ярты көндә ясап бетерәсең ич син аны. Ә мин сиңа бүтән берәр эшеңә булышыр идем. Чаңгы ясаган өчен дә буш итмәс идек.

— Юк, энем, алай гына барып чыкмый шул,— диде Гали абый, бүрекен кыйшайтып, чигәсен тотып уйланып торгач.— Чаңгыны аны теләсә нинди агачтан ясап булмый. Ботаксыз коры өрәңгедән ясыйлар аны.

Аңа ярарлык өрәңгем бар барын, ну әле аны өйгә алып кереп, мич артына куеп, үн-унбиш көн киптерергә кирәк. Так шту, бүтән эшләрем булмаса да, шуннан алдан ясап бирә алмыйм, энем!

Нишлисең, ул шулай дип торгач, башны аска иеп чыгып китүдән бүтән чара калмады.

Без кайтып килгәндә Низам бабайлар тавы малайлар-кызлар белән чуп-чуар: кайсы чана, кайсы чаңгы, кайберләре хәтта бәлеш табаларына утырып, чыр-чу килеп тау шуалар иде.

Без дә тау буена бардык. Шуучыларга кызыгып карап тора башладык. Аннары тирес түгә, утын ташый торган салам чанабыз бар икәне искә төште дә, шуны алып килергә өйгә йөгердек. Һәм менә шул чакта...

Мин төз әвеслек өстенә куелган чананы ишегалдына төшереп, бавын рәтли башлаган идем, нигәдер бик хәтәр җилкенеп, Зәки абый килеп керде. Менә ул миңа ике-өч адым кала туктады. Гадәтенчә, кашларын маңгаена меңгереп куйды да:

— Кил әле монда, малай?— дип бармак изәде.

Мин, ни булыр икән дип, курка-курка аның янына килдем:

— Нихәл, Зәки абый?

— Минемме? Менә болай минем хәл, аллаң булыйм!— диде ул һәм, мин аны-моны уйлап өлгергәнче, бар көченә эчемә типте.

Тәҗрибәм бар иде ләбаса, азрак сакланырга кирәк иде миңа. Ләкин аның каршында һичнинди гаеп булмагач, аннары үзебезнең ишегалдында да булгач, мин аны шул кабәхәтлеккә барып җитәр дип башыма да китермәгән идем. Берәр йомышы төшеп кергәндер дип уйлаган идем... Тыным бетеп, шундук бөгелеп төштем. Ул шунда бер хуттан Равилгә дә типмәкче иде, ләкин Равил йөгереп кереп китте. Ул арада Зәки абый борылып килде дә:

— Теге чакта минем ботны син тешләгән иеңме? Менә сиңа шуның өчен, менә!— дип бу юлы янтыгыма типте. Ә мин берничек тә каршылык күрсәтә алмыйм, сулу ала алмыйча тилмереп ята идем.

Белмим эш ничек булып бетәр иде икән, ләкин шул чакта, кулына табагач тотып, өйдән әни килеп чыкты:

— Нишлисең син, Зәки? Җибәр баланы яхшы чакта, бирәм шушы табагач белән! Тукта, үтерәсең бит малайны?— диде ул ачыргаланып һәм табагачы белән кизәнеп.

Зәки абыйны куркытырга шул җитә калды:

— Бәтәч, син өйдәмени әле, Мәгъсүмә. Фирмедә түгелмени, аллаң булыйм? Мотри, кара аны, суга күрмә. Кешегә суккан өчен беләсеңме...— дип сөйләнә-сөйләнә арты белән чигенеп, тиз генә чыгып шылды.

Зәки абый тагын әйләнеп кермәсен дип, әни башта капканы эчтән бикләп куйды, аннары минем яныма килеп чүгәләде.

— Кай төшеңә сукты, улым?

— Эчкә типте.

— Ходайның каһәре генә төшсение үзенә, бала-чагага кул күтәргәне өчен. Каяле, улым, авырткан төшеңне күрсәт әле... Төф-төф! Авыруы бетсен-китсен, җилгә очсын!

Шулай сөйләнеп әни минем күкрәкне сыпыра башлауга хәлем җиңеләеп, тыным ачылып китте. Бер бүген генә түгел, һәрвакыт шулай була. Әллә, чыннан да, изге кеше инде ул безнең әни!

Әни өйгә кереп ятып тор, дисә дә кереп тормадым. Чана шуарга да барасы килми иде инде. Зәки абый кыйнаганга мине кызганып, янымда шыңшып басып торган Равил белән икәүләп әти заманыннан калган иске ат чанасының табаннарын сүтеп алдык та шулардан чаңгы ясарга тотындык.

Без чана табаннарының башын чаңгы башы хәтле генә калдырып кисеп, аяк бавы тагарга тишек тишеп азапланганда миннән биш яшькә олы, инде тәмам егет булып җиткән Барый абый килеп керде дә калганын

ясап бетерергә ул ярдәм итте. Шулай итеп, мине бәхет басты: һич көтмәгәндә менә дигән чаңгылы булдым!

«Кешегә хөсетлек эшләүчеләрнең баркайчан да шунын кияләгән күрмичә калганы юк әле. Зәки дә сине кыйнаганның җәзасын татыр»,— ди иде безнең әни. Дөрес әйткән икән. Шуннан соң ел да үтмәде, Зәки абыйның үзенә дә тиярен биреп кайтардылар.

Өченче группа инвалид иде ул. Инвалидларны ул елларда ике елга бер Казанга дәшеп, врач комиссиясе үткәреп торалар. Зәки абыйны да шунда чакырганнар иде. Көтүгә олы малае Габделгазизне калдырып китте бу. Балык Бистәсенә кадәр председатель Мөбин абыйга утырып барган. Аннан пароход белән киткән. Ул елларда пароходларда тәүлек буена диярлек буфет эшләп тора икән. Зәки абый да күреп алган моны. «Карыйм, парин, йөз грамнап та, теләгән кешегә хәтта илле грамнап та салып бирәләр тегендә!— дип сөйләде ул Казаннан кайткач.— Уйлап-уйлап тордым да, парин, әйдә, әле Зәки, сиңа да бер рәхәт күреп барырга ярый торгандыр, дип бер кисәк кәпчүни калбаса белән йөз грамм акны алдым, аллаң булыйм. Аягүрә ашый торган гына булса да, шунда ук берничә өстәл дә бар. Шуларның берсе янына барып бастым да әйбәтләп кенә салып куйдым теге нәмәстәкәйне. Калбасасын ашап карыйм, каклаган каз тәмнәре килә — шундый шәп! Бүтән чакта сразы башка китә торганые, бу юлы кашшыбутерсен әллә эчтем, әллә юк. Менә, мин әйтәм, затлы закуска ничек икән ул. Шуңа күрә нәчәнникләр ашап эчәргә ярата икән, мин әйтәм. Тукта әле тагын бер тапкыр кабатлап карыйм әле, ни әйтер дә ни куяр икән дим. Анысын да тәвәккәлләдем дә тагын бер кисәк калбасаны сугып куйдым. Шуннан соң колаклар кызып китте китүен. Ә күңелдәге шайт...н тагын кыбырсый башлады: «Әллә тагын берәр йөз грамм аласыңмы, Зәки? Аннары урык-сурык килеп йөрмәссең. Берәр почмакка башыңны төртерсең дә ятып йокларсың»,— ди.— Тәки күндерде бит шул шайтан, каһәр. Тагын киттем буфит янына, булгач булсын дип, берью.ы ике йөзне җибәрдем. Аннары парахут коерыгына барып, якер бүкәненә утырдым да беркавым Иделгә карап, хозурланып бардым. Аннары, туктале, ниләр бар икән моның икенче катында дип, өскә менеп карамакчыем, булмады: әзмәвер кадәр бер матрос баскычның яртысын менгәч артымнан куып җитеп, өреп төшерде. Шуннан парахутның иң аскы катына төшеп киттем. «Монысына төшкәнгә сүз әйтмәсләр, монысы безнең ише гади халык өчен булырга кирәк»,— мин әйтәм. Тәки шулай булып чыкты: анда аркасына иске биштәр аскан минем ишеләр шыгырым тулы иде. Күрәм, иркен генә урында бер кеше бер үзе ята. Якын тирәсендә беркем җук. «Әһә, булды бу: шуның янына барып ятыйм әле»,— дип бара башлаган идем, бер хатын-кыз җиңемнән тартып туктатты: «Якын бара күрмә, агай, аның янына: исерек ул, үзен-үзе белештерми, теләсә кемгә сугып йөри башлагач, әләрәк кенә бәйләп салдылар»,— ди. «Курыкма, апаем, мин үзем дә салган, миңа тими ул!»— дип киттем теге мужик янына. Аю хәтле кеше икән, күзләрен калайландырып, каш астыннан гына карап ята бу. Килдем дә, үз итеп, иплән кенә әйтәм мин моңа: «Нихәл, иптәш? Ник болай ятасың? Кем бәйләде аяк-кулларыңны?»

«Ә сиңа нәрсә кирәк?»— ди бу төкерекләрен чәчеп.

«Кирәкми,— мин әйтәм.— Кирәк булганнан соравым түгел. Үзеңне кызганып, үзеңә берәр нәрсә кирәк түгелме икән, дип кенә килгәнием»,— дим.

«Ну, алайса, кил әле бирегәрәк?— ди бу, яткан җиреннән калкына төшеп.— Колагыңа гына бер сүз әйтәм»,— ди.

«Күптән шулай диләр аны!— мин әйтәм.— Әтү, хатын-кыз шикелле, холыксызланып торган буласың.— Янына ук киләм дә:— Я, нәрсә әйтмәкче идең, иптәш?»— дим.

Ә ул шунда кинәт кенә ыргылды да минем иреннең яртысын ам итте дә ташлады...

Зәки абый кесәсеннән иплән төрелгән чүпрәк кисәге чыгарды да, шуны сүтеп бальзамлаган шикелле саргаеп һәм кибеп беткән бармак башы хәтле ит кисәге күрсәтте: «Менә, шул адәм тешләп алган минем ирен ите бу. Истәлек итеп йөртәм...»

Зәки абый сөйләгән бу вакыйгага Әхмәтгали абый нәтиҗә ясады: «Тиешсез җиргә тыкшынып йөрергә ярата торган гадәтең бар шул синең, Зәки. Монда да үзең гаепле булгансың икән. Ярый әле ирененне генә тешләп калган, борыныңны өзеп алган булса ни эшләр идең. Килечәктә акыл булыр үзеңә, саграк кыланырсың».

Мин Әхмәтгали абыйның ул сүзләре белән тулысынча килештем һәм күңелемнән: «Бик әйбәт иткәннәр! Минем ише ятим малайларны бүтән кыйнамаска акыл булыр!»— дип өстәп куйдым.

Шуннан соң да акылга утырмады Зәки абый: җае туры килгәндә лыкынганчы эчеп, кеше белән ямьсезләнеп, тәмсез телләнеп йөрүен дәвам итте. Шуңа күрә үлеме дә фаҗигале булды: денатурат эчеп, янып үлде, мәрхүм.

Эчү дигән нәрсәнең юньлегә алып бармавын мин әнә шул Зәки абый язмышы мисалында аңладым: гомерем буена сабак булды ул миңа.

*Ахыры бар.*

## *Хатлардан юллар*

***

**Хөрмәтле редакция!**

**Миндә күренекле язучы Габдрахман Әпсәләмовның бер хаты саклана.**

**Гомеренең соңгы көннәренә кадәр укучылар белән якыннан аралашып яшәгән һәм эшләгән каләм остасының бу хатын журнал укучыларына да җиткерәсем килә.**

**Нәҗибә АРСЛАНОВА.**

**Казан шәһәре.**

**Хөрмәтле Нәҗибә Арсланова!**

**...«Кояш тотылганда табылган хәзинә»гә карата җылы сүзләр әйтүегез өчен бик зур рәхмәт. Укучы сүзе язучыларга бик кыйммәт ул. Аны укыгач, сөенмичә булдыра алмыйсың. Монда барысы да фәкать ихлас күңелдән әйтелгән, хәтта арттырып җибәргәндә дә астыртынлык юк. Әйе, безнең укучы киң күңелле һәм белемле ул, бер генә минутка булса да аңарда шикләнергә ярамый икән. Бу турыда искә төшерүегез өчен рәхмәт.**

**Татар язучылары укучылар турында бик күп җылы фикерләр әйтеп килсәләр дә, иҗат серләрен, ни өчендер, аңа артык сөйләмиләр. Бу тыйнаклыктан киләме, әллә монда башка нәрсә бармы — белмим. Сезнең хатыгыз, минемчә, язучыларны уйландырырга тиеш.**

**Минем әсәрләремне яратып укучы күп санлы укучыларыбызга миннән кайнар сәлам һәм рәхмәт сүзе тапшырсагыз иде.**

**Эшегездә зур уңышлар теләп, сәлам белән**

**Габдрахман Әпсәләмов.**

# Равил Фәйзуллин

## Туган халкым

Бу дөньяда һәркем лаек ихтирамга,
раслый алса яшәвенең олылыгын.
Туган халкым! Тарихларның давылында
югалмыйча кала алуың — горурлыгым!

Матурлыкка, гаделлеккә, тынычлыкка
хезмәт итсәң — намусың пакь, иҗатың чын.
Туган халкым! Сынауларда сабыр булып,
җиңүләрдә ныгаюың — таянычым!

Йолдызларга менгән кеше, ялгышып та,
таптап китмәс шушы җирнең бер чәчәген.
Туган халкым! Илен-телен саклый алган
игелекле балаларың — киләчәгең!

## Офыктагы юл өстеннән

*Югары авыл юлы,*
*Түбән авыл юлы!*
*Гарифуллам, ник кайтмыйсың?*
*Сагындырдың бу юлы...*

Дәүәни җыры.

Олы юл үргә менә дә,
югала офыкларда.
Карашларың туктап кала
күктәге болытларда.

Юл — кисеп кергән шикелле
болытлар арасына.
Болытлар ишелеп чыга
карашларың каршына.

Юл югалган шул ноктага
төбәлгән күзләр күпме!
Кемдер кайта, кемдер китә
кичеп шул нокта-чикне.

Офыктагы ул болытлар
керми нинди сурәткә!
Үзгәрсә дә сурәтләре,
уелып бара йөрәккә.

Болытлар бер ак булалар,
бер китәләр каралып.
Төсләрне алар — киткәннәрнең
күзләреннән аламы?

Болытлар! Белеп үтегез
юл өстенең ул турын!
Күпме җаннар шул тарафка
юнәлткәннәр күз нурын!

Каплап тора күрмәгез сез
кайтучы, китүчене!
Тамчы булып, иренә
тамыгыз китүченең!

...Олы юл, нигә дип шулай
үрләргә мендең икән?
Офыктагы болытлар күк,
китү — мәңгелек икән!

Китәләр... Ник китмәсеннәр,
кайтырга өмет барда.
Әнә бит болайга таба
йөгерә болытлар да!

## Каскадер

Утлар эченә кер. Сикереп төш
муен сындырырлык биектән.
Аварияләргә эләк. Сугыш.
Тәгәрәп йөр җанвар-киектәй.

Барган шәпкә поездлардан ташлан,
күперләрдән барып очып төш.
Исән-имин кал тик! Хәвефләрдән
үлем ясамау бит — безнең эш!

Дөрес, кайчак без дә азат түгел
ялгышудан яки каушаудан...
Ә шулай да, бу эш тынычрак
сәясәттә сальто ясаудан.

Кемгә — трюк. Уен... Безгә — хезмәт.
Алынгансың, эшең — чын булсын!
Сәнгать белән Хәтәр янәшәдә —
биекләрдән егыл егылсаң!

Киноларда ерак кадрда без.
Алгы планнарда — геройлар!
Без кылганда кичергәннәрне,
ходай белсен, ничек уйныйлар?!

Сау тәнеңнең һәр бөртегенә
хуҗа булу бик җиңел түгел!
Экстремаль халәтләрдә кайчак
йомшап ала, нечкәреп күңел...

Кыл өстендә калган вакытларда
үлем шәүләләре күренә!..
Тарзан булып күпме генә йөрмә,
һәркемнең дә гомере бер генә!

Бу дөньяда язмыш сынавында
буладыр ул һәркем каскадер!
Яшәвенә, шөгыленә карап,
исемнәре генә башкадыр...

## Җигә алсаң...

Кыргый атның горур башын
элмәкләгән табунчыдай,
кулга ала да берәү Вакытны,
сөйри,
        сөйри үз юлына!

Әй тартыша Вакыт!
Әй тартыша!..
(Күнеккән ул
хакимнәрнең хакиме булып!)

...Әгәр җиңеп,
ихтыярына җигә алса
Олуг Вакыт Галиҗәнабен —
шул зат кала

бөек булып,
Вакытының
исемен алып
мәңгелеккә!

## Исеңдәме?

Урман авызыннан чыктык та без
(каршыбызда — кечке шәһәр),
гөнаһлы адымнар белән
(урлап алган бәхет хәвефле),
онытылып, хәлсез сарышып
(гомер юлы шәфәкъка якын),
кояш баешына ашыктык
(тәрәзәдән көтә балалар)...

...Көтмәгәндә, калку юл өстендә
керпе очрап безне туктатты
(ник дип чыккан кечке яланга?).

Тора керпе калкулыкта,
тере йомгак булып офыкта
(төнге якны җансыз димә син!).
Без торабыз
тораташтай, икәү бер булып
(олыгайгач сабый чак тарта)...
Тора керпе алсу фонда
(безне аңлыймы, әллә битәрли?).
Безнең соры кояш түгелме ул
(куктәгесе кереп югалган?)
Шул сурәттә микән әллә
безгә иңгән энәле язмыш
(үткән белән һаман тартыша җан)?

Бераз торгач тәгәрәде керпе
түбән таба тузанлы юлдан
(таң сызылыр тарафка таба).

...Кинәт миңа борылып карадың да
(сиңа ул кич ничә яшь иде?),
озын керфек очларыннан
(элеккечә кайнар үткерләр!)
тамды җиргә
алсу чыклар...

## Ялган

I

Һәр әйтелгән ялган сүздән
мөгез чыкса маңгайга,—
кыяк үләннән күбрәк
мөгез булыр дөньяда!

Әле дә чыкмый. Юкса бездән
сабыйлар качар иде...
Олылар бер-берсен күреп,
акылдан шашар иде!

II

Һәр ялганнан җан көчләнә.
Күз нуры тоныклана.
Ялганчының, бер көн килеп,
баскан туфрагы яна!

Ә туфракка нәрсә ялган! —
Табигать ул яңара!
Һәр ялганнан иң әүвәле —
Ил аңы томалана...

## Кызыгу

*Апрельдә туган якка кайткач*

Тау кашында мәш килә балалар!
Биектә — зәп-зәңгәр, өр-яңа язгы күк.
Тирә-юньдә — яңа гына борын төрткән яшел чирәм.
Җилләр белән әүмәкләшеп,
тәгәриләр,
куышалар,
көрәшәләр яшь малайлар!

Чабак кебек ялтырап ала табаннары!
Бер ишләре кәгазь очкыч җибәрәләр күк катына.
Чаялары учак аша сикерәләр бер-бер артлы.
Кышны җиңү куанычы — йөзләрендә!
Үзгә, яңа дәртле аваз — сүзләрендә!

...Карап торам читтән кызыгып.
Кушылыр идем мин дә уенга —
сикерә алмыйм еллар читәнен!
Бер юаныч — шөгылем бар:
блокнотка сүзләр язам...
«Зәңгәр түтен.
Яшел чирәм.
Төссез яшь...»

## Бер чардуган янында...

Яшь. Сау. Көләч... Булды синең
тулышып килгән ай чагың!
Кая ару, кая талу! —
уйнап йөргән тай чагың!

Кая ул чак еллар санау!
Үткәнен язның, көзнең...
«Дөнья, диден, тик башлана!
Мәңгелек ул — без, үзе!

Теләсәм — карт имәннәрне
суырып алып атам!
Теләсәм — аккан суларны
буып сузылып ятам!

Теләсәм — йолдызлар чүплим!
Кирәксә — тау күчерәм!»

Мин ул чак көнләштем синнән,
һәм сокландым эчемнән.

Вакыт үтә-үтә беркөн
ай да сызылып бетте.
Яшь имәнне яшен сукты.
Хушлашыр вакыт житте.

...Йолдызлар да үз күгендә.
Таулар да урынында.
...Өстенә язу язылган
яңа бер түмгәк тора.

## Ялгызлык

Элек тә алар икәү иде
шушы йортта:
йөгерек хәтер,
кукеле сәгать.

Сәгать бер көн ватылып тукталды.
«Калдым бер үзем...» дип йөргәндә,
табылды бит янә бер иптәш —
төннәрендә аваз биреп куя
мич артында сайрар чикерткә.

# КЫСКА ШИГЫРЬЛӘРДӘН

## Урын

Шһык булып этеп тора үткән еллар.
Борылып карап була. Чигү юк...

## Күперләр

Дусларның күрешкәндәге
кулларының күләгәсе!

## Кояш

Кара урман куелыгында
бер уч алтын кисәге!

* * *

Әйул төнге сөйләшүләр!
Саулыгын һәм сөелгәнен тоеп яткан
һәрбер җанның
һәрбер сүзе
ак канатлы!

## Күпер киткәч...

Очып йөри арлы-бирле
ярдан-ярга бер күбәләк!

* * *

Йөри кайгы агач башларыннан —
кеше башларына сикереп...

## Чакты бал корты...

Чәчәкләр бүләген китереп, бал бирде.
«Дөньяда үч тә бар!»ны раслап, җан бирде.

## Күк

Күк — зәңгәр сандыгым минем.
Бик күп серләрем — шунда!

Ачам кайчак. Ачкычы аның —
сөйгәнем куенында...

## Яшьлек

Алда, артта, ян-янда,
аста, өстә — һәркайда
Теләк ярлары!

* * *

*Моннан Әби патша үткән...*

Ишеткәннәрдән

Җиңгәннәрне хәтерли халык.
Үлгәннәрне — сирәк.

Алганнарны үрнәк итәләр.
Биргәннәрне-сирәк...

## Сагындыра...

Диңгез шавына кушылган
назлы авазлар!..

Сине уйлап, таулар менгән
хыяллы язлар!..

## Гөлдәге чык, җырга әйлән...

Бу — чык түгел, шатлык яше —
сөйгәнем яңагында!

Гөлдәге чык, җырга әйлән
сандугач тамагында!

## Роберт Миңнуллин

### Яхшылык

Кешеләргә без яхшылык эшлик!
Эшләмәсәк — гарьлек.
Тик яхшылык эшләү җиңел түгел,
Ул — зур фидакарьлек!

Яшәү безгә авыр булыр иде
Яхшылыктан башка.
Шуңа күрә яхшылыкны эшлик
Без үзебез башта.

Ятмыйк көтеп яхшылыкны безгә
Эшләр диеп кемдер.
Яхшылыклар эшлик! Җаным, син дә
Үз-үзеңне күндер!

Шунда гына канәгатьлек хисе
Алыр сине биләп.
Һәм үзеңнең КЕШЕ икәнеңне
Син тоярсың кинәт!

Моның шулай икәнлеген күпләр
Яхшы аңлый аны.
Тик барыбер яхшылыкны һәркем
Эшли алмый аны.

Барыбыз да яхшылыкка мохтаҗ,
Бу заманда бигрәк.
...Яхшылыкны эшләү җиңел түгел,
Ә эшләргә кирәк!

### Сиңа җырлар язмыйм инде

«Миңа җырлар язмыйсың»,— дип
Үпкәлисең һаман.
Мин әле дә элек язган
Җырларымда янам:

Хисләрем — шул ук. Аларны
Мин яңартам гына...
Сиңа җырлар язмыйм инде,—
Тик яратам гына.

## Каурый белән...

Тукайның шигырьләренә
Мәңгелек язган икән!
Ул үзенең шигырьләрен
Ни белән язган икән?
  Былбыл каурые беләндер,
  Былбыл каурые белән...

Туфан шигырьләрендәге
Яктылык яздан микән?
Ул үзенең шигырьләрен
Ни белән язган икән?
  Аккош каурые беләндер,
  Аккош каурые белән...

Җәлилнең күпме шигыре
Язылмый калган икән?
Ул үзенең шигырьләрен
Ни белән язган икән?
  Бөркет каурые беләндер,
  Бөркет каурые белән...

## Сәер уйлар

Кинәттән генә башыма
Сәер уйлар төште:

— Кемнәр ничек дәвам итәр
Без башлаган эшне?

Без яшәрбез дә китәрбез —
Ниләр калыр бездән?

Кемнәр йөрер, йөрерләрме
Без калдырган эздән?

Кемнәр җырлар, җырларлармы
Без калдырган җырны?

Ничегрәк искә алырлар
Без яшәгән чорны?

Кемнәр булыр, нинди булыр
Без калдырган токым?

Киләчәккә кем тапшырыр
Безнең токым утын?

Кемнәрне кызыксындырыр
Без калдырган исем?

...Шушы хакта уйланганың
Бармы синең, кешем?

## Соңгы яфраклар

Яфракларның күчеш чоры —
Күктән җиргә, туган җиргә.
Үпкәләре — көзгә түгел,
Ә үзләрен куган җилгә.
  Инде ничә кабатлана,
  Ел да шулай канатлана
  Көзнең алтын яфраклары,
  Көзнең салкын яфраклары.

Ахыргы кат тирбәләләр,
Очыналар, талпыналар.
Кинәт җанны өтеп ала —
Әйтерсең лә, ялкын алар!
  Бөтерелә, бөтерелә
  Бер сүнә дә бер терелә
  Көзнең моңлы яфраклары,
  Көзнең соңгы яфраклары.

Бер яфраксыз кала инде
Көзге дөнья, көзге күңел.
Хәер, сары ул яфраклар
Кышкы инде, көзге түгел.
  Гүя ялгыз кошлар алар,
  Ничек кенә кышлар алар —
  Кышның туңган яфраклары,
  Карлар кунган яфраклары.

## Алтынга мактау

Бөтен әхлак кануннарын бозып,
Шигырь язам алтын хакында мин.
Алтын чынлап макталырга хаклы —
Мактау җырлыйм бүген алтынга мин!

Мактау җырлыйм — дөньядагы барлык
Кара, ак һәм яшел алтыннарга.
Әнкәй кебек алтын алкаларсыз
Күп балалы алтын хатыннарга.

Алтын йөзек киеп карамаган
Хатыннарның алтын кулларына.
Мактау җырлыйм — алтын кояшыма,
Туган җирнең алтын кырларына.

Алтын кырларыма алтын икмәк
Үстерүче алтын кешеләргә.
Мактау җырлыйм — ындыр табагында
Шыбырдашкан алтын көшелләргә.

Мактау җырлыйм — Туган илебезнең
Бәрәкәтле алтын көзләренә.
Акыл иясенең безгә диеп
Иҗат иткән алтын сүзләренә.

Мактау җырлыйм — алтын хәреф белән
Язып куйган алтын исемнәргә:
Бөек яуда һәлак булганнарга,
Яу кырыннан кайткан исәннәргә.

Үзебез дә булыйк алтын кебек!
Кемгә кирәк алтын түгелебез?
Мактау җырлыйм бүген сезгә дә мин —
Алтын булса гына күңелегез!

Сезгә минем алтын теләкләрем —
Алтын булсын сезнең киләшегез!
Кызларыгыз булса, сез бары тик
Алтын егетләргә ярәшегез!

Алтын чәчле кызлар үстерегез!
Кыен чактан тик көлегез генә.
Һәм яшәгез алтын туйга кадәр!
Ә алтынга...
төкерегез генә!

## Туган телемә

Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа азга гына.
Бөтенләйгә түгел — вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагыма.

Синнән алган һәрбер сүземне мин
Күз карасы төсле саклар идем.
Ул сүзләрнең затлыларын сайлап,
Дога итеп кенә ятлар идем.

Ул сүзләрне җырга әйләндергәч,
Мин кайтарып сиңа бирәчәкмен.
Исраф булмас ул сүзләрең миндә,
Җыры булыр алар киләчәкнең.

Әйтә алмыйм әле — ул сүзләрдән
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне!

## Яктылык

Бүген көнгә әйләнде төн —
Үзгәртергә инде соң.
Тәрәзәң калды яктырып.
Ул яктылык — синең сын!

Яктыртты бөтен дөньяны
Синнән төшкән яктылык.
Төн уртасын — беренче кат —
Каплап алды ак тынлык.

Югалды урам утлары,
Йолдызлар тынып калды.
Синнән төшкән яктылыктан
Алар да тоныкланды.

Якты төн. Озатты мине
Бөтен тирә-як тынып.
Балкып калды
Моңа чаклы
Мин белмәгән яктылык.

## Буш оя

Буш оя. Шундый тын —
Эче дә, тышы да.
Үч иткән шикелле
Кырысрак кышы да.

Ничәнче ел инде
Җансыз бу буш оя.
Югалган кошчыгын
Көтәдер кошоя.

Хуҗасыз ояга
Җил генә оялый.
Ә җилгә барыбер —
Оялый... оялмый.

Тын. Тып-тын. Тып-тынлык.
Буш бакча. Кыш. Оя.
Ялгызы салкыннан
Дерелди буш оя.

Мин сине җылыта
Алмам шул —
Хуш,
Оя!

## Канат асты

Җылыдыр ул
Канат асты.
Тик онытма —
Бар бит әле
Канатларны
Канатасы!

Тик очулар
Тимәс сиңа,
Ул бәхетләр
Килмәс сиңа —
Сине күптән
Канат басты!

Рәхәттер ул
Канат асты...

## Сандугачлар язын туа

Әллә күңел сандугачлар
Сайравыннан тулды микән?
Моңландыра. Сандугачлар
Әллә бүген туды микән?

Сандугачлар туган көнне
Мине никтер моңнар баса.
Нәрсә булыр иде — әгәр
Сандугач та моңланмаса?

Ярый әле сандугач бар!
Юк аларның тынганы да.
Сандугачлар язын туа,
Язын туа — моңнары да.

Кайчан үлә? Ничек инде?!
Колак сал җыр куагына!
Сандугачлар үләмени?!
Сандугачлар туа гына!

*1983—1984.*

Аяз Хәсәнов

# ФАТИХА

хикәя

## 1

Тайга урманы арасыннан сузылып аккан елга ярында, офык артына төшеп баручы кызыл шарны күзәтеп, өч яшьлек сабый бала утыра. Читтәрәк бер төркем кеше елгадан ятьмә тарта, баланың әти-әнисе дә шулар арасында. Эш белән мавыгып китеп, алар баланы онытып җибәргәннәр. Бала ялгыз калудан курыкмый. Һавада, нәкъ елга турысында, кечкенә ак болыт эленеп тора, су өстендә карлыгачлар уйнаклый — чебен-черки аулыйлар.

Бала әле дөньяда явызлык барлыгын белми, шуңа күрә каршында ук пәйда булган аю башыннан да курыкмады. Аю ашыкмыйча гына аның зәңгәр күзләрен, сары трусигын, алсу аяк бармакларын исни һәм бу бәлки шулай дәвам да иткән булыр иде. Ләкин шул вакыт сабыйгына күз ташлаган ананың ачыргаланып кычкырганы ишетелде. Аю шунда ук читкә атылды, урманга кереп югалды, ана исә баласына томырылды. Аюга караганда төсе качкан әнкәсеннән ныграк курыкты бала.

...Еллар үткән саен гаиләдә бу вакыйганы ешрак телгә алалар. Малай инде үсте, зур аюлардан куркырга өйрәнде. Ләкин аңа еш кына болай диләр: сиңа, диләр, туган чакта ук урман хуҗасы аю фатиха бирде, язмышың бәхетле булыр, тормышта син бөтен авырлыкларны да җиңеп чыгарсың. Һәм малайда үсә төшкән саен урман хуҗасын күрү теләге көчәйгәннән-көчәя барды.

## 2

Явым-төшемле көз көннәрендә миңа үземнең туган җиремдә — Обь кушылдыгы саналган Чулымның матур ярында урнашкан бер авылда булырга туры килде. Машинадан төшкәндә вак кына яңгыр сибәли иде — шул кадәр тынычява, хәтта күзгә төсләр иңгән агач яфраклары да селкенми. Изрәгән балчык баскан саен батып-батып керә, табан астыннан кара боламык сытылып чыга. Күп тә үтмәде, яңгырдан һәм агачлардан коелган тамчылардан плащым манма су булды.

Кайчандыр без яшәгән һәм менә ике дистә ел инде башка кешеләр

торган өйнең ишеге бикле иде. Мин урамга чыктым. Көянтә-чиләк белән су китерүче кыз йорт хуҗаларының бер атнага Ачинск шәһәренә китеп баруын, үзенең өйгә күз-колак булып калуын әйтте. Минем берәр җылы почмак табып кипшенәсем, чәй эчәсем бик килсә дә, таныш түгел хатын-кыз өенә барып керергә уңайсызландым һәм кайчандыр белгән берничә кешенең исемен атадым.

Мин тәпи йөри башлаган, елга өстендә уйнаклаган карлыгачларны карап яр буенда утырган бу авыл әллә ни үзгәреш кичермәгән, бары тик кешеләр генә алмашынган, гүя Чулымда йөргән пароход, берәүләрне шушында төшереп калдырып, икенчеләрен утыртып алып киткән иде.

Семеченок дигән исемне ишетүгә, бала чакта безне чытырдап торган чыршы сагызы белән сыйлаган кыскарак буйлы, кояшта янган йөзле, сакаллы карт крестьян сурәте күз алдыма килеп басты.

— Аны кайдан табарга соң?

— Гадәттә ул яр буенда була, анда күренмәсә — әнә теге тыкрыкта стенасы агартылмаган өй тора бит — аның өе. Бәлки әле ятьмә саладыр, яисә көймә төзәтәдер. Башта шунда сугылыгыз.

Бакчалар буйлап Чулым ярына килеп чыкканчы ботинкама су тулып өлгерде. Тиздән, яңгырда изрәгән тынлыкны бозып чүкеч тавышы ишетелде.

Кинәт үр өстеннән елга ачылып китте, үзенең тыныч агымы, киңлеге-кырыслыгы белән хәтерне уятып-сискәндереп җибәрде. Вакыт дигәнең яр кырыендагы аяк эзләрен күптән юып төшергән, кайчандыр без суга ыргытып уйнаган яссы ташларны да елга комы күмеп киткән, ә менә балачакның самими хис-инанулары күңелдә элеккечә яшь икән һәм мин табигатьнең бу өнсез манзарасын нәкъ теге чактагыча кабул иттем.

Чулымның каршы ярында яңгыр томаны эчендә утырган наратлар белән көмешләнеп аккан елга бу мизгелдә тылсымлы әкиятне хәтерләтә иде. Мондый матурлыкны ничек ташлап китмәк кирәк...

Юеш йомычкалар сибелгән ком өстендә янтайтылган зур көймә ята. Зур размерлы күн итек кигән ир-ат нәрсәдер эшли. Йөзен сары сипкел баскан. Кем икәнемне әйтеп, бер-ике сүз алышканнан соң, коралларын брезент астына җыеп тыгып, карт мине авылга алып китте.

— Тиздән юллар өзеләчәк. Эх, элек юл өзелүнең нәрсә икәнен дә белми идем — бөтен авыл ямь-яшел чирәм. Хәзер менә машина-трактор белән казып бетерделәр. Язын-көзен әйләнеп чыгарлык түгел. Муеннан кереп чумасың. Хуҗалар, ачуым килмәгәе!

Семеченок, кыштыр-мыштыр китереп, турыдан атлый. Күнитеге астыннан пычрак чәчри.

— Ничек соң, балык бармы?

— Балыгы бар... Шулай да элеккегә җитми инде. И-и, без синең әтиең белән беләсеңме нинди чуртаннар тота идек! Менә бу бәхет! Яр кырыйлатып ятьмә белән бер генә урыйсың — тартып чыгарып булмый. Ну, хәзер дә бар анысы балык. Ләкин менә елга уртасында таплар күренә башлады — кайдадыр өстә нефть тапканнар...

## 3

...Тәбәнәк кенә түшәмле өй. Почмактагы сандык өстендә аклы-каралы мәче ята, вакыт-вакыт киерелеп куя, авызын ачып иснәгәндә соргылт азау тешләре күренеп кала. Артсыз урындыкка куелган радиодан вальс ишетелә, шул көйгә радионың үз гүелдәве дә өстәлә. Өй почмакларында — тузан кунган пәрәвезләр. Кыскасы, Семеченок картның өе шактый ташландык хәлдә. Карт минем карашымны тоеп алды да сакалын кыймылдатып:

— Мин бит монда кунарга гына кайтам,— дип куйды.— Җәйләрен

көне буе елгада, ә кышын тагын чыгып китәм. Хуҗалыкта да кәҗә белән песидән гайре нәрсә юк. Карчык үлгәннән бирле өйне карап торырлык кеше калмады.

Табада бәрәңге пешә, өйгә тәмле ис тарала. Плитадагы борынсыз чәйнек тавышланып кайный.

— Тайгада нәрсә аулыйсыз соң?

— Кышынмы? Тиен, кеш аулыйм. Кечкенә генә өй дә бар анда. Шул тайга туендыра инде.— Семеченок буявы купкан шкафтан савыт-саба алды.

Яңгыр тавышы монда ишетелмәсә дә, түбә кырыеннан тамган тамчыларның җыелган суга чапылдап төшүен аерып була.

— Иртәгә аязырга тиеш,— дип куйды карт. Ул минем сәфәр яңгырлы вакытка туры килүгә борчыла иде, күрәсең.

— Әйдә, ява бирсен,— дидем мин, әллә ни исем китмичә. Каршымдагы бу карт гомерен тайгада үткәргән, ауга йөргән, балык тоткан. Себер урманнары үзенең серләрен нәкъ менә шушындый кешегә генә ача һәм минем аның күргән-белгәннәрен тыңлап утырасым килә иде. Бәлки әле аюлар тормышыннан да берәр нәрсә сөйләр, дип өметләндем мин.

— Аюмы?— диде ул минем соравыма каршы.— Аю урманда патша инде ул. Монда аннан да көчле җанвар юк. Табигать аны барыннан да өстен куйган. Ул тәртипне дә саклый монда, җәзасын да бирә. Акыллы җанвар. Кырыс та. Кайвакытта аның зирәклегенә исләрең-акылларың китә, чәчләр үрә тора.— Аю турында ул зур хөрмәт белән сөйли, гүя аю урман җәнлеге түгел, ә ниндидер илаһи көчкә ия зат.— Бер вакыйга сөйлим әле үзенә. Шул хәлләрдән соң бу җәнлеккә хөрмәтем икеләтә арты. Карт тайгачылардан ишеткәнем бар иде: аюны сәбәпсез борчымаска, урманда йөргәндә дә үзеңне тәртипле тотарга, дип. Әгәр инде йөзгә-йөз очрап, атарга кирәк булса, үтерерлек итеп ат, яралап кына калдырма. Алай итсәң, көт тә тор — үчен кайтарачак. Артыңнан сагалап йөриячәк. Үзен җәберләүчене бер дә онытмый диләр аны.

Алтмышынчы елларда без монда урман кистек. Ни өчен кистергәннәрдер — анысын белмим. Ләкин җитәкчеләрнең урманнан бушаган урынга ашлык чәчтерергә дә исәпләре бар икән дип ишеткән бар иде.

Бригадалап эшлибез, безнекендә — унике кеше. Төрле халык: латышлар, чувашлар да бар. Бер гаилә кебек яшибез. Ләкин безнең артельдә бер тотанаксыз адәм бар — Аникин. Шушында туып-үскән, әмма саранлыгы белән аерылып тора иде. Бер дә кулы тик тормый тегенең, эшләгән эше үзенә берәр файда китерсен иде ичмасам... Хәтерлисең микән, Чулымның теге ягында бер бик биек нарат үсеп утыра иде. Очы күкләргә тия. Тирәюньнең күрке инде менә. Елга ярына чыктың исә беренче булып күзең аңарга төшә. Утыра шулай биек агачлар чолганышында, ә үзе алардан ике башка биек. Ничә яшь булгандыр аңа, берәү дә белми. Кеше туа, яши, үлә, ә нарат тора бирә. Кичләрен баеп барган кояш аның башына менеп бераз ял итә дә, ашыкмыйча гына төшеп, төнге йокыга тала иде. Көннәрдән бер көнне шулай Аникин уйный-шаяра әйтеп куйды: «Җитәр инде, күп яшәде, башкаларга яктылык кирәк»,— ди бу. Берәү дә моңа игътибар итмәде, бу сүз шундук онытылды. Гомумән, күп сөйли иде ул. Ә бер кичне кинәт тирә-юнь чатырдап китте һәм безнең горур наратыбыз гөрселдәп җиргә ауды. Ыңгыраша-ыңгыраша ауды нарат, гүя тормыш белән саубуллашу аңа авыр иде. Яр буенда хатын-кызлар «ах» итте, кулларыннан юган керләре төште. Менә шулай һәлак булды безнең мәһабәт наратыбыз. явыз адәм кулыннан китте. Соң, берәр файдасы тисен иде ичмасам. Уңайсыз төшкәч, турап азапланучы да табылмады наратны. Андый юан агачка кемнең көче җитсен. Шул көннән Чулым яры ничектер бушап, ятимләнеп калды, нәрсәдер җитми иде. Әмма моңа да күнектек. Соңыннан сорыйбыз Аникиннан: «Нигә кистең, комачаулый иде мәллә?»— дибез. Үзе дә белми нигә кискәнен, батырлык күрсәтәсе килгән, үзен хуҗа итеп танытасы. Менә нәрсәгә көче җитә, янәсе...

Шулай без көне буе тайгада агач аударабыз. Ләкин аю-фәлән бик сирәк очрый. Көрән янтыгы күренеп китә дә шундук юкка чыга, анда да әле тәгаен генә әйтә алмыйсың — әллә ул, әллә башка нәрсә. Йөргәндә дә бик сак атлый аю, ботак та шартламас. Бервакыт шулай төшкелеккә туктадык та ашап-эчеп, ял итеп алу өчен читкәрәк барып утырдык. Сәгать-сәгать ярым вакыт узгач, кире килсәк, без кискән наратлар чигендә тырнак эзләре. Кискәндә алар юк иде — анысын төгәл хәтерлим. Димәк, аю килеп тамга салган. Бу инде аның безне кисәтүе, шушы тамгадан ары кермәскә, анда минем биләмәләр башлана, диюе. Без курка калдык, шулай да, бер илле метрлап читкәрәк күчеп, эшне дәвам итәбез. Өйгә кайтканда да иртәрәк кузгалабыз, якты күздә елгага җитәсе, исән-имин килеш теге якка чыгасы килә. Йөргәндә дә саграк йөри башладык. Бер Аникинның гына исе китми — сукмактан барганда да балта белән шаяра, яшь агачларны чапкалый. Бездән соң ичмасам шул яшь агачлар калсын иде, соңыннан бәлки ныгып, күтәрелеп китәрләр иде. Юк, аңа барысын да корытып китәргә кирәк.

## 4

Атнага бер көн ял итәбез. Мунча керәбез, кер юабыз, кием-салымны ямаштырабыз. Ә иртәгәсен тагын урманга, шундый бер ялдан соң эшкә баруыбыз. Аникин бертуктаусыз нәрсәдер тыкылдый, кәефе күтәренке тегенең, кичә ауга киткән җиреннән аналы-балалы пошиларны атып кайткан. Ләкин беребез дә моңа кызыкмады. Ничек атуын сөйләп биргәч, йөрәккә үк бәрде. Чын аучы мондый нәрсә белән мактанмый. Аналы-балалы пошиларны күрсәң, киресенчә, шыпырт кына китәргә, куркытмаска тырышасың. Борчыйсы килми. Ә Аникин башта кайсын атып егыйм икән дип баш ваткан: әнкәсенме, әллә баласынмы? Баласын атсаң, әнкәсенең качып китүе бар. Әнкәсен атсаң, баласының качып китәргә акылы җитмәс, дип, беренче ана пошига аткан. Мылтык гөрселдәгәч, теге тетрәнеп куйган, ләкин егылмаган, аякларын терәп һаман тора икән. Тагын аткан Аникин, пошиның муеныннан кан бәреп чыккан, ләкин барыбер аумаган бичара хайван. Ялварып көч сорагандай, тора икән аякларын терәп. Тәмам шашкан моны күреп Аникин, тагын бер аткан ана пошига. Ни хикмәт — бу юлы да аумаган тегесе. Ничек кенә ахмак булмасын, барыбер барып җиткән явызга: әнкә пошины бит янәшәдә торган баласы тота, шул егылырга ирек бирми. Үлеп китсә, кем карар аның газизен...

Шушы нәрсә аңына барып җиткәч, пошиның баласын атып еккан Аникин. Баласы артыннан ана поши да җиргә ауган. Харап иткән бит явыз, малкайларны. Ите дисәң, бала пошиның ите дә йомшак, тотрыксыз бит аның, ашап та булмый. Кара инде син бу туң йөрәкне!..

Шуннан соң без Аникинны күрә алмас булдык. Күралмыйбыз и вәссәлам. Бер без генә дә түгел иде, күрәсең... Ул көнне эшнең рәте китте, унлап агач аудардык та, ботакларын чистарткач, өеп куйдык. Эшкә бер дә кул бармый. Бүрәнәләргә утырыштык, тәмәке суырабыз, черки куабыз. Шул вакыт аюны күреп алдык. Ул үз дәрәҗәсен белеп, качмый-посмый гына күренеп үтте. Аникин түзмәде:

— А ну-ка, йөрмә монда, камыт аяк!— дип кычкырды. Җикеренеп кычкырды. Бер-ике минуттан аю кабат агачлар арасыннан килеп чыкты, туп-туры безгә килә бу. Без тораташ булып каттык. Уйлыйм: «Әллә, мәйтәм, күрми микән? Кешеләргә таба килә бит». Алай да күзләре безгә төбәлгән, күрә, димәк. Нишләптер туп-туры Аникинга бара. Килеп җитте дә, арт аякларына басып, тәпиен күтәрде, тегенең бүрегенә кагылып алды. Карыйбыз — Аникинның баш тиресе кубарылып маңгаена җыерылып килгән. Аю борылды да ничек килгән булса, шулай китеп тә барды...

Без Аникинны көч-хәл белән елгага алып барып җиткердек. Көймәдә җан бирде.

Менә шундый ул урман хуҗасы аю. Кем дә булса тәртип бозса, шуны акылга утырта. Таләпчән, җитди хуҗа ул.

## 5

Караңгы почмактагы караватта Семеченок карт байтак ухылдады, ятагын шыгырдатты, әә өйалдында чикерткә черелдәде. Карт сөйләгәннәр тәэсиреннән мин дә озак вакыт йоклый алмый яттым, аннан соң гына ниндидер томан суырып алды. Менә өй ишеге шартлап ябылды, мин куркынып күзләремне ачтым. Ни арада көн туган! Уянып килгән авыл өстеннән ертык болытлар агылыша, чыгарга азапланган кояшны каплыйлар. Мин юеш болдырга чыгып бастым, дымлы һавадан калтыранып куйдым. Аяк астында бөгәрләнеп мәче утыра, күзләрен ачкалап, юеш дөньяга карый.

Авыл өстендә, һаваны кискәләп, карлыгачлар оча. Бу миңа балачакны искә төшерә...

Семеченок картның суга төшерелгән көймәсенә тырыс, кәрзин, чиләкише нәрсәләр тоткан карчыклар һәм кызлар утырышкан, көнбагыш яралар. Көймә зур: сигез хатын-кыз, ике ишкәкче, хуҗа белән мин — барыбыз сыеп беттек. Бу көенчә ул кечкенә судноны хәтерләтә. Чулым ярларында тагын да шундый көймә бар микән?

Семеченок ишкәкләрне егетләргә бирде дә мине үз янына — койрыкка утыртты.

— Ну, капитан, кабыз катерыңны! — дип команда бирде арадан бер карчык һәм итәгендәге көнбагыш кабыкларын кагып төшерде.

— И-и, син дә мондамени әле, чибәрем,— дип шаяртты карт.— Картыңны ничек берүзен калдырырга батырчылык иттең, мич башыннан төшеп берәр яры китеп барса?

— Китә бирсен, бик шәп булыр, башканы табармын, яшьрәкне! — дип карчык та югалып калмады.— Син, мәсәлән, кемнән ким — менә дигән кияү! Өстәвенә мәшәкатең дә аз: җәйләрен елгада, кыш буе тайгада. Өйлән миңа, әйдә!

— Бик өйләнер идем дә — үкенерсең дип куркам. Әйтерсең соңыннан — игътибар итми, яратмый, дип.

— Акчаны күбрәк алып кайтсаң, башкасын сорамам...

Менә шулай уен-көлке белән көймә кузгалып та китте. Чулымның теге ягына мүк җиләге җыярга чыгып барабыз. Ә минем исәп — аюлар яшәгән урманда йөрү, күптәнге хыялымны тормышка ашырасым, дөньяга аяк басканда ук миңа үзенең «фатихасын» биргән урман хуҗасын үз күзләрем белән күрәсем килә. Теге чакта Чулым ярында утырган өч яшьлек малай — мин бит инде ул. Шул вакыйгадан соң мин монда тагын ике ел торганмын. Үзем туган бу җирләрне начар хәтерлим, өйдәге кайбер хәлләр генә күз алдына ачыграк килеп баса.

Ярга килеп төртелергә берничә метр калганда, көймә тизлеген акрынайтты.

— Ну, җанашларым, аягыгызны чылатырга курыкмыйсызмы? — дип сорады Семеченок карт.

— Ә син безне күтәреп чык, менә булырсың ир. Барыбер көнозын суда чупырдыйсың.

Ишкәкче егетләр суга сикереп төштеләр дә көймәне ярга табарак тартып китерделәр.

— Болай килешик, чибәркәйләр: кояш төш вакытын узгач, барыгыз да монда җыеласыз. Соңга калган кеше бүреләргә азык була. Аңлашылдымы?

Икешәр йөз ел утырган мәһабәт наратларның башлары тып-тыныч. Җилнең әсәре дә юк. Кайбер урыннарда юан нәрсәләр арасына тартылган пәрәвәз җепләре очрый. Кулга ботак алып, алардан юлны чистартам.

Семеченок карт яр буйлатып су̂лга таба китте. Ул тарафта болын, халык печәнне шунда чаба, соңыннан гына көймәләр белән аргы якка чыгара. Хатын-кызлар башка якка юнәлделәр. Ә мин туп-туры урман ышыгына кереп киттем, салкынча-дымлы һава шундук үзен сиздерде. Картның сөйләвенә караганда, монда аю очрый икән, елгага якын ук килә, ди. Шулай да мин аны күрә алырмын дип бик өметләнмим, чөнки аю бит кеше күзенә күренеп йөрергә яратмый. Өстәвенә монда хәзер һава да дымлы, салкынча, нигә суга якын килсен ди ул.

Урман ешлыгына килеп керү белән кемнеңдер мине күзәтеп торуын сизеп алдым. Эчкәрәк үткән саен тойгы үзен ныграк сиздерә. Туктап тыңлап та торгалыйм, куләгәләргә күз йөртеп чыгам, ләкин бер шикләнерлек әйбер күрмим. Тайга көзге моңсулыкка чумган.

Тайга хуҗасын күрә алырмынмы, юкмы — билгесез. Бәлки, ул мине инде күзәтеп тә торадыр? Әлеге тойгы шул күзәтү нәтиҗәсе түгел микән? Бу уйдан аркалар чымырдап китә. Шулай да тайга хуҗасы белән очрашудан баш тартырга уйламыйм.

Күрен син миңа. Мин бит монда изге ният белән килдем. Һәм шул ният белән китеп тә барачакмын. Күрен. Минем сине бик тә күрәсем килә. Тере килеш. Кыргый килеш. Горур килеш. Күрен син, ул мизгелне мин гомергә истә калдырачакмын. Синең биләмәләреңдә мин бер генә җәнлеккә дә тимәм, бер генә агачны да сындырмам — кисмәм. Ниятем изге. Синең тере икәнеңә, бу яшел дөньяның хуҗасы булуыңа ышанып китәсем килә. Күрен син, күренеп ал. Теге чакта, егерме ел элек, минем янга нәрсәдер әйтергә килгәнсеңдер кебек тоям. Һәм бу «нәрсәдер» бик кадерле, күңел түреннән чыккан булгандыр, чөнки син бит, урманнан ачык җиргә чыгып, тормышыңны куркыныч астына куйгансың — якында гына авыл, яр буе тулы халык... Ул чакта нәрсә әйткәнеңне инде хәтерләмим, хәтта ул очрашу турында да кеше сөйләве буенча гына беләм. Чык син урман ешлыгыннан, әйт миңа сүзләреңне. Сөйли белмисеңме? Алайса күзләремә генә карарсың. Мин барысын да аңлармын.

Менә, сискәндереп, табан астында ботак шартлап сынды, тән буенча ток үткәндәй булды. Мин, хәлем китеп, җиргә утырырга мәҗбүр булдым, күзләремне йомдым. Кайдадыр баш өстендә тукран тукылдады, аңа каршы канәгатьсез тавыш белән күкшә кычкырды. Кичәге яңгырдан соң ылыс юеш иде.

Утырган җиремнән башны күтәреп карасам, кинәт агачлар арасында аю күрдем. Әллә тоелды гынамы? Барып тикшерсәң ничек булыр икән? Тагын карыйм. Һәм шул вакыт миннән утыз метр арада зур кара аю басып торганны күрәм. Кымшанмый, миңа төбәлеп карый. Тораташ кебек каткан. Шул мизгелдә миңгерәгән миемдә уй туа — аю түгел ич бу. Юк, аю түгел. Ләкин күзне алмыйм, атлый бирәм һәм ярты юлны үткәч кенә «аю»ның бик карт бер агач төбе икәнен төшенәм. Я алла, болай бит акылдан язуың да бар...

Үземне кулга алып, бераз тынычлангач, янә хәйран калам. Дөньяда мондый юан тагын берәр нарат бар микән? Вакыт тукыманы ничек тузанга әверелдерсә, бу төп тә череп тәмам тузан өеменә әйләнгән. Бу мәһабәт наратның гөрселдәп авуына байтак заманнар үткәндер, күрәсең. Бәлки дистә еллар шулай чери-чери күперенгән-бүртенгәндер. Дистә еллар? Әйе, бу бит теге нарат булырга тиеш, биеклеге белән бөтен тирә-юньне ямьләндереп утырган гигант нарат. Семеченок карт нәкъ аның турында сөйләгән болай булгач.

Төп әйләнәсендәге җирне аяк белән капшыйм. Һәм шунда аягым батып китә. Кабере шушы урында ахрысы наратның. Явыз адәм кулыннан һә-

лак булган нарат шушында ауган, җиргә үк батып кергән, вакыт аны күмеп тә киткән...

Урманда мин байтак йөрдем. Сазлыкка да барып чыктым. Анда хатын-кызлар мүк җиләге җыя иде, тавышларын ишетеп, кире борылдым. Кайтканда, турыдан кистереп, көймә калган җирдән шактый ерактa елга ярына чыктым. Бу төштә урман белән елга арасында калкулык бар икән. Шунда күтәрелеп беравык әйләнә-тирәне күзәтеп тордым, елга аръягында авыл, кая карама зәңгәрсу-яшел тайга җәелеп ята. Елга өстендә болыт күренә. Бераз карап торгач, көймәгә таба юнәлдем. Күп тә үтмәде, урманнан тырыс, кәрзин күтәргән хатыннар килеп чыкты. Болын ягыннан безгә таба кечкенә нокта якынлаша, бу Семеченок карт иде. Минә туган җирем белән аерылышу сәгатьләре дә якынлаша.

Көймәгә җитәрәк туктап картны көтеп алдым.

— Курыкмадыңмы соң?— дип сорады ул.

— Ә кемнән куркырга?— дип гаҗәпләндем мин.

— Ничек кемнән? Аюдан, әлбәттә, кемнән булсын!

— Мин бит аны күрмәдем. Тавышлардан куркып ул эчкәрәк кергәндер, күрәсең.

— Син аны бөтенләй күрмәдеңмени? Ул бит синең арттан ук урманнан чыкты. Калкулыкка менде!.. Тукта, син кая?..

Бар көчкә йөгердем, тын кысыла. Калкулыгы да ерак калган икән. Йөгереп аның өстенә үк мендем һәм... эзләр! Аю эзләре! Менә алар — урман хуҗасының эзләре. Ярылып ята. Кайберәүләре минем эзгә үк туры килә. Димәк, син мине күргәнсең! Артымнан йөргәнсең! Нигә соң яныма килмәдең, сүзеңне әйтмәдең. Куркырмын дип уйладыңмы? Әйе, анысы да бар. Курыккан булыр идем. Әңгәмә барыбер барып чыкмас иде. Бу мине кызгануың инде алайса. Рәхмәт. Мин чыннан да бик нык курыккан булыр идем. Бая төптән курыккан кебек...

Һәм кабат череп тузанга әйләнгән агач төбе күз алдыма килеп басты. Кайчандыр ул да яшьнәп утырган бит. Һәм тамырлары янында үз каберен тапкан. Бәлки, шулай булырга тиештер дә? Бәлки, һәркем шулай тамыр җәйгән җирендә гомерен дә төгәлләргә тиештер. Бәлки син — бөек урман хуҗасы — миңа шул хакта әйтергә теләгәнсеңдер?

Җәмит Рәхимов

# ЕРАКТАГЫ БИЛӘМӘЛӘР

Нефтьчеләр турында язганда «ерактагы» сүзе байтак еллардан бирле кулланылып килде. Баштарак Лениногорскидан яки Әлмәттән утыз-кырык чакрымдагы хәлләр хакында да, «ерактагы промыселда» дип, авыз тутырып сөйли идек. Бераздан бораулаучылар һәм нефть чыгаручылар Азнакай якларында эшли башладылар, аннан Чирмешән, Зәй тирәләренә барып чыктылар. Аннары тынгысыз нефтьчеләребез Кама буена барып төпләнделәр, Алабуга тирәләрен айкап йөри башладылар. Ул тарафлардан тагы да гаҗәбрәк хәбәрләр ишетелә иде. Кырыгар метрлы корыч манараларны баржаларга утыртып, аларны Кама буйлап күчереп йөртәләр, имеш. Бу очракта «ерактагы» сүзе чын-чынлап ераклыкны аңлата сыман тоелды. Әмма болар бар да баласы гына булып чыкты, мичтә калган икән анасы. Берзаман безнең Татарстан нефтьчеләре Оренбург далаларына, Удмуртия урманнарына оча башламасыннармы!

Ниһаять, нефтьчеләребез Төмән якларындагы чыганаклар белән җенләнә башладылар. Җыйнаулап-бригадалап та шунда эшкә китәргә тотындылар. Хәтердә: Зәй-Каратаеннан Урайга тулы бер урам булып күчеп утыручылар да табылды. Көнбатыш Себер промыселлары инде чын-чынлап ерак-та, хәтта Татарстанда яшәүче журналистларның буе җитәрлек түгел кебек иде. Әмма барыбер хәйләсен таптык — анда да барып чыктык. Тик ни гаҗәп, Себердән язган репортаж-очеркларыбызда «ерактагы» сүзен кулланырга батырчылыгыбыз җитмәде. Нигә дисәң, Төмән җире инде күңелләрдә йөрүче ераклык төшенчәсенә генә сыймый иде. Андагы гигант эшләр колачы, сөйләп, кеше ышанмаслык хәлләр, нефтьчеләрнең каһарманлыгы, фидакарьлеге — бөтенләй башка. Төмән дидек, чоңгыллы баткакларын сурәтләдек, тайга чытырманлыкларын, киңлекләрен искә алдык, әмма «ерак» сүзе телдән төшә барды.

Унберенче бишьеллыкның соңгы елы якынлашып килгән көннәрдә әнә шул онытыла башлаган сүз янә калкып чыкты. Арадан кайсыбыздыр: «Татарстан нефтьчеләренең ерактагы биләмәләре»,— дип ычкындырды. Һәм моңа ябыша калдык. Моның инде нигезе бар иде. КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы партиянең Татарстан һәм Башкортстан өлкә комитетларының Төмән өлкәсендә нефть чыгару куәтләрен үстерүдә ярдәм күрсәтү турындагы инициативасын хуплады. Менә шуннан соң инде «ерактагы» сүзе яңа мәгънә алды кебек. Ул хәзер «үзебезнеке» дигәнне дә аңлата шикелле.

* * *

Шәм кебек төз, мәһабәт гәүдәле, дулкынланып торган кара чәчле, мөлаем бу кешене күптән беләм. Аны нефть промыселларында да, җыелыш-киңәшмәләрнең трибунасыннан да, өендә пианинода уйнаганда да, баянда халык көйләрен сыздырганда да күргәнем бар. Мин аның тыйнак кына авыл укытучысы чагын, аннары оператор булып скважинадан-скважинага йөргән вакытларын хәтерлим. Инде менә ничә еллар ул республикабыздагы иң эре предприятие — «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры.

Әкълим Касыйм улы Мөхәммәтҗанов кайда гына эшләмәсен, кемнәр белән генә очрашмасын һәрчак үзе булып кала торган иде: төпле, эшлекле, энергияле, сабыр, басынкы. Югары культуралы булуы, эрудициясе сөйләвендә яисә гамәлендә генә түгел, йөзенә үк чыккан. Һәрхәлдә, аның дуамалланганын күргәнем юк иде. Бүген исә аның җаны ярсулы ачыну белән тулган. Болай ачыргаланырга бөтенләй урын юк сыман иде лә. Ул җитәкли торган «Татнефть» берләшмәсе коллективы, һәрвакыттагыча, еллык социалистик йөкләмәләрен дә арттырып үтәде, планнан тыш меңнәрчә тонна «кара алтын» бирде. Шуңа да бүген, яңа елның беренче көннәрендә, Әлмәтнең Культура сараена чакырылган партия-хуҗалык активы җыелышына килүчеләр алкыш-тантанага әзерләнгәннәр иде. Генераль директор исә, трибунада икәнен дә онытып, сәхнә алдына чыгып баскан да, гаять рәнҗетелгән кеше сыман өзгәләнә:

— Ун ел эшләгәннәр бит! Дистә ел буе нефть һәм газ чыгару идарәсе исемен йөрткәннәр! — дип гаҗәпләнеп кабатлый. — Ә бүген — кышкы челләдә сыңар машина кертеп куярлык гараж кисәге, кешеләр җылынып чыгарлык куыш та юк!..

Сүз соңгы елларда шактый кыен хәлгә калган Төмән нефтьчеләре, дөресрәге, Көнбатыш Себердәге нефть һәм газ чыгару идарәләренең берсе — «Урьевнефть» хакында бара иде. Моннан биш-ун еллар элек Обь буе промыселларында йөргән көннәр хәтердә яңарды. Соңгы вакытларда шул яклардан килгән аяныч хәбәрләр кабат ишетелгәндәй булды...

...Төмән өлкәсе! Себер җире! Бу очсыз-кырыйсыз иркенлекләр, тайга чытырманлыклары һәм шушы якның нык ихтыярлы кешеләре турында тәфсилләп яза башласаң, олау-олау кәгазь кирәгер иде. Төмән — илебезнең иң зур өлкәсе. Шуның өстенә, ул гаять бай да. Аның мәйданында меңнәрчә олы һәм кече елгалар ага, йөз меңнәрчә күлләр җәелгән. Җире ифрат юмарт. Анда арыш, бодай, тары, карабодай, солы, арпа, борчак, вика, җитен, кукуруз, көнбагыш, шикәр чөгендере, фасоль, кәбестә, помидор, кыяр, суган һәм башка күп кенә культуралар үстереп була. Җир эшкәртү инде Котып сызыгын үтеп, төньякка барып җиткән.

Хәзер өлкәдә дүрт меңнән артык предприятие эшли. Конвейерлардан автомашиналар, тракторлар, юл төзү машиналары, агач эшкәртү станоклары, аккумуляторлар, трактор һәм автомобильләр өчен электр җиһазлары, елга теплоходлары, рефрижераторлар, баржалар, агач ташу өчен үзбушаткыч машиналар,механик пресслар, электр моторлары кебек бик кирәкле әйберләр чыга.

Төмән өлкәсенең урманнары Балтик диңгезе кадәр мәйдан били. Шул карурманнарда агач әзерлиләр, аны эшкәртү промышленносте киңәя бара.

Төмән җире — затлы балыклар цехы. Илебез эчендәге төче суларда тотыла торган балыкның егерме проценты шушы өлкәгә туры килә. Монда шим, мәрсин, нельма, муксун, щокура, сырка, ала балык, чөгә, чуртан, опты, шамбы, алабуга, шыртлака, чабак кебек илле биш төрдәге балыкларны тоталар.

Өлкәдә киек җәнлекләр күп. Төмән илебезгә ел саен 85—90 миллион сумлык тире-яры бирә. Ул тиреләр СССРда гына түгел, чит илләрдә дә бик югары бәяләнә.

Рус җиренә азатлык даулап башлап чаң сугучыларның берсе А. Н. Радищев 1791 елда үзенең Илим төрмәсеннән җибәргән хатында болай дип язган иде: «Нинди бай як бу Себер дигәнең, нинди куәтле як! Гасырлар үтәр, һәм ул үзләштерелгәч, аңа дөнья елъязмасында зур роль уйнау насыйп булыр». Әйе, Төмән җиренең байлыклары исәпсез. Соңгы чирек гасырда аның хәзинәләренә нефть һәм газ да өстәлде.

Шунысын да әйтергә кирәк, Төмән җиренең бетмәс-төкәнмәс хәзинәсен табигать гасырлар буе яшереп саклаган. Тобольск губернасы турында гомуми мәгълүматлар төзеп, 1871 елда башкалага болай дип язганнар: «Тобольск губернасының минераль байлыкларына килгәндә, губерна гаҗәеп ярлы... Хәтта Урал сыртының бу губернага кергән өлешендә дә файдалы казылмалар табылуга өмет юк. Тобольск губернасының минералларга ярлылыгы хакында шуннан чыгып та хөкем йөртергә мөмкин: Тобольск, Төмән, Ярково һәм өлешчә Туринск шәһәрләрен төзү өчен таш Пермь губернасыннан китерелә...»

Шул рәвешле, Себер җире, үз хәзинәләрен күрсәтә алмыйча, еллар буе сөрген урыны гына булып кала биргән. Һәм, ниһаять, аңа күңелле

тормыш бүләк итүчеләрне күрде ул. Килделәр алар. Кешеләрнең шат тавышы мәңгелек йокыдагы урман-сазлыкларны уятты. Гасырлар тынлыгын бозып моторлар гүләде. 1971—1975 елларга СССР халык хуҗалыгын үстерүнең бишьеллык планы буенча КПССның XXIV съезды карарларында болай диелә: «Тугызынчы бишьеллыкта Түбәндәге һәм Мангышлактагы зур яңа чыганакларда нефть чыгару киң җәелдереләчәк». Себердәге әлеге чыганакларны үзләштерүгә партиянең XXV һәм XXVI съездлары карарларында да зур әһәмият бирелде.

Хәзер бай «кара алтын» чыганаклары ачылган Обь буеның геологик картасында белгечләргә генә аңлашыла торган бик күп тамгалар бар. Себер җирендә тимер һәм марганец рудалары, ташкүмер, слюда һәм тау хрустале ятмалары, күмер запасы табылды. Шулай да төп байлык — нефть һәм газ.

Никадәр генә мул булмасын, нефть һәм газ ятмаларын табу әле эшнең башы гына. Мең мәшәкатьләр белән коелар тишү, аларны нефть җыю пунктлары белән тоташтыру да әле, эш тәгәлләнде, дигән сүз түгел. Хикмәт нефтьнең эшкәртү заводларына барып җитүендә, халык хуҗалыгына хезмәт итүендә. Менә шуңа да Төмән нефть ятмаларын үзләштерү өчен бөтен ил өмәгә күтәрелде. Монда килгән нефть осталарының күбесе безнең як егетләре, Зәй һәм Шушма буйларында Татарстан нефть мәктәбен узган азаматлар иде. Дистәләрчә милләт егетләре һәм кызлары кулга-кул тотынып дөньяда тиңе булмаган мәшәкатьле эшкә алындылар. Һәм әйтергә кирәк, кыска гына вакыт эчендә мондагы гигант ятмаларны үзләштерделәр, офыктан-офыкка сузылган, хәтта континентларны тоташтырган торба юллары салдылар, чайкалып-тирбәлеп торган сазлыкларда яңа калалар күтәрделәр. Аларның уңышлары бөтен дөньяга мәгълүм. Алай да... Бүген менә сүз нигездә әнә шул «алай да» турында бара да инде. 1983 елда Төмән нефтьчеләре бик җитди өзеклеккә юл куйдылар: регионның нефть тарихында беренче тапкыр «кара алтын» чыгару планы үтәлмәде. Ул елның җәе Көнбатыш Себердә гаять елак булды: көн тудымы, яңгыр килә дә коя. Чоңгыллы батkaклар аша салынган юллар өзелде. Хәлне вертолетлар һәм теләсә кайдан үтешле машиналар гына бераз җиңеләйтә иде. Ләкин алар гына җитешми. Башка техникага озын-озын салларга охшап калган юллар чыдамый. Шул көннәрдә нефть чыгару күзгә күренеп кимүгә таба китте.

Хәлнең башка сәбәпләре дә ачыклана башлады. «Главтюменьнефтегаз» җитәкчеләре бу аяныч хәлнең сәбәпләрен санарга тотындылар: алар — капиталь төзелештә һәм нефть мәйданнарын җиһазлауда артта калу, проектлаштырудагы ялгышлар, техника җитешмәү, җиһазларның камил булмавы һәм башкалар. Баксаң, әлеге хәл Төмән нефтьчеләренең беренче уңышсызлыгы гына түгел икән. 1982 ел планы да үтәлеп җитми калган иде бит. Ул чакта министрлык планга төзәтмә керткән иде. Тик шул чакта ук үткәндәге хаталардан тиешле нәтиҗә ясалмаган.

Төмәнлеләр баштa берни белән дә хисаплашып тормадылар, чөнки ул чакта тотылган чыгымнарның кайтарып бирү сәләте бик зур иде: кайсы гына скважинаны бораулама, фонтан ата. Шуңа да төп игътибар бораулауга бирелде.

Инде менә нефтьне җир куеныннан чыгару, өскә күтәрү өчен скважиналарны тиешенчә җиһазлау мәсьәләсе килеп басты. Төмән промыселчылары моңа әзер түгелләр иде, алар тантаналарга һәм алкышларга күнеккән булып чыктылар, гаепне читтән эзли башладылар. Обь буен үзләштерүнең яңа этапка керүен ныклап анализлау, киләчәккә карап программа төзү урынына, нефть предприятиеләре җитәкчеләре җиңел юлга — планнарны киметүгә өмет багладылар.

Планны киметеп кенә кыенлыктан котылырга теләү тагын да ямьсез нәтиҗәләргә китереп чыгарырга мөмкин. Узган бишьеллыкта монда торак йортлар, культура-көнкүреш биналары салу акрынайды. Бу да — җентекләп уйланмый торып планлаштыруның конкрет мисалы. Нефть планы башта исәпләгәнгә караганда сизелерлек арттырылды, ә көнкүреш мәсьәләсе планда шул килеш калды. Нәкъ менә шуның аркасында ашыгыч рәвештә ярдәмгә башкаларны чакырырга туры килде. Бүгенге көндә бирердә бораулау эшләренең 40 проценты «канатлы» бораулаучылар, ягъни вахта-экспедиция ысулы белән эшләүчеләр җилкәсенә төшә. Өстәвенә әле һаман да «канатлы» бораулаучылар санын арттыруга исәп тотыла. Сүз дә юк, башка өлкәләрдән самолетларда очып килеп эшләүчеләр төмәнлеләр алдында торган зур бурычларны хәл итүдә бик нык булышалар. Әмма бу ысул файдалымы, юкмы — анысы әлеге бәхәсле...

Әкълим Касыймович Мөхәммәтҗановны тыңлый-тыңлый, әнә шуларны да уйдан кичерәм.

Узган ел үзәк матбугатта басылып чыккан мәкаләләрдә — СССР халык контроле комитеты материалларында «канатлы» бораулаучылар мәсьәләсендә шактый каты әйтелде. Бу кешеләр, Төмән промыселларында үзләренә бүлеп бирелгән җиһазларга, механизмнарга, материалларга хуҗаларча карамыйлар, дип, тәнкыйть ителгәннәр иде анда. Төмән нефть промыселларындагы җитешсезлекләр хакында күп сөйләргә мөмкин. Ләкин, безнеңчә, аларның иң зурысы — күнлекче психологиясе, үзеңне хуҗа итеп тоймау. Менә шуңа да Татарстан белән Башкортстан яңа тәкъдим белән чыктылар да инде, Төмән җирендәге кайбер авыррак хәлдәге промыселларны үз карамакларына алырга булдылар.

Хәер, Татарстанның «кара алтын» осталары Төмән нефтенә беркайчан да битараф калмадылар. Татарстан белән Төмән өлкәсенең язмышларында уртаклык та бар. Икәве дә чагыштырмача тиз арада бик нык үскән промышленность үзәкләренә әверелделәр, һәр икесендә нефть промышленносте һич күрелмәгән темплар белән үсте, тиз арада илдә беренчелеккә чыктылар, ниһаять, үзара ярдәм, дуслыкка нигезләнгән социалистик ярыш аларны бик нык якынайтты, бертуганнар сыман итте. Менә шуңа да Обь буенда нефть табылу белән, андагы нефтьчеләргә башлап ярдәм кулы сузучылар Татарстан осталары булды. Шуннан инде бу дуслык ярдәме тукталмады. Татарстан Төмәнгә иң яхшы егетләрен һәм кызларын гына түгел, вышкалар төзү, бораулау һәм нефть чыгарудагы тәҗрибәсен, җиһазлар һәм технология яңалыкларын җиткереп торды. Соңгы елларда, Төмән җирендә кадрлар кытлыгы башлангач, башлап ярдәмгә ашыгучылар Татарстаннныкылар булды. Бөгелмәдә, Минзәләдә һәм башка кайбер төбәкләрдә «канатлы» нефтьчеләр барлыкка килде. Алар Обь буена барып, җир тишү, скважиналар ремонтлау кебек иң авыр эшләрдә ярдәм итә башладылар. Төмәндә катлаулы хәл килеп тугач, Татарстан промыселчылары, үзләренең «авызларыннан өзеп», Обь буена җир асты һәм капиталь ремонт бригадалары җибәрделәр. Әмма эшләр моның белән генә җайга салудан узган иде.

Менә шунда инде Татарстан нефтьчеләре, Башкортстан осталары белән бергәләп, яңа тәкъдим белән чыктылар. КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы хуплаган бу башлангычны гадәти ярдәм белән генә тиңләп булмый. Сүз Көнбатыш Себердәге иң артта калган нефть предприятиеләрен «Татнефть» берләшмәсе карамагына алу, аларның чын хуҗасы булу турында бара.

Татарстан нефтьчеләре «Нижневартовскнефтегаз» системасындагы «Покачевнефть» һәм «Урьевнефть» идарәләрен, бер бораулау идарәсен һәм дистәгә якын башка нефть предприятиеләрен «Татнефть» берләшмәсе карамагына кабул иттеләр, мондагы хуҗалыкларның хәлен җентекләп тикшерделәр, яшәүчеләрнең тормыш-көнкүреш шартлары белән таныштылар.

Нәкъ шул көннәрдә «Татнефть»тә яңа вазифа — генераль директорның Көнбатыш Себер буенча урынбасары вазифасы барлыкка килде. Бу эшкә энергияле белгеч Равил Кәлимуллович Ишкаев билгеләнде. Шушы гаять катлаулы, җаваплы эшкә Р. К. Ишкаев куелуы һич кенә дә очраклы хәл түгел иде. Ул Төмән промыселларын кемдер сөйләве буенча түгел, үзе «капшап» белә. Министрлык кушуы буенча Себер промыселларында берничә ай рәткә эшләрнең торышын өйрәнүче белгечләр арасында ул да бар иде. Бу юлы эшне ничек һәм нәрсәдән башларга икәне аңа яхшы мәгълүм.

Мондагы хәлләр исә шактый аяныч иде. Промыселларда һәр дүртенче скважина тик тора, яңа бораулаган нефть коелары озак вакытлар буенча эшкә кушылмый, идарә итү, хезмәтне оештыру системаларында да кимчелекләр җитәрлек. Кабул ителгән промыселлар сигез мең квадрат километрдагы баткак мәйданга җәелгәннәр. Безнең егетләргә әнә шул кырыс Себер шартларында, өйләреннән еракта эшләргә туры килә. Хәер, Татарстан нефтьчеләре, анда рәхәт булыр, дип хыялланмадылар, эшләрне тизрәк җайга салу турында уйландылар. Яңа елның беренче эш көнендә үк «Татнефть» берләшмәсендә махсус приказ чыкты. Әлеге документ Татарстан нефтьчеләренең күп меңле отрядын алдагы зур эшкә мобилизацияләү, уртак көч белән Көнбатыш Себер промыселларында нефть чыгаруны январь аенда ук билгеләнгән күләмгә җиткерүне тәэмин итү турында иде. Актив җыелышында Ә. К. Мөхәммәтҗановның кулыннан төшмәгән зәңгәр тышлы папка әнә шул тарихи приказ иде инде. Шул приказ нигезендә Себердәге

промыселларның һәркайсы «Татнефть» берләшмәсенең җиде идарәсенә беркетелде. Һәм бу саллы, аякларында нык тора торган идарәләр кыска вакыт эчендә Көнбатыш Себер промыселларында нефть чыгаруны җайга салырга тиешләр иде.

Приказ нибары ике биттән тора. Аның каравы, кушымтасы, ягъни оештыру-техник чаралар планы — тулы бер китап. Ул чараларда Көнбатыш Себер промыселларына ярдәмнең бөтен стратегиясе билгеләнгән. Монда бүген үк хәл ителергә тиешле оператив чаралар да, ел дәвамында һәм киләсе елларда башкарылырга тиешле перспектив эшләр дә бәйнә-бәйнә язылган, аларны үтәргә бурычлы предприятиеләр һәм җаваплы кешеләр күрсәтелгән.


Татарстан егетләре эшне Көнбатыш Себер промыселларында бүген үк уңай йогынты ясардай оператив чараларны тормышка ашырудан башладылар. Беренче көннәрдә үк Обь буена җир асты ремонты бригадалары һәм башка осталар җибәрелде. Күп кенә машиналар кырыс Себер шартларында эшләү өчен яраклаштырылды һәм ерактагы Лангапес поселогына озатылды. Январь аенда ук Татарстанның биш йөзләп нефтьчесе эшли иде инде монда. Егетләрнең сүзләре эштән аерылмады — Татарстанга беркетелгән промыселларда нефть чыгару тәүлегенә өч мең тоннага артты.

Болар әле оператив чараларның башы гына. Көн үткән саен, алар киңәя, саллырак төс ала бара. Әйтик, скважиналар төзү эшендәге кимчелекләр бетерелә. Инде бүген үк Бөгелмә бораулау эшләре идарәсе Урьевск нефть чыганагында яңа скважиналарны промыселчыларга шунда ук файдаланырлык итеп тапшыра башладылар. Татарстан белгечләре катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру эшенә дә кыю алындылар, нефть чыганакларын эксплуатацияләүнең цикл ысулына күчә башладылар. Бу исә, Татарстан тәҗрибәсеннән күренгәнчә, җир асты амбарларының гомерен озайта, кыйммәтле чималны күбрәк алуны тәэмин итә.

Баштагы оперáтив ярдәм чаралары ук «Покачевнефть» һәм «Урьевнефть» идарәләренең кыен хәлдән тиз арада чыгачакларына ышаныч тудырды. Яңа көчләр килүнең беренче айларында ук дистәләрчә скважиналар ремонтланды, тик торучылары эшкә кушылды, яңа нефть коелары кыйммәтле чимал бирә башлады, күп кенә скважиналар оптималь режимга күчерелде. Ә алда — «Покачевнефть» һәм «Урьевнефть» идарәләре промыселларында йөзләрчә чакрым нефть һәм газ үткәргечләр, су һәм нефть кудыру станцияләре, югары вольтлы электр линияләре, юллар һәм башка объектлар салу. 1985—86 елларда гына да мондагы нефтьчеләр яши торган Лангапес поселогында өч йөз кешегә исәпләнгән клуб, кунакханә, урта мәктәп, пекарня, аптека, кибет, зур мунча, больница, санаторий-профилакторий, балалар бакчасы һәм, әлбәттә, торак йортлар салыначак. Кыскасы, боегып калган промыселларга чын хуҗалар килде.

Татарстан нефтьчеләре әле беркайчан да әйткәннәрен үтәмичә калганнары юк. Төмән өлкәсендәге бурычларын да башкарып чыгарлар, дип ышанырга була.

# УРАЛЬСКИДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ



Чаган елгасының Уралга кушылган урыны. Биредә Тукай ял итәргә яраткан, шушында ул Крылов мәсәлләрен дә тәрҗемә иткән.

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

**Шерали Турдыев,**

филология фәннәре кандидаты.

# ТУКАЙ ҺӘМ ҮЗБӘК ӘДӘБИЯТЫ

Бөек Октябрь революциясенә кадәрге чорда Урта Азия һәм киң Казахстан җирлегендә китаплары иң күп таралган, иң күп укылган шәхесләрнең берсе, әлбәттә, Габдулла Тукай булды. Аның заман сулышын тоеп халыкчан рухта язылган, рус һәм Көнчыгыш классик әдәбиятының уңай тәэсирендә шытым алган үзенчәлекле әсәрләре яңарак кына мәгърифәт юлына баскан бу төбәктәге яшь көчләрнең йөрәк тибешенә бик тәңгәл килде, тетрәндереп җибәрде. Хәмзә Хәкимзадә, Садретдин Айни, Мөхәммәтшәриф Суфизадә, Мөхәммәт Сералин кебек төрле милләт, төрле әдәбият вәкилләре Тукай иҗатының халыкчан рухын да, интернациональ юнәлешле булуын да шундук тоеп алдылар, үз иттеләр. Г. Тукайның ирекккә, хөрриятккә омтылган үз халкы күңелендәге уй-фикерләрне тапкыр әдәби сурәтләр, үткер сүз аша оста чагылдыра алуы, бөтен иҗатын хезмәт ияләрен җәберләүче сорыкортларга каршы юнәлткәнлеге төркстанлы әдипләр һәм укучылар күңеленә дә бик хуш килде.

1908 елда ук инде без Габдулла Тукай әсәрләренең тәрҗемә вариантларын очрата башлыйбыз. Әйтик, Ташкентта чыккан «Төркстан вилаяте» газетасы шушы елда шагыйрьнең берничә шигырен үзбәк телендә бастыра. Алар Казанда татар телендә чыккан «Яшен» журналыннан күчереп алынды, диелә. Беренче тәрҗемәләр арасында ук без әдипнең үткен сатира белән дин әһелләрен камчылаучы «Ысулы кадимче», «Хатирәи Бакырган» шигырьләрен очратабыз.

Танылып килүче татар шагыйренең әсәрләрен тәрҗемә итеп чыгару белән беррәттән шул елларда ук аңа багышлап мәкаләләр, шигырьләр язу очракларын да күзәтеп була. Бу җәһәттән бигрәк тә үзбәк һәм казах язучыларының активлыгы күзгә ташлана. Мәсәлән, 1913 елда үзбәк Хаҗи Мөгыйнь «Һәр шагыйрьнең хөрмәтлесе», Мирмухсин исә 1914 елда «Язучы әфәнделәргә үтенеч» хезмәтләрен язып бастырды, шул ук көннәрдә казах Мөхәммәт Сералин «Тукай хакында» дип мәкалә язып чыкты.

Г. Тукай шигъриятеннән илһамланып, аңа охшатып һәм ияреп иҗат итүләр дә нәкъ шул заманда ук башланып китте. Без бу уңайдан Абдулла Әвланинең «Безнең өшкерүчеләр», Төләгән Хаҗимияровның «Гамәлдәге сүзләр», Солтанмәхмүт Торайгыровның «Туган халкыма», «Алданган казах кызына», А. Алиминең «Миллэтемә» кебек шигырьләрен атап үтә алабыз. Бу әсәрләрнең барысы да диярлек Беренче бөтендөнья сугышы башланыр алдыннан ике-өч ел дәвамында язылганнар.

Габдулла Тукайның үткен фикерле сатирик шигырьләре, искелек яклы руханиларны, карун байларны фаш итеп язылганлыктан, бу әсәрләр Урта Азия мохитына да бик туры килә иде. Һәм бу әсәрләр Төркстанның үз җирлегендәге кайбер алдынгы әдипләрнең иҗатына да бик авазадаш иделәр. Тукай иҗатына теләктәш Аваз, Хәмзә, Суфизадә, Әвлани һ. б. алдынгы фикер ияләре шигъриятендә тиздән аңа хас төсмерләр чагылыш таба.

Мисал өчен үзбәк сатирик шигыйре Төләгән Хаҗимияровның «Сәдаи Төркстан» («Төркстан авазы») газетасында, 1914 елның 26 апрель көнендә, ягъни, «Габдулла әфәнде Тукаев үлеменең елына атап» диелгән гомуми баш астында чыгарылган шигырь-элегиясенә тукталырга була. Әйе, егерме дүрт юллык бу шигырьне автор элегия дип атаган, әсәрнең һәр юлыннан авторның «бөек татар шагыйренә» булган мөнәсәбәтен сизеп торасың. Һәм иң мөһиме, шагыйрьнең исеме дә «Мәрхүм Габдулла әфәнде Тукаев шигыренә ияру» дип исемләнгән. Бу элегиядә олуг шагыйрьнең мохтаҗлыкта үткән авыр тормышы да чагылыш тапкан, үзбәк әдибенең аның юлын дәвам итәргә, ул кабызган утны сүндермәскә омтылуы да сурәтләнгән. Менә ул шигырьнең башлангыч юллары (юлга-юл тәрҗемә):

Әйтсәм әйтим, иртән вә кичен бар фикерем багышлы миллэтемә.
Ул сәламәт икән, мин тынычмын һәм савыкның да савыгы...
Мәрхүм Габдулла Тукай кеби яшьли дөнья куймасам.

Гаҗизанә, шагыйрең булмакка бардыр ниятем.
Инде ел тулды вафатына Тукайның дип бүген,
Багышлавым, шигыренә ияреп, искә алып ятимне.
Әй, күзем нуры, билем куәте, яну йөрәгем,
Тереклектә гел мактармын: миллатем вә миллиятем!..

Бу шигырь-элегия алдыннан газетада Т. Хаҗимияров Габдулла Тукайга олы ихтирамын белдергән сүз башын да урнаштыра. «Бер ел әүвәл генә бу дөньяны калдырып, без яшьләрне тирән кайгыга салып Габдулла Тукай әфәнде арабыздан китте. Ул татар әдәбиятының тансык былбылы иде. Үз нәүбәтемдә, минем дә аның иҗатына ихтирамым вә ихтыяҗым көчле иде. Шуларны истә тотып һәм мәрхүм шагыйрьнең кайбер шигырь өлгеләрен кулланып, аңа охшатып шушы элегияне яздым. Бу — минем тиңсез хәсрәтем чагылышыдыр, шул хисемне «Сәдаи Төркстан» аша белдерүемдер», ди шагыйрь.

Шагыйрь һәм публицист Мирмухсин Шермөхәммәтов үзенең шушы ук уңайдан язылган «Каләм әһелләре әфәнделәргә бер үтенеч» мәкаләсендә Габдулла Тукай әсәрләрен яратуын, аларга соклануын белдерә. («Төркстан вилаяте» газетасы, 1914, 14 сентябрь) «Андый бөек затлар, бигрәк ки әдип вә шагыйрьләр, заман күренешләрен вә мөнәсәбәтләрен аңлау һәм юнәлеш бирү өчен, шул югарылыктан торып үз халыкларын тәрбияләү өчен туалар. Әгәренки бер милләтнең арасыннан шагыйрь исемен йөртүче табылса, аның көчен, куәтен һәм зурлыгын үз халкына ничек хезмәт итүенә, бирелгәнлегенә карап бәһалиләрдер. Нәүбәтендә, халкы да андый әдибен һич онытмас, ихлас күңеленнән яратыр. Андый олуг шәхесләр вафатыннан соң да халкы күңеленнән һич китмидер — аңа атап тантаналар оештырыла, мирaслары даими рәвештә туплана, барлана тора. Габдулла Тукай язмышы моңа дәлил булырлык», дип язды М. Шермөхәммәтов.

Үзбәк дөньясында якты эз калдырган шагыйрь һәм драматург Хәмзә Хәкимзадә Ниязи иҗаты да Г. Тукайның бәрәкәтле йогынтысын кичерде. Хәмзә дә беренче шигырьләреннән үк тар фикерле муллалар һәм тәкъва түрәләрдән, саран байлардан көлеп язды. Аның әсәрләре бер яктан үзбәк классик әдәбияты һәм үзбәк халкының авыз иҗаты җирлегендә туса, икенчедән, аның иҗатында фәкать Г. Тукай шигырьләренә генә хас үзенчәлекләрне дә күрми мөмкин түгел. Әйтик, «Ишаннар хәле», «Бер ишан авызыннан», «Туендырды» шигырьләрендә үзбәк сатирик әдәбияты дәвамын да, бу әсәрләргә татар шагыйренең «Мулланың зары» исемле шигырь йогынтысын да ачык сиземләргә мөмкин. Ә инде Хәмзәнең «Рамазан» шигырен язарга Тукайның «Нәсыйхәт»е рухландыруын әйтеп торасы да юк. Бу ике шигырьдә дә халыкның аянычавыр хәле, матди ярлылыгы тасвир ителә, бай һәм түрәләрнең халык зарына колак салмаулары әйтелә. Шулай ук бу әсәрләрнең бер үк фикерне кабатлап — киләчәкнең үзгәрәчәгенә якты өмет баглап — тәгәлләнүләре дә очраклы түгел, әлбәттә.

Бу хакта күренекле үзбәк галиме, филология фәннәре докторы, профессор Ләзиз Каюмов «Тукай һәм үзбәк шигърияте» мәкаләсендә болай дип язган иде: «Тукай һәм Хәмзәнең поэтик мирасын чагыштырып өйрәнү шуны күрсәтә ки, Габдулла Тукай Хәмзә иҗатына үрнәк булган, остазы булган дия алабыз»[1].

Тукайның вафат булуы турындагы хәбәр тиз арада үзбәк халкына да барып ирешә. Интеллигенция вәкилләреннән яраткан шагыйрьләре белән хушлашу өчен аерым кешеләр җибәрелә. Ташкент, Сәмәрканд, Бохара, Хива һәм башка шәһәрләрдә бу уңайдан матәм кичәләре оештырыла. Чөнки үзбәк халкы инде Г. Тукай иҗатын тәмам үз итеп, яратып өлгергән иде. Алай гына да түгел, Тукайның кайбер шигырьләре мәктәп-мәдрәсә уку китапларына кертелгән иде. Шундый җыентыкларның беренчесе итеп, шөбһәсез, үзбәк халкының мәгърифәтчесе һәм шагыйре Абдулла Әвлани тарафыннан әзерләнгәнен күрсәтергә була. Анда Тукайның берничә шигыре, шул исәптән «Туган тел», Әвлани тарафыннан тәрҗемә итеп урнаштырылган. Ә, гомумән, үзбәк халкы, бигрәк тә интеллигенция вәкилләре Тукай шигырьләрен әдипнең үз телендә, тәрҗемәсез укыганнар. Профессор Ләзиз Каюмов билгеләп үткәнчә, бу чорда халык арасында бигрәк тә «Шүрәле», «Япон хикәяте», «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» һ. б. кайбер шигырьләре киң таралган булган.

Татар һәм үзбәк халыклары арасындагы әдәби бәйләнешләр, культура, әдәбият яңалыклары белән уртаклашу, үрнәк алышулар һәм шул исәптән бөек татар шагыйре Габдулла Тукай иҗатын барлау, өйрәнү эшләре Бөек

[1] Габдулла Тукай (Сборник статей). Казань, 1968, 61—62 бб.

Октябрь революциясеннән соң тагын да җанлана төште. Совет власте елларында күпмилләтле совет әдәбияты вәкилләре белән берлектә, татар язучыларының иҗаты белән кызыксыну да арта төште. Әмма, элеккечә, Урта Азия республикаларында аерата күп укылганы, өйрәнелгәне — Тукай мирасы булды. Яңа тормыш өчен барган көрәштә күтәрелеп чыккан яңа буын шагыйрь һәм әдипләре: казахлар Сәкен Сәйфуллин, Сабит Моканов, үзбәк Абдулла Кадыйри, Уйгыннар аның шигырьләре белән рухланып яшәделәр, үз халыкларының бөек шагыйрьләре Нәваи һәм Абай белән беррәттән алар Тукайны да үз остазлары дип атадылар.

Октябрь революциясеннән соңгы матбугатка күз төшерик. Менә Исмәгыйл Габидев мәкаләсе. Ул Төркстан халыклары арасында революциягә кадәр ихтирам казанган «Тәрәкъкый» («Прогресс») газетасының элеккеге редакторы, милләте буенча татар. 1920 елның 15 апрель санында ул Төркстан Коммунистлар партиясе органы булган «Иштиракиюн» («Коммунист») газетасында «Шәрык шагыйре Габдулла Тукай» исемле зур мәкалә бастыра. Яшь Совет властеның актив җәмәгать эшлеклесе һәм белгече бу мәкаләсендә шагыйрьне шәрыкнең киң танылган фикер ияләре белән бертиң куя. «Бөек шагыйрьләр әл-Мәгарри, Хафиз, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Нәваилар мирасы арасында Габдулла Тукай әдәби мирасы да кадер-хөрмәткә ия. Аның иҗаты төрки-татар халык массаларын Россиядәге революциягә хәзерләде», дип билгели Габидев.

Г. Тукай мирасын өйрәнү һәм барлауга багышланган андый мәкалә, хезмәтләр дә, Төркстан краеның төрле төбәкләрендә аңа багышлап тантана кичәләре уздырылуы хакындагы кыска-кыска хәбәрләр дә бу елларда байтак басылган. Мәсәлән, шул ук «Иштиракиюн» газетасында Лөтфинең «Тукай кичәсе мөнәсәбәте уңаеннан» исемле мәкаләсе урнаштырылган (29 апрель саны, 1920 ел). Менә «Төркстан» газетасының 1923 елгы 1 июнь сәхифәсе. Анда бер автор Фәтхи Бурнашның «Эшче» газетасында Тукайга багышланган мәкаләсендәге кайбер фикерләргә каршы төшә, бәхәсләшә.

Болар, билгеле, Г. Тукай әсәрләре белән кызыксынуны арттыра гына төшәләр. Аның шигырьләрен кичекмәстән башка телләргә күбрәк тәрҗемә итү ихтыяҗын тудыралар. Һәм үзбәк, казах, каракалпак һ. б. телләрдәге газета-журналлар, уку китаплары яңа тәрҗемәләр белән баетылалар.

Г. Тукай шигырьләре белән революция елларына кадәр үк танышып өлгергән, аннан үзенә үрнәк алган Хәмзә Хакимзадә егерменче елларда да бу юлдан тайпылмый. Ташкент һәм башка шәһәрләрдә оештырылган Тукай кичәләрендә катнаша. Бу хакта да көндәлек матбугатта хәбәрләр бар.

Шушы ук чорда, Урта Азия җирлегендә, Г. Тукайның русчага тәрҗемә ителгән аерым әсәрләре дә күренә башлый. Рус телендә аңа багышланган аерым мәкаләләр дә басыла. Әмма аеруча әһәмиятлесе шул, 1920 елда бирегә аның шигырьләренең русча аерым басмасы чыга. Бу «Сайланма әсәрләр» китабын Төркстан Халык Мәгариф Комиссариаты каршындагы нәшрият Габдулла Тукай вафатының җиде еллыгына багышлап чыгара. Аңа тупланган әсәрләрне татарчадан Валентин Вольпин тәрҗемә иткән, кереш сүзне И. Янбаев язган. Бу җыентыкка шагыйрьнең халык арасында киң таралган һәм темасы белән революцион үзгәреш чорына авваздаш яңгыраган «Кярханәдә», «Эш», «Шагыйрь», «Алтынга каршы», «Кыйтга» һ. б. шигырьләре тупланган. Китапның кереш өлешендә Г. Тукай иҗатына югары бәя бирелә, әсәрләренең гади, халыкчан телдә язылуы, халык күңеленә якын булуы әйтелә. Шунда ук Тукайның башка халык әдипләренең, мәсәлән, А. Пушкин, М. Лермонтов, М. Кольцов, И. Никитин, Шиллер, Гете һәм башка шагыйрьләрнең мирасыннан күңеленә хуш килгән шигырьләрен тәрҗемә итеп, төрки-татар дөньясына якынайту тәҗрибәсе дә уңай бәяләнә. Хәер, аларны тәрҗемә генә дип билгеләве дә кыен, Тукайга хас осталык белән мөстәкыйль яңа әсәр тудырылган, шагыйрь үзе аларны «фәлән автордан» дип билгеләмәсә, һич аерып та булмас иде, дип белдерә бу китапка кереш мәкаләсендә Ибнеәмин Янбаев. «Тукай иҗатының шифалы йогынтысы бер татар әдәбиятына гына түгел, барлык төрки телле әдәбиятларга да кагылды, төрки шигъриятен үстерде, аңа киләчәккә юл ачты» дип тәмамлый ул «Биографик очерк» дип исемләнгән кереш сүзен.

Г. Тукай мирасын өйрәнү, әсәрләрен башка телләргә тәрҗемә итеп чыгару утызынчы һәм кырыгынчы елларда тагын да җанлана төште. Бу чорда А. С. Пушкин, А. М. Горький, Г. Ибраһимов һәм Абай әсәрләре белән беррәттән газета һәм журналлар Габдулла Тукай шигырьләрен дә бик теләп бастыралар. Яңадан-яңа тәрҗемәләр туа, аның әсәрләре тупланган аерым басмалар дөнья күрә. Үзбәк әдәбиятында инде бу — Гафур Голәм, Хәмит Алимҗаннар актив

эшли башлаган чор, Тукай варислары — Муса Җәлилләр белән иңгә-иң тотынып халыклар дуслыгын тагын да ныгыту өчен остазлары башлангычын дәвам итүчеләр заманы. Бу буын вәкилләре Тукай шигъриятенә яңа сулыш өрделәр — тагын да камилләшә төшкән тәрҗемә үрнәкләре бирделәр һәм 1946 елда нигездә яңа тәрҗемәләрдән тупланган китап дөнья күрде.

«Габдулла Тукайның сайланма әсәрләре» — сугыштан соңгы беренче тыныч елда туган җыентык, үзбәк нәширләре һәм рәссамнары тарафыннан бик пөхтә итеп эшләнгән һәм бизәлгән. Бу китап шагыйрь тууына алтмыш еллыкка багышлап чыгарылган иде. Анда шагыйрь тормышын һәм иҗатын тулаем күзалларлык күләмле кереш тә бирелгән.

Ә инде тагын да тулыландырыла һәм яңартыла төшкән яңарак басма 1961 елда, хәзер Гафур Голәм исемен йөртүче матур әдәбият һәм сәнгать нәшриятында дөнья күрде. Ун мең тиражлы бу китапны Үзбәкстанның танылган шагыйре һәм прозаигы Әсгат Мохтар төзегән, баш сүзне Тукайның милләттәше, үзбәк әдибе Абдулла Уразаев язган. Ә шигырьләрне үзбәк халкының мөхтәрәм шагыйрьләре Гафур Голәм, Уйгын, Миртимер, Әсгат Мохтарлар тәрҗемә иткәннәр.

Хәзерге көндә, бөек татар шагыйре Габдулла Тукай тууга йөз ел тулу уңаеннан, китап сөючеләр аның тагын да тулыландырыла төшкән яңа шигырь тупланмасын кулларына алу алдында тора. Моңа инде эшлекле хәзерлек бара, бу эшкә Үзбәкстан Язучылар союзы идарәсе тарафыннан җаваплы кешеләр билгеләнгән. Тукай әсәрләренең яңа басмасын әзерләү Гафур Голәм исемендәге нәшриятка һәм аның бүлек мөдире шагыйрь Абдраззак Әбдрәшитовка йөкләнгән. Бу уңайдан шуны да искәреп үтик, А. Әбдрәшитов ике-өч ел әүвәл икенче бер танылган татар шагыйре — Муса Җәлил шигырьләренең яңа тәрҗемәләр тупланмасын да барлап чыгарган иде. Ул китап та үзбәк укучылары тарафыннан бик җылы кабул ителде.

Үзбәк халкының иң мөхтәрәм шагыйрьләреннән Гафур Голәм, Уйгын, Хәмит Алимҗан, Шәехзадә, Зөлфияләр үз иҗатларына Алишер Нәваи, А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтовлар белән беррәттән Габдулла Тукай әсәрләренең дә бик нык тәэсир итүен, илһам өстәвен кат-кат тәкрарлап әйтә һәм яза килделәр. Әйтик, 1966 елда, Казан шәһәрендә уздырылган тантаналы бәйрәм — Тукай тууына сиксән ел тулган көннәрдә академик шагыйребез, Ленин премиясе лауреаты Гафур Голәм болай дип белдергән иде. «Тукай ул татар халкының горурлыгы, әмма шуның белән бергә Тукай Россиядә яши торган күп кенә башка төрки халыклар арасында, аларның укымышлылары арасында киң танылган, иң элек яратып укыла торган зур әдип тә».

Хәер, моның шулай икәнлеген үзбәк, казах, кыргыз, каракалпак һ. б. халык әдипләренең һәм галимнәренең Габдулла Тукайга багышланган күп санлы хезмәтләреннән дә күрергә була. Менә ул хезмәтләрнең, шигырьләрнең кайберләре — Г. Голәм: «Габдулла Тукай — үз шагыйребез», С. Моканов: «Тукай турында сүз», С. Мәүләнов: «Тукай табуты янында», М. Сәгыйтов: «Габдулла Тукай һәм каракалпак әдәбияты», И. Йосыпов: «Тукайга» һ. б.

Үзбәкстанның халык шагыйре Уйгын болай дип язган иде: «Тукай мирасы белән үзбәк халкы күптәннән таныш инде. Без аның шигырьләрен бала чакта мәктәп-мәдрәсәләрдә укып, өйрәнеп үстек, аның «Туган теле» безнең дәреслеккә кертелгән иде. Шуның сәбәпле без аны һәрвакыт үз шагыйребез, үз остазыбыз дип таныдык». Аның сүзләрен куәтләгәндәй каракалпак халык шагыйре Ибраһим Йосыпов та: «Тукай иҗаты аша без егерменче гасыр башы татар әдәбиятының Урта Азия халыклары әдәбиятына булган бәрәкәтле йогынтысын тоябыз»,— дип язды.

Үзбәкстан Совет республикасында яшәп иҗат иткән бу ике олы әдипнең сүзләренә кушылып шуны әйтәсе килә: үзбәк халкы бөек Тукай иҗатын мәңге шулай хөрмәт итәр, данлар.

*Ташкент шәһәре*



*Татарстан — туган төбәгем*

**С. Р. Төхбәтуллин,**
КПССның Чүпрәле районы беренче секретаре

# БЕЗ — ЛЕНИН ЯКТАШЛАРЫ

Безнең район кешеләре даһи Ленин якташлары булулары белән горурланалар. Фронтовик-шагыйрь Шәрәф Мөдәррис, якташларының уртак фикерен белдереп, болай дип язган иде: «Безнең Чүпрәле районы элекке Сембер губернасына кергән. Бабайларның бөтен күргән-белгән шәһәрләре бары Сембер булган. Безнең яклар гасырлар буена Сембер рухы белән яшәп, текә ярлы чокырлар, менделе-төштеле ачык аланнар аркылы бу калага ат юлы салганнар.

...Юл тузаннарын сулый-сулый татар атлаган, Зөя күперендә аны рус куып җиткән, каршыга чуваш очраган, аларга мукшы сәлам биргән. Кем белә, бәлки нәкъ шул вакыт алар янынннан үзенең иптәш малайлары белән шаяра-шаяра Зөягә таба яланаяклы нәни Володя да чабып узгандыр.

1905 елгы революция өермәсе безнең авылга Сембер аркылы килеп керде. Шушы елны Каракитәдә ярлы игенчеләрнең революцион чыгышы була... Алмалы авылының рус, Шамкино авылының мукшы, Баеш авылының чуваш крестьяннары да аларга шактый ярдәм иткәннәр.

...Сембер аша безнең авылга Февраль революциясе давылы килеп җитте. Сембер аша безнең авыл күгенә Бөек Октябрь социалистик революциясенең нурлы кояшы балкып чыкты»...

Безнең төбәктә халык мәгарифе эшләрен оештыруда Сембер губернасының халык училищелары директоры Илья Николаевич Ульянов күп хезмәт куйган. И. Н. Ульянов авылларда ай ярым йөреп, утыздан артык мәктәпне тикшерә, конкрет, ярдәм күрсәтә.

Безнең район авыллары тарихи вакыйгаларга бай. 1773—1774 елларда узган Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесендә төрле милләт кешеләре арасында безнең район крестьяннары да катнашкан. Восстаниенең соңгы чорында, сугыш Иделнең уң ягына күчкәндә 50 дән артык крестьян отряды Пугачев гаскәрләренә кушылуны көтеп торганнар. Шул отрядларның берсе Кече Чынлы авылы кырында урнашкан булган. Бу турыда Гомәр Колмакай бабай язып калдырган язуда «Шул Пугачев чирүе (гаскәре) 25 майда килеп 26 июльдә киттеләр...»,— диелгән. Крестьян явы торган урынны халык хәзер дә «Пугачев кыры» дип атый.

1905—1907 еллардагы революцион көрәш дулкыны безнең якларга да килеп җитә. Кече Чынлы крестьяннары 1906 елның язында 850 дисәтинә күләмендәге бәхәсле җирнең 200 дисәтинәсен сөрергә чыгалар. Әлеге җирне алардан XVIII йөзнең ахырында Рус Чынлысы алпавыты Мотовилов алган булган. 6 апрельдә авылга атлы казаклардан торган җәзалау отряды килеп төшә һәм крестьяннарны рәхимсез җәберли.

Гасырлар буена ачлыкта һәм хәерчелектә яшәгән безнең як крестьяннары өчен дә 1917 елның Октябрендә азатлык кояшы балкый. Авылларда якты тормыш кору өчен бөтенхалык хәрәкәте башлана. 1918 елның октябрендә Городищега Петроград эшчеләреннән 91 кешедән торган азык-төлек отряды килә. Отряд җитәкчесе Максим Николаев инициативасы белән 1919 елның декабрендә Городище авылында коммунистик ячейка оеша.

Беренче коммунистлар җитәкчелегендә волостьларда Совет власте ныгытыла башлый. Городище волостенда, мәсәлән, Совет власте 1917 елның ноябрендә үк урнаштырыла. 1918 елның январенда волостьта съезд үтә. Съезд Буа өязенең эшче һәм солдат депутатларының I съездына унөч

делегат сайлый. Буада съезд ун көн буе бара һәм өязнең барлык авылларында Совет власте урнаштырырга, дигән карар кабул итә.

1930 елның августында волостьлар, өязләр бетерелә һәм районнар оештырыла. Шушы елның августында беренче тапкыр партиянең район конференциясе үткәрелә. Райкомның беренче секретаре итеп Петр Андреевич Державин сайлана.

1930 елның 30 августында Советларның беренче Чүпрәле район съезды ачыла. Съездда ашлык әзерләү, колхозлашу мәсьәләләре карала. Анда райбашкарма комитеты председателе итеп моңа кадәр Городище волисполкомы председателе булып эшләгән, 1918 елдан коммунист Насыйбулла Төхфәтуллович Мулеевны сайлыйлар.

Район авылларының кайберләрендә 1921 елда ук авыл хуҗалыгы кооперативлары оеша. Алар беренчеләрдән булып Городище, Татар Бизнәсе, Иске Чәке, Кече Чынлы авылларында барлыкка килә. 1929—1930 елларда район авылларында күмәк хуҗалыкларга берләшү массовый төстә башлана. 1932 елда Чокалы МТСы төзелә. Алты айлык курсларда тракторчы кадрлар әзерләнә. 1933 елның июнь аенда МТСка 15 трактор кайта һәм алар колхозларда эшли башлыйлар. Колхозларда алдынгы игенчеләр барлыкка килә. 1932 елда республикада унбер кешегә Социалистик төзелеш Герое исеме бирелә. Шулар арасында безнең Шланга авылындагы «Кызыл юл» колхозы члены Гафур Вахитов та бар.

Күмәк хуҗалыкларга МТСлардан килгән тракторлар эшли башлагач, игенче хезмәте сизелерлек дәрәҗәдә җиңеләя. Билгеле булганча, Татарстан АССР 1935 елда тракторлар белән эшләүнең дәүләт заданиесен үтәү буенча Советлар Союзында беренче урынны яулады. Трактор бригадаларының һәм тракторчыларның героик эшен ил югары бәяләде. 1935 елның декабрь аенда иң яхшы эшләгән 15 кешегә Ленин ордены бирелде. Өч тракторчы безнең районнан: Матактан Мария Ромашкина, Яңа Чүпрәледән Закир Алимов, Иске Задурдан Шакир Зарипов.

Бөек Ватан сугышы башлангач, колхозлардагы машина, тракторлар шактый кимеде. Авыр эшләргә үгез, хәтта сыерларны җигә башладылар. Ләкин тылдагы колхозчылар, бигрәк тә хатын-кызлар, фидакарь хезмәт үрнәге күрсәттеләр. Трактор бригадалары арасында Чүпрәле МТСының Кыям Шәрәпов җитәкләгән механизаторлар коллективы алдынгылар сафында барды. Шуның өчен Кыям Шәрәпов СССР Верховный Советы Президиумының 1945 ел 10 декабрендәге указы буенча «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнде. Фронт өчен армый-талмый икмәк җитештерүче механизатор К. Шәрәпов 1943 елны танк алырга дип 35 мең сум акча бирә. Шул ук елны Калинин исемендәге колхоз председателе Тимофей Шадриков та 50 мең сум акча тапшыра.

Бөек Ватан сугышында безнең районнан биш кеше Советлар Союзы Герое исеменә лаек булды. Алар — Хорновар-Шигали авылыннан Петр Юхвитов, Яңа Кәкерледән Зариф Алимов, Матактан Семен Уганин, Зур Чынлыдан Михаил Хәкимов, Мунчәлидән Нурулла Фазлаев.

Сугыштан соңгы еллар авыл хуҗалыгы өчен шулай ук бик авыр булды. Әмма кыен шартларда да авыл хуҗалыгын күтәрүдә яхшы нәтиҗәләргә ирешүче, зур уңыш үстерүче осталарыбыз табылды. 1947 елда арыш һәм бодайның һәр гектарыннан 20 дән 30 центнерга кадәр уңыш җыеп алган өчен алдынгы колхозчыларга Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Бу югары исемгә безнең районның Чапаев исемендәге колхоз председателе Лазарь Дергунов та лаек булды.

Икенче Герой — колхоз председателе Әхмәтгәрәй Шакирҗанович Абдреев. Сугыштан кайтып, 1955 елда колхозны җитәкли башлап, бүгенге көндә дә председатель булып эшләүче Әхмәтгәрәй Абдреев XXII партсъезд исемендәге колхозны алдынгы хуҗалыклар сафына чыгарды. Әхмәтгәрәй Абдреев — колхоздагы күп эшләрнең инициаторы. Кырчылыкны югары культуралы итүдә, терлекчелек фермаларын бүгенге дәрәҗәгә күтәрүдә аның тырышлыгы зур. Иң мөһиме — ул үз эшләрен намус белән башкаручы тырыш һәм уңган кадрлар үстерде. Бүген колхоз Зоя Акимова, Лидия Павлова, Зәкия Басыйрова, Фәез Әхмәдуллин, Равия Дәүләтшина, Миргалифан Алиуллин кебек терлекчеләре, Нуретдин Азизов, Әнвәрша Вахитов, Рәис Рәхимов кебек механизаторлары белән хаклы рәвештә горурлана. Зоя Ивановна Акимова утыз елдан артык дуңгыз карый. Ул бик күп яшьләрне үз һөнәренә өйрәтте. Бу алдынгы терлекче Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы

орденнарына лаек булды. Ферма коллективын озак еллардан бирле җитәкләүче Миргалифан Алиуллин да Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.

XXII партсъезд исемендәге колхоз үз кешеләренең тормыш-көнкүрешен, экономик хәлен, культура ихтыяҗларын яхшырту буенча зур эш алыр бара. Моңа бу хуҗалыкның мөмкинлекләре дә зур. Бүген колхозның өч миллионнан артык акчасы бар. Иске Шәйморза авылы үсә, яхшыра. Матур бизәкле зур-зур тәрәзәле өйләр янына хәзер ел саен тагын да матуррак ташпулатлар өстәлә. Бу күркәм яңалыкларда да батыр председатель Әхмәтгәрәй Абдреев тырышлыгының өлеше зур.

Безнең якта андый тырышлар күп. Әйтик, Усман Алиев. Сугыштан кайткач «Ирек» колхозында тракторчы һәм бригадир булып эшләп, басуда елдан-ел зуррак уңыш алганы өчен, аңа 1973 елда Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде.

Тагын бер якташыбыз турында да әйтеп китәргә кирәк. Ул — озак еллар буе СССР Авиация промышленносте министры булып эшләгән Петр Васильевич Дементьев. Социалистик Хезмәт Герое исеме аңа ике мәртәбә бирелде.

Район халкы талантлы якташларыбыз белән хаклы рәвештә горурлана. Сәнгать осталары Асия Измайлова, Һидият Солтанов, Ринат Таҗетдинов, Габдулла Рәхимкулов, Рафаэль Ильясов, шагыйрьләр Шәрәф Мөдәррис, Зәки Нури һәм язучы Шамил Рәкыйпов та — безнең районнан. Революциягә кадәр үк күтәрелеп чыккан культура эшлеклесе Шиһап Әхмәров Тукайның якын киңәшчесе булган. Биология фәннәре докторы Рәкыйп Хөсәенов, Казан дәүләт консерваториясе профессоры Афзал Хәйретдинов, филология фәннәре кандидатлары Шәйхи Садретдинов, Нурмөхәммәт Хисамовлар фән, культура һәм сәнгатькә үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр.

Хәзер Чүпрәле районында 36 мең кеше яши. 19 авыл Советы иллеләп авылны берләштерә. Районда йөз мең гектарлап җир бар, шуның 80739 гектары сөрү җирләре. Басуларыбызның 72 проценты уңдырышлы кара туфраклы җирләр. Район хуҗалыкларында эрозиягә каршы көрәш алып барыла, агачлар утыртыла.

КПСС Үзәк Комитетының октябрь (1984) Пленумы карарлары нигезендә җирләрне мелиорацияләү безнең район шартларында терлек азыгы культуралары уңышын күтәрергә ярдәм итәчәк.

Шикәр чөгендере үстерүче осталарыбыз — районның тагын бер мактанычы. XXII партсъезд исемендәге колхозда аның һәр гектарыннан — 300 центнерлап уңыш алалар. Район дәүләткә шикәр чөгендере сату планын арттырып үти.

Терлекчелектә дә уңганнарыбыз байтак. Сыер савучылардан Зөбәйдә Алтынбаева, Рәхимә Юсупова, Әнисә Хәлиуллина, терлекчеләр Елизавета Моисеева, Белла Скворцова, Зәделбану Әхмәдуллина, механизаторлардан III һәм II дәрәҗә Хезмәт Даны ордены кавалерлары Мансур Субаев, Мөнир Шихморатов, Мөстәкыйм Низамов, Юрий Юркин һәм башка бик күпләр социалистик ярышның алгы сафында баралар. Райондагы специальләшкән хуҗалыклардан Калинин исемендәге колхозда — дуңгызчылык комплексы, Чапаев исемендәге колхозда нәселле таналар үстерү фермасы үзләренең куәтләрен арттыра баралар.

Колхозлар белән җитәкчелек итүче кадрлар да ныгый. Хезмәт юлын тракторчылыктан башлаган, инде 15 ел колхоз председателе булып эшләүче Алимҗан Әмирханов җитәкләгән «Ирек» колхозы елдан-ел югары күрсәткечләр бирә. Мансур Җамалетдинов, Фәүкать Зарипов, Рамил Хисмәтов, Әмир Айнуллов, Иршат Юсупов, Җәүдәт Гафуровлар җитәкләгән хуҗалыклар — үсеш юлында. Партиянең район оешмасы хәзерләгән перспективалы җитәкче кадрлар алар.

Безнең районда промышленность предприятиеләреннән Убидагы яшелчә киптерү заводын, Иске Кәкерледәге кирпеч заводын, төзү оешмаларын һәм тимер юл станциясен, элеваторны күрсәтергә мөмкин.

Районда елдан-ел яңа мәктәпләр, культура йортлары, медицина пунктлары, өйләр күпләп салына.

Халыкның көнкүреш шартлары яхшыра бара. Авыл кешеләре матур яшиләр, киләчәккә омтылышлары да якты.

Рэфис Измайлов

# КӨРӘШ ДӘВАМ ИТӘ

ВЬЕТНАМ БЛОКНОТЫННАН

Халыкта, «башын югары күтәреп», «карашын биеклеккә төбәп» кебек гыйбарәләр, нигездә, шатлык диңгезендә йөзүче кешегә карата кулланыла. Вьетнамлылар турында уйланганда шушы сүзләр искә төште дә үзалдыма: «Бу очрак өчен бик туры килеп бетми икән»,— дип куйдым. Вьетнам кичергән хәлләрне сурәтләүче фотографияләргә, кинокадрларга игътибар итик: югарыга төбәлгән карашларда — шом, нәфрәт, яшь. Чөнки өстә, зәңгәр күктә якты кояшны каплаган дошман самолетлары оча, алар үлем ташыйлар, ут чәчәләр. Шифалы яңгыр урынына агулы диоксин ява. Шул ук вакытта бу күзләрдә какшамас горурлык, җиңүгә ышаныч та чагыла кебек.

Вьетнам җире утыз еллап кан коюлы сугышлар кичерде. Башта японнар, французлар интектерде аны, аннары америкалылар ябырылды. Бу илгә соңгы тапкыр баруымда, Вьетнам Компартиясе Үзәк Комитеты секретаре иптәш Хоанг Тунг бу хакта:

— Империалистларның безгә каршы алып барган сугышлары гаять авыр булды,— диде. — Америка агрессорлары кулланган шартлаткычлар хуҗалык әйләнешендәге миллионлаган гектар җирне сафтан чыгарды...

Чыннан да. Әгәр саннарга мөрәҗәгать итсәң, хәйран калырлык: Вьетнам мәйданына Икенче бөтендөнья сугышында кулланылганга караганда ике тапкыр артыграк бомба ташланган. Илнең төньяк өлешендә бомбага тотылмаган бер генә шәһәр дә юк. Винь, Донгхой, Фули, Вьетчи, Тхайнгуен кебек шәһәрләрдән җимереклекләр генә калган. Бөтен күперләр, портлар шартлатылган. Көньяк Вьетнамда исә унбиш мең авылның яртысыннан артыгы юкка чыгарылган. Агулы диоксин яңгыры тәэсирендә урманнарның һәм басуларның 40 процентлабы харап ителгән. Бу агуга эләккән хатын-кызлар ана булу бәхетеннән мәхрүм.

Вьетнам җиренә тынычлык килгәнгә алты-җиде ел гына әле. Мин бу горур һәм кыю кешеләргә гаҗәпләнү катыш сокланып карыйм. Кыяфәтләрен элекке фотолардагы сурәтләр белән чагыштырам. Күпме күзәтсәм дә, шомланып куркынган карашлар очратмыйм. Тынычлар, сабырлар алар. Сулу алган саен күкнең аязлыгына, көннәрнең тынычлыгына чиксез шатлык кичерәләр. Бомбалардан качарга кирәкми хәзер, дошман самолетын аулыйсы да юк, траншеялар буйлап, бил бөгеп йөрүләр дә артта калган. Үз җирләренә нык басып, башларын югары тотып, матур киләчәккә омтылып яшиләр алар.

Дөрес, күпьеллык сугыш эзләре әллә каян сизелеп тора. Ул бомбалар хасил иткән чокырлар, кара көйгән урман-кырлар, завод-фабрикаларның җимереклекләре... Кешеләр җанына һәм тәненә салынган яралар тагын да тирәнрәк. Яныңнан велосипедта выжлап үтеп торучы шат күңелле яшьләр арасында я аягы, я кулы булмаган инвалид күренеп кала. Больницаларда диоксин яңгырына эләгеп агуланган кешеләр интегә.

Дистәләрчә елларга сузылган шәфкатьсез сугыш эзләрен бетерү өчен 6-7 ел тыныч тормыш азрак шул. Әлегә Вьетнам халкы шактый нәрсәләрнең җитенкерәмәвен тоеп яши... Өйләргә бирелә торган электр энергиясе дә, предприятие ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, өзелеп-өзелеп торгалый.

Ягулык та, транспорт чаралары да житеп бетми. Әмма тыныч тормышның рәхәтлеген берни белән дә тоныкландыру мөмкин түгел. Аның күңелләргә иңдергән сөенече урамдагы кешеләр йөзендә нур булып балкый. Сөйләшүчеләрнең шатлыклы авазлары да, төзелешләрдәге кран-машиналарның чыңлы гүләве дә, дөге кырларында эшләүче крестьяннарның житез хәрәкәте дә, уку йортларындагы эшлекле аңгәмәләр дә, тамаша залларындагы алкышлар яңгыравы да — барысы да шуңа дәлил.

Вьетнам әр-яңадан төзелә. Бу яңалык экономикада да, культура тормышында да сизелә. Үсеш темплары 1982 елда Вьетнам Коммунистлар партиясенең V съезды булганнан соң аеруча кызуланды. Бу съезд илнең өченче бишьеллык планын раслады. Вьетнам Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының Генеральный секретаре иптәш Ле Зуан әйткәнчә, вьетнамлыларга өч юнәлештә: производство мөнәсәбәтләрендә, фән һәм техника өлкәсендә, идеология һәм культура дөньясында көрәш алып барырга туры килә.

Инде шул тармакларга күз салыйк. Ханой үзәнлеген элек-электән су басып интектерә. Бу тирәдә урнашкан жиде провинция су белән көрәштән жәфа чигә. Әмма тиздән бу көч сынашуларга чик куелачак һәм анда, һичшиксез, кешеләр жиңүче булып калачак. Су ташкынына каршы торасы Хоабинь буасы вьетнамлыларның хәзерге бишьеллыгында иң мөһим төзелештән санала.

Да (Кара) елгасы буендагы бу буа — жирне су басудан коткару чарасы гына түгел. Анда сафка кертеләчәк электр станциясе ике миллион киловатт энергиягә чамалана. Бу көч Вьетнамның энергетика куәтен бермә-бер арттырачак һәм илнең Төньягын тоташтан электрлаштырырга мөмкинлек бирәчәк. Станция янындагы ясалма диңгез исә республиканың авыл хужалыгы өчен искиткеч табыш булачак. Өстәвенә, Кара һәм Кызыл елгалары тирәнәячәк һәм аннан илнең көнбатыштагы провинцияләрен көнчыгыштагы Хайфон порты белән өзлексез элемтәдә тотучы транспорт йөри башлаячак. Хоабинь илнең иң матур шәһәренә әйләнәчәк.

Бу гигант төзелештә вьетнамлы дусларыбызга безнең ил белгечләре зур ярдәм күрсәтәләр. Хоабиньда безнең белгечләр яши торган яңа микрорайон бар. Хәзергә аны «рус поселогы» дип йөртәләр. Төзелеш тәмамланып, белгечләр үз илебезгә кайткач, бөтен уңайлыклары: парклары, бассейннары, балалар бакчалары, спорт заллары булган бу поселок туристлар яши торган үзәккә әйләнәчәк.

Төзелеш мәйданында йөргәндә миңа барысы белән дә якыннан танышырга туры килде. Коллективның партоешма секретаре Чонг иптәш белән без төрле белгечләрнең биниһая катлаулы эшләрен күрдек. Берсендә Чонг миңа: «Без хәзер буа салыначак урында басып торабыз,— диде. — Шушы төштән алып елга аръягына кадәр сузылачак ул. Озынлыгы — 640, биеклеге — 128 метр. Братск ГЭСында да, ялгышмасам, буаның биеклеге шундый...»

Монда һәрнәрсәне безнең илдәге казанышларга, бездәге вакыйгаларга бәйләп сөйләргә яраталар.

— Бу станция кайчанрак энергия бирә башлар икән? — дигән идем, Чонг бик тиз:

— Бөек Октябрь революциясенең 70 еллыгына! — дип жавап кайтарды. — Безнең бишенче бишьеллыкның төгәлләнү чорында.

Гидрокомплекстагы төзелеш гөрләп тора. Машиналарда, краннарда кызлар бик күп эшли. Барысы да безнең белгечләрне мактыйлар.

— Аларның ничек тырышуын күргәч, без тагын да яхшырак эшләргә тотынабыз,— диләр.— Барысы да безнең өчен ясала бит, безгә начар эшләргә ояп.

Совет төзүчеләре вьетнамлыларга үзләрендәге бай тәжрибәне, оештыру һәм тәрбия эшләрендәге белемнәрен бирел калдырырга телиләр. Эштән соңгы сәгатьләрдә төрле түгәрәкләрдә, курсларда дәрес алып баралар. Соңгы ике-өч ел эчендә генә дә бу дәресләрдә Вьетнамның биш меңләп яшүсмере төрле һөнәргә өйрәнгән. Инде биредә техникум ачарга әзерләнеп торалар. Анда совет белгечләре белән бергә Вьетнамның үз инженерлары һәм эшчеләре дә укытачак...

Без Хоабиньнан киткәндә, яңгыр коярга тотынды. Бер төзүче:

— Бу әле башы гына,— диде. — Су ташкынын китерә торганнары мондый гына булмый.

Яңгырлар хәбәрчесенә жавап биргәндәй, төзелештә, буа булачак якта көчле шартлатулар башланды. Төзүчеләр гүя ташкынга каршы торачак комплексны тизрәк сафка кертергә ашыгалар иде.

* * *

Советлар Союзы Вьетнамның халык хуҗалыгы өчен бик әһәмиятле ике йөзгә якын объект коруда катнаша. Беренче чиратта энергетика объектлары төзелә. Аларның «Тхакба» ГЭСе, «Уонгби» ТЭЦе инде ток бирәләр. «Фанай» ТЭЦе белән «Хоабинь» энергетика гигантларында эшнең иң кызган чагы.

Вьетнам Коммунистлар партиясенең V съезды авыл хуҗалыгын үстерүне халыкка кирәкле товарларны күпләп җитештерүне дә кичекмәстән хәл ителергә тиешле мәсьәлә итеп билгеләде. Илдә бу мәсьәләне уңай чишәргә эшче көчләр дә җитәрлек, табигать шартлары да уңайлы. Вьетнамда хәзер 60 миллионлап кеше яши. Ә авыл хуҗалыгына яраклы шартлар шул — монда бөртеклеләрдән елына ике-өч тапкыр уңыш алырга була. Бөртеклеләр, дигәнем, беренче чиратта — дөге, әлбәттә. Дөге һәр вьетнамлы өчен изге ризык. Ярмасы гына түгел, аның саламы да кояш кызуыннан һәм яңгырдан саклый торган эшләпәләр, сумкалар, себеркеләр һәм тагын уннарча төр әйберләр ясарга ярый.

Шулай да бер дөге белән генә чикләнеп булмый. Хәзер күп кенә кооперативлар һәм әлегә сакланып калган аерым хуҗалыклар партия чакыруына кушылып, башка тармакларны да: терлекчелекне, яшелчәчелек һәм җиләк-җимеш үстерүне алга сөрәләр. Миңа Ханойдан ерак түгел «Бинь Минь» («Таң») кооперативында булырга туры килде. Бу күмәк хуҗалык моннан егерме еллар элек оешкан. Председатель Нгуен Зуан Хуа, коллектив тарихын искә алып:

— Без бары тик үзе теләгән кешеләрне генә кабул иттек,— дип,— сөйләп китте. — Кайберәүләр кооперативтан кире чыгарга уйладылар. Җибәрдек, чөнки иң ышанычлылар кала бирде. Алары илгә мөстәкыйльлек яулап, француз колонизаторларына каршы көрәшеп йөргән ир-егетләр иде. Күмәк көчнең ни икәнен тирәннән аңлаучылар. Хуҗалык нигездә шундыйларның тәвәккәллегенә һәм карусыз хезмәтенә таянып тернәкләнде. Беренче уңышларыбызны күргәч, авырлыклардан чигенүчеләр кире кайттылар. Хәзер бернинди көч тә аларны бездән кабат җибәрә алмый инде. Күмәк хуҗалыкның уңайлыгына ышандылар.

Председатель Нгуен Хуа үзе дә унбер ел буе ил азатлыгы өчен сугышкан. Кооперативта тагын алты йөз член шундый каһарманлык юлын узган. Хуҗалыкта барлыгы мең җиде йөз гаилә исәпләнә. Аларның — 437 гектар җирләре, төрле техникалары бар. Ягулык яки запас частьлар җитмәгәндә, машиналарны буйволлар һәм сыерлар алмаштыра.

Көчләрне бергә туплагач, крестьяннарның эше күзгә күренеп яхшырган.

— Аерым хуҗалыклар булып яшәгәндә без дөгене гектарыннан ике тонна чамасы ала идек,— ди председатель. — Хәзер сигез тоннадан да артык...

Бу үсешкә, иң беренче чиратта, җирдән интенсив файдаланып ирешелгән. Дөгене елга ике тапкыр чәчәләр. Арада башка культуралар да утыртып алалар. Бәрәңге, мәсәлән, нәкъ шул арада өлгерә. Минем әңгәмәдәшләрем:

— Без әле бу җирдән дүртенче уңышны да алабыз,— дигәч, мин ышанырга да, ышанмаска да белмәдем.

— Ничек, кай арада ?— дим.

— Анысы — үрдәк ите. — Крестьяннар көләләр.

Май аенда, дөгедән беренче уңышны җыеп алгач, болай да сулы җирдә, көчле яңгырлар чоры башланганга, күлләр хасил була икән. Шунда үрдәк үстереп өлгерәләр.

Материаль яктан ныгыгач, халыкның көнкүреше турында кайгыртуны да кооператив өлешчә үз өстенә алган. Монда хәзер ундүрт балалар бакчасы, ун ясле, урта мәктәп, клуб, китапханә бар. Балаларны бушлай ашаталар. Артыбрак калган керемнәрне бергә туплап, уртак кирпеч заводы булдырганнар. Хәзер бу завод, торак йортлар салыр өчен, елына ике миллионлап кирпеч һәм 400 мең чирәп чыгара. Ташпулат саласың килә икән — рәхим ит!

Кооператив членнарының эшчәнлегенә сокланып туймассың! Тик утыручы бер баланы гына да очрата алмыйсың монда. Авыл хуҗалыгы эшенә көче җитмәгәннәр (ә эшләрнең бераз кимегән чорында бөтенесе бер булып) кул эшенә ябыша: чигү чигәләр, эшләпә үрәләр, челтәр бәйлиләр. Кооперативта мондый осталарны дүрт мең чамасы диделәр. Алар ясаган әйберләрнең шактый өлешен хәтта чит илләр сатып ала.

Крестьяннарның үз карамагында да җирләр бар. Дөге игәләр, терлек азыгы әзерлиләр һәм... балык үрчетәләр. Һәр гаиләнең 20—25 квадрат метр чамасы мәйданда үз күле бар. Күлләрдә, президент Хо Ши Мин тәкъ-

дим итеп калдырганча, балык симертәләр! Бу шөгыль бөтен илгә таралган. Балыкчылык азык-төлек муллыгына ирешүдә шактый отышлы тармактан санала. «Бинь Минь» кооперативы гына да дәүләткә 10—15 тонна балык тапшыра.

Бу кооперативның эше бөтен илгә үрнәк итеп пропагандалана.

* * *

Без ТУ-134 самолетында Көньяк Вьетнамга очабыз. Ханойдан Хошимин шәһәренә — ике сәгатьлек юл. Ике сәгать... Тик аралар шулай якынайсын өчен, ил бер бөтен булсын өчен, Көньяк Вьетнамны сатлык җаннардан арындыру өчен күпме корбаннар бирелгән?!

Илнең бу өлеше 1975 елның язында гына, Азат итү Армиясенең һөҗүменнән соң, Сайгон шәһәре алынып, Америка ялчыларын кырып бетергәч кенә тулы азатлыкка иреште. Шунда гына Вьетнамның Төньяк һәм Көньяк өлешләре бер бөтен булып, уртак максат белән яши башладылар. Хошимин (элекке Сайгон) шәһәренең бетон аэродромында әле булса хәрби самолетлар тора. Алардан һич арынып бетәрлек түгел. Чөнки АКШ империалистлары бу төбәк өчен хәрби һава флотын шушында туплаганнар. Шуннан торып Кампучия, Лаос, Төньяк Вьетнам кебек илләргә үлем чәчеп ятарга ниятләгәннәр.

Сайгон режимын кичергән еллар Көньяк Вьетнамның экономик һәм рухи тормышына шактый яман эз салып өлгергәннәр. АКШтан агылып торган миллион-миллиардлар һич кенә дә милли экономиканы ныгытуга тотылмаган, аларны сайгон генераллары, буржуазия чиновниклары, америкаңнар белән бәйле предпринимательләр үзләштереп яткан. Илне Япония һәм Америка товарлары тутырган, Көньяк Вьетнамның үзендә вак кустарь промышленность кына калган. Күбрәк сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү тармаклары тамыр җәйгән. «Көнбатыш үрнәгендә» яшәүче сорыкорт җәмгыять туган.

Мондый тормыш кешеләрнең социаль аңын томалаган, рухын агулаган. Неоколонизаторлар Көньяк Вьетнамда өч миллион эшсез кеше, йөз меңнәрчә фахишәләр һәм наркоманнар, ун меңнәрчә гангстерлар һәм бандитлар, миллионнарча авырулар һәм наданлык калдырып киткәннәр. Кешелек кысасыннан чыгарылган бу җәмгыятьне тиз арада төзәтергә кирәк. Элекке кадрларны тәрбияләү, яшьләрне социализмга бирелгәнлек рухында саклап калу өчен көрәш башланган.

Яңа кеше өчен көрәш — социалистик революциянең иң мөһим бер баскычы. Ул экономикадагы авырлыклар аркасында тагын да катлаулана. Җитмәүчелек тә үзен шактый нык сиздерә әле, эш белән тәэмин итү дә канәгатьләнерлек түгел. Элекке белгечләрнең кайберләре саботаж ясыйлар. Кыскасы, коммунистларга һәм барлык намуслы кешеләргә чынлап торып көрәшергә туры килә. Ә читтәге дошманнар бу хәлләрдән оятсызларча файдаланып калырга ашыгалар. «Америка тавышы», «Би-би-си», «Ватикан тавышы» кебек унтугыз радиостанция көн саен вьетнамлылар телендә агу чәчә. Чит илләрдә вьетнамлылар телендә 70 газета чыгарыла. Аларны астыртын юллар белән Вьетнамга да кертәләр. Сәхифәләре — тоташ ялган, яман коткы...

«...Элек 60 донг акча түләп мотоцикл алырга мөмкин иде, хәзер мотоцикл 18 мең тора,— дип яза бер газета. — Бензин юк. Элек ул су урынына ага иде. Сез басуда транзисторлардан яңгыраган музыканы тыңлый-тыңлый эшләдегез. Инде батарейкалар юк, радиоалгычларыгыз өнсез калды. Бәс шулай икән, яңа тормышның нәрсәсе яхшы соң?..»

Мең-миллион афәтләрне, бинеһая көчле дошманнарны җиңеп чыгып, хәзер вакытлыча экономик кыенлык кичерүче ил турында шушындый пычрак пропаганда алып барудан да оятсызрак ни булырга мөмкин?! Аларның төп максаты кешеләрне мул яшәтү икән, ни өчен соң алар илнең авыр хәлдә калуының сәбәпләрен дә күрсәтмиләр? Радиоалгычлардан төрле көйләр яңгыраган вакытта ил өстенә үлем шаулэсе эленеп торганлыгын ник бер дә искә төшермиләр? Көньяк Вьетнамда ул елларда һәлак булган миллион ярым кеше турында да онытып җибәрәләр. Миллионнарча гектар җирнең һәм урманнарның агуланганлыгын ник белмәмешкә салышалар?

«Хо Ши Мин яшьләре коммунистик союзы» на кергән егет-кызларны котыртканда да идеология дошманнары үзләре Вьетнамда чакта аларны концентрацион лагерьларда ничек мыскыллаганнарын хәтердән чыгарып то-

ралар. Сайгонның үзендә генә дә 8 үзәк төрмә, 11 район төрмәсе, 144 квартал төрмәсе һәм 140 аулау пункты көйләп куелган иде.

Менә сиңа ул чактагы күңелле, мул тормыш! Сайгонда рәхәт яшәүчеләр бар иде, әлбәттә. Алары — Вьетнамның төп халкы түгел, американнар һәм аларның ялчылары иде. Ул зиннәтле сарайлар, ул гаҗәеп бакчалар — исең китәр! Һавасын сафландырырга кондиционерлары бар, теләсәң, Вашингтон, Нью-Йорк, Париж, Токио белән сөйләшә аласың — туп-туры телефон элемтәсе булдырылган.

Миңа Внугтау шәһәрендә тропик агачлар һәм 70 гыйбадәтханә ышыгына салынган искиткеч матур коттеджларны күрсәттеләр. Халыкны талап баеган миллионерлар, сайгон армиясе генераллары монда кәеф-сафа сөргән. 1975 елда үзләре үк хәрби вертолетлар өчен салган киң бетон юлдан аларны куып җибәргәннәр. Күңелсез булган агрессорларга, бик күңелсез булган! Аларга хәзер дә, Вьетнамның тормышы көннән-көн яхшыра бара, социализм идеяләре җиңә, дигән хәбәрләрне ишетеп тору рәхәт түгел.

Башта дошманнарга сатылган, аннары аларга ияреп, илләрен ташлап киткән качакларның хәле тагын да аянычрак. Шуңа күрә алар Көньяк Вьетнамга әле дә провокацион хәбәрләр ишеттерергә азапланалар: күчтәнәчләр җибәрәләр, газета-журналлар, открыткалар тараталар. Рәсемнәрендә — эшләмичә тук яшәүче фәхишләр. Янәсе, алар әнә ничек рәхәт гомер кичерә. Һәр сурәт читенә сайгончылар байрагын кыстырып куярга да онытмыйлар. Ул байрак сарылы-кызыллы. Посылкаларындагы балалар ыштаны да шундый тукымадан тегелгән.

Социалистик Вьетнам качкын сайгончыларны туган илләрендәге якыннары белән элемтәдә торудан мәхрүм итмәгән. Хатлар, посылкалар алышалар. Әмма теге яктан хуҗалары аларны һәр хатка «агу» салып җибәрергә мәҗбүр итә. Элемтә хезмәткәрләре кулыннан ай саен меңнәрчә посылкалар үтә. Магнитофон кассеталарын тикшерү аеруча катлаулы. Вьетнамда киң таралган патриотик җырларның көенә бик яман дошмани сүзләр җырлап яздыралар икән. Шуны Вьетнамга озаталар. Бу пычрак «күчтәнәчләр» Хошимин шәһәренә әллә ничә илдән килә. Кечкенә генә бер Вьетнамга ерак-е953 ерак-еректагы АКШ, Англия, Япония, Бельгия, ФРГ, Швеция, Австралия кебек илләр агу озатып утыралар.

Кара көчләргә каршы Көньяк Вьетнам халкы, коммунистлар нинди чаралар табып өлгерәләр соң? Иң әүвәл шуны әйтергә кирәк: илнең һәр кешесе бик сизгер булырга өйрәнгән. Икенчедән, вакытлыча кыенлыклар турында ачыктан-ачык аңлатып һәм илнең көн саен алга китешен, үсә баруын күрсәтеп, читтән кергән ялганнарны фаш итәләр. Идеология көрәшендә иң ышанычлы ысул булып халыкны аң-белемгә өйрәтү санала. Бу өлкәдә шактый зур уңышлар да бар инде. Көньяк Вьетнам азат ителеп, өч ел узуга, халыктагы наданлык бетерелде. Хәзер монда 14 миллион бала мәктәпкә йөри. Мәктәпләрнең һәм барлык башка уку йортларының программалары тамырдан үзгәртелде. Аларда яшьләрнең политик әзерлегенә аеруча зур игътибар бирелә.

Халык арасында культура-тәрбия эшләре дә яңа юнәлештән алып барыла. Клублар, культура сарайлары салына, анда эшләү өчен кадрлар әзерләнә. Газета-журналларга язылганнарны мөмкин кадәр күбрәк кешегә җиткерү, радиотапшыруларны сугышчан рухта алып бару, яшьләрне революцион рухта тәрбияләү, неоколониализм калдырган чирләрне фаш итү яңа социалистик яшәү рәвешен формалаштыруда төп чаралардан санала.

Көньяк Вьетнамда совет авторларының китаплары, күп кенә кинофильмнар популярлашкан. Миңа «Корыч ничек чыныкты?», «Чапаев», «Оптимистик трагедия» кебек фильмнарны бик яратып карауларын сөйләделәр. Чөнки вьетнамлылар бу әсәрләрдә үзләрен борчыган сорауларга җавап табалар.

Һәвәскәрләрнең чыгышы өчен ачык эстрадалар булдырылган. Халык андый кичәләргә бик теләп йөри. Балаларны бушлай кертәләр. Урын җитмәсә, кайберәүләр агач кәүсәсенә менеп кунаклый. Үзешчән артистларның репертуары бик бай: халык җырларын композиторлар яки үзләре үк язган әсәрләр алмаштыра. Лирик җырлар белән бергә үк политик җырлар да яңгырый. Русча башкарылган җырларны да тыңлаучылар алкышлап каршы алалар.

Ачык эстрада концертларын һәр район, өяз, завод-фабрикаларда атнага өч тапкыр күрсәтәләр. Кайчак һәвәскәрләр арасында профессиональ артистлар да чыгыш ясый. Тамашачыларның саны меңнән артып китә, чөнки клуб

дигәненең чиге юк, килгән һәр кеше сыя аңа. Сыймасаң койманың тышкы ягында торып булса да, җырчыларны ишетергә мөмкин ич! Концерттан соң кешеләрнең күңеле сафланып кала, һәрберсенең йөзе балкый.

Күңел сафлыгы димәктән, тагын бер коллектив эше истән чыкмый. Мине анда алып барганда, без хәзер «яңа кеше тәрбияләү училищесы»н карарбыз диделәр. Күргәч, аптырый калдым. Андагы хәлләр саташулы яман төш кебек хәтергә килә.

Училище директорының урынбасары Фан Нгуен Бинь:

— Менә бу егетне кичә генә, урамнан тотып, китерделәр,— дип аңлатты. — Наркоманиянең иң авыр стадиясе. Бүген беренче дәваны бирдек. Кризис кичерә. Атна буе шулай ятачак әле. Без, нигездә, халык медицинасы ысуллары һәм энә кадау белән дәвалыйбыз.

— Файдасы тиярме?— дип сорыйм. — Терелерме?

— Әлбәттә...

Училище 1975 елда ук оештырылган. Шул арада ун мең яшүсмер, дәваланып, яңа тормышка аяк баскан. Тәрбия эшендә А. Макаренконың юлдан язган ятим балаларны тәрбияләү алымнарыннан да киң файдаланалар икән. Наркоманиядән дәвалау — эшнең беренче баскычы гына. Училище әхлакый һәм физик яктан харап ителгән яшьләрне яңа тормышка яраклы кешеләр рәтенә бастыра, һөнәрле белгеч итеп чыгара. Аудиторияләрдә лекцияләр укыйлар, остаханәләрдә хезмәткә өйрәтәләр: балта эшенә, тегәргә, аяк киеме төзәтергә, уенчыклар ясарга.

Училищеның музее бик бай. Монда яшьләр кулы белән ясалган әйберләр куелган. Бер бүлектә авыруларның училищега килеп кергән чагындагы куркыныч кыяфәттә төшкән фотолары да бар. Алар янында пыяла тартма эчендә шушы коточкыч авыруның чыганаклары — чит илдәге «дус»лардан килгән наркотиклар, шприцлар, ампулалар. Аларны китапларның калын тышларына яшерен «оя» ясап та, зонтик саплары эченә тутырып та, кәкре башлы таяк буена салып та озатырга тырышалар. Вьетнамлылар бу «бүләк»ләрне «матур кәгазьгә төрелгән үлем» дип йөртәләр.

Вьетнамның кунакчыл, ачык йөзле, эшчән халкы хәзергә шактый җитди кыенлыклар кичерә. Шулай да ул һәрвакыт, хәтта бик авыр сугыш елларында да, матур киләчәккә ышанып яши. Бүгенге көннәрдә бу ышаныч ныгыганнан-ныгый бара. Вьетнам Коммунистлар партиясенең V съезды ачылыр алдыннан Ханойда халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе оештырылды. Хәзер ул баетылып тора. Анда илнең ышанычлы юлдан үсә баруы конкрет төстә раслап күрсәтелә. Һәр экспонат — халык көченең чиксез мөмкинлекләренә дәлил. Күргәзмәгә куелган әйберләрнең кайберләре әлегә бердәнбер нөсхәдә генә. Экскурсовод:

— Тиздән без аларны күпләп ясый башлаячакбыз,— дип әйтергә ашыга.

Вьетнамның бай тарихыннан хәбәрдар булсаң, бу сүзләргә ихластан ышанасың. Чөнки моңарчы бу ил үзенең һәр максатына ирешә килде. Алдагы бурычлар да, һичшиксез, тормышка ашырылыр.

*Ханой — Хоабинь — Хошимин — Мәскәү.*

# ҺАМАН ИСЕБЕЗДӘ...

## Хезмәт кешесе иде

Кантон шәһәре Алабугада 1921 елның көзендә татар педагогия техникумы ачылды. Авыр ел, ачлык булу сәбәпле, ул башта тулы көч белән эшли алмады, тик 1922 ел көзендә генә ике группа белән укулар башланды.

Техникумның җитәкчесе, укытучы кадрлары яхшы хәзерлекле, көчле кешеләр булды: Гобәй Усманов, Гыйният Адылов, Гобәй Балтанов — революцион көрәштә чыныккан, Совет властен урнаштыруда чиксез зур көч куйган коммунистлар иде. Ана телен укытучы Салих абзый Баязитов, математик Мирза абзый Алиев та бар. Болар һәммәсе дә Буби мәдрәсәсендә тәрбияләнгән, күпкырлы һәм тирән белем алган галим кешеләр.

Техникум элекке реальное училище йортына урнашкан. Уку-укыту корпусы мәһабәт, матур эшләнгән ике катлы бина. Аның сул ягыннан Совет власте өчен көрәшләрдә һәлак булган хисапсыз күп корбаннарны үзенә алган Тойма елгасы күренә. Каршы ягында чиксез матур болынлык. Уң ягында еракларга җәелеп тын гына ага торган Кама. Анда 1918 елны акчехлар кулыннан ерткычларча үтерелгән фидакарьләрнең гәүдәләре аккан... Укытучылар һәм студентлар урнашкан тагын өч корпусы, матур бакчасы белән, техникум үзенә бер кварталны биләп тора иде.

1925 ел. Җәйге ялдан кайтып әле яңа гына җыелышкан көннәр. Төп корпусның аскы катындагы ашханәдә туклану вакыты. Техникум директоры Гыйният абзый Адылов урта буйлы, кара костюм, ак күлмәк кигән, галстуктан, ачык йөзле, мөлаем карашлы, утыз-утыз бишләр тирәсендәге бер ир кеше белән килеп керде. Без дәррәү торып аякка бастык. Директор кул хәрәкәте белән утырырга кушты.

— Менә безнең коллективка яңа иптәш килде. Ул үзе Салагыш волосте, Баржы-Умгада туган, ләкин бик күп җирләрдә йөргән. Иж заводында, Самарада, Сембердә, Мәскәү һәм Казанда эшләп, менә безнең янга — Алабугага килгән. Таҗи абыегыз Гыйззәтов техникумда нигездә хуҗалык эшләрен алып барачак.

Гыйният абзый Таҗи Гыйззәтне электән үк яхшы белгән, таныш булган, ахры.

— Ул сезгә театрлар куярга, җырларга, биергә дә ярдәм итәр әле. Аның үзенең язган сәхнә әсәрләре дә бар. Вакытлы гына килгән кунак түгел, семьясы белән озак эшләргә килде,— дип директорыбыз Таҗи абыйга карап елмаеп куйды. Без дулкынланып алдык, йөзләребездә шатлык билгеләре балкый иде. Мин исә «якташым икән», дип уйладым.

Таҗи абый бик тиз арада комсомол һәм профсоюз җитәкчеләре белән бәйләнешкә кереп, яңа тәртипләр урнаштыра башлады. Егетләр һәм кызлар торакларына берәр җаваплы студент билгеләнде. Шунысы кызык булды — Таҗи абый инициативасы белән һәрбер кыз студент бер егет студентка шефлык итәргә, аның тегү-ямауларын, чиста-пөхтәлекләрен карарга, тәртипләрен күзәтергә тиеш булды. Кайбер кызлар үзләре теләгән егетләрне сайладылар, тартынып-уңайсызланып торучылар җирәбә алдылар.

Озак та үтмәде түгәрәк оештырып, «Сүнгән йолдызлар»га хәзерлек башланды. Минзәлә ягы приютыннан килгән Хөсәен Маликов, Буби приютыннан Якуб Әхмәтов кебек рояльдә яхшы уйнаучылар табылды. Төп корпусның икенче катында зур зал, яхшы эшләнгән сәхнә бар иде. Репети-

цияләрне Таҗи абый шунда үзе алып барды. Без аның күпчелек рольләрне хәтердән белүенә, җырга булган сәләтенә сокланып тордык.

Бу әсәрне сәхнәгә хәзерләгәндә Таҗи абый искиткеч зур көч куйды. Рольләрне башкарганда сәхнәдә яшьләрнең үз-үзләрен тотулары, бер-берсенә мөнәсәбәтләре, тавыш-интонация сайлау, сәхнәгә керү-чыгу манералары аеруча кыеннан бирелә иде. Яшьләрнең оялу, тартынулары да бар, аларны да җиңәргә кирәк. Укучылар өчен театр уены әле яңа, тәҗрибә юк. Шулай да Таҗи абый искиткеч сабырлык, түземлелек белән өйрәтте. Аны без бик яраттык, тиз ияләштек. Октябрь урталары булса кирәк — бер табак кәгазьгә төрле төстәге каләмнәр һәм оста кул белән язылган афиша төп корпусның ишегалды як стенасына эленеп куелды.

«Сүнгән йолдызлар»ның аягы җиңел булды, яшьләрдә театр куюга дәрте үскәннән үсте, яңадан-яңа сәләтләр калка башлады. М. Фәйзи, К. Тинчурин, Г. Камал һ. б. әсәрләре уйналды. Тора-бара театр уеннары яшьләрдә яңа сыйфатлар барлыкка китерде, кайберләренең мәхәббәт тарихлары да шушы вакыйгалар эчендә башланды.

Гыйният абзый Адылов өч баласы, хатыны Әминә апа белән кызлар корпусының икенче катында яши иде. Таҗи абый аларга гадәттә кичләрен кереп, киңәшеп ала торган булды. Кичләрнең берендә, мин Әминә апа янына кергән вакытта, Таҗи абый да килеп керде. Озак утырдылар. Шәхси тормышлары, театр, студентлар, сәхнә өчен әсәрләр табу һ. б. турында сөйләшкәндә укыту планнарына да кагылдылар. Таҗи абыйның бик акыллы фикерләре хәтеремдә уелып калган.

— Без башлангыч мәктәп укытучылары хәзерлибез, аларның күпчелеге авылларга китәчәкләр. Хәзерге шартларда авыл укытучыларына гаять катлаулы бурычлар йөкләнә. Әлегә бу студентларның күпчелеге дөрес, матур һәм культуралы итеп яза да белмиләр, сөйләү культурасы да бик зәгыйфь. Алар, элементар рәвештә булса да, җыр, музыка, театр сәнгате белән дә коралланган булырга тиешләр. Әгәр боларны укыту планнарына кертү мөмкин булмаса, җәмәгать тәртибендә булса да бераз төзәтергә булмасмы? — диде ул. Гыйният абзый алар турында педагогик советта сөйләшергә, киңәшергә кирәклеген әйтте.

Шушы сөйләшүдән соң техникумда хор һәм музыка түгәрәкләре оешты, студентлар арасыннан җитәкчеләр дә билгеләнде. Матур гына җырлаучылар, уйнаучылар да бар иде.

Таҗи абый техникумда гына эшләп калмый, шәһәр, кантон, хәтта өяз күләмендә дә бик тиз танылды. Ул атаклы революционер С. Н. Гассар җитәкчелегендәге Алабуга большевиклар партиясе оешмасында эшләгән карт коммунист Шакирҗан ага Альметьев һәм аның гаиләсе белән аралаша, гражданнар сугышы герое В. М. Азин отряды врачы Зәйнуллин белән дуслаша. Бондюг эшчеләре арасыннан күтәрелгән коммунист Шәфикъ Шакиров белән якыннан таныша. Алар революцион көрәшнең утын-суын кичкән, яңа социалистик җәмгыять төзүдә бөтен барлыгын биргән кешеләр иде. Таҗи абый менә шулар арасына килеп керә, шулар эчендә кайный.

Алабугага килүенә күп тә вакыт үтмәде, техникум эшләрен беркадәр тәртипкә салып, шәһәр кешеләрен һәм «Сүнгән йолдызлар»ны уйнаган өметле генә яшьләрне сынагач, Таҗи абый шәһәр театры турында уйлап йөри башлады. Әсәр табу проблема түгел. «Талир тәңкә» язылган, «Наемщик» хәтта Сембердә уйналып зур сынау үткән. Җитәкче оешмаларда «Наемщик»ны кую, гомумән, театр эшен башлап җибәрү мәсьәләсен уңай хәл итәләр. Өметле яшьләр җыелып әсәрне укыйлар, яраталар. Бик зур дәрт белән техникум сәхнәсендә репетицияләр башлана. Таҗи абыйга булышучы иң актив кешеләрнең берсе — Мәрьям апа Зәйнуллина, ул артистка да, киемсалым, сәхнә кирәк-яракларын табу, гомумән, оештыру эшләренә җиң сызганып керешә. Кәшфия, Җамал, Сәрвәр апалар Камай, Танай, Бирганга да барып, кайбер кирәк-яракларны табып кайталар. Ахырда, 1925 елның кышында, ап-ак карлар яуганда, шәһәр урамнарында бик матурлап язылган зур-зур афишалар күренә башлый. Хәтерем ялгышмаса, ул Таҗи абый бенефисына багышланган иде. Театр техникумнан пристаньга таба бер квартал ераклыкта булган таш йортта куелды. Яхшы урындыклар белән җиһазландырылган зур зал, сәхнәсе иркен, рояле дә яхшы, төзек. Укытучылардан Әминә һәм Лотфия апалар, Мәликә апа (Таҗи абыйның хатыны) үзе катнашты, калганнары техникум яшьләре иде. Таҗи абый Булат ролендә сәхнәгә чыгу белән халык гөрләп, хәрәкәтләнеп алды. Уен соңында

әсәрне, уйнаучыларны зур алкышлар белән каршыладылар. Таҗи абыйны исә аягүрә басып, озакка сузылган кул чабулар белән тәбрикләделәр.

Алабугада булган бу изге эш турында хәбәрләр якын-тирә авылларга, шәһәрләргә барып җитә. Таҗи абыйның үзенә, кантон мәгариф бүлегенә, канткомолга театрны чакырып язылган үтенеч кәгазьләре ага башлый.

1926 ел язында Таҗи абый, сәламәтлегенең шактый какшаган булуына карамастан, труппасын җыеп Бондюг, Чаллы якларына чыгып китә. Бондюг эшчеләре аларны зурлап каршылый, уңай шартлар тудыра, бик яхшы кунак итәләр. «Наемщик» постановкасы күтәренке рух белән бара. Зур тантана белән тәгалләнә. Аянычка каршы, күп кенә эшчеләр керә, күрә алмый кала, урын сыйдырмый. Менә шул хәлне истә тотып, театрны кимендә ике мәртәбә кабатлауны сорыйлар. Ләкин Чаллыда афишалар ябыштырылган була. Тагын килергә вәгъдә биреп, Чаллыга китеп баралар.

Шулай итеп, Таҗи абыйны Алабуга кантонында театр сәнгатенә нигез салучы, аның «Наемщик» драмасы сәхнә тарихын башлап җибәрүче, дип тә әйтергә кирәк.

1930 ел. Казан. Мин торган Шакирҗан абыйлар гаиләсенә ял көннәрнең берсендә Таҗи абый белән Мәликә апа килде. Кундылар, кичен бик озак утырдык...

Казанга килүеннән Таҗи абый бик риза, шат иде. «Наемщик»ны яңабаштан эшләвен, күп яңалыклар өстәп, халык көйләрен файдаланып музыкаль драма итеп язуын сөйләде. Әсәрен сорап, үзен кунакка чакырып унлап шәһәрдән килгән хатларны күрсәтте (Мәскәү, Троицк, Астрахань, Оренбург, Уфа һ. б.).

Ул көнне Шакирҗан абзый аңа яңа алган китапларын, энциклопедияләрен күрсәтте, аерым урыннарын укыды да. Аннары кинәт гәүдәсен турайтты да:

— Ярар, боларны син үзең дә укырсың. Ә менә хәзер мин сиңа китап итеп язылмаган, әмма минем йөрәгемдә зур җәрәхәт булып калган, үлә-нитә калсам югалачак бер генә күренеш турында сөйлим,— дип Алабугадагы гражданнар сугышы тарихына кайтты.

Без, бала һәм яшь чакларыбызда гражданнар сугышы вакытында акчехлар һәм Колчакның ерткычлыгын үз күзләребез белән күргән хатын-кызлар, аны кайнар күз яшьләре белән тыңладык, бик күп уйлар баштан кичте. Таҗи абый сүзсез-нисез бүлмә буйлап йөреп алды да, Шакирҗан абый янына килеп аны кукрәгенә кысты.

1934 ел. «Талир тәңкә»нең төзәтелгән варианты «Чаткылар» дөнья күрде. Аны Татар академия театры, шәһәрнең бөтен клублары диярлек, башка бик күп шәһәр театрлары куйды. Шушы шатлыклы көннәрдә көчле дулкынлану белән Таҗи абый безгә килеп керде. Йөзе ачык, шатлыгыннан үз-үзен көч-хәл белән тыеп тора. Мин әзрәк аптырап карап тордым да:

— Таҗи абый, тагын бер улыгыз тудымы әллә? — дидем.

— Туды, туды, Җамал! Менә ул, менә! — дип матур төпләнгән, калын гына бер китап күрсәтте. Мин:

— Шәп булган, Таҗи абый, нинди калын җыентыгыгыз чыккан бит. Мәгәричкә хәзер бер шешә Ижевский суы алып кайтам,— дигәч:

— Мә әле, тотып, ныклабрак кара! Син бик арзан бүләк белән котылмакчы буласың, зуррагы кирәк булмасын!! — дип, китапны минем кулыма үк тоттырды. Карасам — «ВКП(б) тарихының кыскача курсы». Иптәшем Мөхәммәт[1] белән без китапны кат-кат әйләндереп карыйбыз. Педагоглар бит без, эшебез өчен ул китап — маяк, шатландык шул без дә. Ә Таҗи абый безнең кулдан китапны кире алды да, битләрен ача-ача укып бара башлады. Вакыт-вакыт ул башын китаптан күтәрә дә:

— Ялгышмаганмын, Мөхәммәт, ялгышмаганмын бит! Тарихи дөрес юлда торганмын, әнә «Чаткылар»ны яңадан барып карагыз. Миңа тагын да киңрәк юл ачылды хәзер,— дип шатлыклы уйларын уртаклашты. Ул үзен һәрвакыт партия тәрбиясен алган кеше, авырлыкны җиңүдә көчле кеше итеп карый иде. Бу юлы да уй-фикерләренең рас килүенә ихлас куанды ул.

1936 еллар. Югары уку йортлары өчен татар совет әдәбияты программасына төзәтүләр, өстәүләр кертергә кирәк булды. Таҗи абый иҗаты моно-

[1] Мөхәммәт Гайнуллин (1903—1985) — танылган әдәбият галиме. (Ред.)

график тема рәвешендә моңа кадәр программага кертелмәгән иде. Аның тулы биографиясе һәм иҗат юлы турында басылган материаллар булмау сәбәпле, турыдан-туры үзенә мөрәҗәгать итәргә туры килде, язып бирүен үтендек. Бу яңалыкка аның нык шатлануы сизелде. Ләкин телдән юмартланмады, тыйнак кына ризалык бирде. Озакка сузмады, телефоннан шалтыратып, ул үзе безгә килде. Мөхәммәт тә өйдә вакыт. Китергән материалы машинкада бит ярым, җыйнак, бик тыйнак язылган. Тулырак булса, укыту өчен безгә дә җиңелрәк булыр иде дә бит, нишлисең, канәгатьсезлекне сиздермичә, рәхмәт кенә әйттек.

Шактый утырдык, ул безгә «Ташкыннар» өчен озак эзләнүе, күп укуы, зур көч куюы турында сөйләде. Мөхәммәт аңа:

— Таҗи абый, киң колач җәеп, шул кадәр бай материал белән зуп-зур бер роман язсагыз? — диде.

— Әй, Мөхәммәт, эш менә нәрсәдә бит: мин бит бик яшьтән бирле драма, сәхнә чире белән каты авырыйм! Үземне дәвалау өчен башка эшкә дә күчеп карадым, юк бит, котылып булмады, ул мине һаман үзе ягына тартты, чалбардан йолкып торды... Хәзер дә «Ташкыннар» гына мине бу «авырудан» коткармас, ахры...— дип җавап бирде. Мөхәммәт шактый тирән уйга калып торгач, һаман да бу әсәрне бүлгәләү кирәклеге турында фикер тудырды. Таҗи абый тиз һәм җиңел генә җавап бирергә ашыкмады, уйланды, нык кына борчылды да ахрысы.

— Ничек? «Ташкыннар»ны сүтәргә, берничә төенчек итеп яңадан язаргә? — дип үз-үзенә сораулар да куйды һәм аннары:

— Булмый, Мөхәммәт, булмый! Арыдым, тәмам арыдым! Бу «Ташкыннар» шул килеш калсын әле,— дип ул турыдагы сөйләшүгә нокта куйды.

Таҗи абый бер кеше турында сөйләмәс, бер нәрсә хакында зарланмас. Үз эшенә бирелгән, аны саф намус белән үтәп баручы затлы бер кеше икәнлеге ап-ачык иде. Ул тагын да якын, тагын да кадерле бер кешебез булып китте.

Татар совет әдәбияты программасын төзегәндә, аеруча укытканда шактый уңайсыз хәлдә калган чаклар булды. Чөнки драматургның әсәрләр исеме саналса да, басылганнары бик аз, хезмәт һәм иҗат юлы турында да кулъязма автобиографиясендәге кайбер күрсәтмәләрдән яки сәхнәдә уйнаган рольләрен күрүдән башка бер материал таба алмыйсың. Татар халкы яшәгән һәрбер почмакта, хәтта Мәскәүнең үзендә спектакльләре гөрләп барган, утыздан артык сәхнә әсәре язган, егерме ел артистлык хезмәте булган Таҗи абыйга карата, аерым рецензияләрдән башка әйбер күренми. Ниһаять, менә 1939 елда «Кызыл Татарстан» газетасының 15 февраль санында М. Гайнуллинның «Драматург Таҗи Гыйззәт» исемле мәкаләсе басылып чыга. Аңа карата бу беренче күләмле мәкалә. Анда Таҗи абыйның тулы гына биографиясе бар, иҗат эшчәнлегенә, драма әсәрләренә анализ бирелгән.

Иртәгесен кулына бер төргәк газета тотып Таҗи абый үзе безгә килеп кермәсенме! Иңнәренә канат куйганнармыни — шул кыяфәттә ашкынып килеп керде ул. Күзләрендә, йөзендә шатлык балкый.

— Карагыз әле, Мөхәммәт, күрдегезме, минем турыда нинди шәп мәкалә чыккан! Менә моның белән мин дөньяга фаш булам инде! — дип шаярып та куйды ул һәм Мөхәммәтне ныгытып-ныгытып кочаклады. Бик яратты Таҗи абый бу мәкаләне.

1944 ел. Таҗи абыйлар безне Островский урамындагы квартираларына кунакка чакырдылар. Язучылар союзы председателе Кави Нәҗми, аның хатыны Сәрвәр Әдһәмова да бар иде. Өстәл җыйнак булса да күңел күтәренке, чөнки фронтта эшләрнең безнең файдага борылган чаклары. Ләкин Таҗи абый бераз борчулы күренә. Сәбәбе — аның «Изге амәнәт» драмасын театр һәм язучылар коллективы кат-кат укыган, мактаган, шулай булуга да карамастан, сәхнәгә һаман куелмый икән, колактан колакка төрле сүзләр дә таратканнар. «Мин тормышны җентекләп өйрәнмичә, күрердәйләрен күзем белән күрмичә һәм аларны иҗтимагый-политик бизмәнгә салмыйча әсәр яза башламыйм. Үземне мин дөрес позициядә торам дип беләм һәм нык ышанам да. Шуңар күрә уйламый-белми әйтелгән фикерләр белән килешә алмыйм», — дип ачынып сөйләде Таҗи абый. Алгарак китеп әйтим — «Изге амәнәт» шул ук елны уйналды, аны халык яратып, алкышлап карады.

1946 елның 9нчы Мае — Җиңү көне истә калган. Без шушы тантаналы көнгә багышлап кунаклар чакырдык. Кырыклап кеше арасында Таҗи абый

белән Мәликә апа түрдә иң кадерле кунагыбыз. Таҗи абый Җиңү кенена багышлап шигырь язган, ул үзе укып бирде, көчле һәм матур язылган шигырь. Аяныч каршы, шигырь бездә калмаган, бәлки Таҗи абый архивында сакланадыр.

Таҗи абый хезмәт кешесе иде. Замандаш язучыларының күпчелеге кебек үк аңарга да институт бетерергә туры килмәде. Ул аны завод эшчеләре арасында, гражданнар сугышы чорында, көрәш эчендә узды. Совет власте тудырган шартларда студиядә укып, аеруча үз өстендә нык эшләп, үз вакытының политик яктан җитлеккән кешесе булып формалашты. Аның бу сыйфаты зур тарихи темаларны күтәреп, тарихилык һәм партиялелек рухында чишә алуында күренде.

Ул чын мәгънәсендә иҗат кешесе иде. Утыз елдан күбрәк иҗат гомерендә ул утыздан артык сәхнә әсәре, бик күп публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләре язды. Истәлекләренә караганда ул кайбер әсәрләрен 15 әр вариантта язган. Чын иҗади талантка ия булган кешеләрчә Таҗи абый һәр яңа әсәрен башкаларга укый; кимчелекләрне күрсәтүгә чырай сытмый, урынлы тәнкыйтькә колак сала белә иде. Аның өчен ялагайлык, ярарга тырышу бөтенләй чит иде. Ул иҗатында тынгысыз, эзләнүчән булса, гаилә тормышында, көнкүрештә гаять тыйнак, барына канәгать итеп, күтәренке рух белән яшәде.

Таҗи абый туган илен, халкын, аның культурасын ихлас күңелдән ярата иде. Ул чын мәгънәсендә интернационалист язучы булды, шуның өчен дә аның әсәрләрендә сурәтләнгән башка милләт образлары тулы канлы булып гәүдәләнде.

Әйе, ул олы җанлы, алдынгы совет язучыларына хас булган гүзәл сыйфатларга ия иде. Әнә шуңа күрә бүген тагын шуны да шатланып, басым ясап әйтәсебез килә: гаиләсе дә Таҗи абыйның васыятенә тугры булып калды. Олы улы Казбек бөтен көчен иҗат эшенә бирде. Атасы аның укып кеше булуын теләгән иде. Казбек үзенең тырыш иҗади хезмәте белән атасының теләгенаклады, философия фәннәре докторы булу дәрәҗәсенә үсте. Халкыбызны дуслык һәм интернационализм рухында тәрбияләүгә багышланган зур-зур китаплар авторы булды. Шул җаваплы эшләре булуына карамастан, ул тормыш иптәше Фирдәвес белән бергәләп Гыйззәтовлар гаиләсенең үзәгендә калды, хәзер ул гаилә 12 кешедән тора. Аерым квартираларда яшәсәләр дә алар еш бергә булалар, көнкүреш, эш итү планнарын, шатлыкларын бергә кичерәләр. Таҗи абыйның оныкларыннан: Казбекнең олы кызы инглиз телен укыту өчен кандидатлык диссертациясен яклады, кече кызы фәнни коммунизм буенча аспирантура үтә.

Күпләргә үрнәк булырлык бу гаиләнең эшчәнлеге һәм тормышы безне, аларның якын танышларын, әлбәттә, шатландыра. Алар Таҗи абыйның дәвамчылары бит.

**Җамал ВӘҖИЕВА.**

# Әти турында...

Безнең әти турында сүз барганда, иң элек аның бер сыйфатын телгә аласым килә: ул гаҗәеп дәрәҗәдә эшкә, иҗатка бирелгән кеше иде. Моның төп сәбәбе дә ачык: әти артист һәм драматург булып гаять авыр шартларда формалашкан. Әтиләрнең крестьян семьясы, җирдән мәхрүм ителүе аркасында, зур мохтаҗлыклар кичерә. Таҗи исә, семьяда иң олы бала буларак, тормышның бөтен авырлыкларын үз өстенә ала. Ул байга, муллага ялчы булып тора, көтү көтә, сука сукалый, печән чаба, сезонлы эшләрдә чиләнә — урман кисә, җир казый, таш вата, юл сала, йөкләр бушата. Аннан соң берничә ел Ижевск мылтык заводында эшли. Октябрь революциясеннән соң Таҗи Гыйззәт — Кызыл Армия сафында. Гражданнар сугышы алдыннан ул үзешчән сәнгатьтә катнаша, артист, соңрак драматург булып китә.

Сәнгать юлы аның каршына яңа авырлыклар, яңа проблемалар куя. Аннан зур интеллектуаль белем сорала. Күрәсең, шушы хакыйкатьне яшь егет Таҗи бик яхшы тоя һәм үзенең бөтен көчен, ихтыярын үзлегеннән белем алуга, укуга багышлый. Шулай итеп, әти тормышта һәм физик, һәм рухи, һәм гыйльми чыныгу ала.

Таҗи Гыйззәт үзенең өч дистә еллык иҗат гомерендә утыз дүрт драма әсәре язган. Димәк, ул ел саен кимендә бер әсәр иҗат иткән. Әле шунысын да

әйтергә кирәк: әти үз әсәрләренә һәрчак тәнкыйть күзлегеннән карый белгән. Инде язылып беткән, хәтта сәхнәдә куелып, матбугатта басылып, җәмәгатьчелек тарафыннан әйбәт каршы алынган, үзенә шөһрәт китергән әсәрләрен дә ул кат-кат редакцияләгән. Республика Үзәк Дәүләт музеенда аның кайбер пьесалары алтышар-җидешәр вариантта саклана.

Таҗи Гыйззәтнең сәләтенә, иҗади җитезлегенә тулы бәя бирү өчен тагын бер мөһим моментны искә алырга кирәк: ул драматург кына түгел, актер да иде бит. Илленче еллар башына хәтле ул Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының артисты иде һәм, озак еллар дәвамында, бигрәк тә 20—30 нчы елларда, бу аның төп һөнәре булды.

Таҗи Гыйззәт үзенең күпчелек әсәрләрен нәкъ Академия театрының спектакльләрендә актив уйнап килгән елларда язды.

Артистның көндәлек режимы бик үзенчәлекле төзелә. Иртән ул репетициягә барырга тиеш, кичен спектакльдә уйный. Ә спектакль алдыннан аңа әле үзлегеннән рольне өйрәнергә кирәк. Шулай итеп, хезмәт көне берничә «кисәккә» бүлгәләнеп, иртәдән төнге 12 ләргә хәтле дәвам итә (30 нчы елларда спектакльләр аеруча соң бетә иде). Әгәр инде артист җәмәгать эшләреннән дә мәхрүм ителмәгән икән (әти озак еллар буе театрның җирле комитет председателе булып тора), аңа нинди дә булса башка эш белән шөгыльләнергә вакыт бөтенләй калмый. Шунлыктан әти язу эшенә үзенең йокы сәгатьләрен сарыф итә иде. Спектакльдән соң, арган-талган килеш, ничек итеп үзен «төнге сменага» буйсындыра алгандыр — монысы инде аңа гына мәгълүм.

Нәкъ шулай — эше һаман күп булганга күрә, ул вакыт дигән нәрсәнең кадерен белергә өйрәнгәндер дә. Шунлыктан эш табалмый, вакытны юкка әрәм-шәрәм иткән өчен безне каты ачулана торган иде.

Әтинең максаты — тамашачыга, укучыга яңа сүз, сәнгатьчә яңа идеяләр җиткерү булды. Художникның эшчәнлеге бары тик аның башында оригиналь фикерләр булганда гына нәтиҗә бирергә мөмкин. Һәм ул фикерләр иҗат итүче шәхес өчен генә түгел, җәмгыять өчен дә бик әһәмиятле булырга тиеш. Ышанып әйтергә мөмкин — Таҗи Гыйззәт иҗтимагый яңгырашы көчле булган әсәрләр иҗат итте һәм зур иҗади мирас калдырды.

Таҗи Гыйззәт, язучы буларак, 20 нче елларның азагында, 30 нчы елларның беренче яртысында формалашты. Ул, татар драматургиясендә үзенә хәтле булган традицияләргә, бигрәк тә Г. Камал, Ш. Камал, М. Фәйзи, К. Тинчурин иҗатларына тирән ихтирам белән карый. Шуның белән беррәттән, ул татар драматургиясе һәм театры өлкәсендә булган кайбер тискәре тенденцияләрне дә күрми калмый, аларга каршы чыга һәм үзенең иҗатында социалистик реализм тудырган тенденцияләрне расларга тырыша.

Мәсәлән, кайбер пьесаларда революциягә кадәрге татар крестьяны тормышын уен-көлке рәвешендә генә сурәтләп килү, тормышның социаль коллизияләрен ачмый калдыру әтине борчый иде. Шунлыктан ул үзенең әсәрләрендә сюжетны социаль конфликтларга корырга тырыша. Бу яктан, «Наемщик», «Чаткылар», «Ташкыннар», «Бишбүләк», «Фәрхиназ» һ. б. әсәрләр җанлы мисал булып тора. Мәсәлән, «Чаткылар»ның нигезендә 1905—1907 нче еллардагы революциядән соң патша хөкүмәтенең авылда Столыпин җир политикасын үткәрүе һәм шуның нәтиҗәсендә туган сыйнфый бәрелешләр ята. Шуңа күрә геройларның үзара мөнәсәбәтләре дә, язмышларындагы хәлиткеч вакыйгалар да җәмгыятьтәге үзгәрешләр, олы вакыйгалар белән үрелеп бара.

Әтинең иҗат принциплары турында сүз барганда, мин аның эстетик критерийлары, идеаллары хакында да кайбер күзәтүләремне әйтми калдыра алмыйм. Аның әйдәп баручы персонажлары — гадәттә, алдынгы идеяле, халык мәнфәгате өчен көрәшүче кешеләр. Алар — көчле ихтыярлы, физик яктан куәтле, арыслан йөрәкле, «баш китәрлек» эшләр эшләп ташларга сәләтле кешеләр. Шундыйлардан: «Наемщик»та — Батырҗан, «Фәрхиназ»да — Каһарман (боларның исемнәре генә дә ни тора бит!), «Чаткылар»да — Рамай, «Мактаулы заман»да — Ногман һ. б.

Таҗи Гыйззәт ир кешенең шундый көчле характерга ия булганына соклана. Аның уңай геройлары яшь коймый, сыкранмый. Мәсәлән, «Ташкыннар»да Биктимер карт өстенә дөнья хәтле кайгы-хәсрәт килә. Ләкин автор Биктимерне сәхнәдә мескен рәвешендә күрергә теләми. Башкорт театры режиссеры Имашевка язган хатында ул, Биктимер ролен башкарганда аеруча сак булырга, образның героик пафосын югалтмаска, бу рольгә театрның иң көчле артистын куярга киңәш бирә.

Ә хатын-кызларда ул акыл, сабырлык, мөлаемлык сыйфатларын күрергә тели. Ләкин аның хатын-кыз персонажлары йомыкый түгелләр, алар — алдынгы принциплар өчен көрәшчеләр, кыю йөрәкле, тәвәккәл кешеләр. Гөлйөзем («Наемщик»), Маһи («Чаткылар»), Гөлчәһрә («Ташкыннар»), Фәрхиназ (шул исемле драма), Бибкәй («Кыю кызлар»), Гөләндәм («Чын мәхәббәт»), Халидә («Алсу таң») кебек хатын-кызлар үзләренең батырлыклары, тәвәккәл эшләре белән арысландай егетләрдән һич тә ким түгел.

Таҗи Гыйззәт, башка күп кенә язучылар кебек, теге яки бу персонажларны, образларны тасвирлаганда прототипларны тормышның үзеннән ала иде. Аның кайбер әсәрләрендә автобиографик мотивлар да чагыла. Мәсәлән, «Чаткылар»дагы Гаяз белән Маһи язмышларында язучының атасы Кәлимулла, анасы Фатиха тормышыннан алынган элементлар бар. Рамай образын ул атасының туган энесе Мөхәммәтҗан абыйсына охшатып иҗат иткән.

Мондый алымнар турында әйткәндә бер моментка мин киңрәк тукталыр идем. Ул «Таймасовлар» әсәренә бәйләнгән. Пьеса Ватанны саклау темасына иҗат ителгән (язылу вакыты 1940—1941 еллар). Әсәрнең сюжетын автор карт эшче Таһир Таймасов балаларының ак финнар белән барган сугышта кылган батырлыкларына кора. Пьесада төп акцент Таһир Таймасовның кече улы, 18 яшьлек Марат образына юнәлтелгән. Фин сугышы башланганда ул — унынчы класс укучысы, шоферлар курсын тәмамлаган яшь егет. Билгеле булганча, сугыш озак дәвам итми (1939 елның 30 ноябрендә башланып, 1940 елның мартында тәмамлана). Ләкин шушы кыска гына арада, фронтка доброволец булып киткән кичәге мәктәп укучысы Марат танк командиры дәрәҗәсенә үсеп, сугышта зур батырлыклар күрсәтеп, Советлар Союзы Герое булуга ирешә.

Әлбәттә, таләпчәнрәк тәнкыйть күзлегеннән караганда, геройның казанышлары гадәти «нормалардан» тизрәк темпта бара. Ләкин Бөек Ватан сугышы алдыннан халкыбызда булган тирән һәм олы патриотик хисләр, теләсә нинди дошманны бик тиз рәвештә генә кырып ташларга, сугышчыларыбызның дошман белән очрашуда һәр яктан да өстен булачагына ышаныч шул хәтле зур иде ки, укучы һәм тамашачы әсәрдәге җиңү пафосын һәм персонажларның шуннан чыккан бөтен ирешүләрен табигый, шөбһәсез кабул итә иде.

Әйтергә кирәк, 30 нчы еллар азагына эчтәлеге һәм формасы ягыннан камил әсәрләр иҗат итүдә зур уңышлар казанган драматург Т. Гыйззәт «Таймасовлар» пьесасының нигезенә шушындый «кызурак» темпта бара торган сюжет сайлаган икән, моның бер субъектив сәбәбе дә бар иде. Ул язучының олы улы Үзбәкнең кайбер биографик моментларына бәйләнгән.

1939 елның ноябрендә фин сугышы башлануын Үзбәк 16 яшьлек яшүсмер булып каршылый. Ул гаҗәеп дәрәҗәдә сәләтле, энергиясе ташып торган, тирән хисле, зур темпераментлы, аның уйлары, омтылышлары романтика белән сугарылган иде. Үзбәк үзенең 15—18 яшьләрендәге дус-ишләре арасында шөбһәсез авторитет һәм лидер булды. Ул — мәктәп үзешчән сәнгате өчен пьеса язып, аны үзе куеп, баш рольне (партизаннар отряды комиссары ролен) башкаручы. Ул — мәктәп газетасы редакторы буларак, газета өчен сатирик шигырьләр язып (каләмгә укучыларны гына түгел, кайбер ялкаурак, «рәтсезрәк» күренгән укытучыларны да эләктергәләп), шул шигырьләрдәге «персонажларга» дусларча шаржлар, карикатуралар ясап, мәктәп халкы арасында төрле резонанслар тудыручы. Ул — иптәш малайлары арасында кемнеңдер кызыграк хәлгә калуына нигезләнеп, эч катарлык көлке бәетләр чыгаручы. Ул — махсус китаплардан дары составын һәм аны ясау технологиясен өйрәнеп, шуны үзе әзерләүче һәм ишегалдындагы апайлар, әбиләрнең котын алырлык «бомбалар» шартлатучы. Ул — Н. Островский, Л. Войнич геройлары традицияләрендә тәрбияләнеп, мәктәптә («андый-мондый сугыш-фәлән чыга калса», дип) «Юнармия» оештырып, мәктәп җитәкчеләрен аптырашта калдыручы һ. б., һ. б.

Фин сугышы башлануын без, ул вакыттагы мәктәп яшендәге балалар, патриотик хисләр белән каршы алдык. Безнең укудан соң кичен урамда җыелыша торган гадәтебез бар иде. Бүгенгедәй хәтеремдә, 30 ноябрьнең киче бик матур иде. Кыш башланган инде, урамда йомшак кар явып тора, ә багана башындагы репродуктордан сугыш турында шомлы тапшыру ишетелеп тора. Безнең компания моны әсәрләнеп тыңлый. Финляндия чигендә хәрби провокация оештыручы Англия һәм Франция империалистларына карата йодрыклар йомарлана, кайнар нәфрәт сүзләре әйтелә. Гомумән,

ул кичне дөнья империалистларына бездән шактый «эләкте» дип саныйм. Ләкин безнең стихияле рәвештә башланган «митинг»ның кульминациясе дә бар икән әле: компаниябезнең лидеры Үзбәк безгә мондый шартларда «җылы өйдә утырып калалмаячагын», доброволец булып сугышка китәчәген әйтеп салды.

Үзбәк, ниятендә нык торып, республика военкомына кадәр барып җитә. Военком кулына гомерендә корал тотып карамаган 16 яшьлек малайны сугышка җибәрә алмый, әлбәттә. Шулай да «мондый чая егет армиябез өчен зарарлы булмас әле» дип уйлаган, күрәсең — Үзбәкне (кагыйдәдән чыгарма ясау рәвешендә) хәрби училищега урнаштырырга вәгъдә бирә. Үзбәк исә, теләгенә тулысынча ирешә алмаса да, командирлар әзерли торган училищега эләгүне үзе өчен казаныш дип саный.

Билгеле, Үзбәк фин сугышында катнашырга өлгерми. Ләкин бу сугышның безнең өчен җиңүле тәмамлануы ул вакытта бер кемне дә тынычландыралмады. Чөнки бөтен халыкара атмосферада тагын да дәһшәтлерәк сугыш исе аңкый иде.

Менә шушы шартларда әти үзенең «Таймасовлар» әсәрен иҗат итәргә керешә... Беренче пәрдә — Идел буенда карт эшче Таһир Таймасов дачасында бара. Моны сурәтләгәндә әти Түбән Осланда үзебез яшәгән дача обстановкасыннан чыгып эш иткән (сугышка кадәр Язучылар союзы литфонд катнашы белән һәр елны шушы авылда дачалар ала иде). «Таймасовлар»ның беренче пәрдәсенә әти түбәндәге сурәтләүне биргән: «Тамашачыларга карап зур дача балконы тора. Әйләнә-тирәдә алма, чия агачлары. Артта — бормаланып Идел ага. Аның аръягында — болын, урманнар. Урман өстеннән Казан шәһәре күренә...» Әйе, Куйбышев ГЭСы төзелгәнче Идел аръягыннан Казанга күренеш нәкъ шушындый иде. Ә менә Таһир Таймасовның кече улы Марат бөтен «кыланышлары», характеры белән язучының олы улы Үзбәкне хәтерләтә.

«Таймасовлар» 1941 елда Мәскәүдә булачак татар совет сәнгате декадасы өчен языла һәм әти аны шушы елның җәй башына өлгертә дә. Әмма фашистлар Германиясенең илебезгә басып керүе һәм вакыйгаларның Ватаныбыз өчен драматик рәвештә үсә баруы декада мәсьәләсен көн тәртибеннән алып ташлый. Сугыш башланганда Үзбәк Сызрань шәһәрендә танк училищесында укый иде әле. Июнь азагында әти белән әни мине һәм кечкенә энекәшем Рубинны алып — барыбыз да Сызрань шәһәренә Үзбәк абыйны күрергә киттек.

Хәтерлим, бу очрашуда абый, 17 яшьтә генә булуына карамастан, уефикере, үзен тотуы һәм башка сыйфатлары белән шактый үзгәргән, олыгайган иде инде. Әти дә улын үзенә тиң санагандай, аның белән аерым бер ихтирам, олылау һәм, әлбәттә, эчке соклану белән сүз алып барды. Төп тема, билгеле, сугыш, безнең чигенү... Ул вакытта сугышның шушындый фаҗигале һәм озакка сузылачагы башка сыймаса да, абыйның тиздән сугыш утына керәчәге эчке әрнү белән сиземләнә иде.

Әти «Таймасовлар»ны гомумән язып бетергән булса да, абыйдан танклар турында, аларның эчке төзелеше, танк экипажының составы, экипаж членнарының вазифалары һәм башка шушындый хәрби детальләр турында сораштырды, абыйга «Таймасовлар» да фронт обстановкасын гәүдәләндергән эпизодларны укып күрсәтте. Абый исә аның сорауларына җавап биреп, үзеннән киңәшләр әйтте.

«Таймасовлар» беренче тапкыр Академия театрында 1941 елның җәй азагында куелды. Сугыш башланганнан соң татар театры сәхнәсендә Ватанны саклау темасына куелган беренче спектакль иде ул. Марат роле тамашачыбызның яраткан артистларыннан берсе, зирәк, батыр егет рольләрен аеруча сөйкемле, оста башкаручы Ибраһим Гафуровка тапшырылган иде. Ул аны шулай егетләрчә уйнады да.

...Танк командиры лейтенант Үзбәк Гыйззәтов 1942 елның сентябрендә Калинин фронтында һәлак була. Бу көнгә аңа 19 да тулмаган иде әле. 18 августта язган кечкенә генә хатында ул: «Үзем исән-сау, бик кызу, һич хат язып булмый, язсаң да җибәреп булмый. Дошманның тылына кереп койрыгын йомарлап тоттык» дип сөендергән иде. 4 сентябрьдә ул үзенең соңгы хатын яза...

Үзбәк абыйның һәлак булуы турында частьтан рәсми хәбәр алу этине каты тетрәтте, әлбәттә. Инде хәзер, 40 елдан артык вакыт үткәннән соң, мин этинең шушы мәлдәге халәтен аңларга тырышам. Үлем хәбәрен алудан биш ел элегрәк Т. Гыйззәт үзенең «Ташкыннар»ында түбәндәге эпизодны сурәтләгән иде.

...Биктимер карт гаиләсендә фаҗига өстенә фаҗига. Әле генә кызлары Гөлчирәнең Мирзахан тарафыннан мәсхәрәләнүе мәгълүм булган иде. Ә хәзер менә уллары Мирхәйдәрнең сугышта үлгәнлеге турында язу китерәләр... Биктимер бүлмәдә үзе генә кала. Идәндә яткан кайгы кәгазен кулына алып, яшенә тыгыла-тыгыла: «Балам Мирхәйдәр, мин сине шушы бер кәгазь кисәге өчен карап үстердеммени?» — дип әрни, сыкрана...

Мин этинең эчке халәтен әнә шул үзе үк иҗат иткән психологик күренеш белән чагыштырам, шуның белән үлчәргә, шуның белән бәяләргә тырышам. Этинең башына шушы ук (Биктимер әйткән) уйлар, теленә шушы ук сүзләр килмәгәндер дә, чөнки вакыйгаларның социаль асылы башка, әмма улын сугышта югалткан атаның хисләре үзләренең көче, тирәнлеге белән Биктимер карт кичерешләренә тәңгәл булгандыр, дип уйлыйм.

Эти үзенең ачы хисләрен тышка чыгарып, үзен башкалардан кызгандыручан, жәлләтүчән түгел иде. Әмма улы Үзбәкнең тере образы гомергә аның күңелендә калды, әлбәттә. Үзбәкнең хатларыннан, шулай ук аның фронтовик дуслары авызыннан ишетелгән кайбер хәбәрләр (сугыш детальләре) Таҗи Гыйззәтнең башка әсәрләрендә дә чагылыш таба. Мәсәлән, «Изге амәнәт»тә Әсфан: «Миңа каты сугышларда, дәһшәтле атакаларда, дөрләп янган танк эчләрендә калырга туры килде». Шул ук Әсфан башка эпизодта: «...коточкыч сугышта танкым минага эләгеп, сафтан чыккан...» һ. б.

Бу детальләр нәкъ Үзбәк кичергән вакыйгаларны хәтерләтә. Үзенең фронттан салган соңгы хатында ул түбәндәгене язган иде: «Без Ржев өчен сугышабыз. Утызында (1942 елның август ае — К. Г.) атакада танкымны подбить иттеләр... Урынында кузгалмаслык хәлгә килгәч, танкны калдырдык. Ләкин кая карама — фриц: окружениега эләктек. Танк янына килгән фрицларның өчесен 2 граната белән кадалдырдым, берсен револьвердан атып үтердем һәм берсен ранить иттем. Төн җиткәч танк янына үрмәләп килеп (аны) яндырдым һәм водителем белән икәү тагы бер немец телефонистын үтереп, 2,5 км җирне түштә үрмәләп үзебезнекеләргә кайтып җиттек... Хәзергә исән-сау әле. Дошман каты каршылык белән чигенә...»

Шулай, Үзбәк образы Т. Гыйззәтнең «Таймасовлар» әсәрендә турыдан-туры прототип ролен үтәсә, аерым мотивлар рәвешендә ул язучының башка кайбер әсәрләрендә дә чагыла. Моның турында югарыда китерелгән «Изге амәнәт»тән башка, 1944 елны иҗат ителгән «Даулы көннәр»дә Нургали, 1946 елны язылган «Безнең авыл егете»ндә Советлар Союзы Герое Айтуганов образлары сөйли.

Моның сәбәбе шәхси, туганлык бәйләнешләрендә генә түгел, бәлки, югарыда әйтелгәнчә, язучының эстетик принципларында ята. Т. Гыйззәтнең Нургали, Марат, Әсфан һәм башка шушындый уңай образлары элегрәк иҗат ителгән Батырҗан, Рамай образлары системасына килеп кушыла. Әлбәттә, аталган әсәрләрдә тарихи чорлар, вакыйгаларның социаль шартлары бер түгел. Ләкин бу образларның барысын да берләштергән уртак сыйфатлар бар: уңай геройларның изге эшкә бирелгәнлеге һәм тугрылыгы, җиңү өчен үз-үзен аямавы, аның гражданлыгы, шәхси батырлыгы. Гомумән, бу сыйфатлар Т. Гыйззәт эстетикасында доминант принциплар булып торалар. Сәнгатьтә аларның тәрбияви роле һичкайчан да кимемәячәк.

Этинең уңай образларны шушы планда гәүдәләндерергә омтылуы аның үз холкындагы сыйфатларга да бәйләнгән. Ул үзе дә — яшь чагында ук мәйданга чыгып «бил алышкан», сабан туйларында бүләкләр алган кеше. Эти һәр эштә дә ярыш элементын, егетлекне ярата, җиңеп чыгуның тәмен белә иде. Шуңа күрә Язучылар союзында, театр җәмгыяте клубында үткәрелгән шахмат ярышларында ул даими катнашучы булды. Өлкән буын язучыларыбыздан, артистларыбыздан кайсы гына аның бик хирес балыкчы булуын хәтерләми икән? Эти спорт ярышларын карарга ярата иде. 30 нчы елларда Казан циркында французча көрәш күрсәтелеп килде. Эти шуны карарга һәрвакыт Үзбәк абый белән мине дә ала, көрәшү вакытында барган һәр әңгәмәгә кушылмый калмый иде. Урамнан узганда, кузна яисә футбол уйнаучы малайларны күрде исә, тукталып, күзәтеп тора, җиңелә башлаганнарын ярсытып ала. Шунлыктан булса кирәк, энем Рубин спорт белән бик бирелеп шөгыльләнде.

Безнең гаилә, башка күпчелек гаиләләр кебек үк, бик тату яшәде. Әни (ул 1976 елда үлде) үз чоры өчен укымышлы, белемле кеше булганга, этинең беренче киңәшчесе иде. Әлбәттә, эти барыбыз өчен дә зур авторитет булды. Без һәрчак аның таләпчәнлеген тоеп тордык.

Эти кешеләргә турысын әйтергә ярата иде. Аның бу сыйфаты кайберәүләргә ошап та җитмәгәндер, әмма аның дуслары күп иде. Сәнгать кешеләреннән Г. Болгарская, Ф. Ильская, Х. Сәлимҗанов, Ш. Сарымсаков, Х. Уразиков, С. Сәйдәшев, Җ. Фәйзи һәм башкалар белән ул һәрвакыт аралашып яшәде.

Эти гомеренең соңгы көннәренә кадәр иҗат эшен туктатмады. Соңгы атналарда — бу 1955 елның феврале иде — ул «Наемщик» музыкаль драмасын опера итеп үзгәртү өстендә эшләде. Бу вакытны ул түшәктән күтәрелә алмый иде инде, текстларны телдән әйтеп яздырды. Соңгы көннәрендә, үзенең тиздән үләчәген белеп (аңарда рак авыруы иде), ирләрчә салкын канлылык белән иҗади архивын барлатты, аны тәртипкә китерү буенча күрсәтмәләрен бирде...

Эти — безнең күңел түрендә. Үзенең гомере, яшәү һәм иҗат принциплары, тырышлыгы, нәтиҗәле эшчәнлеге, егетләрчә холкы-фигыле белән ул безгә — якты үрнәк.

Казбек **ГЫЙЗЗӘТОВ**,
философия фәннәре докторы, профессор.

# Ял вакытында

Мең тугыз йөз илленче елның җәендә без Җәүдәт Фәйзи һәм Хөсәен Гыйззәтуллин семьялары белән бергә Актаныш районының Мәсәде авылына ялга бардык. Сугыштан соңгы чор. Илебез өчен авыр гына еллар. Шунда, авыл халкы белән аралашып, эти үзенең киләчәк әсәрләре өчен образлар, характерлар күзләгән, материал туплаган. Әйтергә кирәк, эти, чыгышы белән крестьян булгангадыр, күрәсең, авыл кешеләре белән уртак телне бик тиз таба торган иде... Тагын мин шуны хәтерлим. Җәүдәт Фәйзи үзе белән фонограф алган иде. Бу — өч балавызлы валиктан торган механизм заманында тавыш язу эшендә үзенә күрә бер могҗиза дип санала иде кебек. Һәр валикның язу вакыты — 10 минут, 3 валикның барлыгы 30 минут чамасы була. Язып алучылар алдында шактый катлаулы бурыч тора иде: нибары 30 минут эчендә авылдагы халык иҗаты җәүһәрләрен түкми-чәчми язып алырга кирәк. Бу эш кызыклы гына спектакль рәвешендә узды.

Башта колхозчылар арасында «разведка» сыман нәрсә башкарылды: кайсы авылда, кем нинди көйләр, бәетләр белә. Шуннан соң колхоздан ат сорап алынды. Эти ат җигү белән яшьтән таныш булганга күрә, бу вазифаны рәхәтләнеп үз өстенә алды. Фонографны арбага менгезеп, китү өчен барлык нәрсәләр әзерләнеп беткәч, ниһаять күрше бер авылга кузгалабыз.

Ә тегендә шундый нәрсә килеп чыга. Җырчы, бәетче бабайлар һәм әбиләр (аларның кайсына 80—90 яшь булгандыр) фонографны күрү белән шүрләп калалар, җырны башлап җибәрергә батырчылык итми торалар. Җыр язу чаралары бик дефицит булганга күрә (барлыгы 30 минут) эти белән Җәүдәт абый аппаратураны җибәрү алдыннан башта «солистларны» әзерләргә мәҗбүр булалар. Монда инде этинең халык әйтемнәрен, мәкальләрен яхшы белүе, аның артистлык сәләте эшкә җигелә. «Солистларга» берничә тапкыр «прогон» ясап, ярыйсы гына сыйфатка ирешкәч, ниһаять, фонографка язу башлана. Шунысы да хәтеремдә, Мәсәдедән кайткач, эти белән Җәүдәт абый бу язуларны көлешә-көлешә тыңлаганнар иде.

Шушы Мәсәдегә барган елны эти белән әни мине урманга алып бардылар. Әни белән без җиләк җыябыз, эти исә зур тырышлык белән зифа буйлы кармак саплары карады. Үзен канәгатьләндерерлек берничә сап кисеп алганнан соң, ул юкә кайрысы әзерли башлады. Урманда күпме вакыт булганбыздыр, хәтерләмим, ләкин аннан кайткач эти шушы кайрыны бик җентекләп кенә эшкәртте. Күренә иде ки, ул әлеге эшнең технологиясен әйбәт белә. Бер вакыт күршедән шөшле алып, чабата ясарга кереште. Башта — безгә, малайларга (Мәсәдегә Җәүдәт абый һәм Хөсәен абый да миңа тиңдәш улларын алып барганнар иде), аннан инде — олыларга. Шулай, берникадәр вакыт уз-

ганнан соң, әни белән без генә түгел, Җәүдәт абый, Хөсәен абый, шулай ук без тукталган өй хуҗасының семья членнары — барыбыз да чабаталы булып куйдык. Берничә пар чабата Казанга да кайтты. Хәтеремдә, әти аларны театрга бүләк иткән иде. Ниндидер спектакльне караганда мин хәтта кайсыдыр геройның аягында әти Мәсәде авылында ясаган чабаталарны таныган да кебек булдым...

**Рубин ГЫЙЗЗӘТОВ.**

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**Сорау:**

— Быел җәй Мәскәүдә яшьләр һәм студентларның XII Бөтендөнья фестивале зур уңыш белән узды. Сез иҗат иткән эмблема яшьләр фестиваленең рухына тулысынча тәңгәл иде: биш кыйтганың дуслыгын чагылдыручы ромашка-эмблеманың үзәгендә — тынычлык даулап очучы ак күгәрчен. Очраклы хәлдерме бу, аның канат җилпүләре безнең Казан күгендәге күгәрченнәрне хәтерләтә кебек... Рафаэль Зиннурович, миллионнар күңеленә хуш килердәй бу эмблеманы иҗат итү ничегрәк булды?

**Рафаэль Мәсәгутов, Киев рәссамы, Украина комсомолының Н. Островский исемендәге премиясе лауреаты:**

— Сүз дә юк, фестиваль эмблемасын «уйлап табу» өчен байтак көч сарыф итәргә туры килде. Хәтерлисездер, яшьләр фестивален Мәскәүдә үткәрү турында карар чыккач та иң яхшы эмблемага Бөтенсоюз конкурсы игълан ителгән иде. Конкурста нәкыш, графика һәм плакат осталарының өч йөздән артык эше каралды. Мин үзем унлап вариант ясаган идем, шуларның өчесен конкурска тәкъдим иттем. Арадан иң гадиен һәм аңлаешлысын фестиваль эмблемасы итеп расладылар.

Фестивальнең «Империализмга каршы бердәмлек, тынычлык һәм дуслык өчен!» дигән девиз белән узачагы мине нык уйландырды. Эскизларымның күбесенә тынычлык символын чагылдырган ак күгәрчен килеп керде. Һәм бу бик табигый иде, чөнки яшьләр фестиваленең төп максаты — тынычлыкка өндәү, үзара тыныч яшәүне зурлау. Җир шары фонындагы ак күгәрчен — барлык халыклар өчен дә кадерле булган интернациональ кош, әлбәттә. Ә инде аның Казан күгәрченен хәтерләтүе, уенын-чынын кушып әйткәндә, шулай ук нигезсез түгелдер. Чөнки яшьлегем иртәсе Казанда үтте. Биредә художество училищесын тәмамладым. Халкыбызның культура үзәге булган Казан миңа беренче сәнгать тәрбиясе биреп кенә калмады, иҗатымның формалашуына да зур йогынты ясады. Киев художество институтына укырга килгәндә мин инде рухи яктан шактый бай мәктәп узган идем.

Казан белән хәзер дә турыдан-туры иҗади элемтәдә яшим. Билгеле булганча, 1986 елда бөек шагыйрьләребездән Габдулла Тукайның тууына — 100, Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулачак. Бу ике олуг бәйрәм уңаеннан Киевта да әзерлек эшләре бара. Ике татар шагыйренең украин телендә чыгачак сувенир китапларын бизәү эше миңа тапшырылды. Әлеге китаплар ике милләт халкы арасындагы дуслыкны тагын да ныгытыр дип уйлыйм. Тукайның әсәрләрен украин теленә шагыйрь Юрий Буряк тәрҗемә итә. Быел без аның белән Казанда булдык. Тукай урыннары һәм Кырлай мемориаль комплексы белән танышу һәр икебезнең иҗатына да бетмәс-төкәнмәс илһам бирде.

Якындагы көннәрдә тагын бер яңа эшемне — «Сталинград авазлары» сериясен тәмамларга җыенам. Бөек Ватан сугышының кайнар җилләре безнең балачакка да кагылып узды. Сугыш башлангач та мин, җиде-сигез яшьлек малай, көтү-көтү малларны тылга куалау эшендә катнаштым. Идел кичкән вакытта фашистларның ничек итеп Сталинградны яндырганнарын үз күзләрем белән күрергә туры килде. Шул чакта күргәннәрем әле дә тынгылык бирми. Әлеге сериядә мин совет халкының батырлыгын күрсәтергә, тынычлыкның һәркем өчен кадерле нәрсә икәнен раслап бирергә телим.

# ...ЯКТЫЛЫККА, НУРГА ИЛТӘ



Соңгы елларда татар совет театры күренекле уңышларга иреште, үз үсешендә мөһим яңа үрләр яулады. Бу уңышлар — республикабыздагы театр коллективларының, язмышларын милли сәхнәгә бәйләгән күпләгән иҗатчы шәхесләрнең фидакарь хезмәте нәтиҗәсе.

Театрларыбызның соңгы егерме ел эчендәге эшчәнлеге драматург Туфан Миңнуллин иҗаты белән аеруча тыгыз бәйләнгән. Т. Миңнуллин бүген күпмеңләгән тамашачыларның яраткан драматургына әверелде, аның әсәрләре хәзер күпмилләтле илебезнең төрле шәһәрләре сәхнәләрендә еш уйнала, үзәк телевидениедән күрсәтелә.

Т. Миңнуллин әдәбиятка алтмышынчы еллар башында юмористик хикәяләр һәм кечкенә күләмле сәхнә әсәрләре белән килә. Соңрак ул драматургия жанрының олырак формаларында көчен сынарга керешә. 1962 елны яшь авторның «Безнең авыл кешеләре» исемле өч пәрдәлек комедиясе — Минзәлә драма театры, балалар өчен язылган өч пәрдәлек «Азат» исемле пьеса-әкияте Казанда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела һәм, тамашачыларның игътибарын казанып, театр җәмәгатьчелегендә һәм тәнкыйтьтә уңай бәя ала. 1967—1969 елларда Әлмәт дәүләт драма театрында — «Күрше кызы», Татар дәүләт академия театрында — «Миләүшәнең туган көне», ә Татарстан республика Күчмә театры (хәзерге — Татар дәүләт драма һәм комедия театры) сәхнәсендә «Нигез ташлары» һәм «Йөрәк янар өчен бирелгән» исемле яңа пьесалары куелгач, Т. Миңнуллин тәнкыйтьтә үзенчәлекле драматург буларак телгә алына башлый.

Җитмешенче еллар — Т. Миңнуллинның художник-драматург буларак иҗади йөзе формалашу, табигый талантының үзенчәлекле рәвештә ачылып китү һәм индивидуаль сыйфатларга байый бару чоры дияргә мөмкин. Драматург форма һәм эчтәлек өлкәсендәге эзләнүләрен тагы да тирәнәйтә төшә, тормыш материалын, үзен кызыксындырган, борчыган иҗтимагый һәм әхлак проблемаларын сәнгатьчә хәл

итү, заман кешесенең рухи дөньясын, яшәеш фәлсәфәсен укучыга, тамашачыга үтемлерәк, тулырак илтеп җиткерү өчен сәхнә әдәбиятының төрле жанрларына һәм алымнарына мөрәҗәгать итә, иҗтимагый тормышның төрле-төрле темаларын кузгата. Әдипнең иҗади активлыгы бермә-бер көчәя. 1970—1983 еллар арасында аның Татар академия театры сәхнәсендә — тугыз пьесасының, Әлмәт дәүләт драма театрында — дүрт, Татар дәүләт драма һәм комедия театрында — биш пьесасының премьерасы була. Бу спектакльләр һәммәсе дә диярлек тамашачыда зур кызыксыну уята, озак еллар буе сәхнәдән төшмичә уйналып килә.

Туфан Миңнуллин әсәрләренең уңышы, беренче чиратта, аларда сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы, реалистик нигезе белән аңлатыла. Язучы тормышны, аның үзгәрүле агышын нечкә сиземли, анда әледән-әле туып торган әхлакый һәм мөһим социаль мәсьәләләрне оста тотып алып, аларны конкрет материал җирлегендә заманча яңгырашлы, сәнгатьчә тәэсирле-гыйбрәтле итеп сурәтли белә. Автор күпчелек әсәрләрендә олы философик категорияләр турында — кешенең дөньяда яшәү мәгънәсе, аның җәмгыять һәм үз алдындагы гражданлык җаваплылыгы, әхлакый сафлыгы, намуслылыгы, Туган җиргә, Ватанга тугрылыгы, үз халкының үткәненә ихтирамы һәм киләчәгенә ышанычы турында сүз алып бара.

Т. Миңнуллин — әсәрләре илебез сәхнәләрендә иң күп уйнала торган татар драматургларыннан берсе. Аның пьесалары Башкортстан театрларында («Диләфрүзгә дүрт кияү», «Үзебез сайлаган язмыш», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Кырларым-тугайларым», «Әниләр һәм бәбиләр» һ. б.), Үзбәкстан театрларында («Диләфрүзгә дүрт кияү» һәм «Әлдермештән Әлмәндәр»), шулай ук Мари, Калмык, Дагестан театрларында, Мурманск, Новокузнецк, Әстерхан, Горький, Мичурин һ. б. шәһәрләрнең рус драма театрларында сәхнәләштерелде. Илебез театрларының Т. Миңнуллин драматургиясе белән кызыксынуы елдан-ел арта бара.

Т. Миңнуллин «Нигез ташлары» комедиясе һәм «Үзебез сайлаган язмыш» драматик хикәясе өчен 1974 елда Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясенә, «Ай булмаса, кояш бар» әсәре буенча Әлмәт драма театрында куелган спектакль өчен 1979 елда Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә һәм Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле өчен 1979 елда РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Татар театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа Татарстан АССРның (1978) һәм РСФСРның (1984) атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Т. Миңнуллин — Татарстан Верховный Советы депутаты, Верховный Совет Президиумы члены.

Республикабыз әдипләре үзләренең X съездында Т. Миңнуллинны Татарстан Язучылар союзы председателе итеп сайладылар.

Шушы елның август аенда Туфан Габдулла улы Миңнуллинга 50 яшь тулды. «Казан утлары» журналы редакциясе шул уңайдан юбилярны кайнар котлый һәм үз укучыларына Т. Миңнуллин белән уздырылган әңгәмә тәкъдим итә.

* * *

— Туфан Абдуллович, сәхнәгә булган мәхәббәтегез кайчан һәм ничегрәк башланып китте?

— Үземне үзем белә башлаганнан бирле. Яшь чагында безнең әти авылыбыз клубында «театр уйнарга» яраткан. Әнине дә шул эшкә димләгән. Ләкин әни «кеше көлдереп» йөрергә теләмәгән. Әмма әти уйнаган вакытларда абыйны җитәкләп, мине күтәреп клубка барган. Соңга таба әнинең итәгенә тагылып клубка йөргәнмен, тик әнинең әйтүенә караганда, сәхнәгә түгел, күбрәк

тирә-ягыма караныт утырырга ятратканмын. Тамашачыларның күлүе, кул чабуы «артистлар» уенына караганда мисла ныграк ошаган. Андый чакларда сикерә-сикерә, кул чаба-чаба тыела алмыйча көлгәнмен. Хәтеремдә сакланган иң беренче спектакль — Мирхәйдәр Фәйзинең «Ак калфагы». «Ак калфак» икәнен мин соңыннан гына белдем. Исемдә исә Бакый дигән егетнең сәхнәдә чыбыркы шартлатып йөрүе калган иде, Бакый исеме бик ошаган һәм гаҗәпләндергән иде. Бу хәл сугыш алдыннан булды.

Драматургиягә мәхәббәт бәлки әни укыган китаплардан да күчкәндер. Белеме юк иде әнинең, иҗекләп җыеп укый иде. Әмма буш вакыты булса, кулына китап ала иде. Укыганы гел пьесалар була торган иде. Аларны ул авыл, мәктәп китапханәләреннән алып кайтарттыра иде. Көлә-көлә, җылый-җылый укый иде ул аларны. Аннан күреп китапка мин ябыша идем. Кайбер аналар безнең улыбыз яки кызыбыз китап укырга яратмый дип зарланалар. Димәк, ул үзе укымый. Анасы ни эшләсә, баласы шуны кыла — борынгыдан билгеле хакыйкать бу.

Сәхнәгә мәхәббәт дигәндә, шуны да онытмаска кирәк: театр ярату — татар халкының канында ук бар. Театр уйнамаган авыл юк иде ул элгәрәк. Унбиш-егерме өйле авылларда да җыелып театр куялар иде. Күрше авылларга «гастрольләргә» йөрешү гадәте дә бар иде. Бәрлегуҗа «артистлары» безгә, без Бәрлегуҗага бара идек, мәсәлән. Кызганычка каршы, авылларда театр уйнау хәзер сирәгәйгәннән-сирәгәя бара. Вакыт юк, эш күп дигән булалар. Чепуха. Элек авылда эш күбрәк иде. Ләкин кешеләр — яшьләре һәм өлкәннәре дә — вакыт табалар иде. Йөрәкләренә мүк үсмәгән иде әле кешеләрнең. Бүгенге авыл кешесенә тел тидерәсем килми, ләкин җан әрнегән чакларда әйтелә шул: кибет төбенә җыелып аракы чөмерүчеләр ишәйде бит. Алар күбәйгән саен театрлар уйнау кими барды. Кайчакларда авылга баргач, безгә театрлар сирәк килә дип зарланалар. Элек театр килеп, уйнап күрсәткәнне генә көтеп ятмыйлар иде, үз көчләрен үзләре дә күтәрә беләләр иде. Хәзер клубка яшьләр барса, җимерек магнитофонның шыңгырдавына сикергәлиләр һәм вәссәлам. Нинди көйгә икәнен шайтан үзе дә белми. Гармун уйнаучылар беткәннән-бетә авылда, аларны әлеге дә баягы магнитофон алыштыра. Авыл кешесе сәнгатьтә иждевенецка әйләнә башлады. Әзергә бәзерне көтеп ята. Бу бик куркыныч чир. Авылда идеология эшен алып баручылар моны тирәннән аңларга һәм нәтиҗә ясарга тиешләрдер. Театр уйнау күңел ачу гына түгел ул. Халыкның культура дәрәҗәсе аның театрга мөнәсәбәте белән бәяләнә. Театры булмаган халыкны югары культуралы мөстәкыйль халык дип әйтеп булмый.

Әлбәттә, соңгы елларда безнең профессиональ театр сәнгатебез нык үсте. Драма һәм комедия театры, Әлмәт, Минзәлә театрлары, Оренбург шәһәрендәге театр труппасы чын сәнгатьчә эшләнгән спектакльләр куярга сәләтлеләр. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры исә илебездәге теләсә кайсы театр белән ярышырлык дәрәҗәгә менде. Тамашачыларыбыз спектакльләргә өерелеп йөри. Ләкин, шуңа карамастан, һәрбер авылның үз театры булган чагын сагынам мин. Чөнки сәхнә җене миңа шул чакта кагылды. Минем үземне сәхнәгә күтәреп менгезеп, урындыкка бастырып шигырь сөйләттеләр. Күңелемне күрер өчен кул чаптылар. Башта бүтәннәр язганны сөйләдем, аннан үземнең язасым килә башлады.

— Ә драматургиягә килүегез ничек булды? Иҗат юлыгызның башында үзегезгә кемнәрнең тәэсирен сиздегез, кемнәрдән өйрәндегез?

— Төрле җирдә эшләп йөргәннән соң юлым, барыбер, театрга килеп тукталды. 1956 елда Мәскәүдәге Щепкин исемендәге театр училищесына укырга алдылар. Училищеда иҗат атмосферасы көчле иде. Татар студиясендә укучыларның күбесе, бигрәк тә авыл җиреннән килгәннәр, ни дә булса язып карау белән шөгыльләнә иде. Баштарак шигырьләр яздык, аннан хикәяләргә, пьесаларга күчтек. Шаяра торгач ныклап керешеп кителгән — язганнарның берничәсен Казандагы гәҗит-журналларда бастырып та чыгардылар. Укуны тәмамлап кайткач, «Азат» исемле пьесаны академия театрында уйнап та күрсәттеләр. Менә шуннан китте дә китте инде. Хәзер тукталып ял итәсем килгән чакларда да тукталып булмый.

Минем язганнарда аерым бер драматургның тәэсире булгандыр дип уйламыйм. Үземә хәтле язганнарның (мин укыганнарның) барысына да гашыйк идем мин. Кайбер әсәрләрдәге җитешмәгән якларны күрсәм дә, классик драматургиябезне әле дә бик югары бәялим. Кайбер «атачларнең» «Галиябану»лар искерде диган сүзенә: «ә син шундыйны башта язып күрсәт», дип җавап бирергә яратам. Г. Камалның моннан туксан ел элек язылган «Бәхетсез егет»е былтыр яңадан сәхнәгә менде. Без язганнар нишләр? Мин шул турыда уйланам да куркып калам.

— Менә хәзер, инде җитлеккән драматург булгач, Сез бүгенге драматургия өчен иң мөһим дип нәрсәне саныйсыз? Аеруча безнең татар драматургиясе нәрсәгә күбрәк әһәмият бирергә тиеш?

— Җитлеккән драматург? Язучы җитлегә микән ул? Өзеп кенә әйтә алмыйм. Бәлки җитлегәдер. Кыланып әйтүем түгел, мин үзем җитлегә алмыйча интегәм. Биюче бии-бии остарган шикелле, яза-яза мин дә бераз остарганмын. Пьеса язуның кайбер серләрен тоям шикелле. Әмма осталыкның чиге бармыни? Бүгенге драматургиябез өчен иң мөһим нәрсә дигәндә дә шул осталык мәсьәләсен әйтер идем. Нәрсә турында язарга беләбез бугай без, кемнәр турында язарга кирәклекне дә чамалыйбыз, ә менә шуны ничек итеп язарга? Кайберәүләребез өй салуның ние бар, мүклисе дә чутлыйсы диебрәк, пьеса язуны ансат эшкә санап ялгышкалыйлар. Аннан соң, пьесаларын теге яки бу театр куймагач, куелып та тамашачы ул әсәрне карарга йөрмәсә, кемнәрнедер гаепләргә тотыналар. Миңа хәтле бәлки әйткәннәрдер, мин кабатлыйм гынадыр: драматургия әсәре өчен иң беренче таләп — ул карала торган булырга тиеш. Син язганны тамашачы карамый икән, синең язганыңдагы әллә ниткән глобаль фикерләрең беркемгә дә ишетелмичә кала, искән җилгә агач сәнәк белән кадау гына килеп чыга.

Әлбәттә, тамашачы карарлык итеп язылган әсәрләр безнең эстетик таләпләргә җавап бирерлек югарылыкта һәм фикерле булырга тиешләр. Югыйсә, тамашачыны оста алдап, аңа өч тиенлек тәти күрсәтеп тә көлдерергә була. Иң арзанлы пыяланы да сәхнәдән хрусталь итеп күрсәтергә мөмкин ләбаса. Димәк, безнең төп бурыч — осталыгыбызны камилләштерү, тамашачы алдындагы җаваплылыкны онытмау. Калганы бездә җитәрлек.

— Тукайның атаклы «Театр» шигыре шундый юллар белән башланып китә:

Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,
Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.
Театр — яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.

Сез бу юлларны ничек аңлатыр идегез?

— Бу сорауны бөек Тукай шушы шигырендә бик акыллы итеп аңлаткан инде. Шигырьне ахырына чаклы укып чыгарга гына кирәк. Тукайның даһилыгы шунда — бу сүзләрне ул 78 ел элек әйткән, әмма аны бүген аңламаучылар арабызда йөри. Шактый йөри. Театрга бер тапкыр да аяк басмаган килеш, халык культурасы турында акыл саткан кешеләрне беләм мин. Шунысы кызыклы — минем болай дип әйткәнне андый кешеләр барыбер белмәячәкләр, чөнки алар «Казан утлары»н укымыйча да әдәбиятыбызны сүгеп йөриләр.

— Билгеле булганча, тормыш яшь буынны тәрбияләү буенча безнең алга шактый зур бурычлар китереп куйды. Ул юнәлештә театрларыбыз инде байтак эш башкаралар. Сезнең үзегезнең дә «Нигез ташлары»ннан алып һәр әсәрегез диярлек яшь буынга әхлакый сабак бирүгә багышланган. Аларны яше дә, карты да ярат[illegible] карый. Әмма, яшь буын тамашачыларны театрларга тагын да активрак тарту өчен, безең театрларга һәм драматургларга әле тагын ниләр эшлисе бар?

— Әйе, бу иң житди сорауларның берседер. Яшьләр... Яшьлек... Кайсыбыз гына яшь булмаган да, кайсыбыз гына ялгышмаган. Кайсыбыз гына өлкәнәйгәч, яшьләргә акыл өйрәтмәгән. Тормыш шулайдыр инде ул. Диалектика дигән нәрсә дә шулдыр. Әгәр яшьлек булмаса, һәм ул яшьлек ялгышкалап алмаса, дөнья бик күңелсез булыр иде. Ләкин ялгышу белән ялгышу арасында да аерма бар. Кешеләр өчен изгелек эшләгәндә, тәҗрибәсезлеге аркасында ялгышып куя икән бергә, аны төзәтү җиңел дә, күңелле дә. Әмма җинаятьләр кодексы кулланып төзәтергә калса...

Яшьләрне тиешле юнәлештә тәрбияләү җәмгыятьнең төп бурычы инде ул. Тәрбияләү комплекслы алып барылырга тиешлеген дә беләбез. Бу мәсьәләдә сәнгатьнең роле дә билгеле.

Бүгенге яшьләрне мин нидә дә булса гаепләргә җыенмыйм. Әмма кайбер күңелсезлекләрне күреп борчылам. Иң борчыганы — яшьләр арасындагы ваемсызлык, рәхимсезлек, җавапсызлык. Дөньяда бернәрсә белән дә кызыксынмый торган үле җан яшьләр очрый башлады. Куркыныч әйбер. Аның өчен үткән дә юк, киләчәк тә юк, халык та юк, туган ил дә, туган тел дә юк, дус та, туган да юк. Идеалсыз кешедән дә яман кеше бармы икән? Нишләргә? Минемчә, нинди чаралар гына кулланып булса да яшьләрне аракыдан аерырга кирәк. Партиянең шул явыз чиргә каршы кискен көрәш ачуына сөенеп туя алмыйм. Миңгерәү егетләрне тамаша залында күреп җылыйсы килгән чакларым да була. Андыйларның театрга килмәве килүеннән яхшырак.

Беркөнне «Әниләр һәм бәбиләр» спектакле бара. Иң тетрәткеч сәхнә: яшь ана үз баласын бала тудыру йортыннан алырга теләми. Аны үгетлиләр, иманың бармы? дип сорыйлар. Залда сигезенче рәттә яшь кенә ике-өч пар егет белән кыз кочаклашып утырганнар да авыз ерып көләләр. Бәлки мин гаепледер, яза белми язганмын, шуңа көлкеле тоеладыр? Ләкин бит залдагы бүтәннәр игътибар белән тыңлый, күпләр җылый. Ә болар көлә? Кайда үскән болар? Кем аларны мәрхәмәтсез итеп тәрбияләгән.

Яки икенче бер мисал. Кунакка барган җирдән, хуҗаларның телевизоры ватык булганга, күршеләренә телевизор карарга кердек. Әдәби тапшыру иде, миңа аны карарга кирәк иде. Татар әбие «әйдәгез, әйдә» дип каршы алды. Кызы белән кияве дә өйдәләр иде. Кияүләре телевизорны кабызды. Карый башлагач, унҗиде, унсигез яшьләрдәге бер егет белән бер кыз кайтып керделәр. Керделәр дә: «Чево каля-баля смотреть» дип, программаны күчерделәр дә телевизор каршына утырдылар. Исәнләшү юк, сорашу юк. Чыгып китәргә мәҗбүр булдык. Егет — боларның уллары, кыз — күршеләре икән. Нәрсә бу? Мондый кусәктән нинди мәрхәмәт көтмәк кирәк? Малайның әтисе сүз әйтмәкче иде, әнисе «ярар инде, я чыгып китәр, эзләп йөрисе була», дип ирен туктатты. Ифрат яман хәл. Кайда безнең бала үстерүдәге традицияләребез? Нигә ул буталды? Уйландыра.

Бүгенге заман — киеренке заман. Безнең һәрберебездән иман ныклыгы таләп ителә торган заман. Яшьләрне тәрбияләү турында күп сөйлибез, күп эшлибез дә. Ләкин ул гына җитми, күрәсең.

Ә инде конкрет драматургиягә, театрга килгәндә, әлбәттә яшьләргә үзләренең тормышыннан алынган конкрет проблемаларны яшьләрчә итеп сурәтләгән әсәрләр кирәк. Үрнәк геройларны түшәмнән эзләмичә, яшьләрнең үзләре арасыннан табарга кирәк. Алар бар. Һәм алар күп. Күпләр арасында чүпләрне күреп йөрәк әрни дә инде.

— Безнең драматургиянең һәм, киң алганда, гомумән, әдәбиятның да, бөтенсоюз киңлегенә чыгу мәсьәләсенә Сез ничек карыйсыз? Бу өлкәдә иң кичектергесез эшләнергә тиешле нинди эшләр күрәсез?

– Шәп язарга кирәк. Бу сорауга шулай дип кенә җавап биргәндә дә бик дөрес булыр иде. Әмма бездә (хәер, бездә генә дә түгелдер) бөтенсоюз киңлегенә чыгуны берьяклырак аңлаучылар да бар. Алар, үзләренең әсәрләрен рус яки башка телгә тәрҗемә иттерәләр дә, мин инде танылган, бөтенсоюз аренасындагы язучы дип әйтмәсәләр дә, шулайрак кыланалар. Әлбәттә, тәрҗемә ителү генә язучыны бөек тә, популяр да итми. Урта кул әсәрне мең телгә тәрҗемә итсәң дә урта кул булып кала. Киресенчә, яхшы әсәрнең сыйфаты тәрҗемә иткәндә түбәнәю очраклары бик еш була. Минемчә, язучы үз халкы өчен үз телендә үзенә иң зур таләпләр куеп, үз-үзен аямыйча эшләргә тиеш. Бөтенсоюз аренасына чыгуны гына максат итеп куеп, рәтле нәрсә язып булмыйдыр. Шекспир үзенең гениаль трагедияләрен язганда япон театрында куелу турында уйламаган-

дыр, шат. Шуңа күрә дә ул бүген дөньяның бөтен театрларында уйнала. Драматургның инглизләргә атап язылган әсәрләрен бөтен халыклар да аңлыйлар икән ләбаса.

Әмма шунысы да бар: үзебезнең халык яратып кабул иткән, югары зәвыклы әсәрләребезне үзебез генә бикләнеп укып тәм табу да чикләнүгә, саранлыкка китерә. Байлыгыбызны бүтәннәр белән дә уртаклашырга тиешбез. Безнең байлыгыбыз аз түгел. Дөнья күләмендә горурланырлык әсәрләребез бар. Аларны таныту өчен, әлбәттә, шул әсәрләр югарылыгында фикер йөртә алган, аларны чынлап-чынлап яраткан, тәрҗемә эшен кәсеп эше дип кенә карамаган тәрҗемәчеләр кирәк.

— Иҗат союзыбызның җитәкчесе буларак, бүгенге татар совет әдәбияты алдында торган берничә иң зур проблемага тукталсагыз иде.

— Алдагы җавапта әйтелгәнчә, әдәбиятыбызның зурлыгын бүтән халыкларга күрсәтү проблемасы бүгенге көндә союз җитәкчелегендә торган кешеләрнең төп эшедер.

Язучыларыбыз югары художестволы әсәрләрне күбрәк язсыннар иде, халкыбыз аларны шатланып каршы алсын иде, без ул әсәрләрне бөтенсоюз күләменә чыгару өчен көчебезне кызганмас идек.

Бүгенге татар совет әдәбияты алдында торган зур проблемаларның тагын берсе — яшь алмаш әзерләү. Бу бик четрекле нәрсә. Чөнки кешене укытып кына язучы эшләп булмый. Язучы булу өчен иң беренче чиратта табигать биргән сәләт — дөньяны образлар аша күрә белү сәләте, телне күңел, җан белән тоя белү сәләте кирәк диләр. Мондый яшьләр, кызганычка каршы, көннән-көн сирәгәя бара. Бәлки бу вакытлы гына хәлдер. Кем әйтмешли, арысланнар көтү белән йөрми. Шулай була күрсен иде.

— Яшь алмаш мәсьәләсе һәр тармакта иң мөһим мәсьәлә булып тора. Әдәбиятка соңгы елларда килгән яшь көчләрнең кайсы яклары Сезне куандыра, ә кайсы сыйфатлары борчый? Һәм үзегезне борчыган сыйфатларны бетерү өчен яшьләр нәрсәләр эшли алырлар иде дип уйлыйсыз?

— Сәләт чаткылары булган яшьләрне безнең союз идарәсе югалтмый. Хәтта кирәгеннән арттырып җибәреп тә иркәли бугай. Ике-өч ярыйсы гына шигырь язса да яшь иптәшне күккә чөеп мактаучы өлкән абыйлары табыла. Хәер, мин үзем мактауны кирәксез, зарарлы нәрсә дип санамыйм. Яшьләрне мактап бозып булган кебек, тәнкыйтьләп тә әдәбияттан биздереп буладыр. Тәнкыйтьче булсам, мин кайбер язучыларны мактап сынап карар идем. Зур язучы мактауга түзә алырга тиеш. Дөресрәге, ул аны ишетмәскә тиеш.

Ул яктан килгәндә безнең яшьләр түземле. Алар нәрсәнең нәрсә икәнен яхшы аңлыйлар. Бүгенге яшьләргә әз генә булса да скептиклык хас. Алар һәр әйтелгән сүзгә ышанмыйчарак карыйлар шикелле. Хәтта кайвакытларда ышанырга тиешле сүзне дә колак өстеннән генә уздырып җибәрәләр сыман. Аяныча каршы, йөрәк өстеннән генә уздырып җибәрүчеләре дә очрый. Монысы инде бик яман нәрсә. Язучының йөрәге һәрвакыт яраланып торырга тиештер, йөрәгеннән кан саркып тормаган язучы әдәбиятка кәсеп урыны итеп кенә карый, укучыларда түбән зәвык тәрбияли, укучыны әдәбияттан этәрә. Кәсепче язучылардан сакларга кирәк әдәбиятны.

Мин әдәбиятка шома гына килгән яшьләргә шикләнебрәк карыйм. Ялгышып, ялгышын төзәтеп, эзләнә-эзләнә үз юлын тапкан язучы һәрвакыт төпле була. Мондый яшьләр бездә берәү-икәү генә булса да бар. Мин аңа шатланам.

Тырыш яшьләрне күреп тә шатланам. Ялкауларны җенем сөйми. Яшь кеше үз-үзенә туктаусыз эш табып торырга тиеш. Бездәге кайберәүләр эшсезлектән интегә. Юньләп шигырен дә язмый, җәмәгать эшеннән дә кача. Гражданлык активлыгы җитенкерәми ахры яшьләргә...

Яшьләр мәсьәләсендә традицион мыжык картка әйләнә барамдыр, ахрысы. Бәлки яшьләр үзара җыелып зур эшләр турында сөйләшәләрдер, бер-берсенә яңа шигырь-поэмаларын укыйлардыр, качып кына берничә роман язганнары да бардыр. Шулай булсын иде. Яшьләргә шулай кыек сүз әйткәнемә оялырга язсын иде. Шул сүзләрем өчен мин алар алдында тезләнеп гафу үтенергә риза. Тик татар совет әдәбиятына туктаусыз яңа алмаш кына килеп торсын. Дөньядан киткән өлкәннәребезнең өметләре генә аклансын.

— Культурабыз тарихыннан билгеле булганча, гасыр башында һәм, гомумән 30—40 елларга кадәр, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре үзара актив аралашып яшәгәннәр. Бу әдәбият-сәнгатьнең гомум үсешенә дә уңай тәэсир иткән. Безнең чорда шушы аралашуны үстерү буенча союзыбыз нәрсәләр эшли алыр иде?

— Авырткан җиргә кагылдыгыз, егетләр. Аралашмыйбыз шул. Юк, бер-беребез белән күрешеп, исәнләшеп йөрибез анысы. Ләкин мәсьәләгә тирәннәнрәк карасак, без, сәнгать эшлеклеләре һәм әдәбият әһелләре, бер-беребезне белеп бетерәбез микән? Мәсәлән, композиторларыбыз нинди уйлар белән яшәгәнен без, язучылар, беләбезме? Музыка кичәләренә язучыларыбызның күпмесе йөри? Рәссамнарыбызның күргәзмәләрендә ничәләп язучыбыз була? «Казан утлары» журналына язылган һәм аны укып барган композитор яисә рәссамнарыбыз бармы?.. Әдәбиятны яхшы белгән ничә артистыбыз бар? Еллар буена театр бусагасын атлап кермәгән язучы юк дип уйлыйсызмы?

Язучыларыбызны сәнгать эшлеклеләре белән аралаштыру өчен союзыбыз мактанырлык эш майтарганы юк бугай. Ләкин язучының сәнгатьне, сәнгать кешеләренең әдәбиятны белүе төрле чаралар оештыруга гына кайтып калса, әйбәт түгел инде ул. Аралашу ул безнең профессиональ бурычыбыз ич. Музыка яисә рәсем сәнгатендә надан язучыдан чын әсәр көтеп буламы икән? Арыш, бодайны яхшы танып та, сыер-сарыкның ни икәнен белмәгән авыл кешесе кебек буладыр ул.

— Сезнең язганнарыгыздан һәрчак юмор бөркелеп тора. Сез юморның, уен-көлкенең яшәүдәге бөек көчен нечкә тоясыз, аны әсәрләрегездә оста файдаланасыз. Бу хакта үзегезнең уйларыгыз белән уртаклашсагыз иде.

— Әллә?.. Шулай гына була күрсен иде. Дөньяда иң бәхетсез һәм куркыныч җан иясе — юмор хисеннән мәхрүм ителгән кеше. Юмор хисе ул, минемчә, табигать тарафыннан гына бирелә торган хис түгел. Ул хисне яшьтән үз балаларыбызда тәрбияләргә тиешбездер. Авылда элек юморга өйрәтүнең «мәктәбе» бар иде. Олылар җәй көннәре эш беткәч, кич белән бүрәнә өстенә тезелешеп утыралар иде дә, дөнья хәлләре турында сөйләшәләр иде. Житди сүздән соң мәзәк сүзләр сөйләнелә иде. Авылның үз мәзәкчеләре бар иде. Без, бала-чага, бер читкә посып һәр сүзне күңелебезгә сеңдереп бара идек. Аннан соң, үзебез генә калгач, олылар сөйләгән мәзәк хәлләрне кабатлап сөйләшеп, тәгәри-тәгәри көлешә идек. Авылыбызның Минһаҗ бабай, Мәхмүт абыйлары бар иде. Тапкыр кешеләр иде алар. Халыкның ничәмәничә йөз еллар буе җыелган сүз осталыгын үзләрендә саклаганнар иде. Аларның мәзәге хатыннан акча урлап, бер ярты алып эчүгә генә корылмаган иде. Мәгънәле иде аларның мәзәге.

Хәзер мин авылга кайткач әниемнең 87 яшьлек абыйсы — яшь бабай янына ашыгам. Нәнә әйтә, яшь бабаңа һаман акыл керми әле, ди. Телендә һаман мәзәк, ди. Ә үзе яшь бабай мәзәк сөйләгәндә рәхәтләнеп тыңлый. Әллә ничә тапкыр ишеткән булса да, тыңлый. Чөнки яшь бабайның мәзәге тапкыр. Ул булган хәлләрне дә мәзәк итеп, кызыклы итеп сөйли. Әгәр минем әсәрләрдә юмор бар икән, аларның берсе дә мин үзем уйлап чыгарган түгел, барысы да мин күргән, мин белгән кешеләрнеке. Бервакыт авылыбызның кызыклы кешесе Касыйм абый кешеләр җыелып торган җирдә миңа карап хәйләкәр елмайды да:

«Туфан, син сөйләгәнне тыңлап торасың да, шуны китапка бастырып чыгарып, акча аласың икән... Түлә бурычыңны — үзең дә безгә Казанның берәр мәзәген сөйлә», — диде.

Әйе, бурычым зур кешеләр алдында, түләп бетерерлек кенә түгел.

«Туфан, син язганны исемеңне әйтмәсәләр дә таныйбыз», — диләр.

Танымаска ни. Үзебезнеке ич язганнарым. Бармактан суырып чыгармаска тырышам. («Бармактан суырып» дигәнне бездә икенче төрле итеп тә әйтәләр — анысы, минемчә, тапкыррак).

Уен-көлке дигәннән, бер парадоксны искә алып китәсем килә. Тәнкыйть ни өчендер комедия жанрына бераз кимсетебрәк карый, аны житди әсәрләр тирәнә кертергә бик ашыкмый. Ә бит, дөресен генә әйткәндә, комедия язу драма язуга караганда күп мәртәбә авыррак. Тормышта да кешене җылату җиңел, көлдерү кыен. Җылату өчен тупаслык та житә, көлдерү өчен тапкырлык кирәк. Тапкырлык инде ул акыллылык галәмәте. Димәк, уен-көлкенең көчен нечкә тоясыз, дип сез дә мине бик зурладыгыз. Бу яхшылыгыгызны онытмам, җае туры килгәндә «урагыгызны урышырмын».

— Сездә, шәхсән үзегездә дә, шулай ук әсәрләрегездә дә, оптимистлык ташып тора. Кешелек тормышында ахыр чиктә барыбер яхшылык тантана итәчәгенә Сез җаныгыз-тәнегез белән ышангансыз. Иҗатта оптимизмның ролен Сез ничек аңлатасыз?

— Оптимизм шул юмор, уен-көлке дигән нәрсәгә бәйле бугай инде ул. Әйе, яшерми әйтәм, мин оптимист булырга һәм оптимистик әсәрләр язарга бик тырышам. Җылак, мескен бәндәләрдән көләм. Бәлки дөрес эшләмимдер әмма көләм. Беренчедән, безне яшьтән үк җыламаска өйрәттеләр, авыз тулы кан булса да, кеше алдында төкермәскә — сер бирмәскә өйрәттеләр. Әтиләр фронтка киткәч, җыелышып җылап утырсак ни булган булыр иде? Безнең әниләр оптимист иделәр, җиңүнең киләчәгенә ышандылар. Безне дә ышандырдылар.

Дөньяда кеше өмет белән яши. Язучы моны яхшы белергә тиеш. Минем әсәрләрне бер журналист артык оптимист булганнары өчен тормышчан түгел дип әйткән иде. Ул аны конкрет мисаллар белән исбатлады. Мин бәхәсләшеп тә тормадым. Чөнки мин тормышның, яшәүнең дөньяда иң гүзәл нәрсә икәненә инанган кеше. Минем тормышта да төрле хәлләр була. Кайгы-хәсрәтне дә күрмәдем түгел, кәефнең кырылган чаклары да еш була. Әмма мин оптимист, кешеләр янында шат күңелле булырга тырышам. Минем кәефемнең начар булуында бүтәннәрнең ни гаебе бар?

Ә инде «караңгы әсәрләр» язып кешеләрнең өметен өзү — җинаять. Безнең әсәрләрне укып яки карап җылаганда да, җылаучыларның күз яше кайгыны юа торган, чиста күз яше генә булырга тиештер. Әдәбиятның «яктылыкка, нурга» илтүен мин шулай аңлыйм.

Кайберәүләр «Әлдермештән Әлмәндәр»дәге эпилогны артык диләр, әсәрне суза, диләр. Әлмәндәрнең китүе белән пәрдәне ябарга кирәк, диләр. Бәлки шулайдыр. Ләкин Әлмәндәрне болай гына җибәрәсем килми. Теге дөньяда да Әлмәндәр фәрештәләрне кочаклап йөрсә, минем өчен рәхәтрәк. Кешене өметтән аерырга ярамый. Күк йөзендә Кояш бар, Кояш булмаса, Ай бар, «Ай булмаса, йолдыз бар».

— Сез кайчакны үзегезнең төп жанрыгызны читкә куеп, «сулга» да йөреп кайтасыз — повестьлар, хикәяләр, эсселар, уйланулар язып куясыз. Моны ничек аңлатасыз?

— Әйе, «уҗымга» кереп чыккалыйм. Ләкин уҗым басуын кешенеке генә дип санамыйм, анда минем дә кишәрлегем булырга тиештер. Хәтта шигырьләр дә язгалыйм әле мин. Аларын инде чыннан кача-кача эшлим һәм бик яратып эшлим. Иң рәхәте — шигырь язу. Шагыйрьләрдән үлеп көнләшәм. Ләкин шагыйрьлек бирелмәгәч, нишләтәсең. Тик нигәдер кайберәүләр шуны аңламыйлар, язган шигырьләрен бүтәннәргә укытып, кайчакта бастырып та чыгарып, үзләрен кадерсезлиләр. Үзебез кичергән һәрбер рәхәтлекне кеше алдында эшләргә ярамый лабаса. Ә хикәяләрне мин чынлап язам. Тырышып язам. Төп эшем итеп язам. Чөнки бөтен нәрсәне дә драма теле белән әйтеп биреп булмый. Әйтәсе килгән сүзләр күп бит. Бик күп.

Гомумән, язучы бер генә көн дә тик тормаска тиеш. Әләктән башканы барын да язып карарга ярый. Язу — язучының эше. Озак язмый торсаң, каләм тутыга, акыл үшәнләнә, күңел тупаслана.

— Бүгенге татар әдәбиятын оештыру буенча «Казан утлары» журналы алдында торган нинди принципиаль мәсьәләләр күрәсез?

— «Казан утлары» безнең бердәнбер әдәби журналыбыз. Шуннан барысы да аңлашыла инде. Аның намусын саф итеп саклау барыбызның да изге бурычы. Бу мәсьәләдә без бөтенебез дә шәхси зәвыкларыбыздан өстен була белергә, бары тик әдәбиятыбызның олылыгы турында гына уйларга тиешбез.

— Без тынгысыз һәм гаять киеренке чорда яшибез. Сезнең, җәмәгать эшлеклесе буларак, туган илебездә һәм дөньяда барган бүгенге вакыйгаларга мөнәсәбәтегезне дә белү кызыклы булыр иде.

— Безгә хәтле заманнарда яшәгән кешеләр өчен дә үз заманнары катлаулы булгандыр. Катлаулы проблемаларын алар аң дәрәҗәләренә карап төрлечә хәл итәргә тырышканнар. Тыныч юл белән уртак тел таба алмасалар, коралга тотынган-

нар. Безнең заман элеккеләргә карaганда шунысы белән аерылып тора — бүген кешелек дөньясы бәхәсне корал белән хәл итә алмый. Әгәр бүтән заманнарда сугыш кырларыннан исән кайтучылар булса, бүген аларның булуы шикле. Бөтен җир өсте сугыш кырына әверелеп, Җир дип аталган планета өстендәге иң гүзәл нәрсә — тереклекнең язмышы да кыл өстенә куелачак. Шулай булгач безнең һәрберебез өстенә гаять зур бурыч йөкләнгән. Ничек тә булса үтеп китәр әле, дип читтә посып яшәп булмый бүген. Идеология өлкәсендә эшләүчеләргә бигрәк тә уяу һәм зирәк акыллы булырга кирәк. Чөнки аларның сүзе аеруча зур игътибар белән тыңланыла.

Безнең илдә тынычлык өчен көрәш иң беренче нәүбәткә куелган, сугышка өндәү закон белән тыелган. Ләкин империализмның котырган башлары безгә туктаусыз янап торалар. Безнең көчебезнең ныклыгын, акылыбызның камиллеген, хисебезнең сафлыгын сынамакчылар. Вакыты-вакыты белән Рейган кебекләре чикләреннән чыгып китеп, иң томана адәм баласы да әйтмәслек сүзләр ычкындыралар. Без андый провокацияләрне күп ишеткән халык. Көчле, акыллы кеше һәрвакыт сабыр була. Яныып торган кисәү башы белән бомбалар тирәсендә уйнаучыларга ул әшәке уенның нинди катастрофага китерәчәген зур сабырлык, түземлек белән аңлатырга тырышабыз. Әтәчләнүчеләрнең кикрикләрен шиңдерерлек көчебез бар. Шуны күрә торып нигә кизәнәләрдер — һич аңламыйм. Бәлки туктаусыз кизәнеп, безнең матди куәтебезне чикләребезне саклауга юнәлттереп, безне экономик бөлгенлеккә төшерергә омтылалардыр? Нигә үткәннәргә борылып карамыйлар? Сынауларның иң авырларын үз башыннан кичергән халык яши ләбаса Советлар Союзы территориясендә.

Әйе, безне сыныйлар. Без сынатмаска тиеш. Аның өчен безнең рухыбыз һәрдаим нык, акылыбыз аек булырга тиеш. Бүгенге язучының төп бурычы — шуларны акылына, хисенә сеңдергән чын мәгънәсендәге ватандарлар тәрбияләргә булышу.

Иң зур кешелекле идеяләр белән коралланган партиябез бездән шуны таләп итә.

**Флүн Мусин**

# ОЛЫ ЮЛДАН

### ГАРИФ АХУНОВКА — 60 ЯШЬ



Ул әдәбияттагы беренче адымнарыннан ук иҗатын җәмәгать эшчәнлеге белән тыгыз бәйләде. Г. Ахунов республика Язучылар союзының Әлмәт бүлеген оештыручы булды, аннан соң «Казан утлары» журналының җаваплы редакторы, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе һәм секретаре сыйфатында хәзерге татар әдәби хәрәкәтен оештыруда актив катнашты. Г. Ахунов СССР һәм РСФСР Язучылар союзы идарәләре секретаре буларак илебезнең әдәби тормышында да якыннан катнашып килде. Ул партиянең XXV һәм XXVI съездлары делегаты, тугызынчы һәм унынчы чакырылыш СССР Верховный Советы депутаты була. СССР Верховный Советы делегацияләре составында Һиндстанда, Нигериядә һәм Бельгиядә булып кайта.

Г. Ахуновның шундый иҗтимагый активлыгы аның иҗатына зур йогынты ясый. Баштан ук ул тормыш турында тормыштан чыгып язарга тырыша, иҗатының тормышчанлыгы турында кайгырта. 1959 елда дөнья күргән беренче җыентыгында ук яшь автор үзе күргән һәм белгәннәр турында гына язарга теләвен белдерә. Җыентык очерк һәм хикәяләрдән тора. Аларда хәзерге авылның һәм эшчеләр сыйныфының алдынгы вәкилләре, эшчән һәм тырыш кешеләре сурәтләнә. Болар хакында автор җыйнак итеп, тормышчан фактларга һәм детальләргә нигезләнеп сүз алып бара. Шул рәвешле сурәтләнгән эшчән һәм булдыклы колхоз председательләре Хазбулат Сираҗиев («Хазбулатның яңа гадәтләре»), Әхмәдиев («Яңа хуҗа»), авылда төзелеш бригадасы җитәкчесе Миңлегали абзый («Инженер»), балык үрчетүче Нигамь («Күлләр»), бораулау остасы Закир Гарипов («Закир абзый бригадасы»), маляр кыз Әсмагөл («Әсмагөл») образлары хәтергә кереп кала. Биредә автор башлыча геройларының хезмәткә мөнәсәбәте белән кызыксына һәм аларның эшчәнлек сыйфатларын ачуга басым ясый. Шул ук вакытта Г. Ахунов үзенең хикәяләрендә каршылыклырак язмышларга, геройны эчке үсеш-яңарышта тасвирлауга да дикъкать итә. Бу яктан аның «Соңарып килгән бәхет» хикәясе кызыклы. «Егерме ел буена дөньяның иң мәшһүр биючеләрен узып китәм» дип хыялланган, ләкин теләгенә ирешә алмаган, ә кырыкның өске ягына чыккач, баштагы хыялларына кул селтәп, педагоглыкка күчкән Собханкулов турында бара анда сүз.

Автор геройның, олыгая төшкәч, ничек итеп беренче мәртәбә үз эшеннән рухи канәгатьлек табуын күрсәтә. Нефтьчеләр каласындагы зур киңәшмәдә катнашучылар өчен биреләчәк үзешчәннәр концертын әзерләүгә Собханкулов башта бер дә күңел бирмичә, бары югарыдан кушканга гына алына. Ә инде эшкә тотынгач, мавыгып китә һәм соңыннан тырышлыгының бик күңелле нәтиҗә бирүен күргәч, һичкайчан булмаганча шатлана, «бик соң килгән бәхеткә» ирешүен аңлый.

Хикәя жанрына Г. Ахунов иҗатының башлангыч чорында күбрәк игътибар итә. Бу эшчәнлек билгеле бер дәрәҗәдә авторга тагын да колачлырак иҗатка күчү өчен тәҗрибә һәм көч тупларга ярдәм итте. Яшь автор бераздан күләмле формаларда — повестьта һәм романда — эшләр өчен үзендә дәрт һәм дәрман барлыгын аңлый. Аның иҗат йөзе дә шушы формаларда тулырак ачылды. Университетта укыганда күргән-кичергәннәренә нигезләнеп, ул 1955 елда беренче күләмле әсәрен — «Яшьлек яме» повестен тәмамлый. Студент елларының кайнар эзеннән яшьлек дәрте белән язылуы сәбәпле, әсәрдә дөньяга лирик-эмоциональ караш көчле. Студентлар тормышын, яшьтәш геройларның уй-кичерешләрен автор бик якын күреп, күңел җылылыгы белән тасвирлый. Шулай да яшьлек романтикасын чагылдыру аның төп максаты түгел иде. Әсәренең идеясен Г. Ахунов соңрак болай аңлатты: «Яшьлекнең яме нәрсәдә? Хыялланып яши белүдә. Яшьлектә кешенең матди байлыгы булмый, аның бердәнбер хәзинәсе — күңел байлыгы, намусы. Әнә шул намусны яшьтән үк саклый белсәң, хезмәтне юлдаш итеп алсаң — бәхет синнән ерак йөрми». Әйе, повесть үзәгендә яшь чакта, мөстәкыйль тормыш юлына аяк басканда кеше алдына үзгә бер җитдилек белән куела торган «ни өчен һәм ничек яшәү» мәсьәләсе. Төп геройлар — студентлар Таһир, Гөлнур һәм Айрат шушы мәсьәләгә мөнәсәбәттә сурәтләнәләр. Аларның яшәү рәвешен, дөньяга карашларын автор үсеш-хәрәкәттә ача алган. Бу яктан Айрат образы аеруча отышлы күренә. Башта ул укучы алдына бик булдыклы, эшлекле зат булып баса. Тышкы кыяфәте үк («давыл төсле тузган чәчләре, үткен карашлы, акыллы соры күзләре, озынча кылыч борыны һәм кысылган юка иреннәре») аңа «булдыклы, җитди чырай биреп торалар иде». Университетта ул үзен уку отличнигы һәм актив җәмәгать эшлеклесе итеп таныта. Тышкы яктан бик күркәм булып күренгән бу зат белән автор бераздан якыннанрак кызыксына башлый, аның эчке дөньясына үтеп керә. һәм шунда Айратның бөтен тырышлыгы, уй-омтылышлары белән бер нәрсәгә — дан һәм дәрәҗә артыннан куугa юнәлтелгән булуы ачыклана. Нәтиҗәдә ул иптәшләре белән конфликтка керә һәм алар тарафыннан кире кагыла. Уңай геройлар итеп бирелгән Таһир белән Гөлнур образларында исә автор аларның коллективизм, иптәшлек һәм намуслылык кебек сыйфатларын ачуга басым ясый. Алар иптәшләренең дә ихтирамын казаналар.

Бу әсәреннән күренгәнчә, Г. Ахунов үз иҗат биографиясен вузда укыган елларында туплаган тормыш тәҗрибәсенә нигезләнеп башлый. Ә бераздан ул әдәбиятта үз сүзеңне әйтү өчен бу тәҗрибәнең генә җитмәвен, аны тулыландыру, баету кирәклеген аңлый. Моның өчен халык тормышына якынрак булырга, аны ныклап өйрәнергә кирәк иде. 1955 елның январь аенда аны шагыйрь Ш. Маннур үзе белән Татарстанның нефть районнарына алып чыгып китә. Анда алар бер ай буе йөриләр. Бу якларда башланган зур үзгәрешләр яшь язучыга нык тәэсир итә. Биредә ул үзе өчен бик күп яңа нәрсә, озаклап һәм ныклап өйрәнүне сорый торган үзгәреш-яңарыш күрә. «Казылып ташланган чокыр-траншеяларда, кыр уртасыннан узган гудрон юлларда һәм каядыр ашкынып чапкан металл баганаларда әле минем өчен ачылмаган серле бер дөнья торып калды. Әнә шул серләрне ачасы, тойгыларны кәгазьгә төшерәсе килә иде»,— дип яза Г. Ахунов һәм моның өчен Әлмәткә күчеп килә.

Нефть якларындагы тормыштан һәм хезмәт кешеләреннән алган беренче тәэсирләрен яшь автор кәгазьгә төшерергә һәм укучыларга җиткерергә ашыга. Тиз арада нефтьчеләр турында очерк һәм хикәяләр, журналист Ф. Мостафин белән бергә «Җир куенында» исемле пьеса да язып ташлый. Болар яңа зур теманы үзләштерүдә беренче адым була. Шул ук вакытта автор биредә күргәннәрнең аерым очерк яки хикәягә генә сыймавын, күләмлерәк формада чагылдыруны таләп итүен тоя. һәм ул «Хәзинә» исемле роман язарга керешә. Әсәрнең исемен тормыш аңа үзе тәкъдим итә. Нефтьчеләр хезмәте, төрле-төрле язмышлар белән якыннан танышу язучыга яңа теманың социаль-әхлакый асылын тирәнрәк аңларга булыша. Ул, нефть никадәр зур байлык булса да, төп хәзинә җир асты байлыгын табучылар — кешеләр икәнен аңлый.

1957—1961 елларда язылган бу роман шул вакытта безнең әдәбиятта алып барылган идея-эстетик эзләнүләрне дә үзендә чагылдырды. Сүз бирсдә, барыннан да элек, әдәбиятның реаль чынбарлыкка йөз белән борылуы турында бара иде. Әдәби иҗатның тормыш белән элемтәләре ныгу соңгысының үсеш тенденцияләрен тирәнрәк күзалларга ярдәм итте. Язучылар аеруча сугыштан соңгы чорда республикада промышленностьның яңа тармаклары барлыкка килүнең, фән-техника прогрессының татар халкы тормышына ничек тәэсир итүе белән чынлап торып кызыксына башладылар. Республиканы индустриальләштерү процессының яңалык белән искелек көрәшен көчәйтеп җибәрүенә игътибар артты. Бу хәл әсәрләрдә конфликтлылыкның көчәюенә китерде. Шул юл белән җәмгыятьнең социаль-рухи үсеше тагын да ачыграк итеп, динамик рәвештә чагылдырыла башлады.

«Хәзинә» романы Татарстанда сугыштан соң үсеп чыккан нефть промышленностеның республикабыз экономикасына гаять зур үзгәрешләр алып килүе белән бергә, аннан да әһәмиятлерәк процессны да — меңнәрчә татар крестьяннары тормышында һәм язмышында җитди борылыш тудыруын да — ачып бирә. Татар халкы өчен яңа булган бу процессны тирәнрәк гәүдәләндерү өчен Г. Ахунов мәсьәләгә тарихи яссылыкта килә, әсәрне йөзьяшәр Йөзлекәй карчык турындагы сабыр һәм талгын гына хикәяләү белән башлап җибәрә. Автор аның «татар авылларында сирәк очрый торган озын гомерле һәм хәсрәт-кайгыны батыр күтәрә алган чыдам кешеләрнең берсе» булуын әйтә. Үз гомерендә күпне күреп, күпне кичергән бу карчыкның зур тормышы, әйтерсең, аның туган җире Кәлимәтнең авыр үткәнен алга бастыра. Һәркем кебек, Кәлимәт кешеләре дә гомер-гомергә матур тормыш турында хыялланганнар. Бәхетне үз җирендә тапмагач, алар «Кара шәһәр» Бакуга, Грозный якларына китеп барганнар, нефть промышленниклары кулы астында, кысан, кара баракларда яшәп, үрчеп, җан биргәннәр, кара сакалларын кая барсалар да ияртеп йөргәннәр. Бәхетнең бик якында гына, аяк баскан урында гына булуын, җир токымнары аркылы тирәнгәрәк карый белергә генә кирәк икәнен белмәгәннәр. Моның өчен «илне җәбердән коткарырга», «меңнәрнең күзен ачарга» кирәк булган.

Үткәнгә шундый караш ташлаганнан соң, автор хәзерге заманга борыла: роман битләренә реаль тормышның катлаулы вакыйгалары килеп керә, төрле-төрле язмышка, омтылышларга һәм характерларга ия булган геройлар калкып чыга.

Алга таба әсәр үзәгенә Йөзлекәй карчык улы Шәвәли семьясын куеп, автор тормышта искелек белән көрәштә яңаның җиңә баруын төрле яклап ача. Семья башлыгы Шәвәли образында без иске дөнья гореф-гадәтләре һәм яшәү принципларының яңа чынбарлык басымы астында чигенә баруын күрәбез. Шул нигездә геройның электәге үз-үзенә ышанычы югалуы да тормышчан детальләрдә күрсәтелә. Әйе, аның гайрәтле заманнары, «бер кычкырып җибәрсә, тавышы өч чакрымдагы Торналы авылына ишетелә торган чаклары» инде сагынып сөйләргә генә калган иде. Соңгы елларда «каты кара сакалы җитен сүсенә әйләнгәч, бер-бер артлы йортны ташлап чыккан балалары өчен, көн саен туза, җимерелә барган хуҗалыгы өчен борчылу, кайры корты кебек, йөрәген кимерә башлады».

Геройның рухи эволюциясен ачу өчен дә автор кызыклы һәм мәгънәле детальләр таба. Баштарак, үз-үзенә, дөнья котә белүенә чамадан тыш нык ышанган заманда, Шәвәли «Уралгамы, Бакугамы нифте чыгарырга киткән» күршесе Лотфулла Дияровны, тормыш итә белми торганрак кеше итеп, үзен аңардан өстен куеп карый. Әмма байтак еллардан соң Лотфулланың танылган нефть мастеры булып элекке нигезенә кайтып төшүе, гөрләтеп яши башлавы картның әлеге карашын җимереп ташлый. Лотфулланың көн саен иртән бер үк вакытта «шыгырдап торган каты кожаннан һәм таза күн итекләрдән эшкә барырга чыгуын» Шәвәли читән буена басып, «көнләшүгә якын бер хис белән» озатып кала башлый.

Дияров белән Шәвәли образларын чагыштырып сурәтләү аша автор романның төп идеясен үтә бер көч белән яктыртуга ирешә. Әсәрдә Лотфулла «муеннарын күккә сузган кран-манаралары» белән туып килүче яңа Кәлимәт кешесе итеп, Шәвәли исә яңа шәһәр күләгәсендә ничектер кечерәеп, мескенләнеп калган иске Кәлимәт кешесе итеп бирелә.

Әгәр Шәвәли образында иске тормыш фәлсәфәсенең, яшәү принципларының яңа чынбарлык белән бәрелешләрдә какшый һәм җиңелә баруы гәүдә-

ләндерелсә, аның кызы Фәйрүзә язмышында исә әнә шул яңа чынбарлык йогынтысында кеше рухының үзгәрүе, баюы чагылыш таба. Шул ук вакытта автор биредә бик әһәмиятле процессны — авыл кешесенең элекке татар тормышына хас булмаган яңа үзенчәлекле өлкәләргә күчүен, шул нигездә аның профессиональ һәм интеллектуаль яктан үсүен күрсәтә.

Роман идеясен ачуда зур роль уйный торган һәм язучының кызыклы ачышы булган тагын бер образ бар. Ул — бораулау мастеры Кәрим Тимбиков. Аның характер үсеше чынбарлыкның конкрет шартлары белән бәйләп күрсәтелә. Ачыграк әйтсәк, Кәримдә мин-минлек, дан артыннан куу кебек сыйфатларның көчәеп китүендә рекорд куюо белән мавыгуның роле зур. Производствога җитди зыян китергән бу зарарлы практиканың аерым кешеләр үсешенә һәм язмышына кире йогынты ясавы күрсәтелә әсәрдә. Трест җитәкчелеге тарафыннан аның бригадасы өчен махсус шартлар тудырылу сәбәпле, бораулауда рекорд артыннан рекорд кую Тимбиковны масайтып җибәрә. Шул ук вакытта геройның дөньяны аңлавы чамалы икәне, аңа әчке культура җитмәве ачыклана. Әмма беренче уңышлардан башы әйләнгән һәм үзен талант дип әйткәнгә чынлап ышанган Кәрим боларны сизми һәм ул үсүдән туктый, рухи яктан бушый-саега бара. Автор моңардан фәлсәфи нәтиҗә ясый: «Ә табигать бушлыкны яратмый, буш урынны тутырырга омтыла». Геройның характеры белән рухи дөньясы арасындагы бәйләнеш өзелә һәм бу хәл аны котылгысыз рәвештә һәлакәткә алып килә.

Геройларының шактый үзенчәлекле тормыш юлын, рухи эволюциясен сурәтләп чыкканнан соң автор шулар нигезендә әсәрнең төп идеясен раслый торган нәтиҗәләр ясый. Ягъни һәр персонаж язмышы, тегеләйме-болаймы, тормыштагы яңалык белән искелек көрәшен, бу көрәштә яңалыкның җиңеп чыгуын раслый. Кыю рәвештә алга карап, тормышның көчле агымыннан төшеп калмаска тырышып яшәгән геройлар теләкләренә ирешә баралар. Шәвәли карт кызы Фәйрүзә, мәсәлән, күңеле теләгән эш табып һәм сөйгән кешесенә иргә чыгып, матур семья кора, Арслан үзенә тиң Сәгыйдәгә өйләнә. Ә инде заман белән бергә атлый алмаган, иске гореф-гадәтләргә һәм карашларга буйсынып яшәгән персонажлар тормышта җиңелүгә дучар булалар һәм читкә алып ташланалар. Монысы Шәвәли карт белән Кәрим Тимбиков образларында чагылыш таба. Бу уңайдан автор әсәр идеясен исбатлый торган кызыклы бер символик чагыштыру да китерә. Тимбиков аварияга эләгеп һәлак булган көнне Фәйрүзәнең баласы дөньяга килә. Бу факт тагын бер мәртәбә чынбарлыктагы мәңгелек туу-яңару процессын, тормышның искелектән арынып яңага күчә баруын, аның бернигә карамый алга атлавын раслый.

Шушы гомум процессны конкрет милли җирлектә, гыйбрәтле язмышлар аша ышандырырлык итеп чагылдырган «Хәзинә» романы бәхетле язмышка дучар булды: ул хәзерге татар прозасының эшчеләр сыйныфы турында иң уңышлы әсәрләреннән берсе булып танылды, татар һәм рус телләрендә берничә мәртәбә басылды, аның буенча шул ук исемдәге нәфис фильм куелды.

«Хәзинә»дә сурәтләнгән чынбарлык гаять күпьяклы һәм катлаулы иде, шуңа күрә әдип аның турындагы уй-фикерләрен бер әсәрдә генә чагылдырып бетерә алмады. Бу тема өстендә эшләвен ул алга таба да дәвам итте. «Хыялый Хәйрүш егетләре» повестен һәм, шушы әсәрне драматургия теленә күчереп, «Утлар яна уракта» исемле пьеса язды. Аларда нефтьче яшьләрнең үзара мөнәсәбәтләре, ярату-мәхәббәт тойгылары йомшак лиризм белән сугарылган. Бераздан Г. Ахунов кабат «Хәзинә» геройларына әйләнеп кайта һәм аларның киләчәк язмышларын чагылдырган «Хуҗалар» романын яза. Гәрчә бу әсәрдә дә геройларны иҗтимагый җирлектә, хезмәткә мөнәсәбәттә күрсәтүгә басым ясалса да, биредә авторга дәлилле фикерләү җитенкерәмәде. Бигрәк тә үзәк герой — промыселлар идарәсе начальнигы Арслан Гобәйдуллинны акыллы һәм эшлекле җитәкче итеп күрсәтү теләге шактый декларатив төстә хәл ителә. Ә менә персонажларның шәхси язмышларын һәм уй-кичерешләрен сурәтләүдә уңышлы гына адымнар ясала.

Тынгысыз күңелле автор боларак, Г. Ахунов иҗади эзләнүләрен дәвам итте. Ул иҗатының һәм тематикасын, һәм проблематикасын киңәйтергә, баетырга омтыла. Алтмышынчы еллар башында ук аңарда тарихи-революцион темага роман язу теләге туа. Шул чакта бик катлаулы язмышка очраган бер кеше белән танышу нәтиҗәсендә туган бу ниятен тормышка ашыру өчен ул җиң сызганып материал җыя башлый, татар халкының XX йөз башындагы тормышын ныклап өйрәнергә керешә. Шушы максатта Әгерҗе якларына барып чыккач, анда бер милиция капитаны белән танышып аның гыйбрәтле тарихын

белә. Бу тарих аны, әлеге романны калдырып торып, яңа әсәр язуга рухландыра. «Чикләвек төше» повесте әнә шулай языла. Тормыш материалы әсәрнең стиленә һәм пафосына ныклы эз сала. Геройның авыр һәм киеренке заманнарга туры килгән кырыс язмышы реаль хәлендә һәм үз төсендә сурәтләнә. Повестьның хикәяләү алымы шактый үзенчәлекле. Анда сүз гомер буе иреннән аерылырга теләп тә аерыла алмаган хатын исеменнән алып барыла... Табигый, хикәяләүче үзе сөйләгәннәргә битараф булып кала алмый, үз позициясен һәм бәясен чагылдырып килә. Монда хикәяләүче Рокыя белән аның ире, үзәк герой Халикъ Саматовның тормышта капма-каршы позицияләрдә торган затлар булулары да үз ролен уйный. Башта мещанка рухлы Рокыя фикерләве аша ир белән хатынның яшәү максатлары һәм принциплары бик төрле булуы үзгә бер кискенлек белән ачыла. Әсәрдә иң әһәмиятлесе, әлбәттә, Саматовның тирән мәгънәле тормыш юлын, яшәү рәвешен һәм принципларын ачу. Автор үз героеның гомум мәнфәгатьләр өчен янып яшәүче, нык рухлы һәм эшкә бирелгән шәхес булуын күрсәтүгә аеруча басым ясый. Үз гомерендә кайда гына булырга һәм нәрсә белән генә шөгыльләнергә туры килми аңа! Саматов байтак вакытлар милиция органнарында хезмәт итә, аннары аны Идел-Балтик каналы төзелешенә җибәрәләр, анда бераз эшләгәч, ул туган якларына кайта һәм аңа һөнәр училищелары белән җитәкчелек итү эше йөкләнә. Саматов, кайда гына булмасын, үзенә тапшырылган эшне бөтен күңелен биреп башкара. Шундый сыйфатка ия булган коммунист Саматовны илленче еллар уртасында тагын бер җаваплы участокка — авылга утызмеңче итеп җибәрәләр. Әсәрнең байтак өлешендә геройның менә шушы соңгы эшчәнлегe яктыртыла. Биредә Саматовны авыл җитәкчесе итеп күрсәтүгә, аның җитәкчелек стилен һәм принципларын ачуга зур урын бирелә. Үз хезмәтенә ул бик җаваплы карый һәм булсынга эшли. Аның гадәттән тыш тырышлыгы белән колхоз тиз арада аякка баса. Бу яктан Саматов илленче еллар башы прозасындагы нык ихтыярлы җитәкчеләрне хәтерләтә кебек. Әмма үзенең эш принциплары буенча ул әлеге шәхесләрдән шактый аерыла. Ул волюнтарист түгел, бәлки акыл белән, нык уйлап эш итә торган җитәкче. Авылга килүгә герой экономиканы өйрәнә башлый. Формализмның дошманы булган Саматов хуҗалыкны үстерүнең экономик яктан нигезләнгән һәм акланган принципларын алга сөрә. Бу юлда аңа еш кына гадәти карашлар һәм күнегелгән принциплар белән конфликтка керергә туры килә. Менә ул, бер яктан, колхоз экономикасын ныгыту, икенче яктан, туфракның уңдырышын күтәрү нияте белән җитен һәм күпьеллык үлән чәчәргә керешә. Ә бу вакытта үлән чәчү системасы кире кагылган була һәм бераздан өлкә газетасында Саматовны тәнкыйтьләп «Травопольный король» дигән мәкалә чыга. Районнан исә аны клевер җирләрен сөреп ташларга мәҗбүр итәләр. Нәтиҗәдә моңа кадәр сөт тапшыруда районда беренче булып килгән колхоз, «яшен сугып сындырган агач төсле, кинәт артка авып» төшә. Ә менә җитен чәчү колхозга зур файда китерә. МТС техникасын колхозларга сату башлангач, бары Саматовның гына бу техниканы алырга мөмкинлеге булуы ачыклана.

Кыскасы, Саматов — аек акыл белән, алга карап эш итә торган җитәкче. Геройның ничек эшләвен сурәтләү белән бергә, автор аның ни өчен эшләвенә, бу эшчәнлекнең социаль-әхлакый максатларына да дикъкать итә. Колхоз экономикасын күтәрү Саматов өчен һич тә үзмаксат түгел. Аның көнне-төнне, алны-ялны белмичә, бик күп бәлаләр һәм кыенлыклар кичереп тырышуының төп максаты — авыл кешесенең тормышын яхшырту. Шушы хакыйкатьне аңлаган колхозчылар, гәрчә баштарак яңа председательне таләпчәнлеге һәм кырыслыгы өчен өнәп бетермәсәләр дә, бераздан аны иң якын һәм хөрмәтле кешеләре итеп күрә башлыйлар. Авыл кешеләренең үз җитәкчеләренә шушындый мөнәсәбәтен калку итеп чагылдыру өчен автор үтемле деталь тапкан. Соңыннан үз белдеге белән эш иткән өчен райком Саматовны председательлектән азат итәргә теләгәч, колхозчылар аны ярдәм яклап чыгалар. Биредә җитәкче белән коллективның бердәмлеге сәнгать чаралары аша ышандыргыч итеп ачыла.

Шул ук вакытта автор Саматов сайлаган яшәү рәвешенең һәм принципларының безнең тормышта иң дөрес һәм гадел булуларын, шул сәбәпле, башкаларга да тәэсир итүләрен әсәрнең буеннан-буена күрсәтеп килә. Бу хәл бигрәк тә Рокыя образында ачык чагыла. Баштарак дөньяга карашы ягыннан иреннән бик ерак торган, аны аңламаган һәм аңларга да теләмәгән Рокыя, Саматовның гомум эш өчен никадәр тырышуын еллар буе күреп килә торгач, аның кешелек асылын, намуслы шәхес булуын аңлауга кадәр күтәрелә. Героиня иренең, бик зур кыенлыкларга, гаделсезлекләргә дә карамастан, үзе сайлаган

юлдан читкә тайпылмыйча бара алуының серләре белән дә кызыксына. Саматов аңа болай дип җавап бирә:

«Беләсеңме... тормышта төрле хәл булуы мөмкин. Әгәр кешенең үзәге чын булса, ягъни чикләвекнең төшенә зыян килмәсә, ул тагын тернәкләнә, тагын яңа үсенте бирә... Яшермим синнән, әйтәм: үзәгемне саклыйм мин, төшемне. Мине туктаусыз дөмбәсләп чыныктыралар».

Күпләргә үрнәк булырлык кешелек сыйфатлары, яшәү рәвеше белән Саматов хатынын «үз юлы белән алып» китә, аңа баштагы мещанлык фәлсәфәсеннән һәм тар карашларыннан арынырга ярдәм итә, дөньяга башкача карарга өйрәтә.

Халикъ Саматовны халык интереслары өчен янып яшәүче намуслы, принципиаль һәм эшлекле шәхес итеп күрсәтүе белән Г. Ахунов заман героен әдәбиятта чагылдыруга үзеннән лаеклы өлеш кертте.

«Чикләвек төше»ннән соң Г. Ахунов кабат тарихи-революцион роман язу эшенә әйләнеп кайта. Әсәрне язарга керешкәнче бик тырышып материал җыя. Үзен кызыксындырган тарихи урыннарда була, архивларда утыра, иске газета-журналларны актара. Шундый эзләнүләр дәвамында аның тәүге планы киңәя, тирәнәя бара.

Автор моның белән генә дә чикләнми. Бүгенге көн әсәрләре булган «Хәзинә» романы һәм «Чикләвек төше» повестеннан егерменче гасыр башы тормышына йөз тотачак «Идел кызы» трилогиясенә җанлы күпер салыр өчен беренче бишьеллык каһарманнарын өйрәнүне дә үзенә бурыч итеп куя. Шул нигездә «Ардуан батыр» повесте иҗат ителә. Тормышның шактый ук авыр чагын, куәтле техника да, тәҗрибә белән белем дә җитмәгән дәверен, ләкин берни белән дә алыштыргысыз энтузиазм, кыенлыкларны җиңә белү, якты киләчәк хакына үз-үзеңне аямау, хәтта корбан итүгә кадәр бару — беренче бишьеллыкның бөек төзелешләрендә катнашкан кешеләргә хас шушы сыйфатлар язучыны егерменче гасыр башы революционерларына китереп тоташтыра. Трилогиянең «Идел кызы» исеме астында дөнья күргән беренче китабында вакыйгалар революция алды елларыннан алып утызынчы еллар башына кадәрге тарихи чорда бара. Шундый киң колачлылык әсәрнең күп вакыйгалы һәм күп геройлы булуына китергән. Өч йөз алтмыш йортлы Зартугай авылының XX йөз башындагы әле шактый талгын аккан тормышын сурәтләүдән башлап, автор алга таба хикәяләү диапазонын киңәйтә бара. Авылдан вакыйгалар Идел, Кама буйларына, Казанга күчә. Әсәргә төрле сыйныф һәм катлау вәкилләре килеп керә. Романның шушы күпсанлы геройлары автор тарафыннан төрле күләмдә һәм төрле рухта тасвирлана. Бер ишеләре эпизодик рәвештә генә сурәтләнсәләр, икенчеләре бөтен әсәр дәвамында күрсәтеләләр. Яңа тормыш төзү өчен көрәшкә актив катнашкан геройлар — Шәяхмәт Айдаров, Шәймәрдән Ибраһимов, Нәҗия Уразаева һәм башкалар күбрәк шушы көрәш яссылыгында һәм публицистик пафос белән гәүдәләндереләләр. Автор башлыча аларның көрәшче сыйфатлары белән кызыксына. Шунлыктан әсәрдә мондый персонажларның революциягә бирелгәнлеге, яңа тормыш дошманнарына каршы үз-үзләрен аямыйча көрәшүләре аеруча ачык булып алга баса. Кайвакыт революцион аскетизм идеясе дә чагылып китә.

Яшь геройлардан Солтан белән Нурияне сурәтләгәндә авторны күбрәк аларның балалык елларыннан алып егет һәм кыз булып җиткәнчегә кадәрге чордагы шәхси тормышы һәм күңел дөньясы кызыксындыра. Бу хәл хикәяләүнең пафосына да йогынты ясамый калмый. Әлеге персонажларны сурәтләгәндә лирик буяуларга еш мөрәҗәгать ителә. Солтан белән Нуриянe, аларның үзара мөнәсәбәтләрен тасвирлаудагы лиризм чорның кырыслыгын һәм кискенлеген контраст итеп күрсәтергә дә булыша кебек.

Әсәрнең иң зур уңышы, әлбәттә, Габбас мулла образы. Бу образ белән Г. Ахунов тарихи-революцион темага багышланган прозабызның геройлар галереясын баета, әдәбиятка яңарак тип персонажны алып килә. Моның нигезендә әлеге киеренке чорга автор карашының киңәюе, аны бөтен катлаулылыгында күрсәтергә омтылу ята. Биредә «Тын Дон» эпопеясын татарчага тәрҗемә итү дәвамында М. Шолоховның иҗат манерасы беләнныклап танышуның да билгеле бер катнашы булгандыр, күрәсең. Чөнки Габбасның тормышта үз-үзен тотышында «Тын Дон»дагы Григорий Мелехов белән беркадәр авазлашлык сизелә. Бу фаҗигале язмышның төп сәбәбен Г. Ахунов та кешедән сыйнфый позицияңне ачык билгеләүне сораган киеренке һәм дәһшәтле заманда геройның тормышта үз урынын таба алмавы, урталыкта калуы белән бәйләп аңлата. Очраклы рәвештә генә кара мужиктан мулла булып киткән Габбас

үзен шундый дәрәҗәгә күтәргән авыл байлары арасында да ала карга булып кала, шул ук вакытта үзе туган социаль җирлектән дә аерыла. Гүяки ул җир белән күк арасында эленеп тора. Менә шушы сыйнфый хәленең һәм кыйблалсының анык булмавы аны фаҗигале язмышка дучар итә. Бу язмышны дөрес һәм ышандырырлык итеп ачып бирү теләге автордан төпле психологик анализны һәм трагедия чараларын куллануны да таләп иткән.

Г. Ахунов романы хәзерге әдәбиятта елдан-ел ачыграк күзаллана торган бер тенденцияне чагылдыра. Сүз тормышны аерым бер яссылыкта гына түгел, бәлки бөтен барлыгында, колачлап алып күрсәтергә омтылу турында бара. Хикәяләүнең идея-эстетик яктан күләмле һәм киң гомумиләштерелгән булуына ирешү теләге белән бәйләнгән бу тенденция жанр структурасына да кагыла. Нәтиҗәдә хәзерге әдәби жанрлар, беренче чиратта роман, төрле жанр сыйфатларын үзендә туплаган синтетик формага әверелә. «Идел кызы»н да моңа кадәр әдәбият фәнендә һәм тәнкыйтьтә кабул ителгән социаль-психологик роман, семья-көнкүреш романы, публицистик роман яки тарихи хроника чикләрендә генә карап булмый. Чөнки аңарда мондый жанр төрләренең һәркайсының сыйфатларын табарга мөмкин. Роман структурасын болай катлауландыруы, аңа синкретик төс бирергә омтылуы белән Г. Ахунов хәзерге гомум идея-эстетик эзләнүләр юлыннан баруын күрсәтә.

Г. Ахунов иҗаты күп тармаклы. Аны әдәбиятның төрле-төрле өлкәләре кызыксындыра. Драматургиягә мөрәҗәгать итеп ул «Җир куенында» (Ф. Мостафин белән бергә), «Утлар яна учакта», «Ардуан батыр» (шул исемдәге повестька нигезләнеп), «Чулпы җыры», «Икәүдән икәү генә» пьесаларын язды. Аларда 20—30 еллардагы хезмәт героикасы, үткәндәге һәм хәзерге авыл, нефтьчеләр тормышы сурәтләнә. Автор күбрәк геройларының хезмәткә мөнәсәбәте, рухи-әхлакый йөзе белән кызыксына.

Г. Ахунов иҗатының прозадан кала икенче әһәмиятле өлкәсен әдәби тәнкыйть белән публицистика тәшкил итә. Әдәбияттагы беренче адымнарын тәнкыйтьче буларак башлап җибәргән автор, гәрчә бераздан прозага күчсә дә, баштагы эшчәнлеген дә ташламый. Газета-журналларда әдәбиятның гомуми торышына яки теге-бу мәсьәләләренә, аерым язучыларга багышланган чыгышлары даими рәвештә күренеп тора. Моннан тыш, ул сәнгатьнең башка тармаклары вәкилләре турында да әледән-әле мәкаләләр белән чыга. Аның әдәби тәнкыйтькә караган чыгышларының бер өлеше «Әдәби язмышлар» исемле җыентыкта дөнья күрде.

Г. Ахуновның мөһим стиль сыйфатларыннан берсен тәшкил иткән публицистлык, һичшиксез, аның публицистика жанрында актив эшләве белән бәйләнгән. Ул — иҗтимагый-политик темаларга багышланган күп санлы публицистик мәкаләләр, замандашларның хезмәттәге батырлыкларын чагылдырган очерклар, туган якның үткәне һәм бүгенгесе турындагы документаль язмалар авторы. Алар республика һәм үзәк матбугат битләрендә, аерым җыентыклар һәм китаплар рәвешендә дөнья күрделәр. Соңгылары рәтенә «Без яшибез Әлмәттә», «Канатлар кая илтә» һәм «И кадерле туган як» (М. Зарипов белән берлектә) дигән китаплар керә. Бу төр иҗатында Г. Ахунов заман белән тыгыз бәйләнештә, аның мөһим проблемалары белән кызыксынып, аларны өйрәнеп һәм үз мөнәсәбәтен белдереп яшәүче гражданин әдип булып алга баса. Авторның актив тормыш позициясен чагылдыру белән бергә, публицистика һәм тәнкыйть Г. Ахунов иҗатында кайвакыт үзара керешеп тә китәләр. Моның ачык мисалы — «Йолдызлар калка» китабы. Әсәр үзендә төрле характердагы материалны берләштерә. Автобиографик тасвирламалар да бар анда, аерым язучыларның тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтен яки иҗат йөзен чагылдырган эпизодлар да, әдәби тормыш күренешләре дә, авторның әдәби хәрәкәт һәм аерым язучылар иҗаты турында күзәтү-уйланулары да, үз иҗат лабораториясенә алып керүләр дә бар. Материалның мондый төрлелеге язучыга әдәби тормыш мозаикасын тудырырга булышкан. Бу төрлелек үз чиратында хикәяләү стилендә дә чагыла. Анда автобиографик хикәяләү алымнары тәнкыйть мәкаләсе стиле белән, көндәлек язмалар стиле мемуар стиле белән үзара үрелеп бирелә.

«Йолдызлар калка»да төп герой — автор үзе. Сюжет аның искә төшерүләрен, көндәлек язмаларын, әдәби хәрәкәт һәм аерым язучы иҗаты турында уйлану-күзәтүләрен, үз иҗат тәҗрибәсен һ. б. сөйләп баруга корыла. Минем

уемча, мондый ирекле хикәяләү кайвакыт авторны идея-эстетик кыйммәте чамалырак булган фактлар һәм детальләр белән мавыгуга да китерә. Алар күбрәк язучының үзе һәм үз семьясы турында сөйләгән эпизодларда чагылалар.

Әдәби иҗатны баштан ук актив иҗтимагый эшчәнлек белән тыгыз бәйләгән Г. Ахунов үз әсәрләрендә һәрвакыт тормышның үзәк проблемаларына һәм әйдәп баручы геройларына йөз тота, аларны әле кырыс реалистик, әле лирик-эмоциональ, әле публицистик пафос белән чагылдыра. Шул ук вакытта язучы стиленең төсләргә һәм тасвир чараларына баюы, структур яктан катлаулану юнәлешендә үсүе күзгә ташлана. Әдип талантының күпкырлы булуын, аның төрле яклап ачылуын күрсәтү белән бергә, бу хәл аның стиле камилләшүе, иҗади эзләнүләргә аваздашрак була баруы турында сөйли.

Баштан ук әдәби сәләтен халыкка тугры хезмәт итүгә багышлаган, заманның мөһим мәсьәләләре турында уйланган, шуларны сәнгатьчә хәл итәргә омтылган Г. Ахуновның иҗтимагый-әдәби эшчәнлеге югары бәяләнде. Иң әүвәл язучының иҗади язмышында зур роль уйнаган, аны әдәбиятның олы юлына чыгарган Әлмәт җире «кара алтын» табучыларның тормышын һәм хезмәтен сәнгатьчә яктыртуда актив һәм нәтиҗәле катнашканы өчен аңа зур хөрмәт күрсәтте: Г. Ахуновка Әлмәт шәһәренең почетлы нефтьчесе дигән мактаулы исем бирелде. Язучының күкрәген Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Халыклар дуслыгы орденнары бизи, ул Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, РСФСРның атказанган культура работнигы исемнәрен йөртә.

Гариф Ахуновны бәхетле язучы диләр. Әйе, бу чыннан да шулай. Әмма бу бәхетне аңа нинди дер мифик бәхет кошы китереп бирмәде. Әлеге бәхетне ул үзенең намуслы, тырыш хезмәте белән яулады. Бу бәхет аңа тормышта һәм иҗатта һаман да яшь булып калырга ярдәм итә, аны яңа иҗади эзләнүләргә рухландыра.

## Фоат Галимуллин

# ТАКЫЯЛАР БАЛКЫШЫ

М. МАЛИКОВАГА — 50 яшь



Табигатькә күз төсләре иңә башлады. Урман-кырлар алтын төскә манылды, игеннәре җыеп алынган басулар күпереп торган кара туфракка әверелде. Күзге агачлардагы яфракларның төсмерләрен рәссамнар да тәгаенләп бетерә алмыйдыр, мөгаен... Шулай да иртә күзнең иң хозур билгесе — ул муллык.

Табигать баласы булган кеше гомеренең дә үз фасыллары бар. Ниндидер бер яшькә җиттеме, ул үзе дә, аны белгәннәр дә әнә шул вакыт чигендә башкарылган эшкә күз төшерәләр. Җыярлык, кеше күзенә күренерлек уңыш бармы? Һәм бу табигый дә. Без һәммәбез дә бары тик кылган гамәлләребез, кешеләргә, җәмгыятькә булган мөнәсәбәтебез белән генә тәкъдир ителәбез. Яулап алган абруебыз хезмәтебезгә бирелгән иҗтимагый бәя ул.

...Мәдинә Маликова башта хикәяләр язды, аларны вакытлы матбугатта бастыра килде, аннан соң 1967 елда «Юлдашлар» дигән җыентыгында туплап чыгарды. 1971 елда аның «Казан каласы — таш кала» исемле повесте дөнья күрде. Һәм, әйтергә кирәк, әдәбиятта тыйнак кына, уйлап кына, җиренә җиткереп язарга омтылучы, пөхтә эшләүче прозаик пәйда булды. Менә шулай итеп ул күпләгән хикәяләр, дистәгә якын повесть, бер роман бастырды. Әгәр дә М. Маликованың профессиональ язучы гына түгеллеген дә искә алсаң, егерме еллык иҗат өчен болар аз түгел. Ул бит әле бер үк вакытта «Азат хатын» журналының җаваплы секретаре да, күп төрле җәмәгать эшләренә өлгерүче дә һәм гаилә алып баручы уңган хатын да, йомшак күңелле ана да.

Сүз уңаенда шунысын әйтү дә мөһим: М. Маликова — татар әдәбиятында хатын-кыз язучы тарафыннан иҗат ителгән беренче романның авторы.

Язучы иҗатта төрле темаларга мөрәҗәгать итә. Аны тормышчан проблемаларның әхлакый катламы кызыксындыра. Нәкъ менә шушы әйбер аның иҗатын бербөтен итә.

Бу совет әдәбиятының төп максатыннан, аның асыл сыйфаты булган гуманизмнан килеп чыга. Әнә шулай итеп, замандашларыбызның әхлакый сыйфатларын, аларның рухи дөньяларын сәнгатьчә өйрәнү әдибәнең бөтен иҗаты буенча кызыл җеп булып сузыла. М. Маликова халыкның гомер-гомердән килә торган яхшы әхлакый-этик сыйфатларының хәзерге яшьләрдә ни рәвешле дәвам итүен, үстерелүен, яңа төсмерләр белән баетылуын күзәтергә ярата. Автор кешеләр мөнәсәбәтендәге сафлыкны, эчкерсезлекне яклый. Аның үткен күзләре беренче карашка интеллигент кебек күренгән, яхшы манераларга ия булган кешеләрдәге буш күңеллелекне, әхлакый бозыклыкны тиз сизә. «Сары тюльпаннар» хикәясендә автор болай уйлана: «Бер нәрсәне һич кенә дә башыма сыйдыра алмыйм — ул да булса мәхәббәт өлкәсендә хыянәтнең, ялганның, мәрхәмәтсезлекнең, шәфкатьсезлекнең җәзасыз калуын».

Әйе, җәмгыятьтә кешеләр үз эш-хәрәкәтләрен нигездә ике төрле үлчәүгә салып карыйлар — хокук кануннары һәм әхлак критерийлары үлчәвенә. Аларның беренчесе мәгълүм закон актлары белән беркетелгән булса, икенчесен гадәттә язылмаган, әмма күпчелек тарафыннан һич шикләнми кабул ителгән гореф-гадәтләр тәшкил итә. Әмма тормыш үзе катлаулырак, ул кагыйдәләргә генә сыеп бетә алмый. Кайвакыт беренче карашка яхшы дигәнең начар, начар дигәнең яхшы булып чыгуы да бик мөмкин икән. «Сары тюльпаннар» әсәренең героинясы Люцияне кайсысына кертергә? Аңардагы яхшы сыйфатлар бернечә кешегә җитәрлек. Институтны бик яхшы тәмамлаган, аспирантурада калдырылган, егерме биш яшендә фәннәр кандидаты булган, хәзер докторлык диссертациясе өстәлендә ята. Егетләр дә аны яратмаганнар түгел, тик кыз үзенең үтә эшлекле булуы, җитди кыяфәте белән аларны бераз куркыткан, читләштергән. Әсәрдәге бер персонаж аңа болай бәя бирә: «һәрнәрсәне артык җитди итеп кабул итә. Берәр егетнең үзенә күңеле төшкәнен сиздe исә, бу миңа гомерлек яр була алырмы, мәхәббәте чынмы моның, юкмы дип тикшерәнә башлый, егетне микроскоп астына салгандай итә. Кемгә ошасын микроскоп астына керү!» Шушылай сайлану аны ялгызлыкка дучар иткән. Люция үзен яратучы булса, аның ямьсезлегенә дә риза булыр хәлгә җиткән... һәм көннәрдән беркөнне ул үзеннән сигез яшькә кечерәк егеткә гашыйк була. Тик кешеләрне микроскоп аша карарга сәләтле Люция бу егетнең гашыйк ролен оста башкаруын абайламый кала. Әлеге егет, үзенең уенын уйнап туйгач, икенче бер кызга өйләнә. Бу — Люциянең үз хатасы өчен алган җәзасы. Әмма безнең героинябыз эчкерле дә икән һәм ул әхлак кануннарын атлап чыгарга да сәләтле икән. Кияү белән кәләш Загс ишегеннән чыкканда Люция кара «Волга»га утырып килеп җитә һәм, башыннан аягына кадәр карага киенгән хәлдә, яшь пар аягы астына сары тюльпан чәчәкләрен ташлый. Әгәр табигатьтә кара чәчәкләр булса, ул, әлбәттә, чәчәкләрнең кара төслесен китергән булыр иде. Тик табигать кайбер кешеләр кебек рәхимсез түгел, анда чәчәкләрнең кара төслесе юк.

Хатын-кыз күңелендә бара торган мондый нечкә тирбәлешләрне һәм аның холык-фигылен шулай табигый итеп сизү, сурәтләп бирү әдибәгә җиңелрәк бирелә. Ул язганнар ышанычлы яңгырый. Әлеге хикәя вакыты белән салмак, кирәк чакта өермәләр ясап ага. Авторны бередә дидактизм да сагалап тора, ләкин М. Маликова аннан котыла алган.

«Узма, гомер» әсәре дә үзәккә кешенең катлаулы тормыш юлы куелу белән игътибарны җәлеп итә. Утыз яшьләрне узган Зәйтүнә исемле ханым санаторийда өлкән яшьләрдәге Степан Петрович дигән кешене очрата, сүзләре килешеп китә һәм ул аңардан күңелендә иң тирән яткан серләрен сөйләтүгә ирешә. Әсәрнең прелюдиясен тәшкил иткән беренче битләрдә үк автор безне хатын-кызның үзенә бертөрле психологиясенә алып кереп китә. Ул үзенчәлекнең берсе шуннан гыйбарәт: хатын-кыз, үзе никадәр көчле ихтыярлы һәм сәламәт булмасын, ул ир кешенең яклавына мохтаҗ, күңел рәхәтлеге өчен генә булса да үзен кемнәрнеңдер яклавын көтеп яши. Укучылар хәтерлиләрдер, Г. Мопассанның «Сөйкемле дус» әсәрендә Клотильда дигән хатын Дюруа белән арзанлы ресторанnарда йөри. Никадәр гаҗәп тоелмасын, югары даирәләрдә яшәгән әлеге мадам үзен бередә кемнең дә булса мыскыллавын һәм Дюруаның аны яклап сугышуын тели. Зәйтүнә белән дә шуның сыман хәл килеп чыга. Берәү аңа төбендә мыскыллы мәгънә яткан тәртмәле сүз әйтә. Степан Петрович исә шушы чарасыз ханымны үз канаты астына ала. Шул җирлектә бу икәү арасында ышаныч барлыкка килә, күңелендәгеләрне бер-берсенә сөйләү теләге уяна.

Әдибәне бу өлкән кешенең хатын-кызга мөнәсәбәте күбрәк кызыксындыра, шул юл белән ул аның кешелек сыйфатларын ачып салырга тели. Ир кешенең

кем икәнен белергә теләсәң, аның хатын-кызга булган карашын аңла дигән фикер язучының бу очракта төп бурычы булып калкып чыккан.

Яшәеш аяусыз, гомер чикле. Картлык кешегә үз проблемаларын алып килә. Тик яшьләр кайвакыт өлкәннәрне аңлап бетерә алмыйлар. «Ай сүрелгән чак иде» хикәясе менә шушы теманы күтәрә.

Җаек шәһәрендә Әдһәм исемле карт яши. Карчыгы вафат булган, кызы икенче шәһәрдә тора башлый. Картка ялгыз яшәве күңелсез. Бу шигъри җанлы кешегә әллә кем дә кирәк түгел. «Каршыма утырып чәй эчсә, шигырь укыганымны тыңласа, сөйләшеп утырса, шул җитә миңа»,— ди ул. Тик кызы аңа яңадан өйләнергә рөхсәт итми. Шул яшькә җиткән кешенең өйләнүен оят эш дип саный. Иң кызыгы шунда, автор аның кызын, хәзер инде үзе балалар анасы булган хатынны гаепләргә ашыкмый. Хикәяләүче Дания үз-үзенә сорау бирә. Аның да әтисе үлде. Әнисе тол яши. Әгәр дә бер көн килеп ул кияүгә чыгам дисә, нәрсә дияр иде? «Дания үзенең әнисен кем белән булса да янәшә күз алдына китерә алмый». Шуннан автор бик кирәкле бер нәтиҗә ясый. «Яшьлек бәхет, тигезлек, мәхәббәт таләп итәргә үзен хаклы саный, әмма картлыкны бу хокуклардан мәхрүм итә. Яшьлек үз хокукларын аяк терәп яклый, ә картлык тыйнак, оялчан була икән... Яшьлекнең үз хәленә игътибарны җәлеп итү өчен бик зур чарасы — киләчәккә өметләре бар. Ул, ачу итеп, ярсып өметләрен аклый яки, көче җитмәсә, өметләрен үз кулы белән кисеп, язмыштан шулай үч ала. Ә картларның куллары буш, аның өметләре беткән, югалтыр әйберсе дә, үч алыр чарасы да юк». Без бу юллардан әдибәнең әсәрне язганда куйган максатын, яза торган әсәренә мөнәсәбәтен сизәбез, позициясен күрәбез. Бу исә әсәрнең интеллектуаль ягын күтәрүгә китерә. Әлеге очракта ул безнең игътибарны өлкән кешеләрнең тыйнак ихтыяҗларына юнәлтә, укучының күңеленә миһырбан орлыклары сала.

М. Маликованың хикәя жанрындагы табышлары турында күп язарга мөмкин булыр иде. Алар повестьларда тагын да зуррак үсеш алдылар. Менә «Адашканга юл кайда» дигән повесть. Детектив жанрда язылган булуы өчен генә түгел, кызыклы образлар, язмышлар шактый оста сурәтләнгәнгә күрә дә әсәр йөгерек укыла.

Җинаятьче төрле кыяфәттә була. Әлеге повестьта ул — чиста-пөхтә костюмлы чибәр егет Атлас. Аны кеше үтереп, сейфлар талап йөрүче дип уйларга берәүнең дә башына килмәс. Әсәр шушы җинаятьченең йөзен фаш итү процессын, аның катлаулылыгын күрсәтә. Намуслы шофер егет Ниязның игелекле характеры ачыла.

Консерватория студенткасы Зөлфә бөтен барлыгы белән шома егет Атласка гашыйк. Егетнең кыз белән мөнәсәбәтендәге яхшы манералары, зәвыклы булуы аны әсәрләндерә. Нияз исә кыз тормышына бөтенләй көтмәгәндә килеп керә. Егетнең бусы чибәр дә түгел, тупасрак та, интеллигентлык та чамалы аңарда. Язучы вакыйгалар барышында Зөлфәнең егетләргә карата фикере үзгәрә баруын күрсәтеп бирә. Чөнки ул Нияздагы кешелеклелек, намуслылык кебек затлы якларны күңеле белән сизми кала алмый. Кешеләрне тануда ялгышлыклар җибәрүе аңа гаять тирән күңел газаплары алып килә. Зөлфә сызыгы әнә шундый лирик-психологик тирәнлекле көчәйтә. Боларның һәммәсе әсәрнең төп герое булган Ниязның — үз теләге белән җинаятьче эзенә төшү бурычын җилкәсенә алган шофер егетнең — хәтәр маҗараларын мавыктырырлык итә.

Язның беренче чәчәкләреннән үрелгән такыя киеп карамаган кыз бармы икән? Әмма утыздан узган толлар чәченә яткан такыя инде, ни дисәң дә, төрле уйларга этәрә. Бу чәчәкләр моңлы йөзне бераз ачып җибәрсәләр дә, аның хуҗасының күңелендәге авыр юшкыннарны алып ташлап бетерә алмыйлар. М. Маликованың «Язгы такыялар» повесте геройлары Газзә белән Маһруйга — ирләре сугыштан әйләнеп кайтмаган толларга — әнә шундый язмыш насыйп була. Җыйнак кына булса да, повесть үзенә тулы бер чор кешеләренең уртак язмышын сыйдырган. Әсәрнең героинясы Газзә укучы күз алдында зур юл үтә. Сигез яшьтәге кыз ятимлек, кадерсезлек кебек авырлыкларга ачы күз яшьләрен түгә-түгә булса да, түзә, байларда ялчы булып тамак туйдыра. Газзә кебекләрнең шәхси бәхете бары тик социалистик революция китергән үзгәрешләрдән соң гына мөмкин иде. М. Маликова үз героинясының бу ике халәтен шактый төгәл штрихлар аша бирә. Ләкин ялчыдан ширкәт председателе булып әверелү кебек үнҗиде-унсигез яшьлек кыз өчен генә түгел, тормыш тәҗрибәсе туплаган кеше өчен дә баш әйләнгеч үзгәрешнең, диалектиканың күңелдәге каршылыкларын сурәтләүдә авторның бераз түземлелеге җитмәгән кебек тәэсир кала. Мондый кимчелек Газзә гомеренең шактый дәвамлы чорын иңләүгә исәпләнгән әсәрдә

күзгә бәрелеп тора, чөнки М. Маликова үз героинясы тормышындагы эпизодларның күбесен санап китү белән генә чикләнә. Бу бигрәк тә әсәрнең икенче яртысына карый. Дөрес, әсәрнең төп канвасы әнә шулай йөгерек искә төшерүләргә корылган. Һәм повесть кысалары артык киңәю мөмкинлеген бирми дә. Әмма гомер юлын такыя итеп үреп бетереп килгән кешенең оптимизмын бирә алуы белән әсәр күңелдә якты хисләр уята. Язучының оста каләме белән сурәтләнгән көчле рухлы татар хатыны синең якын танышың, билгеле күләмдә идеалың булып әверелә. Бу инде язучы өчен аз түгел. М. Маликова, шул рәвешле, тарихи-социаль темага алынып, үзенең иҗат палитрасын киңәйтеп җибәрде.

Кызлар үреп кия торган такыя төрле-төрле чәчәклардән җыелган кебек, кешеләр дә гаять төрле. Язучыга бер генә характер иясен әдәби әсәрдә тасвирлау өчен дә кешеләрне никадәр яхшы белергә кирәк. М. Маликованың әдибә буларак уңышы, барыннан да элек, сурәтләнгән кешеләрнең индивидуаль үзенчәлекләрен ачып бирә алуында. «Янартаулар яктысында» повестеннан бер өзек укып карыйк: «Менә алар паркта, Зуфирә башына сары яфраклардан такыя үреп кигән дә, фонтан суына иелеп, шәүләсенә карый, үзеннән бигрәк янында торган Эльвирны күрә.

— Такыя сиңа шундый килешә,— ди Эльвир». Шулай итеп, укучы тагын яңа кешеләр белән очраша. Кем алар, нинди уйлар, омтылышлар белән яшиләр? Язучы шушы сорауларга җавап килеп чыгарга тиешле тормыш йомгагын сүтү эшенә керешә һәм укучы бу шөгыль белән мавыгып киткәнен сизми дә кала.

Музыка училищесында укучы Эльвир белән сәнгать училищесы студенткасы Зуфирә яшьлек таңында танцы кичәсендә очрашалар.

— Сез шундый җиңел бисез, очып йөргән кебек кенә. Ничек мин сезне моңарчы күрмәгәнмен,— дип башланган сүз икән йомгак очы. Г. Кутуйның Искәндәре дә Галия белән шулайрак таныша бит. «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис, җылы». Ләкин тормышка төрле мөнәсәбәт, иҗтимагый идеаллар дәрәҗәсендәге аерымлыклар аларның юлларын башка тармаклардан алып китә. Г. Кутуй да, М. Маликова да нык ихтыярлы, киләчәккә ышанып караучы, үзләрен башкарган хезмәтләре белән расларга омтылган хатын-кыз образларын кыйблаларын югалткан ирләренә караганда көчлерәк итеп тасвирлыйлар. Әйе, табигате белән йомшак хатын-кыз ир канаты астына сыенуны ярата. Әмма хатын-кыз мескен ирләрне яратмый. Андый очракта ул үзе алардан өстен булырга омтыла.

Килеш-килбәте, сүзе-өне белән Эльвир кызның йөрәген яулап ала. Һәр очракта кызның күңел халәтенә туры китереп уйнаган моңнары белән аны тәмам әсәрләндерә дә. Әмма гаилә корып яши башлагач, әлеге тышкы ука тиз коела, Эльвирның эчке дөньясындагы ямьсезлекләр ачыла башлый. Бу аның хатынына булган хыянәтендә, әнисенә булган тупаслыгында аеруча чирканыч ачыла. Зуфирә улы тәрбиясеннән, аның җылы карашыннан мәхрүм калган, авыр сырхауга тап булган каенанасын берүзе тәрбияли. Дөрес, авыру тәрбияләп арыган чаклары да булмый түгел. Әмма, ничек итсә дә, каенанасын үз өеннән кадерләп зиратка озатуга кадәр түзә. Ярый әле Эльвирның әнисен күмешергә килергә акылы җитә. Зуфирә мондый кешене, кызының әтисе булуына карамастан, гафу итә алмый. Хатын күңелендә, соңга калып булса да, икенче ут та кабынып өлгерә. Язмыш аны Камчаткадагы балык тоту корабле капитаны Өмит белән очраштыра. Еракларгы өмет уты хатынны үзенә дәшеп, ымсындырып тора. Шунысы кызык, Зуфирә, рәссам буларак, Эльвирны да, Өмитне дә картинада сурәтләргә омтыла, ләкин күңеле көткән нәтиҗәгә ирешә алмый. Аларның эчке дөньяларын ачып салу шактый кыен эш булып чыга. Зуфирә кичергән газапларның чыганагы да әнә шунда инде: иҗатчы буларак кына түгел, гап-гади кеше буларак та бөтеннәрне аңлау җиңел түгел икән. «Үзеңне янартаулар яктысында сынарга кирәк». Әсәрнең лейтмотивын тәшкил иткән бу фикер тора-бара күңелендә иҗат уты пыскып кына яшәгән Зуфирәнең яшәү девизы булып әверелә. Эзләнгән, ләкин эзләгәнен таба алмый интеккән Зуфирә бер хакыйкатькә төшенә: «Бәхетнең зурысы кыюларга, тәвәккәлләргә генә килә. Ә кыюлар, тәвәккәлләр гел яңа юллардан йөриләр».

М. Маликованың шушы ук әсәрендә игътибарны җәлеп итә торган менә мондый сүзләр дә бар: «Кешеләргә тәэсир итү өчен үзең шул утларда янарга кирәк бит!» Әйе, язучы буларак М. Маликова үз алдына бурычның бик җитдиен куя һәм шуңа якынаю омтылышы белән иҗат итә.

М. Маликова иҗатының төп хасияте турында уйланганда аның әсәрләрендәге интеллектуальлек сыйфаты алгы планга килеп чыга. Хәзерге укучы зур әзерлекле, ул тормышның гадәти коллизияләре күрсәтелү белән генә канәгать-

ләнми. Син аңа бүгенге яшәеш, кешенең теге яки бу адым ясауга китергән сәбәпләрнең тирән фәлсәфи алшартларын һәм ахыр нәтиҗәләрен гомумиләштерүләр ярдәмендә ачып бир. Ягъни укучыга фикердәш бул, аны борчыган сорауларны ачыклап бир, булдыра алмыйсың икән, ахыр чиктә шул сорауларны укучы алдына куя бел. Анысы да зур хикмәт. «Янартаулар яктысында» әсәре белән М. Маликова әнә шундый матур омтылыш ясый. «Шәфкать» романында исә бу мәгънәдә алга таба тагын бер адым атлый.

Без кешенең әхлакый сыйфатларын ачуны аның интим тормышы, мәхәббәттәге һәм гаиләдәге катлаулы хәл-әхвәлләре сурәтләнү аша күрергә күнеккәнбез. Ләкин соңгы вакытта эшкә караш, хезмәттәшләр белән булган мөнәсәбәтне ачып күрсәтүнең дә бу өлкәдә никадәр көчле чара булуын язучыларыбыз елдан-ел ныграк аңлый баралар. Эшне аны барыбыз да эшлибез. Әмма аерма шунда — кем ничек эшли? Аның өчен хезмәт стимулы булып иң беренче чиратта нәрсә тора? Бу сорауларга җавап бирү әдәби образның әхлакый йөзен ачып бирү дигән сүз. Әгәр М. Маликованың «Шәфкать» романы Татарстан язучыларының X съездында уңышлы әсәр буларак бәяләнгән икән, моның сере, барыннан да элек, әсәрдәге образларның әхлакый йөзен, тормышыбызның әнә шул ике катламын тыгыз үреп сурәтләүдә.

Шәфкатьлелек, кешенең профессиясенә карамастан, һәркем өчен кирәк. Ул кешелеклелек дигән төшенчәнең иң кирәкле состав өлеше. Әмма табиплар өчен бу сыйфат иң беренче урында торырга тиештер. Авыруга аеруча якын торган медицина персоналының шәфкать туташы дип аталуы очраклы гына түгелдер. М. Маликова бу әсәрендә менә шушы турыда уйлана, бу мәсьәләгә карашларын образларның гамәлләре аркылы ачып бирә. Язучы бу очракта кискен контрастлар белән эш итә. Бөтен гомерен, сәләтен кешеләргә бары тик игелек эшләүгә багышлаган профессор Җәмилә Закировна барлык тырышлыгын карьерага ирешүгә генә биргән доцент Изаил Харисовичка каршы куелса, әле яңарак кына кулларына врач дипломы алган курсташлар Зәйтүнә белән Лариса да — нәкъ менә шундый ук антиподлар.

Җәмилә Закировна Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романындагы Әбүзәр Гириевич кебек, бары тик кешеләр бәхете өчен генә яшәгән. Чын табип бары тик ярдәмгә мохтаҗ кешеләр хакында уйларга тиеш дигән фикер аның өчен яшәү мәгънәсе булып әверелгән. Фәндә ачышлар ясаган икән, бу һич тә хезмәттә нинди дә булса урын яулап алу өчен түгел. Бу кешеләргә мөмкин кадәр уңышлырак ярдәм итәргә омтылу максатыннан эшләнгән. Ул гына да түгел, Җәмилә Закировна медицина өчен яшь кадрлар әзерләгәндә аларны кешенең тәнен генә түгел, җанын да дәваларга өйрәткән. Зәйтүнә кебек йөзләрчә шәкертләре аның өметен аклыйлар да. Юкка гына ул Зәйтүнә артыннан «минем яшьлегем бит бу, минем ныгып, чыныгып кына килгән чагым» дип уйламый. Әйе, ак халатлы шәфкатьле кешеләр арасында Җәмилә Закировна, Зәйтүнә кебекләр күбрәк.

Җәмилә Закировнаның шәкерте Изаил Харисович исә авыруларны фән өчен кызыклы яки кызыксыз сортларга бүлә, үзен фән юлына юнәлткән остазының урынын яулап алу өчен төрле интригалар оештыра. Кеше хезмәтен үзләштереп, фәндә җиңел юл белән уңыш казанырга омтылган Лариса образы да шундыйлар рәтенә керә. Бу ике образның уртак тел таба алулары да күп нәрсә турында сөйли.

Әсәрнең самимилеген, лириклык көчен хасил итүче, барлык сюжет җепләрен бер бөтенгә төйнәүче образ, әлбәттә, Зәйтүнә. Үзендә татар хатын-кызларының сабырлыгын, тыйнаклыгын, уңганлыгын туплаган Зәйтүнәне укучы ярата. Әсәрнең төп уңышы да шушы образның оста сурәтләнүендә.

М. Маликова әсәрләрендә без, аерым очракларны исәпкә алмаганда, гадәттән тыш, күзгә бәрелеп торган вакыйгалар, характерлар белән очрашмыйбыз. Барысы да гадәти кебек. Әмма әнә шул гадилекне кеше игътибар итәрдәй дәрәҗәдә сурәтләү кыен да инде. Биредә персонажларның күңелендә барган хис-кичерешләрнең бик сак кына тоемлана торганнарын да сизәргә, әсәр тукымасына көчәнмичә урнаштырырга кирәк. Бу үзеннән-үзе психологик тирәнлеккә китерә.

Язучы Мәдинә Маликованың бүген әнә шундый иҗади уңышлары, куанычлары бар. Бу казанышлар аңа алдагы үрләрне яулауда ныклы этәргеч булып тора.

...Уңыш җыю аенда табынга куярдай сыең булу язны һәм җәйне тырыш хезмәт белән үткәргәнлегеңне күрсәтә. Ә илһамланып иҗтиһат итү өчен алда әле озын көз бар. Аннан да битәр, язучылар өчен тагын да уңышлырак була торганы — ап-ак кыш бар! Иҗат итү өчен әле тулы бер гомер бар икән ич!

библио графия

# ЗУР МИРАСНЫҢ ҖИТДИ ӨЛЕШЕ

Соңгы ун-унбиш елда татар халык иҗаты әсәрләрен җыю, бастырып чыгару һәм фәнни өйрәнү эше бер җанлану чоры кичерә. Культурабыз тарихы белән кызыксынучылар да моны сизәдер. Сүз — без күптән күнеккән гадәти җыентыклар турында гына түгел, сүз — Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты секторы тарафыннан соңгы ун ел дәвамында җыр, әкият (3 китап), бәет һәм башкаларга багышлап әзерләнгән унике томлык хакында бара. Бу җыелманың әлегә кадәр дөнья күргән сигез томы, фәнни яктан нигездә яхшы әзерләнгән үзенчәлекле китаплар буларак, әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан зур канәгатьләнү белән каршыланды. Шулай ук җыелманың тугызынчы томы — «Татар халык иҗаты. Дастаннар»[1] — күптән көтелгән, татар халкының культура мирасы, шигъри хәзинәсе, әдәбияты һәм сәнгате белән кызыксынучылар тарафыннан зарыгып көтелгән китап булып чыкты.

Әкият, мәкаль, табышмак китапларына без беркадәр күнеккән инде. Андыйлар белән беркемне дә «шаккатыра алмыйсың». Мондый характердагы басмаларның максаты да башкачарак. Күрсәтелгән жанрларга караган китаплар кат-кат басылып чыкты. Ә менә татар халык дастаннарын без беренче тапкыр күрәбез. Җыентыкның иҗтимагый әһәмиятен билгеләгән күрсәткечләрнең беренчесе әнә шуннан гыйбарәт.

Икенчедән. Соңгы елларда халык эпосына игътибар елдан-ел арта. Мәскәүдәге «Наука» нәшриятында «СССР халыклары эпосы» сериясендә һәркайсы ике телдә булган (казахча — русча, башкортча — русча, төркмәнчә — русча һ. б.) гаять җитди күптомлык басылып ята. Казах, кыргыз, үзбәк эпосына багышланган күптомлыклар берничә ел элек чыгарылып, халык арасына таралып бетте. Алма-Атада 1957 елда ук эпос үрнәкләреннән торган биш китап басылып чыккан иде. Соңгы елларда Кыргызстанда «Манас» эпосының Сагымбай Орозбаков варианты 3 томда, Саякбай Каралаев варианты 4 томда кыргыз телендә басылды. Хәзер шул ук әсәрнең кыргызча-русча дүрттомлыгы Мәскәүнең «Наука» нәшриятында басыла башлады. Бу халыкларның эпосына багышланган тирән эчтәлекле фәнни хезмәтләр дә дөнья күреп тора. Димәк, «Дастаннар» китабы — бүгенге татар фольклор фәненең генә түгел, гомумән, совет халыклары иҗатын өйрәнүнең төп тенденцияләреннән берсен чагылдырган басмалар үрнәге.

Өченчедән. Хәзер халык иҗатын өйрәнүдә генә түгел, әдәбиятта да ата-бабаларыбыз тормышына, аларның культурасына игътибар шулай ук тирәнәя. Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» зур кызыксыну белән каршыландылар. Драматургия белән поэзия дә калышмаска тырыша. Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, бигрәк тә Илдар Юзеев әсәрләрендә борынгы мифологик сюжетлар, образлар, шигъри алымнар еш очрый. Дөрес, без күбрәк борынгы грек-рим һ. б. халыклар мифологиясенә мөрәҗәгать итәбез. Үзебезнең татар мифологиясенә әйләнеп карасак, Былтырдан бармагын кыстырган мескен Шүрәле тирәсеннән әллә ни ерак китә алганыбыз юк кебек...

Дүртенчедән. Әле күптән түгел: «Безнең халыкта гомумән зур күләмле эпик әсәрләр — дастаннар бармы?» — дигән сорауга еш кына «Юк!» дип җавап бирә идек. Соңрак халык иҗатын өйрәнүчеләр мәсьәләгә башкачарак карый башладылар. Бу юнәлештәге беренче җитди адымнар Нәкый ага Исәнбәт һәм Хәмит абый Ярми исемнәре белән бәйләнгән. Шулай да әлегә кадәр дөнья күргән мәкалә һәм дастан текстлары нигездә Себер татарлары иҗатына гына карый. Ә инде соңгы 10-15 елда югарыда телгә алынган институтның халык иҗаты секторы казан татарлары иҗаты белән генә чикләнмичә, башка этник төркемнәр фольклорын өйрәнү буенча да махсус эзләнүләр алып барды, күп кенә дастан текстлары язып алды. Кызыклы фәнни мәкаләләр дә басылып чыкты. Әйтик, халкыбызның шигъри мирасын өйрәнү эшенә, бигрәк тә борынгы кулъязмаларны фәнни тикшерүгә М. Госманов зур өлеш кертте. Күзәтелә торган китапның төзүчесе Ф. Әхмәтова дастаннарга багышланган мәкаләләр бастырып, Бөтенсоюз фәнни конференцияләрендә махсус докладлар белән чыкты.

Күп кенә халыкларның эпосын өйрәнү илле, йөз, аерым очракларда меӊ еллар буе алып барыла. Ә без әле беренче адымнар ясыйбыз. (Академик В. В. Радловның 1872 елда дөнья күргән мәгълүм китабы, никадәр генә җитди һәм бай эчтәлекле

[1] Татар халык иҗаты. Дастаннар. Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф. В. Әхмәтова. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1984.

булса да, тел өйрәнү материаллары буларак әзерләнгән иде). Татар халык эпосы турында язганда, без, гадәттә, конкрет материал, дастан текстлары эзләп аптырый идек, аннан-моннан йолкып-тартып, кайвакыт юктан бар итәргә дә тырыша идек. Ә хәзер безнең кулда — махсус җыентык, «Дастаннар» китабы, югарыда телгә алынган фәнни эзләнүләрнең нәтиҗәсе.

Китаптагы материаллар күрсәтүенчә, җыентыкны әзерләү халык иҗаты секторыннан, күптомлыкның редколлегиясеннән (җитәкчесе — Илбарис Надиров), аеруча төзүчедән бик күп түземлек, тырышлык таләп иткән. Һәм бу бик табигый. Китапта соңгы елларда гына халык теленнән язып алынган дастаннарга зур урын бирелгән. Бу юнәлештәге эзләнүләрнең төп авырлыгы төзүче өстенә төшкән, билгеле. Ул халыктан, вариантлары белән исәпләгәндә, уннарча әсәр язып алган.

Татар эпосы әсәрләрен барлауның икенче юлы — борынгы кулъязмаларны өйрәнү. Бу — искиткеч катлаулы, четерекле, зур түземлек таләп итә торган эш. Җыентыкны әзерләгәндә төзүче тарафыннан бу юнәлештә дә зур һәм, һичшиксез, әһәмиятле эш башкарылган. Шул ук вакытта төзүчегә җитди ярдәм күрсәткән рәссам Бакый ага Урманче, профессор Миркасыйм Госманов, әдәбият белгече Мәсгут Гайнетдинов хезмәтләрен дә ихтирам белән телгә алырга кирәк.

Конкрет материалны, татар халык эпосының табигатен аңлап язылган кереш мәкалә; аерым әсәрләргә, аларның вариантларына язылган искәрмәләр; тагы да җитдирәге — 12 дастанның нотага салынган көен урнаштыру китапның күңелне шатландырган уңай якларыннан санала.

Шулай да мин, җыентык кай яктан карасаң да, ал да гөл, анда бернинди җитешсезлек юк, дип әйтергә җыенмыйм. Әгәр кимчелекләр генә эзләп, юклы-барлы тәгәлсезлекләрне күпертеп карый башласаң, китапка нык кына бәйләнергә дә мөмкиндер. Әмма бу рецензиянең максаты ул түгел. Шулай да кайбер мисалларга тукталып үтим. Берничә җирдә казахча **әйнек** (тәрәзә) сүзе очрый. Нигәдер ул **әйнек** түгел, **айнәк** дип язылган. (Биредә мин ялгыш бирелгән казахча сүзләргә күбрәк тукталам. Чөнки әсәрнең лексикасында гына түгел, гомуми стилендә, рифмаларында, ритмикасында казах кыйссалары йогынтысы ачыктан-ачык сизелеп тора). «Бүз егет»тәге «ханга ялгыз ул **битте**» (275 бит) дә дөрес түгел, «ул **бетте**» булырга тиеш иде. **Остап** (тотып) сүзе гарәп графикасыннан ялгыш укылып, **ушлап** дип бирелгән (276 бит). Шул ук «Бүз егет»нең «Ятыптыр так өстендә куендашып» дигән җөмләсендәге **так** сүзе **тәхет** дип аңлатылган (290 бит). Хәлбуки, казахча так — тәхет түгел, гадәти артсыз урындык.

Ярар, мондый вак-төякләр һәрбер китапта булуы мөмкин. Аларны төзәтү — техник эш. Мәсьәләнең икенче — җитдирәк ягына игътибар итик. Язучылар союзында булган бер сөйләшү вакытында: китап ярыйсы ук чуар, анда Идел-Урал ягы татарларыннан гына түгел, Себер татарларыннан язып алынган әсәрләргә дә зур урын бирелгән, дигән фикер әйтелде. Әйе, бу чыннан да шулай: китапта татар халкы яши торган төрле төбәкләрдә җыелган материаллар урнаштырылган. Миңа калса, бу шулай булырга тиеш тә. Казан татарлары, мишәрләр, Себер татарлары — килеп чыгышлары ягыннан гына түгел, тарихи язмышлары, материаль һәм рухи культуралары, ниһаять, телләре белән барысы да бер үк халык вәкилләре бит. Нишләп соң аларны бер-берсенә каршы куярга? Мәсьәләгә болай килү чикләнгәнлек булыр иде. Җыентыкны төзүче һәм редколлегия сайлаган юлның ярыйсы ук киң перспективасы бар. Әгәр татар халык эпосын җыю нәкъ шул юнәлештә дәвам итсә, Казан-Урал тирәләрендә генә түгел, Башкортстанда, Оренбург, Чиләбе һ. б. якларда яшәүче татарлар арасыннан, Омск, Томск һ. б. шәһәрләр архивларыннан тагы беркадәр конкрет материал табылыр иде.

Җыентыкның чуарлыгын билгеләгән тагы бер мәсьәлә турында бәхәсләшергә мөмкин: китапка жанр чикләре ачыкланып җитмәгән материаллар да кертелгән. Әйтик, «Алыплар турындагы хикәятләр» дип исемләнгән беренче бүлектәге әсәрләр — гадәти әкиятләр, дигән фикер әйтүчеләр бар. Беренче карашка, бу чыннан да шулай кебек. Минемчә, мәсьәләгә башкачарак килергә кирәк. Иң элек, бүлектәге «Алыпмәмшән», «Алтаин Саин Сумә», «Йиртөшлек», «Ак Күбек»[1], «Күр улы» әсәрләренең халык дастаннары булуы әллә ни шик уятмый. Бу хакта «Советская тюркология» журналында, аерым китапҗыентыкларда махсус мәкаләләр басылып чыкты. Ә инде «Мешәк Алып», «Кадыш Мәргән» кебек үрнәкләрдә әкияткә тартымлык чыннан да ныграк сизелә. Ләкин монда шаккатырлык берни дә юк. Проза рәвешендә һәм әкияткә якын формада иҗат ителгән эпос үрнәкләре башка халыкларда да бар. Ирландия һәм Исландия сагалары, грузин эпосы әсәрләре гадәттә прозаик формада гына яшәгәннәр. Төньяк халыклары сагаларында, мәсәлән, әкияткә хас сыйфатлар да юк түгел. Хәтта якутларның чын халык эпосы әсәрләре — олонхоларны да әкият дип караучылар бар иде. Берничә ел элек бу хакта төрле бәхәсләр дә булып алды. Казах халкы лиро-эпосы «Козы-Көрпеш белән Баянсылу»ны академик В. М. Жирмунский **әкияти поэма** дип билгеләгән иде.

Гомумән, халык иҗатының бер-берсенә якын торган жанрлары арасында беркайчан да үтә алмаслык чик булмый. Рус фольклоры әсәрләреннән «Авдотья Рязаночка»ны бер төркем галимнәр тарихи җыр дип карасалар,

---

[1] Җыентыктагыча **Күбәк** түгел, **Күбек** дип әйткәндә, мин академик В. В. Радлов билгеләмәсенә таянам. Карагыз: В. В. Радлов. Образцы народной литературы тюркских племен. Часть IV. СПб., 1872, 45-58, 142-152 б.

икенчеләре балладалар рәтеннән саныйлар. Шуңадыр да бу әсәрне баллада җыентыкларында да, тарихи җыр китапларында да очратырга мөмкин. Татар халкының мәкальләр һәм әйтемнәр, җырлар һәм бәетләр, әкиятләр һәм дастаннар кебек бер-берсенә якын торган жанрлары арасында «бикле чик» уздыруы кыен. Бигрәк тә сүз эчтәлеге ягыннан үзенчәлекле, формасы аеруча катлаулы әсәрләр турында барса. Бер үк әсәрдә берничә жанрга хас сыйфатлар булуы мөмкин. Бу типтагы материалларны ике жанрның очрашкан ноктасында торган әсәрләр дип караганда дөресрәк булыр кебек... Ә инде җыентыктагы югарыда күрсәтелгән әсәрләргә әйләнеп кайтсак, мин аларны **әкияти дастан** дип әйтер идем.

Җитди бәхәсләр уятуы мөмкин булган тагы бер мәсьәлә: халык дастаннары җыентыгына китаби әсәрләр кертеп, төзүче һәм редколлегия дөрес эшләгәнме? Татар халык эпосы кебек әле ныклап өйрәнелмәгән җитди мәсьәләдә бик сак булырга, аны фәнни нигездә, барыннан да элек, фольклор әсәрләре булуы шик уятмаган материаллар нигезендә күзәтү таләп ителә. Йөз еллар буе фольклор фәне нәкъ шул юнәлештә яшәп килә. Фольклор, ни әйтсәң дә, фольклор инде ул. Халык иҗаты әсәрләре иң элек халык теленнән язып алынырга тиеш.

«Дастаннар» җыентыгы исә мәсьәләнең икенче ягына, бездә элек-электән киң таралган **китаби дастаннарга** игътибар итә. Кереш мәкаләдә Ф. Әхмәтова болай дип яза: «Башка халыклар иҗатында махсус эпик кануннар, импровизация һ. б. иҗади факторлар көчле булса, татар дастаннарының йөзен күбесенчә китаби традицияләр билгели. Кайчандыр халык теленнән язып алынган дастаннар, китап булып басылып, яңадан халык теленә күчәләр, яисә китаби рәвештә яшәвен дәвам итәләр» (5 бит). Мәсьәлә бик дөрес күтәрелгән. Сүз бөтенләй яңа проблема хакында бара. Аңа киң планда килсәк, төрле мәсьәләләр калкып чыга: китаби дастаннарны өйрәнүнең методологик нигезләре; татар халкы арасында аларның барлыкка килү һәм таралу сәбәпләре; шигъри үзенчәлекләре; халык теленнән язып алынган башка әсәрләргә мөнәсәбәте һ. б. Әгәр керештә яисә искәрмәләрдә нәкъ шул мәсьәләләр киңрәк яктыртылса, бәхәскә әллә ни урын да калмаган булыр иде.

Әйтик, китаптагы «Таһир белән Зөһрә»гә карата искәрмәләрдә мондый сүзләр бар: «Биредә китерелгән текст Әхмәт Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» исеме белән Казанда 1917 елда чыккан китабыннан тулысынча күчерелеп бирелә» (371 бит). Әлегә кадәр бу әсәр халык иҗатына түгел, әдәбият тарихына карый дип санала иде. Ул Мөхәммәт ага Гайнуллинның «Татар әдәбияты. XIX йөз» китабында да урын алган (Казан, 1968, 260-304 битләр). Бәлки, чыннан да, Уразаев-Кормаши әсәрләрен әдәбият тарихына калдырып, «Таһир белән Зөһрә» дастанының халык арасында, дастанчылар хәтерендә яки язма чыганакларда сакланган вариантларына тукталырга кирәктер. «Дастаннар» китабындагы искәрмәләргә караганда, андый материаллар да аз түгел бит. Ул чакта мәсьәләнең бәхәсле яклары да азаер, төзүченең фикерләре дә дәлиллерәк булыр иде.

Биредә, татар халкындагы китаби дастаннар традициясенә махсус тукталып, аерым әсәрләрне тикшереп булмый. Шулай да мәсьәләнең теоретик нигезенә карата берничә сүз әйтергә кирәк. Билгеле булганча, шумер-аккад эпосы «О все видавшем» (б. э. к. XXIII-XXII йөзләр), Гомерның «Илиада», «Одиссея»лары (б. э. к. VIII-VII йөзләр), борынгы һинд халкының «Рамаяна», «Махабхарата»лары (б. э. к. I-III йөзләр), һәм башка кайбер эпик әсәрләр тик язма рәвештә генә сакланганнар. Әмма аларның халык эпосы үрнәкләре булуы күптән исбат ителгән. **Борынгыдан язма культурасы булган халыкларда** (ә татар халкы шундыйлар рәтеннән) **фольклор әсәрләре нинди формада яшәсә дә, моның принципиаль әһәмияте юк.** Алар халык телендә дә яшиләр, кульъязмалар, китаплар аркылы да таралалар. Татар халкы фольклор әсәрләре булган бәетләрен дә еш кына кәгазьгә теркәп, кульъязмалар аркылы да тараткан. Шул уңайдан тагы бер фикер туа. Әгәр бәетләр безнең халыкка гына хас үзенчәлекле жанр икән, бәлки, татар эпосының да әһәмиятле милли үзенчәлекләреннән берсе — аерым әсәрләрнең халык арасында туып, соңыннан китап яисә кульъязмаларга яки, киресенчә, китаптан халык теленә күчүендәдер. Ярыйсы ук катлаулы, төрле халыклар культура тарихында күзәтелә торган әлеге күренеш зур теоретик әһәмияткә ия. Шулай булгач, бу мәсьәләне җентекләп өйрәнәсе, фәнни яктан тирәнтен тикшерәсе бар.

Соңгы сүз. «Татар халык иҗаты» сериясендә чыккан «Дастаннар» китабы — күп еллар дәвам иткән даими тырышлык, түземлелек белән әзерләнгән һәм әһәмиятле проблемалар күтәргән җитди фәнни җыентык. Ул безнең бүгенге фольклор фәненең зур казанышы дип бәяләнергә хаклы. Китап киләчәктә татар халык эпосы әсәрләрен җыю, бастырып чыгару, фәнни нигездә өйрәнү тагы да киңәер һәм тирәнәер, дигән өмет уята.

Фатыйх **УРМАНЧЕЕВ.**

# СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ ТУРЫНДА

Томск дәүләт университеты галиме, тарихчы-этнограф Н. А. Томилов Себер татарлары тарихын, материаль һәм рухи культурасын өйрәнү өлкәсендә озак еллар буе нәтиҗәле эшләп килә. Галимнең 1983 елда дөнья күргән чираттагы монографиясе дә аның бу өлкәдәге яңа бер казанышы[1]. Очерклар сериясе рәвешендә язылган бу хезмәттә Томск, Кемерово, Новосибирск өлкәләрендә яшәп, фәнни әдәбиятта Томск татарлары дип аталучы эуштиннар, чатлар, калмаклар тарихының моңа хәтле аз өйрәнелгән мәсьәләләре яктыртылган.

Хезмәт үзәк һәм җирле архивларда тупланган гаять күп санлы беренче кул чыганакларга нигезләнеп язылган. Китап авторы җитәкчелегендә 1969-1979 елларда Кемерово, Новосибирск һәм Томск өлкәләренә оештырылган экспедиция материаллары биредә беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелгән. 1969—1970 елларда Томск татарлары арасында үткәрелгән ике этносоциологик анкеталаштыру материаллары һәм татар гаиләләрендә массовый төстә язып алынган шәҗәрәләр, ягъни нәсел язулары аеруча фәнни кыйммәткә ия. Алар Томск татарларының килеп чыгышын, этник составын өйрәнгәндә төп чыганакларның мөһим бер өлешен тәшкил итәләр.

Монография кереш өлештән, биш бүлектән, йомгаклау һәм фольклор язмаларын эченә алган кушымтадан гыйбарәт.

Китап автор тарафыннан тикшерелә торган чорда Томск татарларының урнашуы, аларның саны һәм этник составын тикшерүгә багышланган очерк белән ачылып китә. Бу бүлектә автор элегрәк дөнья күргән хезмәтләрендә яктыртылган Көнбатыш Себер тигезлегендәге төрки халыкларның XVI гасыр ахырыннан алып XIX гасырның беренче чирегенә кадәр чорда этник-тарихи үсеше мәсьәләсен тикшерүен дәвам итә. Монографиянең икенче һәм өченче бүлекләрендә Томск татарларының революциягә кадәр һәм совет чорында гаилә көнкүреше һәм йолалары тасвирлана.

Этнографик әдәбиятта беренче буларак, Н. А. Томилов татар халкының бу этник төркеменең бала туу, туй һәм күмү белән бәйләнгән йолаларын тасвирлый. Бу уңайдан автор Томск татарлары йолаларын Себер татарларының башка төркемнәрендәге шундый ук йолалар белән чагыштыра һәм алардагы аерымлыкларны күрсәтеп үтә. Мондый үзгәлекләрнең барлыкка килүен автор Томск татарларының бу төбәктәге башка халыклар белән озак елларга сузылган тарихи бәйләнешләреннән чыгып аңлата.

Китапның җыйнак кына күләмле дүртенче бүлеген дә кызыксынып укыйсың. Ул бу төбәктәге татарларның иҗтимагый көнкүрешен, халык һәм дини бәйрәмнәрен тасвирлауга багышланган. XIX йөз ахыры — XX йөзнең башындагы татар җәмәгатенең (община) асылын ачыклап, автор конкрет мисалларда Томск татар авылларындагы җәмәгать мөнәсәбәтләрен тасвирлый. Шулай ук бу бүлектә сабантуй, кайбер дини бәйрәмнәр, төрле милли уеннар турында да шактый кызыклы мәгълүматлар китерелә, аларның иҗтимагый әһәмияте күрсәтелә.

Рухи культура мәсьәләләрен яктыртуга багышланган бишенче бүлек XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында Томск татарларында мәгариф һәм мәгърифәтнең торышына кыскача характеристика бирү белән башланып китә. Автор XIX йөз ахырларында Томск шәһәре тирәсендәге татар авылларында мәктәпләр ачыла башлавын билгеләп үтә. Хезмәтнең бу бүлегендә төп игътибар 20 нче еллардан алып безнең көннәргә кадәрге чорда Томск татарлары арасында халык мәгарифе, формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураның үсеше мәсьәләләрен тикшерүгә юнәлтелгән. Бүлек авылларда башлангыч һәм җидееллык татар мәктәпләре оештырылу, Томскида татар мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләүче махсус уку йортлары ачылу турында фактик материалларга бик бай.

Анализлана торган китапта Томск татарларының хәзерге вакыттагы культурасын, халык мәгарифе торышын яктырткан материаллар аеруча игътибарны җәлеп итә. Бай фактик мәгълүматларга таянып, автор совет чорында Томск татарларының белем дәрәҗәсе үсүен ышандырырлык дәлилләр белән күрсәтә алган.

Хезмәттә Томск татарларының халык иҗатына гомуми характеристика бирелгән, аларның күп кенә яңа үрнәкләре фәнни әйләнешкә кертелгән. Себер татарларының халык иҗатын өйрәнү тарихына ясалган кыскача экскурс та авторның уңышы дип саналырга хаклы. Н. А. Томилов кайбер риваять, бәетләрнең реаль тарихи вакыйгалар белән бәйләнешен эзлекле рәвештә өйрәнгән. Мәсәлән, Томск татарларының бер этнографик төркеме булган калмакларның риваятьләрендә аларның борынгы бабалары көньяктагы районнардан хәзерге җирләргә

---

[1] Томилов Н. А. Очерки этнографии тюркского населения Томского Приобья. (Этническая история и духовная культура). Томск, 1983.

күчеп килүе, татарларның Рус дәүләтенә кушылулары һ. б. турында сөйләнә. Монографиядә билгеләп үтелгәнчә, кайбер риваятьләрдә Ермак, Күчем хан, Тоян, Басандай һ. б. тарихи шәхесләр турында мәгълүматлар бар. Томск татарлары халык иҗатын чагыштырып анализлауга нигезләнеп, Н. А. Томилов аларда казан татарларыннан, руслардан һәм Урта Азия халыкларыннан алынган элементлар булуын да ачыклый. Бу як халкы казан татарларының «Сак-Сок» бәетен, русларның Казанны алулары, Пугачев восстаниесе һ. б. вакыйгалар турындагы риваятьләрен үзләштергәннәр. Себергә күчеп килгән Идел буе татарларыннан җирле халыкларның мифологиясенә «урман сарыгы» шүрәле һәм су анасы турындагы сюжетлар, хәйләкәр Шомбай турындагы әкиятләр дә үтеп кергән.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Томск татарлары Идел буендагы кардәшләреннән халык авыз иҗаты үрнәкләрен генә түгел, ә туй йолаларының кайбер элементларын да кабул иткәннәр. Мәсәлән, аларда казан татарларындагы кебек үк туйда чәк-чәк бүләк итү гадәте булган, кәләш йортында бу ашамлыкны кияүнең якын туганнарына, ә кияү йортында исә киресенчә — кәләшнең туганнарына бүләк иткәннәр.

Бу бүлектә шулай ук борынгы туй, мәхәббәт, йола, бишек җырларыннан өзекләр тәрҗемә итеп бирелгән.

Томск татарлары халык иҗатының совет чорына караган үрнәкләрен тикшергәндә, автор аларның яңа социаль эчтәлек белән тулылануын һәм күршедәге руслардан кайбер фольклор сюжетлары алу хисабына баюын билгеләп үтә. Автор тарафыннан китерелгән үрнәкләрдән күренгәнчә, хәзерге заман Томск татар җырларында, илебезнең башка тугандаш халыкларының җырларындагы кебек үк, Ленин, партия, халыклар дуслыгы, социалистик Ватанга мәхәббәт турында җырлана.

Кыска җырлар арасында исә элеккеге кебек үк мәхәббәт җырлары зур урын алып тора.

Томск татарларының дини карашларына багышланган бүлектә ислам диненә кадәр булган ышанулар (шаманизм һ. б.), аларның калдыклары турында сүз алып барыла. Автор Томск татарлары ышануларындагы әлеге үзенчәлекне Себер татарларының башка төркемнәрендә булган характерлы ышанулар белән чагыштырып, аларның кайбер гәрәпмылыкларын күрсәтергә омтыла. Мәсәлән тикшерелә торган чорда Томск татарлары үзләренең агач потларын өй түбәсенә беркетеп куя торган булганнар һәм аларны бу йортта яшәүче кешеләрне үз канаты астына алучы, ягъни яклаучы дип исәпләгәннәр. Кайбер төбәкләрдә җирле татарлар табына торган потларына махсус «тораклар» да салганнар. Томск татарларының ышануларындагы тотемизм калдыкларын, ягъни борынгы кешеләрнең ниндидер хайван яки үсемлек белән булган кардәшлегенә ышану, әлеге хайван яки үсемлекне олылау эзләрен автор коймаларга ат башы сөякләре элеп куюда, кайбер кош-корт һәм җәнлекләрне үтерүне тыюда күрә.

Монографиягә кушымта итеп бирелгән «Фольклор язмалары» да зур кызыксыну тудыра. Анда урын алган халык авыз иҗаты үрнәкләренең фәнни кыйммәте шунда ки, алар мәгълүм күләмдә бу төбәктәге татарларның аерым этник төркемнәренең килеп чыгышын, аларның шөгыльләре, гаилә һәм җәмәгать мөнәсәбәтләрен күзалларга мөмкинлек бирәләр.

Рецензияләнә торган китап аерым кимчелекләрдән дә азат түгел. Мәсәлән, авторның XIX—XX гасыр башларында Томск татарлары мәетләргә кием кидергәннәр, ә аларның этнографик бер төркеме булган эуштиннар исә мәетләрне кабердә утырткан килеш күмгәннәр дип раславы шик тудыра. Чөнки XIX, бигрәк тә XX гасыр башында ислам дине Томск татарлары — эуштиннар, чатлар, калмаклар — арасында киң таралыш тапкан иде инде. Шуңа күрә бар җиргә дә борын тәртергә яратучы мөселман руханилары шәригать канунын бу рәвешчә бозуга юл куймаганнардыр, әлбәттә. Монографиядә Томск татарларының гаять зур фәнни кыйммәткә ия булган халык авыз иҗаты үрнәкләре дә урын алган, дидек. Ләкин русчага юлын-юлга тәрҗемә итеп бирелгән бу үрнәкләрнең кайберләре милли колоритын югалткан.

Китапта, шулай ук, аерым фактик төгәлсезлекләр дә очрый. Мәсәлән, автор 1924 елда Томскида Себер төрки-татар педагогия институты ачыла дип раслый. Ләкин бу вакытта Томскида төрки-татар педагогия техникумы ачыла (кара: «Азат Себер», 1923, 14 октябрь) һәм ул Бөек Ватан сугышына кадәр үк педагогия училищесы итеп үзгәртелә. Китапта татар сүзләрен һәм терминнарын бирүдә дә кайбер төгәлсезлекләр киткән.

Әлбәттә, югарыда искә алынган кимчелекләр генә хезмәтнең гыйльми кыйммәтен киметмиләр. Бу хезмәт галимнең этнография фәненә керткән яңа зур өлеше булып бәяләнергә хаклы.

**Фоат ВӘЛИЕВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

**София ИСХАКОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

Наилә Әлмиева

# ҖЫРЛАП АЧЫЛА КҮҢЕЛ

## КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫ КӨНКҮРЕШЕНДӘ МУЗЫКАЛЬ ТРАДИЦИЯЛӘР

Чәчәк бәйләме... Аерым бер халыкның этник төркемнәренә караган фольклор традицияләре төрле төсләрдә җемелдәүче чәчәк бәйләмен хәтерләтә. Бәйләмдәге һәрбер чәчәк үзенчә аерылып тора, гомум милли культурага үзенчә бизәк өсти. Урта Идел төбәгендә яшәүче керәшен татарлары көнкүрешендәге музыкаль традицияләр дә халык иҗатының уртак хәзинәсен үзләренчә баеталар.

Керәшен татарларының югары үсеш баскычына күтәрелгән җыр сәнгате үзенең тамырлары белән борынгы заманнарга тоташкан. Борынгы үрнәкләр булуларына карамастан, алар хәзер дә кулланылыштан төшмиләр. Шундый җырларны тыңлаганда, ничектер, археологик казу вакытында туа торган тәэсирләр кузгала: өстәрәк яткан катламнарда — шушы гасырдагы көнкүреш, тирәнрәк катламнарда — ерагырак тарихи чорлар, аскы катламнарда бик борынгы заманнар авазы ишетелә шикелле. Шунысы кызыклы: «Микулай заманы»ндагы рекрут җырлары, бик борынгы дәверләргә караган түгәрәк уен көйләре, печән өстендә башкарыла торган җырлар, күп тавышка исәпләнгән башка үрнәкләр якынрак елларда туган җырлар белән бергә яшиләр. Кунак каршылауның музыкаль бизәлешен генә алыйк. Мондый йола вакытында дүрт тавышка нигезләнгән борынгы традицион көйләр ишетү бүгенге заман кешесе күңелендә сүз белән аңлатып бирә алмаслык үзгә хисләр гаммасы барлыкка китерә. Әлеге хис-тойгылар, «исемсез» булсалар да, һәркемгә дә аңлаешлы һәм якын. Шунысын да әйтергә кирәк, мондый көйгә төрле эчтәлекле текстларны бик җиңел яңгыратырга мөмкин.

Мелодик стиль, лад, интонацион башкарылу рәвеше һәм хәтта тембр ягыннан аерылып торган көйләр бер үк кеше тарафыннан һәркайсы табигый рәвештә, ягъни үзләренә генә хас үзенчәлекләрне югалтмаган хәлдә башкарыла. Мәсәлән, Зәй районының Урта Баграж авылында яшәүче Е. Краснова (1897 елда туган) кунак каршылау һәм борынгы түгәрәк уен көйләрен стиль аерымлыкларын сокландыргыч дәрәҗәдә нечкә сиземләп, бер-берсенә охшамаган үзгә төсмерләрне бөтен тулылыгы белән балкытып яңгыратты. Әйтергә кирәк, керәшен татарлары көнкүрешендә мондый башкарылыш гадәти күренеш буларак яши.

Керәшен татарларының традицион җырлары коллектив башкарылышка исәпләнгән булулары белән һәм бигрәк тә музыкаль эстетика ягыннан аерылып торалар. Күп тавышлы башкарылыш формасы (гетерофоник стиль) йола үрнәкләрендә берничә «төп калып» рәвешендә кулланыла. Ә гомумән алганда, керәшен татарлары үткәндәге тормыш-көнкүрешнең бөтен якларын колачлаган тулы бер көй-җыр системасын хәзер дә кадерләп саклыйлар. Әлеге җыр фольклоры кулланылыш ягыннан нигездә ике тармакка бүленә: гаилә тормышына кагылышлы йола көйләре; хезмәт эшчәнлегенә һәм аерым ел фасылларындагы бәйрәмнәргә бәйле үрнәкләр. Шулар арасыннан календарь һәм түгәрәк уен җырлары бигрәк тә озын гомерле. Билгеле бер ел фасылында үткәрелә торган бәйрәм җырларын алтмыш яшьтән узган өлкән буын вәкилләре әлегәчә онытмаган. Борынгы түгәрәк уен көйләре, ягъни авыл читендә күңел ачкан чакта башкарыла торган җырлар хәзер үзенең табигый формасында

бөтенләй яңгырамыйлар. Шулай да алар өлкәннәр хәтерендә бүгенгәчә яхшы саклана. (Монда сүз совет чорында татарлар арасында таралган кыска көй төрендәге уен җырлары хакында түгел, ә керәшен татарлары тарафыннан гына башкарыла торган борынгы озын көйләр турында бара.)

Кызганычка каршы, аерым ел фасылларында башкарыла торган җырлар (нардуган көе, тручын көе, май көе) һәм түгәрәк уен көйләре акрынлап югала баралар. Мондый борынгы җырлар бүгенге яшьләрне кызыксындырмый, аларны, фольклорчы үтенече буенча, өлкәннәр генә башкара. Әлеге күренеш, мәгаен, авы...рда традицион күмәк күңел ачу үрнәкләренең бетүеннән киләдер. Мондый формаларны дискотека һәм башка шундый заманча чаралар кысрыклап чыгарды. Шулай итеп традицион җыр культурасының мелодика, фактура, тембр ягыннан гаять үзенчәлекле бөтен бер катламына юкка чыгу куркынычы яный. Әмма традиция үзенең теге яки бу жанр тармагын исән калдыру өчен барыбер ниндидер формалар таба. Түгәрәк уен көйләренең, әйтик, кунак җыю йоласында файдаланылуы әнә шул хакта сөйли. Гадәттә, мондый фольклор үрнәкләре рәт көе рәвешендә мәҗлес рухына ятышлы текстка, гомумиләштерелгән мәгънәгә ия булган очракта, шул ук түгәрәк уен көенә башкарыла. Биредә борынгы йола җырларын яшь буынга тапшыруның иң кулай үрнәге күренә шикелле. Дөрес, түгәрәк уен көйләре сабан туйларында хәзер дә ишетелгәли. Интонацион яктан алар «Авыл көе»нә охшаганнар. Тик мондый көйләрнең югарыда телгә алынган борынгы үрнәкләр белән бернинди дә уртаклыгы юк.

Керәшен татарларының гаиләгә бәйле булмаган йолалары кулланылыш әһәмиятләрен югалта баралар, ә менә туй, кунак җыю һ. б. шундый йолалар иҗтимагый актуальлекләрен җуймыйлар, алай гына да түгел, алар түгәрәк уен көйләрен дә үзләренә «тартып кертәләр». Әлеге йола борыңгы музыкаль традицияләрнең үзенчәлекле үзәгенә әверелеп бара. Үзенә күрә феноменаль күренеш, тирәнтен өйрәнүне таләп иткән яңарыш.

Кунаклар нинди генә уңай белән җыелмасын — туган көн мәҗлесенәме яки егетләрне армиягә озату кичәсенәме — һәрбер очрашу чын мәгънәсендәге җыр бәйрәменә әверелә. Мондый кичәләрдә, гадәттә, ихласлылык ташып тора, һәрбер кеше моң дәрьясында коена. Мәҗлес гасырлар буе камилләштерелгән «сценарий» буенча алып барыла. Җырлар мондый тәртиптә башкарыла: 1. Кунакларны сәламләү һәм хуҗаларның җавап рәвешендәге хөрмәтләве; 2. Кунакларның бәйрәм табынын һәм хуҗаларны мактавы; 3. Үзара кешелек сыйфатларын олылау (икенче һәм өченче пунктлар мәҗлес барышында кабатланып торалар); 4. Табынга ипи, пешерелгән каз чыгару, бәлешне кискәләү кебек аерым моментларны аягүрә басу һәм җыр белән билгеләү; 5. Кунакларны озату...

Җыр арты җыр... Сый-нигъмәтләрдән «сыгылып» торган табын да, пөхтәләп җыештырылган өй дә, яңа дуслар белән очрашу да җырласыны китереп тора шикелле. һәрбер көйгә мәҗлес рухына якын сүзләр сайлана. Кунаклар икмәкне олылап, сыйга рәхмәт белдереп җырлыйлар. Кара-каршы җырлаулар күңелле музыкаль диалогка әверелә. Үзенә күрә бер опера! Гадәттә, диалог бер үк көйгә корыла. Аерым кешеләргә карата кулланыла торган текстлар, кемнең кем булуына карап, төрлечә импровизацияләнеп башкарыла. Җырлаучының чичәнлек сәләте дә күренә. Шигырьдәге беренче ике юл, гадәттә, традицион була, һәм алар соңгы юллар белән, рифма аша тоташып, образлы параллель тәшкил итәләр. Соңгы ике юл исә конкрет вакыйгага яки аерым кешегә карый. Мәҗлестә рәт көе, әнә шулай, өзлексез яңгырый. Сценарийдагы мәҗбүри җырлар белән беррәттән, әйтик, кара-каршы җырларга чакырган яки кешенең аерым бер халәт-кәефенә хуш килгән такмаклар башкарыла. Берәмләп тә җырлыйлар, бергәләп тә... Гомумән алганда, кунак җыю йоласының музыкаль өлеше үзләренең төзелешләре ягыннан төрле-төрле җырларны берләштерә.

Шунысын да әйтергә кирәк: кунак җыю йоласының үз драматургиясе бар, һәм мәҗлестә катнашучылар аның эчке «йөрәк тибешен», әйтик, җырларның эмоциональ төсмерен, темпын һәм стилен үзгәртү тәртибен, ягъни «тәлинкәнең икенче ягын әйләндерү» вакытын бик нечкәләп тоемлыйлар. Һәркем җыр башларга хаклы. Теге яки бу җырны башлап кына җибәр, икенче юлыннан ук аны хор күтәреп ала. Җырлаучы тавышы бер көчәя, бер акрыная, әмма тынып калмый — агыла да агыла.

Һәрбер авылда аеруча яратып башкарыла торган кунак һәм рәт көйләре була, һәм алар, үзләренә күрә лейтмотив буларак, кич буе яңгырыйлар. Керәшен татарларының кунак җыю йоласын театраль-музыкаль циклга охшатырга мөмкиндер. Мондый кичәләрдә ритуалның үзәген билгеләүче төп көйләрне дә,

лирик җырларны һәм шаян такмакларны да күп ишетәсең, үзеңне «музыкаль театр»да булгандай хис итәсең.

Хәзер исә мисал өчен кунак җыю йоласының «җанлы сценарием» китерик. Мамадыш районының Владимир авылында булган мәҗлестән (1980 ел, 13 январь), хуҗабикәгә 70 яшь тулган көнне язып алынган әлеге текстларда без керәшен татарлары җырларындагы кайбер сүзләрнең әйтелеш үзенчәлекләрен саклап калырга тырыштык. Җырлаулар 3,5 сәгатькә сузыла. Укучы үзе дә тояр: сценарийдагы җырлар бик җанлы атмосферада үз-үзеңне иркен тоткан хәлдә башкарыла. «Очынып» торучы сүз, сыгылмалы ритм, шома рифмалар... Халык [illegible]каручылары авызы, кем әйтмешли, җырдан бушамый. Барысы да ихлас күңелдән җырлый. Өйдә яктылык һәм шатлык тантана итә.

Кунакларны каршылау.

Хор:
Әй, туганым, син мәнәй лә,
Син монда килдең мәнәй.
Зәйтүн гөле биш тармаклы,
Бер тармагы син мәнәй.

Кунак кеше хуҗа хатынга бүләк итеп җырлый:

Сандугачлар булып сайрар идем,
Өй артында яшел лә тал булса.
Төнге төшегезгә керер идем,
Төнге йокыларыгыз сак булса.

Түгәрәккәй куак, башы юак,
Мәкнең чәчәгенә ай охшаулы.
Ай, йөзләргә бераү, миңгә икәү
Безнең туганнарга ай охшаулы.

Барчасы бергә:

Түгәрәккәй гинә, ай, аланда
Болын чәчәккәйләре бар анда.
Җыелышкан чакларда җырлашыек,
Җыелып булмыйдыр җаланда.

Хуҗалар:

Ничек кенә килдегез сез безгә,
Төшмичә Кара ла диңгезгә.
Сезләр дә төшсәгез, ай, диңгезгә,
Кемнәр килерләр ләй соң безгә?

Кунаклар:

Иртәләрдә торып, тәсбих әйтеп,
Уң аяккайларымны киенәм.
Сезнеңләр дә белән күрешкәчтен
Ихлас күңелләремнән сөенәм.

Бергә:

Әле генә күрдем мин сезне,
Тагы кайчан күрермен мин сезне.
Итләрем дә бетәр, калыр сөягем,
Шул чакларда онытмам мин сезне.

Кунаклар:

Турыгыздан, әй, үткән чакта
Бик якты ие сезнең дәй утыгыз.
Ашап-эчертәсез, ай, сез безне,
Бай-дәүләтле булса ие йортыгыз.

Кунакның шаяртулы таләбе:

Су буйларында урнашкан
Безнең колхоз амбары.
Итегез булса — турагыз,
Без китәбез аннары.

Кунак:

Настә түтәй җитмештә,
Настә түтәй җитмештә.
Сиксән, туксанга җитсә дә,
Әйтмибез без бер сүз дә.

Кыз туган:

Җиңгәй, сиңа теләгем шул:
Башла сиксәнлегеңне.
Кайда барсаң да теләләр
Синең исәнлегеңне.

Барчасы бергә:

Стенада ике сәгать,
Берсе суга минутка.
Авыр хәсрәтләр булса да,
Туган, безне онытма.

Туганнарым, сезгә әйтәм,
Бергә ашыек ашларны.
Бергә ашагач ашларны,
Югалтмыйбыз башларны.

Җир шары ул, җир шары ул,
Җир шары ул түгәрәк.
Шул түгәрәк эчләрендә
Йөрсәк иде бергәләп.

Әй, туган, син төш икәнсең,
Чикләвек төш икәнсең.
Мәҗлесләрдә утырырга
Беренче кеше икәнсең.

Туган илнең болыннары
Бигрәк матур күренә.
Бу туган ил никләр болай
Онытылмый гомергә.

Манара биек булса да,
Кошлар оя ясамый.
Ал булса да, гөл булса да,
Туган илгә охшамый.

Кунаклар:

Табыннарда булган, әй, баллары
Әче баллар түгел, төче бал.
Безнең күршебезнең өстәлендә
Ни ашарга теләсәң, шунсы бар.

Ишеккәй алларында, әй, йомычка,
Җыеп кына алам ди бер учка.
Күршеләрегез лә әйбәт булгач,
Йөгереп үк керегез йомышка.

Барчасы бергә:

Безләр кишәнке ай ла чикләвекне
Әй, өчкә генә дәй, дүртләргә бүләек.
Без бит барыбыз да, ай-һай, бертуган,
Ай, бер-беребезнең өчен дә үләек.

Стенада ике сәгать,
Берсе суга минутка.
Шушлай бергә утырганны
Аерылгач та онытма.

Кунаклар хуҗаларга:

Ишекләрдән керү белән
Карадым түрегезгә.
Ашыгызга-суыгызга,
Рәхмәт үзегезгә!

Кунак хатын-кыз:

Билләрендәге дә лә алъяпкычың
Кайсы күчергечләрдән күчердең?
Тәмле-татлы ашларны пешергәндә
Мине ничек исеңә төшердең?

Барчасы бергә:

Кулымдагы, әй дә лә, йөзегемнең
Исемнәре аның дый Муллахмәт.
Мал табучыларга бик рәхмәт,
Җырлап утырулар ла рәхәт.

Кубыз авазларын, әй, ишеткәч,
Әйләнәек кубызлар көенә.
Безнең белән бергә бер утыргач,
Безнең туганнарыбыз сөенә.

Яңгырлар ява ла, әй, болыттан,
Тунны тектерәек толыптан.
Бу ашаганнарны, бу эчкәнне
Гомерләрем буена да онытмам.

Ишек алларыңны себереп куй,
Алма тәгәрәтеп тәй уйнарсың.
Бу җырлауларымны ишетеп тор,
Мине исеңә төшереп җыларсың.

Кыз туган:

Тәрәзә төбендә, әй, исле гөл,
Иснә, туганым, әле исле ул.
Урталарында дый бер чәчәк бар,
Өзмәем дә лә сезнең төсле ул.

Барчасы бергә:

Алай да бергә, бергә,
Болай да бергә, бергә.
Безнең бергә булуыбыз
Китсен бөтен гомергә.

Рәхмәт, туганнар, сезгә,
Карап торасыз безгә.
Сез сандугач кебек безгә,
Без ничек икән сезгә?

Кунаклар хуҗаларга:

Рәхмәт сезгә лә, әй тау сезгә,
Бадыяннар белән нә бал сезгә.
Бадыян-бадыян, әй, бетмәсен,
Башыгыздан дәүләтләр китмәсен!

Хуҗалар:

Иртә дәй торып лай тышка чыксам,
Баллар яуган безнең дәй кортларга.
Сез дәй туганнарны килеп күргәч,
Ямь керде безнең дәй йортларга.

Барчасы бергә:

Ишек алларында, әй, тагарак,
Тагаракның эчләре саерак.
Сагынган чакларда без күрештек,
Утырыек әле лә саерап!

Аклы яулык киштәдә лә,
Сатыладыр бистәдә.
Безнең болай утырулар
Юк ие лә истә дә.

Урманнарга керсәм, исем китә
Болын чәчәккәенең исенә.
Үземнең, әй, үзем исем китә
Сезне күргәч сөенүемә.

Өй алларында ла ана үрдәк
Яңа бәбекәйләргә утырган.
Өстәлнең ди башын ямьле итеп,
Безнең кодагыйлар дый утырган.

Биеккәй дәй тауның башларында
Төлке маен куйдым дый табакка.
Йөзләрегез якты, сүзегез татлы,
Гомерегез булсае озакка.

Аклы ситсы кулмәгеңнең
Якасын уймаганнар.
Йөзегездә кояш уйный,
Ай гына куймаганнар.

Агай-эне без икебез,
Житен чәчик бакчага.
Сезнең күк туганнарымны
Табып булмый акчага.

Хуҗа хатын:

Минем дәй бакчада гөлләрем бар,
Гөлләргә дәй элгән сөлгем бар.
Сиңа җырламасам, кемгә җырлыйм,
Синнән якын, туганым, кемем бар?

Кунак хатын-кыз җавабы:

Биеккәй тауның дый башларында
Кайсы илләр ятадыр ай кебек.
Синең дәй әле дәй әйткән сүзең
Йөрәкләргә ятадыр май кебек.

Кунаклар:

Иртәләрдә торып тышка чыксам,
Бай кызлары талкан талкыйдыр.
Китәсе дәй булгач, без китәек,
Өйдәге җәмәгать ярсыйдыр.

Тәрәзәне ачып ла мин сызгырдым,
Болындагы печәннәр кипсен дип.
Болындагы печәннәр, әй, кипте инде,
Безгә кайтыр вакытлар җитте инде.

Хуҗалар:

«Китәбез»,— дисәгез дәй, озатыек,
Китәр юлларыгыз да бик уңай.
Сез дәй киткән юлларга карый-карый,
Ямансулап йөрербез бер уңай.

Кунаклар тарала башлыйлар.
Барчасы бергә:

Биек тауның башларында
Ялтырый моржалары.
Төрлебезне төрле якка
Аера дөньялары.

Урманнарга керсәң, сызгырып җибәр,
Селкенмәгән агачлар калмасын.
Йөргән җирегездә йөрегез яхшы,
Сокланмаган кешеләр калмасын.

Безнең урам буенча ла
Тезелеп киткән ак каен.
Ак каенга һаман карыйм
Сезне сагынган саен.

Әй лэр, алмай аша ди, әй алма аша,
Алма ашасам, тешләрем камаша.
Сез ташласагыз да дый, мин ташламам,
Газраил җаннарны алмаса.

Музыкаль диалог ишек янында дәвам итә. Кунаклар төркем-төркем булып җырлыйлар:

Карлыганнар каралса да,
Без каралмабыз әле.
Таулар-ташлары булса да,
Без аерылмабыз әле.

Тәрәзәңнең пәрдәләрен
Күтәреп куй бер читен.
Килүләре күңелле ие,
Кайтулары бик читен.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Балтырган.
Узган чакта керегез, туган,
Кадер итми калдырмам.

Әйтик әле, әйтик әле
Унын да, тугызын да.
Мәкнең алсу чәчәге күк
Күрәм барыгызны да.

Ай яктыда кырга чыга
Карурманның төлкесе.
Ашыйк-эчик, уйныйк-көлик,
Булмыйк кеше көлкесе.

Урманнарга кергән чакта
Күзем төште куакка.
Бергә чакта җырлыйк әле,
Үлгәч кертмәсләр кунакка.

Бергәләп җырлап тай без карыек,
Килешер лә микән, ай, көебез.
Килешер ләр булса, ай, көебез,
Җалан шушлай берләргә йөрербез.

Кара урманнарны, ай, кергәнсез,
Агач башкынайларын игәнсез.
Настәнең дә лә, ай, җитмешкәчен
Тутырганын сезләр дип белгәнсез!

Мәҗлестә катнашучылар, өйдән чыгып, урам буйлап барганда да шул рәвешчә җырлауларын дәвам иттерәләр.

Керәшен татарларының кунак җыю йоласында, күренгәнчә, халыкның коллектив җыр культурасы традицияләре аеруча ачык чагыла. Гадәти көнкүреш вакыйгасы да музыкаль яктан әнә ничек бизәлә. Җырлаучыларның «сыгылмалы» сценарийдагы бөтен нюансларны нечкәләп аңлаулары да, мәҗлеснең рухына туры килерлек сүз сайлый белүләре дә, аларның чичәнлек осталыгына ия булулары да — барысы да сокландыра. Мондый кунак йоласы, әйе, чын бәйрәм төсендә уздырыла. Кунаклар биредә эстетик ләззәт алачакларын алдан ук белеп киләләр, чөнки алар табын янында ашап-эчеп утырырга гына түгел, ә җырлап күңел ачарга җыелалар. Кыскасы, әлеге йола музыканың халык тормышын тагын да ямьләндереп җибәрүен, яшәргә дәрт бирүен бөтен тулылыгы белән раслый. Борынгы йола җырлары, җанлы аралашу, күңелләрне баету чарасы буларак, яңара-яңара яшәүләрен дәвам иттерәләр.

# ГАСЫРЛАРНЫ КИЧКӘН СЮЖЕТ

Көнчыгыш әдәбиятларыннан тәрҗемә ителеп яки иҗади эшкәртелеп кульъязма һәм басма китап рәвешендә халык арасында таралган матур әдәбият әсәрләре, XIX гасырның әдәби процессында үзе бер юнәлеш булып, татар халкының рухи культурасында зур урын алып тора. Аларны, гадәттә, «хикәят» һәм «кыйсса китаплары» дип атап йөрткәннәр.

Шуларның берсе — «Мәликә китабы» — Казанда 1846 елда университет типографиясендә дөнья күрә. 16 биттән генә торган бу китапның 1905 елга кадәр тагын 10 тапкыр басылып чыгуы аның халык арасында зур популярлык казануы хакында сөйли.

«Мәликә китабы» — XIX гасыр дәвамында кульъязма һәм басма рәвештә бик күп таралган хикәят китапларының типик бер үрнәге. Шуңа булса кирәк, әдәбият тарихчылары шул заман прозасы турында сүз алып барганда аны телгә алмый узмыйлар.

Гали Рәхим белән Г. Гобәйдуллиннарның 1925 елда басылып чыккан «Татар әдәбияты тарихы» китабында, «Хикәят китаплары» дигән бүлектә «Мәликә китабы» турында да сөйләнелә.

Хикәятнең билгеле булган вариантларын үзара чагыштырып карап: «һәрхәлдә, бу рисалә безнең халык каршында бик мәкъбул[1] китаплардан берсе булып, хосусан, хатын-кызлар аны яратып укучан иде»,— диләр.

Профессор М. Х. Гайнуллин да бу хикәяткә игътибар итеп, аның халык арасында зур популярлык казануын билгеләп үтә[2].

XIX гасыр татар прозасы турында махсус хезмәт язган С. Х. Хафизов «Мәликә китабы»ның традицион сюжетка нигезләнеп язылуын телгә алып уза, аның Ф. Халиди иҗат иткән бер вариантын да искә алып: «Традицион сюжет бу очракта язучыга мәгърифәт, зирәклекнең өстенлеген раслау өчен мөмкинлек тудырган»,— дип нәтиҗә ясый[3].

Соңгы вакытта «Мәликә китабы» сюжетына корылган, әлегә татар әдәбияты тарихында билгеле булмаган берничә әсәр табылды, аларның төрле чорда иҗат ителгән күп төрле вариантлары барлыгы ачыкланды.

Алга таба башка вариантлар белән чагыштырып күзәтүләр ясарга мөмкин булсын өчен, «Мәликә китабы»ның кыскача эчтәлеген китерәбез:

Рум шәһәрендә Мәлик исемле бер падишаһ була. Мал-мөлкәте күп булса да, балалары булмый. Ул корбанга кырык дөя чала, алладан үзенә бала бирүен сорый. Тиздән кызы туа. Кыз бик акыллы булып үсә, 20 яшьләренә инде шулкадәр зур укымышлы була, хәтта галимнәр дә аның алдында үзләрен көчсез тоялар. Әтисе кызын кияүгә бирергә тели, бер кешесен пәйгамбәрдән киңәш сорарга җибәрә. Пәйгамбәр җавап бирә: «Никах минем сөннәтләремнән берсе, кем минем сөннәтемне үтәми — шул минем юлдан бармый». Кызына тәэсир итәргә теләп, падишаһ аңа пәйгамбәрнең сүзләрен җиткерә. Әмма кыз үзенә тиң белемле, үзе яраткан кешесен тапса гына аның әйткәнен үтәргә риза була. Вакыты җиткәч әтисе үлә. Кыз тәхеткә утыра. Шәһәрнең бөтен галимнәрен җыеп, аларга:

— Сезгә йөз соравым бар, әгәр кем дә кем барысына да җавап бирсә, патшамы ул, ярлымы ул — шуңа кияүгә чыгам,— ди.

Күпләр үзләренең бәхетен сынап карыйлар, ләкин дөрес җавап бирә алмыйлар. Алдан куелган шарт буенча, кыз аларның башын кистерә. Тиздән бу хәбәр Төркстанга да барып җитә. Анда Гәбделхәлим исемле бер егет зур гыйлемлеккә ия була, шәригать кануннарын һәм матур сөйләү хикмәтләрен яхшы белә. Ул да бәхетен сынап карарга

---

[1] Мәкъбул — кабул ителгән, яратылган.

[2] Гайнуллин М. Х. Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан, 1968, 18 б.

[3] Хафизов С. Х. XIX гасыр татар прозасы. Уфа, 1979, 22 б.

теләп, Мәликә янына килә. Мәликә, егетнең чибәрлеген күреп, сынаудан баш тартырга әнди. Әмма егет:

— Син — чыраг[1], мин — ут янында очып йөрүче күбәләк, үлсәм дә гаҗәп түгел,— дип, мәсьәлә-сорауларга җавап бирә башлый. Берсе арты берсе барлык сорауларга да җавап биреп, Гәбделхәлим бәхәстә җиңеп чыга һәм падишаһ кызы Мәликәне үзенеке итә.

Гали Рәхим һәм Газиз Губәйдуллин бу хикәятне тикшереп аның берничә варианты барлыгын әйтәләр: «Мәликә китабы»ның асылы Урта Азиядән чыккан. Ихтимал, анда бу китапның берничә варианты бардыр. Безгә мәгълүм булганы белән Казан басмасы арасында байтак аермалар бар. 1911 елда Ташкентта ташбасмада басылган бу китап «һәза сөаль Мәликә вә Данешмәнд» («Мәликә белән галимнең мең сөале») дип атала. 100 битле бу китап безнең Казан нөсхәсенә карагында күп зур, андагы сөальләрнең саны китапның исеменнән күренгәнчә, меңгә үк тулмаса да йөздән байтак артык... Шул рәвешчә, әсәрнең мөндәриҗәсендә[2] булсын, телендә булсын, беркадәр аермалар бар. Безнең «Мәликә китабы» яки башка бер чыгтайча вариантыннан күчерелгән, яки татар укучысының үз тарафыннан үзгәртелгән һәм кыскартылган булырга кирәк».

Биредә Г. Рәхим һәм Г. Газизнең кайбер фикерләре бәхәсле. Мәсәлән, «Мәликә китабы»ның асылы Урта Азиядән чыккан», «башка бер чыгтайча вариантыннан күчерелгән» диган сүзләр белән тулысынча килешеп булмый. Чөнки авторларның бу әсәрнең татарларда бик күптәннән тәрҗемә ителгәне һәм кулдан кулга йөрүе хакында мәгълүматлары юк: «Казан басмасында булсын, Төркстан басмасында булсын, «Мәликә китабы»ның кайчан язылуы хакында мәгълүмат юк. Безнең татар арасында ул басылганчыга кадәр кулъязмада йөргәнме-юкмы — белә алмадык...» — диләр. Димәк, ул чорда (20 нче елларда) тикшеренүчеләргә кулъязма әсәрләр билгеле булмаган. Ә кулъязмалар күп нәрсәләр хакында хәбәр бирә, кайбер мәсьәләләргә ачыклык кертә.

Тикшеренүләр барышында шул сюжет урын алган күп кенә кулъязмалар табылды һәм кайбер күзәтүләр ясалды. Иң элек бу әсәргә XVIII гасыр тәрҗемә прозасының зур ядкаре — кулъязма җыентык «Мәҗмугыл хикәят»не өйрәнгәндә игътибар ителде.

«Мәҗмугыл хикәят» — үзенең тамырлары белән борынгы фарсы, гарәп, һинд әдәбиятларының искиткеч бай әдәби һәм фольклор традицияләренә тоташкан, әдәби яктан да, тел ягыннан да бик камил булган 30 дан артык хикәятне берләштергән җыентык. Хикәятләр 1775 елда Себердә, Тубыл өязе Тара елгасы буйларында яшәүче бараба татарлары арасында, Казан өязе Ташкичү авылы кешесе Мөхәммәтрәхим бине Рәфыйк әл-Казани тарафыннан күчерелеп, бер җыентык итеп тупланганнар. Соңыннан бу китап Мөхәммәтрәхимнең туган ягына кайтып ирешеп, кулдан кулга йөргән, укылган һәм күчерелгән. 305 битле бу җыентыкта, әлеге безгә билгеле «Мәликә китабы» сюжетына охшаш сюжетта төзелгән хикәят болай атала: «Шул хикәятдер: кем бер падишаһ Хәләф атлы углы булып, Фәгъфур Чинның кызы белә берничә мәсьәлә араларында улып, күп вакыйгалар үткән хикәятләредер». Бу хикәят — җыентыктагы әсәрләрнең иң күләмлеләреннән берсе. Ул үзендә ике зур сюжетны берләштерә. Шаһзадә Хәләфнең мәсьәләләр биреп егетләрне сынаучы Кытай падишаһы Фәгъфур кызын очратканчыга кадәр тормышы, башыннан кичергәннәре — үзе бер хикәят.

Басма вариантны тикшергән М. Гайнуллин, аның киң таралу фактын аңлатып, болай ди: «Күрәсең, хикәятнең популярлыгы аның сюжетында түгелдер (сюжет бик үк кызыклы түгел), ә бәлки сораулар һәм аларга кайбер җавапларның кызыклы булуында»[3].

Кулъязма вариантта исә сюжет та бик кызыклы һәм мавыктыргыч, хикәятнең теле дә, сурәтләү чаралары да күпкә баерак. Шуңа күрә дә ул тәрҗемәгә лаек булган һәм кулъязмадан кулъязмага күчеп йөргән.

Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә «Мәҗмугыл хикәят»нең вариантларын эзләгәндә «Мәликә хикәяте»нә дә игътибар ителде. Хәзергә бу хикәят 17 кулъязмада табылды. Шуларның өчесе — «Мәҗмугыл хикәят» күчермәләре арасында.

Кулъязмалардагы хикәятләрне күләмнәре һәм сюжет үзенчәлекләре буенча нигездә 3 төркемгә бүлеп карарга була. 1 нче төркем — «Мәҗмугыл хикәят» эченә кергән әсәргә охшаш хикәятләр. 2 нче төркем — Ташкентта басылган ташбасма китаптагы әсәргә охшаш хикәятләр. 3 нче төркем — Казан басмасындагы «Мәликә китабы»на охшаш хикәятләр. Болары күләм ягыннан иң кечкенәләре һәм язылу, күчерелү даталары белән дә иң соңгы чорга, ягъни XIX гасырга карыйлар. «Мәҗмугыл хикәят»тәге вариант исә XVII гасыр ахырларында ук тәрҗемә ителеп, XVIII гасыр дәвамында укылып йөргән һәм татарлар яши торган бөтен төбәкләргә таралган.

Ә иң элгәре вариант кайсы чорга карый соң?

---

[1] Чыраг — ут.

[2] Мөндәриҗә — эчтәлек.

[3] Гайнуллин М. Х. Татарская литература XIX века. Казань, 1975, 28 б.

1982 елның җәендә Ленинград Көнчыгыш институты китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә эзләнүләр белән шөгыльләнгәндә «Кыйсса-и Ибраһим егет вә падишаһ кызы» дип исемләнгән кулъязма табылды. Шигъри икеюллыклар белән язылган бу кыйсса «Мәликә китабы»ндагы сюжетка корылган әсәр булып чыкты. Сюжет бик кызыклы, анда башка вариантларда булмаган мотивлар да бар. Кыз белән егет арасында сорау-җавап ярышы беткәч, ахырда егет үзе бер сорау бирә. Кыз аңа җавап бирә алмый. Бик гарьләнеп, җавапны хәйлә белән белү өчен тесен-кыяфәтен үзгәртеп, төнлә егет янына килә. Егет белән мәҗлес корып, аңа шәраб эчертеп, җавапны сорап белә. Соңыннан егеткә йоклата торган дару биреп, чыгып китә. Әмма егет янында кызның йөзеге онытылып кала. Шушы йөзек аркасында егет зур хәвефтән котыла һәм патша кызы белән кавыша. Менә бу йөзек мотивы башка вариантларда очрамый.

Безнең өчен шунысы әһәмиятле — әсәр ахырында автор кыйссаның язылган вакытын күрсәтә: ул һиҗри белән 784 ел, милади белән бу 1382 елга туры килә. Димәк, әсәр Алтын Урда чорында, Идел буенда төрки әдәбиятның чәчәк аткан чорында язылган. Шушы ук кулъязмада атаклы «Кисекбаш» кыйссасы бар. Аны махсус тикшергән Я. Әхмәтгалиева әсәрнең язылу вакытын XIV йөзгә, Алтын Урда дәверенә нисбәт итә[1]. «Кисекбаш» кыйссасы да, моннан тыш бу кулъязмадагы тагын ике шигъри әсәр дә тел һәм стиль ягыннан «Мәликә кыйссасы»на бик якыннар.

Шигырь белән язылган бу әсәрнең башка нөсхәләре, вариантлары бармы, таралуы ничек,— бу аерым тикшеренүне таләп итә.

Һәрхәлдә, әле бу тулы булмаган нөсхәнең табылуы да безнең XIV йөз әдәбиятына яңа бер әсәр өсти, Көнчыгыш әдәбиятлары белән, аерым алганда, фарсы әдәбияты белән бәйләныш традицияләренең бик тирәннән килгәнен һәм беркайчан да өзелеп тормавын күрсәтә.

«Мәликә» сюжетының татар әдәбиятында XIV гасырдан XX гасыр башларына кадәр төрле вариантларда, төрле формаларда бик киң таралуы борынгы дәвердән үк язма культурасы булган башка халыкларның әдәбиятлары белән чагыштырып карарга, уртак типологик якларны һәм үзенчәлекләрне билгеләргә, беренчел чыганакларны ачыкларга мөмкинлек бирә.

Бу җәһәттән 1600 еллык тарихы булган әрмән әдәбиятында бу сюжетның бездәге кебек үк актив кулланышта йөрүен күрсәтеп үтү урынлы булыр. Әрмәнстанның кулъязмалар саклый торган зур үзәге Матенадаранда бу сюжет урын алган XVI—XIX гасырларга караган 33 кулъязма саклана. Иң элгәрге чорга караган, X гасырда гарәпчәдән тәрҗемәнең күчермәсе булган XIV гасыр кулъязмасы исә заманында Римда сакланган булган. Әрмәнстанда таралган сюжетларны тикшергән әдәбият галиме А. Н. Срапян әсәр хакында болай ди: «Кыз һәм егет турындагы хикәят» үзенең дөньяви рухы, үгетләүгыйрәтү характеры, художество йөзенең, аерым алганда композициясенең, үзенчәлекле булуы белән әрмән урта гасыр художестволы прозасының зур популярлык казанган иң элгәрге үрнәге булып тора»[2]

Әрмән кулъязмалары арасында да, бездәге кебек үк, сюжетның төрле вариантлары бар. X гасыр тәрҗемәсе дип саналган XIV гасыр кулъязмасындагы вариант Казан басмасындагы «Мәликә китабы»на бик якын.

А. Н. Срапян әрмән әдәбиятында таралган бу сюжетның төрле вариантларын башка халык әдәбиятларында йөргән сюжетлар белән, бигрәк тә чыганакка якын дип саналган «Мең дә бер кичә» белән чагыштырып, шундый нәтиҗә ясый: «Хикәятнең турыдан-туры чыганаклары — тәрҗемәләр яки гарәп телендәгеләр — хәзергә табылмады. Башка илләрдә таралганлыгы хакында аның бары тик ераклашкан варианты булган «Таваддуд исемле акыл иясе кыз турында хикәят» дигән исем белән билгеле әсәр буенча гына хөкем йөртергә мөмкин»[3]. Күрәсең, Срапянның төрки әдәбиятларда, аерым алганда, татар әдәбиятында бу сюжетның таралышы хакында мәгълүмате юк. Ә бездәге күп төрле вариантлар тамырларның кайсы чыганакларга барып тоташуын шактый ук ачык күзалларга ярдәм итәләр.

«Мәликә китабы»н әле башлангыч тикшерү процессында гына да кулъязма китаплар арасында аның шактый вариантлары табылды.

Бу урында «Мәликә» сюжеты урын алган әсәр — Ш. Рәхмәтуллинның «Кылаф белән Турандык хикәяте» дигән китабына[4] игътибарны юнәлтәсе килә.

Ш. Рәхмәтуллин бу китабында көнчыгыш әдәбиятында һәм фольклорында бик популяр булган сюжетларны бик оста берләштереп, халык сөйләменә якын әдәби телдә, татарча яңгырашлы кызыклы әсәр тудырган. Язучы бу әсәрендә хатын-кызларның

[1] Ахметгалеева Я. С. Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы». М., 1979, 57, 119 бб.

[2] Срапян А. Н. Армянские редакции повести о Мудрой деве.— К-та: Русская и армянская средневековые культуры. Л., 1982, 70 б.

[3] Срапян А. Н. Күрсәтелгән хезмәт, 74 б.

[4] Шиһабетдин бине Габделгазиз. Кылаф белән Турандык хикәяте. Казан, 1903

кимсетелгән, коллык хәлендә булуына каршы бөтен күңеле белән протест белдерүче ирек сөючән кызның күзгә бәрелеп торган көчле характерын тасвир итә. Монда без характеры буйсыну, үзен-үзе корбан итү, михнәт чигә һәм үзенең теләкләрен тыеп тора белүдән үрелгән хатын-кызны түгел, ә капма-каршы сыйфатлары — үзенең хокукларын, кешелек дәрәҗәсен кыю рәвештә яклау сыйфатлары булган хатын-кыз образын күрәбез.

«Кылаф белән Турандык хикәяте»ндәге сюжет югары без телгә алып узган «Мәҗмугыл хикәят»тәге сюжетка бик якын. «Кылаф белән Турандык»та бары тик вакыйгалар барган урыннарның атамасы шактый конкрет (аларның күбесе төрки җирлеккә карый) һәм күп персонажларның исемнәре төрки-татарча. Мәсәлән: Идел буендагы Әстерхан ханлыгы, анда яшәүче нугайлар, аларның ханы Тимерташ, аның хатыны Алмас ханым, уллары Кылаф (ягъни Хәләф), Әстерхан ханлыгын басып алган Карзум (Хорезм) солтаны, Кытай ханлыгының башкаласы Пекин шәһәре, падишаһы Алтын хан, аның кызы Турандык һ.б.

Чагыштырып караганда сюжетларның икесенең дә бер фарсы чыганагына барып тоташканлыгы аңлашыла. Ә ул нинди чыганак икән соң?

Татар халкы арасында таралган бу сюжетның күп вариантларыннан берсе — Ш. Рәхмәтуллинның «Кылаф белән Турандыгы» — чыганакны ачыклауда үзенә күрә бер ачкыч кебек. Ш. Рәхмәтуллин китабының исеме астына ук: «Әлфе нәһар»дан алынып тәрҗемә ителде»,— дип аңлатма биргән. Димәк, әсәр төрек телендәге «Әлфе нәһар вә нәһар»дан, ягъни «Мең дә бер көн»нән алынган. Төрекчәгә бу җыентык XVIII гасырда французчадан тәрҗемә ителгән. Ә француз тәрҗемәсе исә Көнчыгышны өйрәнүче галим Пети де ла Круа тарафыннан эшләнеп, 1712 елда фарсы хикәятләре җыентыгы булып басылып чыга. Ориенталист Пети де ла Круа бу әсәрне Исфахан суфиларының шәехе Мөхлистән алып торып күчергән була. Ә Мөхлис исә бу хикәятләрдәге сюжетларның шактыен бөтен Көнчыгышка билгеле булган һинд комедияләреннән алып, фарсы телендә оригиналь бер җыентык итеп эшләгән.

Пети де ла Круаның французчага тәрҗемәләре соңыннан «Мең дә бер көн» һәм «Феялар кабинеты» исемле җыентыкларга кертелеп яңадан басылалар һәм бөтен Европага таралалар. Бу җыентык XVIII гасыр ахырында рус теленә дә тәрҗемә ителә[1].

Француз тәрҗемәсендә шаһзадә Хәләфнең исеме «Калаф»ка, Турандыкның исеме «Турандот»ка әйләнә. Шушы ук үзгәртелгән исемнәр төрек һәм татар тәрҗемәсенә дә шул яңгырашлары белән кереп китәләр.

Сюжетның кызыклы һәм вакыйгаларга бай булуы аркасында ул Европа әдәбиятларында, бигрәк тә театр өчен язылган әсәрләрдә файдаланылып, тәрҗемә ителгән заманында ук бик тиз популярлашып китә.

Иң беренче булып бу сюжетны француз драматургы Лесаж үзенең «Кытай принцессасы» исемле комик операсында сәхнә өчен эшкәртә. Опера Парижның Ярминкә театрында 1729 елда куела.

Үзенең сәхнә өчен язылган әкият-пьесаларында төрле халыкларда таралган популяр әкият сюжетларын бик иркен кулланган итальян язучысы Карло Гоцци да (1720 —1806) бу мавыктыргыч сюжетка мөрәҗәгать итми калмаган. К. Гоцци Лесаж операсын белгән хәлдә, сюжетны чыганакка шактый якын итеп кулланып, шуның өстәвенә традицион итальян халык театры репертуары элементларын кертеп, Лесажныкына караганда тирәнрәк һәм баерак эчтәлекле пьеса иҗат итә. «Турандот» дип исемләнгән бу әсәр беренче тапкыр сәхнәгә 1762 елның 22 гыйнварында куела һәм шул көннән ук зур популярлык казана башлый. «Гоццины Турандоты гаилә коллыгыннан үзен азат итү өчен көрәшүче хатын-кызның беренче көчле образы. Веймар театры өчен шактый үзгәрешләр кертеп һәм Турандот ролендә патетик элементларны сизелерлек көчәйтеп «Турандот»ны тәрҗемә иткән Шиллерны бу образ юкка гына сокландырмаган, билгеле».

«Турандот»ның бай әдәби һәм сәхнә тарихы бар. Бу әкият сюжетына сигезгә якын опера, шул исәптән вакыт ягыннан соңгысы һәм иң яхшысы — Дж. Пуччини операсы язылган. «Турандот»ның күп санлы сәхнә куелышларыннан Е. Б. Вахтанговның үз студиясендә (соңыннан ул Евг. Вахтангов исемендәге Дәүләт театры булып киткән) 1922 елда куелышы иң атаклы булып санала.

Татар сәхнәсендә ул беренче тапкыр 1927 елда «Хан кызы Турандот» дигән исем астында куела. Аны татарчага драматург К. Тинчурин тәрҗемә иткән.

XIV гасырда, поэзия жанрларына иркенләп үсеп китәргә мөмкинлек булган, Хәрәзми, Х. Кәтиб, Котб, С. Сараи кебек шагыйрьләр иҗат иткән чорда сюжет шигъри калыпка салынып, кыйсса формасында язылган.

XVIII гасырда исә сюжет проза формасында яши. Татар әдәбиятының үсеше өчен мөмкинлекләр бик нык чикләнгән бу чорда бик күп әсәрләр читтән, көнчыгыш әдәбият-

---

[1] Тысяча и один день. Персидские сказки, переведенные с персидского языка на французский Г. Пети де ла Круа, а с французского на российский М. В. Поповым. Ч. 1 — 4. М., 1801.

ларыннан алына һәм оригиналга шактый якын тәрҗемәләр формасында тарала. Җәмгыятьтәге яңарышлар, дөньяви әдәбиятка, актив геройга булган ихтыяҗ чит әдәбиятларда күзәтелгән күренешләрне үзләштерергә мәҗбүр иткән. Билгеле, бу шартларда сюжетлар күбесенчә проза формасын алган.

Бу чорда әдәби процессы бөтенләй башка шартларда барган, культура үсеше нык алга киткән Италиядә исә сюжет драма әсәре формасында гәүдәләнеш таба.

XVIII гасырда «Мәҗмугыл хикәят» китабында булган һәм башка күчермәләрдә таралган бу сюжет алга таба кат-кат күчерелеп һәм халык теленә күчеп, шул тел җирлегендә адаптацияләнә, үзгәрешләр кичерә, кыскара, яңа вариантлары барлыкка килә. XIX гасырның беренче яртысында татарларда китап басу эше тернәкләнеп киткәч, шул чордагы дөньяви эчтәлекле проза әсәрләренә ихтыяҗга җавап буларак, ул басма китап рәвешендә яши башлый һәм бик нык популярлашып, чын мәгънәсендә халык китабына әверелә.

XIX гасырның икенче яртысында К. Насыйри, Г. Фәезханов, Ф. Халиди кебек Көнчыгыш әкиятләрен тәрҗемә итеп яки иҗади эшкәртеп, китап итеп бастырып чыгаручы галим-язучылар мәйданга килгән чорда бу сюжет электән таралган кульязмалардан һәм бөтенләй башка юллар белән үтеп кергән чыганаклардан да алынып, татар әдәбиятында яшәвен дәвам итә. Ул Ф. Халидинең милли җирлеккә якын әсәр[1] иҗат итәргә омтылышы булып та, Ш. Рәхмәтуллинның кысалы повесть (обрамленная повесть) язудагы бер тәҗрибәсе буларак та шул чорның әдәби процессында эзләнүләр җимеше булып тора. Күчмә сюжетларның татар әдәбиятының төрле чорларында актив кулланылышта йөрүе шуны күрсәтә: мең елдан артык тарихы булган бу әдәбият үз эчендә генә йомылып яшәмәгән, дөнья әдәбиятының игътибарга лаек булырлык, зур художество кыйммәтенә ия булган әсәрләрен, чорына, урынына карата кирәкле идеяләрне сурәтләп бирә алырлык сюжетларны иҗади үзләштергән, үз эстетик зәвыклары системасына яраштырып, үз байлыгы эченә кушып җибәргән.

Әле бер сюжетның әдәбият тарихында хәрәкәтен һәм яшәеш формаларын күзәтеп үткәндә дә, әдәби бәйләнешләрнең бай һәм кызыклы картинасы күз алдына килеп баса һәм татар әдәбиятына гына хас үзенчәлекле яклары ачыла.

Ә андый сюжетлар, аларга нигезләнеп язылган әсәрләр безнең XX гасыр башына кадәр булган әдәбиятыбызда гаять зур урын алып тора. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Х. Кәтибнең «Җөмҗөмә солтан», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», С. Сараиның «Гөлстан бит-төрки» кебек әдәбият тарихыбызның башында торган әсәрләрнең күбесе халыкара күчмә сюжетларны файдаланып иҗат ителгәннәр. Ә инде авторлары билгесез «Сәйфелмөлек», «Бәхтиярнамә», «Тутыйнамә», «Кырык вәзир» китапларын әйткән дә юк! XVIII гасырда таралган «Мәҗмугыл хикәят» китабында гына да 30 дан артык хикәят, шулар эчендә бөтен Көнчыгышта һәм Европа әдәбиятларында популяр булган 60 тан артык сюжет бар. Һәм ул сюжетларның байтагы XIX гасыр дәвамында төрле авторлар тарафыннан иҗади кабул ителеп, эшкәртелеп, күптөрле вариантларда, төрле жанрларда яшәүләрен дәвам иткәннәр.

Югарыда әйтелеп узылган һәм монда телгә алынмаган күп кенә әсәрләр безнең әдәби мирасыбызның аерылгысыз бер өлеше булып торалар. Ә әдәби мирас исә бүгенге культурабызга килеп кушыла һәм аның шактый зур компонентын тәшкил итә. Бүгенге культурабыз тагын да тулырак, баерак булсын өчен тарихның төрле чатларында югалып, онытылып торган, бик аз санда гына сакланып калган, гарәп шрифтлы булулары аркасында хәзерге заман укучыларыннан аерылган мондый әсәрләр яңадан халыкка кайтырга, үз укучыларын табарга тиеш.


Әдәби мирасыбызның башында торган мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» ның соңгы вакытта бүгенге укучыларга аңлаешлы китап булып басылып чыгуы, шуның белән яңадан үз халкына кайтуы һәм рус теле аша башка халыкларның әдәбият сөючеләренә барып җитүе шатлыклы күренеш. Шуның кебек әдәби мирасыбызны тәшкил иткән башка әсәрләрнең дә яңадан басылып чыгып халыкка хезмәт итүләрен һәм гомумкультура хәзинәсенә кушылуларын гына теләргә кала.

**Нәҗип ИСМӘГЫЙЛЕВ.**

---

[1] Халиди Ф. Болгарның солтаны гадел Туктамыш хан кызы Хәлимәнең бәхәсе. Казан, 1897.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост




# КАМА АЛАНЫ

**РӘШИТ АБДУЛЛИН**
музыкасы

**РЕНАТ ХАРИС**
шигыре

Биек ярдан Кама суы
күренеп тора.
Мин Камадан куәт алып
зур шәһәр корам.
Күрәсезме, күрәсезме
Кама Аланын? —
акчарлаклар канатыннан
аклык ала ул.

Матур калам, якты калам,
Кама Аланым,
гомерлеккә сиңа гашыйк
булып каламын!

Кама суы буйларында
зәңгәр урманнар.
Урманнарга сандугачлар
оя корганнар.


Күрәсезме, күрәсезме
Кама Аланын? —
сандугач сайравын тыңлап
тынып калган ул!

Матур калам, якты калам,
Кама Аланым,
гомерлеккә сиңа гашыйк
булып каламын!

Кама өстендә тылсымлы
бер йолдыз яна,
минем шәһәрем гаҗәеп
нур өсти аңа.

Күрәсезме, күрәсезме
Кама Аланын? —
йолдызларга да якты нур
өсти ала ул!

Матур калам, якты калам,
Кама Аланым,
гомерлеккә сиңа гашыйк
булып каламын!


һәр ко-рам, зур шә -һәр ко-рам. Кү-рә-сез-ме, кү-рә-сез-ме
Ка-ма А-ла-нын? Ак-чар-лак-лар ка-на-тын-нан ак-лык а-ла ул. Ма-
тур ка-лам, як-ты-ка-лам, Ка-ма А-ла-ным, гө-мер-лек-кә си-ңа га-шыйк бу-
1.2
лып ка-лам мин.
3.
лып ка-лам мин
ff

# УРАЛ ЕГЕТЕ

Шигырь сөючеләр әле яхшы хәтерлидер. 1983 елгы Шигырь бәйрәмендә шагыйрьләр белән беррәттән Урал ягыннан, данлы Магнитогорск шәһәреннән килгән эшче Расих Мостафинга да сүз бирелде. Ул бөек шагыйребезнең «Пар ат»ын яңгыратып, җаннарга үтәрлек итеп укып җибәрде.

Кем ул Расих Мостафин? Ничек итеп Уралдан Казанга, шигырь бәйрәменә килеп чыккан да, ничек шушы зур бәйрәмнең трибунасына күтәрелгән? Шигырьнең һәр юлын, һәр сүзен, күңеленнән үткәреп, тәмен белеп, башкаларга да җиткереп уку сәләтенә ничек ия булган?

Кыскарак кына буйлы, җиңел сөякле, тимер юлчылар формасы кигән өлкәнрәк яшьтәге бу кешенең шигырь укыганын тыңлаганда бер-бер артлы шундый сораулар туган иде. Бүтәннәр дә шулай уйлагандыр.

Расих Вазихович белән якыннан танышкач, бу сорауларга җавап таптым кебек. Танышуга ук тагын гаҗәпләнергә туры килде. Ныклап сүзгә керешеп киткәнче Расих ага сандык кадәр аккордеонын алды да, каешларын җилкәләренә салып, уйнап җибәрде. Бүлмәгә «Иске кара урман» моңы тулды. Шигъриятне дә, музыканы да бердәй ярата, аларны бер-берсеннән аерылгысыз итеп тоя икән Расих ага. Музыкага малай чагыннан ук дәрт булган.

Утызынчы еллар. Магнитка. Шау-шулы барак. Шунда ук бер оя балалы эшче Вазих гаиләсе. Малайларның берсе — тугыз яшьлек Расих. Эштән буш арада барак халкы ишегалдында. Берәүләр түтәл казый, берәүләр көнбагыш чиртә, кемнәрдер шунда ук гармунда әйттерә, бии. Ә гармунда күрше Аркаша абыйлары. Расихның күзе гел шуның гармунында. Күрше абый саран түгел икән, нәүмизләнеп карап торганын күргәч, гармунын Расихка да тоттыра. Бер тота, ике тота малай, һәм музыкасыз яши алмас була. Кулы да ябышып тора үзенең, көйне тиз аңлап ала. Клубка йөри башлый. Ишле гаиләгә никадәр генә авырга туры килмәсен, әтисе Расихның үзенә гармун алып бирә. Шуннан инде малай музыкадан аерылмый. Дөрес, сугыштан соң баянны аккордеонга алыштыра, тик бусының аерым сәбәбе бар.

Аңа кадәр әле авыр сугыш елларын үтәсе. Афәтле 1941 ел. Расихның җиденче классны тәмамлаган чагы. Сигезенчедә түгел, һөнәр училищесында укырга туры килә. Анда да кыскартылган программа буенча ике генә ай укып кала. Чөнки үсмер малайларны хуҗасыз калган станоклар көтә. Буйга үз яшьтәшләреннән дә шактый кайтыш булган Расихның әрҗә өстенә баскач та кыру станогына буе җитеп бетми, ике әрҗә куярга туры килә. Ләкин хикмәт буйдамыни, теләк, тырышлык булсын. Ә фронтка алар ясый торган миналар кирәк. Заманы шундый, норманы үтәми калу турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Үзе заводта, күңеле белән фронтта, ил язмышы хәл ителгән җирдә. Ниһаять, аның да яше җитә, армиягә алалар. 3 нче Белоруссия фронтында разведчик булып берничә ай сугышка эләгеп кала. «Кенигсбергны алган өчен» медале белән бүләкләнә.

Аннары япон милитаристларына каршы сугыш. «Батырлык өчен» медале.

Ул елгыларның хәрби хезмәте озакка сузыла. Расих Магнитогорскига 1951 елда гына әйләнеп кайта.

Шунысы да бар икән әле: армиядә ул музыка грамотасына өйрәнә, берничә музыка коралын үзләштерә. Тынлы оркестр җитәкчесе солдатның «Маньчжурия сопкаларында»ны көйләп утырганын күреп ала да, аны үз коллективларына чакыра.

Уйнаганына кызыксынып карап торам. Бармаклары белән генә түгел, күзләре, ирене, бөтен йөзе, гәүдәсе белән уйный ул. Гүя дөньяда ул бар да, аккордеоны бар, калган бөтен нәрсәне, каршындагы кешене дә оныта кебек.

— Шулай да, нигә баяннан аккордеонга күчтегез соң?

— Баян җырлый ул, ә аккордеон сөйләп бирә. Миңа менә шул сөйләве кадерле аның.

Шуның өчен дә Расих Вазихович аккордеонын үзеннән калдырмый. Тукай, Җәлил шигырьләренең көчен, моңын йөзләрчә тыңлаучыларына җиткергәндә аңа аккордеоны да ярдәмгә килә.

Сугыштан соң солдат яңадан станок янына баса.

Әдәбият, сәнгать дөньясына тартылу үзенеке итә. Расих шигърият белән дә ныклап кызыксына башлый. Шул елларда шаулап илгә кайткан Муса Җәлил шигырьләрен ул тетрәнеп кабул итә, аларга чын күңеленнән гашыйк була. Җәлил шигырьләрен башкаларга да җиткерәсе килә. Дусларына, танышларына укый. Яңаларын ятлый. Шулай итеп бөтен бер программа хасил була. Магнитогорск ягында татарлар күп, ишеткәне берсе бик яратып тыңлый. Расих аның саен дәртләнебрәк сөйли, шигырьләрнең кеше җанына юл табуына ихлас сөенә. Ул «Моабит дәфтәре»нең шактый өлешен русча да сөйләргә өйрәнә.

Шуннан бирле күпме чыгыш ясады микән ул? Аудиториясе — укучылар, эшчеләр, солдатлар. Мәктәпләргә, шефлык итә торган совхозларга чакырып алалар. Расих Вазихович карышмый, киресенчә, кешеләр белән тагын-тагын очрашырга ашкынып тора ул. Аккордеоны — кулында, шигырьләр — күңелендә. Татарча да сөйли, русча да, казахлар алдында казахча да сөйләп җибәрә. Үзешчән концерт бригадасы составында ул Тындадан алып Беркакитка кадәр БАМның әллә никадәр ноктасында булып чыга, легендар шагыйребезнең олы иҗатын гасыр төзелешендә эшләүчеләргә җиткерә. Бусы БАМда, «Мостострой-10» коллективында эшләгән чагында. (Илгизәк җанлы кеше ул: БАМын да төзешә, ерак Чукоткада Билибино атом электр станциясен төзүдә дә катнаша, Якутиядә дә эшләп кайта). Былтыр «Чиләбе комсомолы» агитпоезды составында өлкәнең берничә шәһәрендә чыгыш ясый, Оренбург өлкәсе шәһәр-авылларына да Җәлил шигырьләре белән бара. Магнитогорскида ул чыгыш ясамаган мәктәп тә калмагандыр инде. Еллык ялын да күбрәк шул чыгышлары белән үткәрә, фронтовикларга бирелә торган өстәмә ялын да шушы изге эшкә багышлый. Металлургия комбинатының культура сараендагы үзешчән татарбашкорт театрының иң актив артистларыннан берсе дә Расих Мостафин.

Ул үзенең тыңлаучыларына Җәлилнең героик язмышы, «Моабит дәфтәре»нең язылу тарихы турында да сөйләп бирә. Дәртләнеп, горурланып сөйли. Сорауларга җавап бирә. Шуның өчен Җәлил, җәлилчеләр турындагы хезмәтләрне өйрәнеп бара, белгәннәрен һаман тулыландырып тора. Үзе өчен дә кирәк дип саный ул аны, шунсыз залдагыларның сорауларына җавап бирүе дә кыен.

«Җәлилче» дип авыз тутырып әйтергә була Расих Вазихович турында. Ул Көньяк Урал тимер юлының Магнитогорск станциясе вагон депосының техник хезмәт күрсәтү пунктында эшли. Әүвәлгечә, токарь, Коммунистик хезмәт ударнигы. Хезмәттәшләренең әйтүенә караганда, станогын да аккордеоны кебек шәп белә.

**Ирек БӘДРЕТДИНОВ.**

* * *

Зөфәр Фәтхетдиновның «Ак «Жигули» эз югалта» повестен укыгач, милиция хезмәткәрләренең батырлыгына, ныклыгына сокланасың: алар бу тормышның иң гүзәл кешеләре булып, күңелдә озак саклаеалар.

Яшь тикшерүче Нәҗип Данишев бик җанлы образ итеп бирелгән, әсәрнең соңгы юлларына кадәр ул кичергәннәрне кичерәсең. Әйе, күпме каршылыклар, күпме йокысыз төннәр, күпме эзләнүләр. Ниһаять, җинаятьчеләр барыбер фаш ителә.

Нәҗип ялгыз түгел. Акыллы һәм сабыр, тәҗрибәле җитәкче капитан Минаев, өлкән лейтенант Шамов һәм башка милиция хезмәткәрләренең үз эшләренә чиксез бирелгәнлеге, катлаулы шартларда да дөрес юнәлеш алулары сөендерә.

Әйе, тормыш без дигәнчә генә түгел. Аның Мервлиев кебек кабәхәт җаннары, Моратов кебек тормышның матурлыгын аракы аша гына күрүчеләре дә бар. Күңелдә аларга карата нәфрәт хисе туа. Әсәр кешене тирән уйларга сала.

**Ислам ГЫЙМАДИЕВ.**

Буа районы, Кул-Черкен авылы.

## Юләр башым

1945 ел. Март ае. Фронт.

Безнең гаскәрләр Кенигсберг тирәсендә сугышалар. Без (фронт газетасы редакциясе), иске урыннарыбызны ташлап, алгы позициягә якынрак җиргә, Гросхауз исемле немец авылына барып урнаштык. Авылда бер немец юк. Фашистлар агитациясенә ышанып, качканнар. Бары ач мәчеләр белән ач этләр генә каңгырышып йөриләр. Алар да безне чит күрәләр... Хәер, берничә көннән шулкадәр иялəштеләр, хәтта элеккеге хуҗаларын да ул чаклы яратмаганнардыр. Ни әйтсәң дә, акыллы хайваннар!

Беркөнне мин гарнизон дежурные идем. Асып йөри торган сумкамда гранаталарымның юклыгын төн уртасында гына күрдем. Үз урыныма ярдәмче офицерны калдырып, кулыма автоматымны алдым да квартирама йөгердем.

Минем белән бер бүлмәдә кече лейтенант Фазыл Басыйров тора — газетабызның корректоры, хикәяләр, шигырьләр язгалаган егет. Бөтен дөньясын онытып, гырлап йоклап ята. Ишекне дә бикләмәгән. Кул фонаре белән бүлмәне яктыртам. Һи күрим!.. Егетем, өстен-башын чишенмичә, караватка менеп ауган. Бары итеген генә салган. Баш астында алты-җиде кирпеч, ә аяклары мамык мендәрләр өстендә.

«Ах, юньсез нәрсә, эчкән ахры!» — дип уйлап, шактый тупас уяттым. Фазыл шундук, сикереп торып, аягүрә басты, гимнастеркасын, бил каешын рәтләде, якасын төймәләде, пистолетын да җайлады. Аек. Эчмәгән. Хәер, мондый хәрабәдә каян аракы тапсын!

— Нишләвең бу синең! — дидем мин, бик ачуланып. — Адәм көлкесе! Баш астында кирпеч, ә пычрак аякларың мамык мендәрләр өстендә.

Егет утны-суны кичкән батыр солдатларча шартлатып җавап кайтарды:

— Виноват, иптәш капитан! Юләр башым аркасында аякларым бик күп газап чикте. Бераз ял итсеннәр дигән идем. Йоклап киткәнмен... Ни боерасыз, иптәш капитан!

Башын мендәргә куеп ятарга куштым да, гранаталарымны алып, штабка йөгердем.

## Әдәби кичә алдыннан

Матбугат йортында әдәби кичәләр әледән-әле булгалап тора.

Шундый кичәләрнең берсе башланыр алдыннан бишенче катка менеп барганда, Кави Нәҗмине ниндидер бер егет куып җитә дә аның белән тәкәллефсез генә исәнләшә:

— Әй, исәнмесез, Таҗи абый! Күптән күргәнем юк үзегезне! Хәлләр ничек? Эшләр барамы? — ди һәм шундук аны янындагы кызга да тәкъдим итә: — Таныш бул, Таҗи Гыйззәт!

Кыз оялып кына башын ия, ә Кави Нәҗми, ни әйтергә белмичә, бик гаҗәпләнеп, баруыннан туктый. Егет исә, үзенең һәр язучы белән таныш та, әшнә дә икәнен кызга ачыктан-ачык сиздерергә тырышып, сөйләвендә дәвам итә:

— Кичә генә романыгызны укып чыктым әле. Бик ошады. Шәп язгансыз. Молодец!

— Нинди романны? — ди Кави, аның әдәбият белән ни дәрәҗәдә танышлыгын белергә теләп.

— Нинди булсын, «Намус»ны, билгеле.
Кави шаркылдап көлеп җибәрүдән үзен чак тыеп тора:
— Туктагыз әле, чибәр егет, мин бит Таҗи Гыйззәт түгел. Сез мине танымыйсыз, ахры.
Егет аңа бераз гаҗәпләнеп карап тора да:
— Әй-й, гафу итегез, зинһар, мин сезне һәрвакыт Таҗи Гыйззәт белән саташтырам!— дип кычкырып җибәрә.— Сез бит Ибраһим Гази! Сезне дә танымагач тагы! «Миңлекамал» романы авторы!
Кави инде бер сүз дә әйтә алмый. Уңайсызланыпмы, әллә инде егет өчен оялыпмы, нидәндер, үзе дә төшенеп бетермичә, якындагы редакцияләрнең берсенә кереп китәргә мәҗбүр була. Ә егет белән кыз, өчәр басманы берьюлы сикерәсикерә атлап, югарыга, бишенче катка йөгереп менеп китәләр. Анда — әдәбият кичәсе.

**А. ТӘУГИЛДЕ** әзерләде.

## Уйга бирелеп

Габдулла Шамуков шөһрәтле артист кына түгел, ул — укытучыостаз да, язучы да. Ул тарих белән дә, шахмат уены белән дә нык мавыгучан, юмарт талантлы шәхес иде. Ул һәрвакыт ни турында булса да тирән уйлана, хәтта кайчакта, уйга бирелеп, әйләнә-тирәгә игътибарын югалта торган иде.
Бер тапкыр ул троллейбус тукталышында басып тора икән. Троллейбус килеп туктый, ишекләр ачыла, Габдулла абый, каталары өстеннән кигән калошларын салып, аягын сөрткәләп, троллейбуска уза. Ишекләр ябыла, троллейбус китеп бара, калошлар тротуарда кала.
Габдулла абый өенә кайтып җиттем, дип уйлаган икән.
Ә икенче бервакыт Габдулла Шамуков театр буфетындагы култыкса янында чират торганда, алдагы кешедән:
— Гражданин, сез киләсе тукталышта чыгасызмы? — дип сораган имеш.

## Әйтергә сүз калмагач

Бервакытны Салих Сәйдәшевкә, артистлар җитмәү сәбәпледер инде, роль бирәләр. Салих абый, рольне ятлап, спектакльгә килә. Сәхнәгә кереп, сүзләрен әйтеп чыга да, кайтып китәргә җыена. Театр баскычыннан төшеп барганда, аңа режиссер Кәрим Тинчурин очрый.
— Кая барасың? — дип сорый режиссер.
— Өйгә! — ди композитор.
— Синең сәхнәгә чыгып сүз әйтәсең бар бит! — ди Тинчурин.
— Мин сәхнәгә чыктым инде, сүземне әйттем,— ди Сәйдәш.
— Тагын өч тапкыр чыгасың бар бит әле,— дигәч, Сәйдәш:
— Әйтергә сүзем калмады инде, бер чыккач бөтен ятлаган сүземне әйтеп бетердем! — дигән.

**Р. БАТУЛЛА** әзерләде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

29 майда узган ачык партия җыелышында эчкечелек һәм алкоголизмга каршы көрәш буенча партия һәм хөкүмәт карарларын тормышка ашыруда әдәбият һәм язучылар алдында торган кичектерелгесез бурычлар турында зур сөйләшү булды.

Җыелышта Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев доклад белән чыкты. Фикер алышуларда Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, язучылар Н. Дәүли, Г. Паушкин, Р. Ишморатова, Б. Гыйззәт, М. Елизарова, Г. Иделле, Р. Мостафин, Д. Вәлиев, композитор С. Садыйкова һ. б. чыгыш ясап, көндәлек тормышта кешеләрнең мораль-әхлак сыйфатларын нygытуга юнәлтелгән идеологик эшне активлаштыру, әдәби әсәрләрнең алкоголизм кебек чиргә һөҗүмчәнлеген арттыру, бу темага язылган әсәрләрнең сыйфаты мәсьәләләре турында сөйләделәр һәм эшлекле тәкъдимнәрен әйттеләр.

## ТЕАТР РАБОТНИКЛАРЫ АКТИВЫ ҖЫЕЛЫШЫ

16 майда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында республика театр работниклары активы җыелышы булды. Анда КПСС Үзәк Комитетының март һәм апрель (1985 ел) Пленумнары карарларын, КПСС Үзәк Комитетының «Янка Купала исемендәге Белорус дәүләт академия театры партия оешмасының эше турында»гы карарын тормышка ашыруның барышы турында Татарстан партия өлкә комитеты бюросы карарын үтәү буенча театр коллективлары алдында торган бурычлар тикшерелде. Әлеге мәсьәлә буенча доклад белән ТАССР культура министры М. М. Таншев чыкты. Фикер алышуларда В. И. Качалов исемендәге Зур драма театрының партия оешмасы секретаре Ю. С. Федотов, Бөгелмә рус драма театрының баш режиссеры К. И. Петров, халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитетының культура бүлеге мөдире И. С. Донская, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының баш дирижеры В. М. Васильев, ТАССР Язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. С. Мөхәммәдиев, сәнгать фәннәре кандидатлары И. И. Иллялова, Х. Л. Кумысников һәм башкалар катнашты.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова чыгыш ясады.

## ӘДӘБИ АЛМАШКА ИГЪТИБАР

4 июньдә Татарстан Язучылар союзының яшь авторлар белән эшләү комиссиясендә «Татарстан яшьләре» газетасы каршындагы «Яңавазъ» исемле яшь тәнкыйтьчеләр студиясенең эшчәнлеге тикшерелде.

Утырышта студиянең җитәкчесе, тәнкыйтьче С. Маннаповның информациясе тыңланды. ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары И. Юзеев, яшь авторлар белән эшләү комиссиясе председателе, шагыйрь Ш. Галиев, ВЛКСМ өлкә комитеты каршындагы А. Алиш исемендәге әдәби берләшмә җитәкчесе, шагыйрь Р. Мингалимов һ. б. иптәшләр чыгыш ясап, «Яңавазъ» студиясенең яшьләрне коммунистик рухта тәрбияләү өлкәсендә уңышлы эшләвен билгеләп үттеләр.

Бу утырышта шулай ук «Комсомолец Татарии» газетасы каршындагы «Әдәби остаханә» (җитәкчесе — драматург Д. Вәлиев) эшчәнлеге турында да җанлы сөйләшү булды.

Комиссия «Әдәби остаханә» һәм «Яңавазъ» студиясенең эшен яхшы дип тапты һәм бу юнәлештә алга конкрет бурычлар билгеләде.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

12 майда Әлмәт язучылар оешмасының чираттагы җыелышында Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм ул елларда фидакарь хезмәт күрсәткән язучылар Рафаил Төхфәтуллин, Сәет Кальметов, Энҗе Мөэминова, Әдип Маликовларга Бөек Җиңүнең 40 еллыгы уңае белән тантаналы шартларда юбилей медальләре һәм бүләкләр тапшырылды. Бүләкләрне КПССның Әлмәт шәһәр комитетының беренче секретаре Р. Галиев тапшырды.

Шул ук җыелышта прозаик Әсрар Галиевнең иҗатын тикшерү булды. Язучылар Ш. Бикчурин, Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин, Р. Вәлиев, Ә. Гаффар, К. Булатова, Э. Мөэминова, А. Хәсәнов, Н. Әхмәдиев язучының иҗатына һәрьяклап бәя бирделәр һәм аны СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим иттеләр.

Язучы Ә. Гаффарның күренекле революционер, В. И. Ленинның көрәштәше Мулланур Вахитов турындагы драмасы Эстония ССР радиосы аша яңгырады. Пьесаны эстон теленә Т. Ринне тәрҗемә иткән. Тапшыру комиссар М. Вахитовның 100 еллыгына багышлап эшләнгән.

## АБАЙ БӘЙРӘМЕНДӘ

4—6 июльдә Казахстанда бөек казах шагыйре Абай Кунанбаевның тууына 140 ел тулуга багышланган тантаналар уздырылды. Казахстан Язучылар союзы чакыруы буенча анда татар әдипләре — шагыйрьләр И. Юзеев, М. Хәсәен, Р. Гатауллин һәм филология фәннәре докторы Ә. Кәримуллин да катнашты. Семипалатинск шәһәрендә уздырылган тантаналы кичәдә шагыйрь И. Юзеев Татарстан Язучылар союзы исеменнән истәлекле бүләк-

ләр тапшырды. Абай һәм Тукай исеменә бәйләгән әдәбиятлар дуслыгы турында шигырен сөйләде; М. Хөсәен һәм Р. Гатауллин да үзләренең бу темага шигырьләрен укыдылар. Абай районы үзәге Караулда уздырылган тантаналы кичәдә И. Юзеев һәм М. Хөсәен чыгыш ясады. Ә. Кәримуллин телевидение аша сөйләде. Кунаклар Семипалатинскида һәм Абайның туган җирендә аның йорт-музеенда булдылар, анда Тукай һәм Абайның Казанда басылган китапларын бүләк иттеләр.

Татар язучыларын Казахстан компартиясенең Семипалатинск өлкә комитетының беренче секретаре С. К. Кубашев кабул итте, халыклар һәм әдәбиятлар дуслыгы турында әңгәмә булды.

## ДУСЛАР ЯНЫНДА

Июнь башында Таҗикстанда совет әдәбияты көннәре булып үтте. Күпмилләтле совет язучылары делегациясе составында Татарстаннан шагыйрь Р. Фәйзуллин да бар иде. Ул Дүшәнбе, Турсунзадә, Нурек шәһәрләрендә булды һәм чыгышлар ясады.

## АЛИШ МУЗЕЕ

Брежнев шәһәренең 4 нче урта мәктәбендә Абдулла Алиш музее ачылды.

Мәктәпнең яшь эзтабарлары дүрт ел буена ялкынлы патриот-шагыйрь турында материаллар җыйдылар, аның дуслары белән хат алыштылар, замандашларын, көрәштәшләрен, туганнарын һәм якыннарын күреп сөйләштеләр. Эзләнү эшенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы А. Закирова җитәкчелек итте.

Музей бүлмәсенең беренче кунаклары Бөек Ватан сугышы ветераннары булды. Алар укучылар монда гражданлык һәм патриотизм дәресләре алырлар, дигән ышаныч белдерделәр.

## ҖЫР ТЫНЫЧЛЫК ӨЧЕН КӨРӘШӘ

3 июньдә Казан шәһәренең Яшьләр үзәгендә «Җыр тынычлык өчен көрәшә» дип исемләнгән кичә булды. Аның программасы Бөек Җиңүнең 40 еллыгы уңае белән иң яхшы патриотик җырлар иҗат итеп республика конкурсында җиңеп чыккан үзешчән композиторлар һәм шагыйрьләр әсәрләреннән төзелгән иде.

Кичәдә жюри председателе — М. Глинка исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты композитор Ф. Әхмәтов һәм ТАССР культура министры урынбасары М. Т. Низамиев, конкурс йомгакларына бәйләп, үзешчән сәнгатьне тагын да үстерү буенча үз фикерләре белән уртаклаштылар, һәвәскәрләргә яңа иҗат уңышлары теләделәр. Аннары республика конкурсында җиңеп чыгучыларга дипломнар һәм медальләр тапшырылды.

## ШАГЫЙРЬЛӘР ҺӘМ РӘССАМНАР КИЧӘСЕ

4 июньдә Татарстан сынлы сәнгать музеенда «Рәссамнар һәм шагыйрьләр» дигән темага сөйләшү үткәрелде. Сынлы сәнгать белән шигърият арасындагы бәйләнешләр мәсьәләсенә багышлап оештырылган әлеге кичәдә РСФСРның атказанган художнигы В. Куделькин, график Н. Әлмиев, сәнгать белгечләре Р. Шаһиева, Л. Николаева, шагыйрьләр Н. Беляев, Р. Гатауллин, Р. Әхмәтҗанов, З. Мансуров һ. б. лар чыгыш ясады.

## АЛМА-АТАДА ЛАТЫЙФ ХӘМИДИ УРАМЫ

Алма-Ата шәһәр Советы башкарма комитеты күптән түгел элекке бер урамга Казахстанның халык артисты, Казахстан ССР Дәүләт премиясе лауреаты Латыйф Хәмиди исемен бирде.

Татар халкының талантлы улы, күренекле совет композиторы Латыйф Хәмиди казах музыкасын үстерүгә дә күп көч куйган кеше. Ул кардәш халыкның беренче вальсын, сюитасын, милли операсын, Казахстан ССР Дәүләт гимнын, казах культурасының алтын хәзинәсенә кергән башка йөзләрчә әсәрләрен иҗат итте.

## ФӘРИТ ЯРУЛЛИН ЭЗЛӘРЕННӘН

Композитор Ф. Яруллин кырык елдан артык Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалучылар исемлегендә йөрде. Ниһаять, Бөек Җиңүнең 40 еллыгы якынлашкан көннәрдә аның кайда, кайчан үлүе турында төгәл мәгълүматлар билгеле булды. Ф. Яруллин Витебск өлкәсендәге Дубровно районының Яңа Тухиня авылын азат иткән вакытта 1943 елның 17 октябрендә һәлак була һәм шунда күмелә. Хәзерге вакытта аның туфрак-җәсәде, меңнәрчә сугышчыларныкы белән бергә шул төбәктәге Рыленки мемориаль комплексында саклана.

1 июльдә Татарстан Композиторлар союзы идарәсе председателе М. Яруллин, Казан дәүләт консерваториясе проректоры Ч. Бәхтиярова, композитор Р. Билалов, скрипкачы М. Әхмәтов, пианистка Ф. Хәсәнова, язучы Р. Низамиев катнашындагы делегация композиторның исәлегеен хөрмәтләү өчен Рыленки мемориаль комплексына килделәр. Композиторның каберенә бер уч Татарстан туфрагы һәм чәчәк салдылар. М. Әхмәтов башкаруында «Шүрәле» балетыннан фрагментлар яңгырады.

Аннары Дубровно шәһәренең музыка мәктәбендә район хезмәт ияләре белән очрашу үткәрелде. Очрашуны кереш сүз белән Р. Билалов ачып җибәрде. Ч. Бәхтиярова Фәрит Яруллинның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштырды. Ф. Яруллинның полкташы М. Тихненко, композиторның бертуган энесе М. Яруллин һәм Киевта яшәүче кызы Н. Яруллинаның чыгышлары һәркемдә зур кызыксыну уятты.

## БАТЫРЛАРГА ҺӘЙКӘЛ

Быел яз Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы уртасында батырларга һәйкәл салынды. Бу авылның 61 кешесе Бөек Ватан сугышы фронтларында илебез азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшеп һәлак булган. Һәйкәл — шул батырлар хөрмәтенә. Ул Олы Мәрәтхуҗада туып-үскән танылган драматург Т. Миңнуллин инициативасы һәм катнашы белән салынды.

## ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, драматург Аяз Гыйләҗевка РСФСР Верховный Советы Президиумының 27 май, 1985 ел Указы нигезендә, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# КАМАЗ ЧИБӘРЛӘРЕ

Нык үскән социализм дәвере үз героен — югары әхлакый һәм рухи кыйммәтләргә ия булган һәм актив тормыш позициясендә торган иҗатчы — кешене яңа биеклеккә күтәрде. Менә шундый гомумиләштерелгән катлаулы образны сәнгатьчә гәүдәләндерү, совет кешесе шәхесендәге яңа чалымнарны бөтен тулылыгы белән ачып күрсәтү рәссамнардан зур осталык һәм җаваплылык таләп итә. Бүгенге замандашыбыз портретын новаторларча иҗат итүчеләр рәтенә без СССРның халык художнигы, СССР Художество академиясе член-корреспонденты Харис Якуповны да хаклы рәвештә кертәбез.

Кешенең әхлакый һәм рухи асылы тулаем хезмәттә чагыла. Сынлы сәнгать остасы әлеге темага әнә шундый критерийдан якын килә, һәм ул үзенең геройларын тормышның «кайнап торган үзәге»ннән эзләп таба. Татарстан Художниклар союзының «Авыл», «Нефть», «КамАЗ» иҗат группаларын оештыруда башлап йөрүче дә Харис Абдрахмановичның хезмәт кешесен олылавы, халык мәнфәгатьләре белән яшәргә омтылуы турында сөйлидер. Авторның «Көчле кешеләр», «Татарстан алтыны», «КамАЗ чибәрләре» исемле картиналары турыдан-туры хезмәт коллективларында алган тәэсирләр буенча иҗат ителгән. Әлеге әсәрләр республикабыз тормышындагы әһәмиятле вакыйгаларның үзенчәлекле чагылышы буларак кабул ителә. Гомумән, Х. Якупов Кама автомобиль гиганты төзелеше темасына беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итүче рәссамнардан санала. «КамАЗ чибәрләре» полотносындагы төзелеш панорамасының бер почмагында ул үзен — этюд төшерүче рәссам фигурасын тикмәгә генә күрсәтмәгәндер.

Төзелеш елъязмасына үзенчәлекле сәхифә булып кергән әлеге картинада бүгенге заман герое — яңа типтагы эшче новаторларча калку итеп бирелгән. Югарыдагы тимер конструкцияләр өстендә торучы кызлар артында бөек төзелешнең офыкны колачлаган манзарасы ачыла. Монтажчы кызлар, әйтерсең, хыял югарылыгына күтәрелгәннәр. Йөзләрендә хезмәттә генә ачыла торган матурлык чаткылары балкый. Рәссам аларны «әре планда» күрсәтә, шулай итеп, һәрберсенең үзгә сөйкемлелеген һәм шул ук вакытта һәммәсенә хас уртак сыйфатларны ачып бирүгә, социалистик җәмгыятьтә хезмәтнең батырлык һәм матурлык чыганагы булуын тагын бер мәртәбә ачык итеп раслауга ирешә.

**Вера ЦОИ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның
бүлек мөдире.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле әдип һәм галим Нәкый Исәнбәт.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

**Ялкын журналы**

Улыгызда, кызыгызда, энекәшегездә, сеңелкәшегездә Ленинча яшәргә, Ленинча көрәшергә, Ватаныбызның данлы традицияләренә турылыклы булырга омтылуны, хезмәткә ашкынып торуны күрергә теләр идегезме? Кечкенә дусларыгызның сәнгатебез, культурабыз җимешләрен, телебезнең байлыгын күреп-тоеп, рухи яктан баеп үсүенә ирешәсегез киләме?

**Яшь ленинчы**

Теләгегезгә ирешергә балаларыгызның, энеләрегезнең, сеңелләрегезнең якын дуслары — «Яшь ленинчы» газетасы һәм «Ялкын» журналы ярдәм итәр.

«Яшь ленинчы» газетасының Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 54124. Бәясе — елга 1 сум 08 тиен.

«Ялкын» журналының Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 73582. Бер елга язылу бәясе — 2 сум 40 тиен.


Илебездәге газета-журналларга киләсе ел өчен язылу дәвам итә. Укучыларыбыздан килгән сорауларны искә алып, Казанда татар телендә чыга торган журналларның Бөтенсоюз каталогындагы индексын һәм язылу хакын хәбәр итәбез.

«ТАТАРСТАН КОММУНИСТЫ»: индексы — 73377, бер елга язылу хакы — 3 сум.
«АЗАТ ХАТЫН»: индексы — 73002, бер елга язылу хакы — 3 сум.
«ЧАЯН»: индексы — 73488, бер елга язылу хакы — 6 сум.
«КАЗАН УТЛАРЫ»: индексы — 73210, бер елга язылу хакы — 10 сум 80 тиен.

Бу журналларга Советлар Союзының барлык элемтә бүлекчәләрендә чикләүсез язылырга мөмкин.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)